# казан утлары

9.1996



## «КАЗАН УТЛАРЫ» 1997 ЕЛДА

«Казан утлары» журналы алдагы елда да әдәбият сөючеләрне кызыклы яңа әсәрләр белән таныштыруны дәвам итә. Редакциябез портфелендә күренекле әдипләрнең күләмле проза әсәрләре дә байтак. Без аларны укыйбыз, өйрәнәбез һәм, әлбәттә, иң яхшы дигәннәрен сезгә тәкъдим итәчәкбез. Менә аларның кайберләре:

Атилла Расих. «Тыныч еллар күләгәсендә». *Истәлек-трилогия*. Аның беренче икесе — «Ишан оныгы» белән «Кәгазьдәгеләр һәм хәтердәгеләр» — безнең журналда дөнья күргән иде. Монысы — әдипнең автобиографик әсәреннән соңгы китап. Аяныч, автор аны тәмамлап бетермәстән вафат булды.

Гариф Ахунов. «Тимерханның атылган наркомнарны эзләве». *Документаль повесть*. Журналыбызда кызыклы шәхес Тимерхан Борһанов хакында язучының ике повесте дөнья күргән иде инде. Әсәрнең өченче кисәге Татарстан наркомнарының фаҗигале язмышы, шәхес культы еллары турында сөйли.

Кыям Миңлебаев. «Бакый». *Роман*. Бөек рәссамыбыз Бакый ага Урманченың тормыш һәм иҗат юлы турында әсәр. Автор сынлы сәнгатебезгә нигез салган олуг остаңы художник (нәгъшьче) итеп кенә түгел, кешелекле шәхес, фикер иясе, тапкыр сүзле фәлсәфәче, каксамас рухлы көрәшче, бай рухи дөньяга ия галиҗанәб зат буларак та тасвирлый.

Зәки Зәйнуллин. «Атом полигоны». *Повесть*. 60 нчы елларда Казагыстанның Семипалат полигонында атом-төш коралын сынауларда катнашкан хәрби кеше язмалары. Экологик зыян хикмәтләре.

Тәүфикъ Әйди. «Иблискә ришвәт». *Роман*. Хәрби әсирләребез Һитлер биләмәсендә, Алманиядә Татар комитеты, Геббельс карамагындагы татарча радиотапшырулар, Идел-Урал легионы Польшада һәм Франциядә, концлагерь, Берлин рестораннары һәм татарлары, арий сылулары — әсәр әнә шундый күп кенә вакыйгаларны колачлый.

Суфиян Поварисов. «Гомер җәе». Күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов турындагы романның икенче кисәге.

Шулай ук Гомәр ага Бәширов, Тәлгат Галиуллин, Аяз Гыйләҗев, Ринат Мөхәммәдиев, Рашат Низамиев, Гурий Тавлин, Фоат Садриев, Вахит Имамов яңа кульъязмаларын китерергә вәгъдә итәләр.

Танылган шагыйрьләребезнең яңа язмаларын укый аласыз:

Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Роберт Миңнуллин, Рәдиф Гаташ, Харрас Әюп, Флера Гыйззәтуллина, Лена Шагыйрьҗан, Илдус Гыйләҗев һ. б.

Фәнни, тарихи, публицистик мәкаләләрдән:

Адлер Тимергалин. Урысның «Слово о полку Игореве» нинди әсәр ул? Уйлану һәм фаразлар...

Солтан Шәмси. «Куликово кыры сабаклары». Автор, тарихи чыганакларны объектив өйрәнеп, Куликово сугышына карата үзенең яңача карашын тәкъдим итә.

Булат Солтанбәков. Үз вакытында хаксыз онытылган, репрессияләнгән татар зыялылары турында фәнни-тарихи очерклар.

Кыскасы, хөрмәтле укучыларыбыз, сезне алда кызыклы язмалар, яңа очрашулар көтә.

Индексыбыз — 73210.

Язылу бәясе ярты елга — 15 мең, бер елга 30 мең сум.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**9**

**(887)**

**1996**

КАЗАН


## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Р. ХАРИС. Гармунчы. *Поэма* ..... 3

Ф. ЯХИН. Ахырзаман пәйгамбәре. *Кыйсса. Икенче китап* ..... 7

Җ. СӨЛӘЙМАН. Өмет. *Шигырьләр* ..... 70

Ф. ЧАНЫШЕВА. Тыңлагыз, Казан сөйли... *Шигырьләр* ..... 75

МАТУРЛЫК ИЛЕНӘ ЮЛ. *Шигырьләр* ..... 150


МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ 50 ЯШЬ


Р. НИЗАМИЕВ. Тауга күтәрелү ..... 79

М. ГАЛИЕВ. Догалы еллар. *Эссе* ..... 80


«СӨЕМБИКӘ» ЖУРНАЛЫНА 70 ЕЛ


Хатын-кызның серле дөньясы. *(«Сөембикә» журналының баш мөхәррире Р. ТУФИТУЛЛОВА белән әңгәмә)* ..... 162


ХӘТЕР


Н. САФИНА. Ә сүз бирмиләр ..... 166


МӘХМҮТ ГАЛӘҮНЕҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ


Р. ДАУТОВ. Әдипнең фаҗигасе ..... 170


КИТАП КҮЗӘТҮ


Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Язмышлар язылганда ..... 177


ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ


Т. ГАЛИУЛЛИННЫҢ «Тәүбә» романына карата укучылар фикере ..... 182

Безнең календарь ..... 176, 181

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 189

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Безнең адрес: 420066,
Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа Ф. ЯХИНА «Последний пророк»; поэма Р. ХАРИСА, стихи Ж. СУЛЕЙМАНА, Ф. ЧАНЫШЕВОЙ и подборка стихов наших читателей.
«К 70-летию журнала «Сююмбикә»: интервью с главным редактором журнала Р. ТУФИТУЛЛОВОЙ.
«К 50-летию М. ГАЛИЕВА»: отрывки из книги М. ГАЛИЕВА «Книга века».
«Память»: статья Н. САФИНОЙ о ИБРАГИМЕ НУРУЛЛИНЕ.
Статья Р. ДАУТОВА «Трагедия писателя» — к 110-летию М. Галяу.
«Книжное обозрение»: рецензия Ф. ГАЛИМУЛЛИНА на книгу А. КАРИМУЛЛИНА «Судьба, судьба», письма читателей по роману Т. ГАЛИУЛЛИНА «Покаяние».
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: фоторепродукция художника Р. Имашева «Лето»; поэтесса С. Гараева.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the sequel of Ph. Yakhin's novel «The Last Prophet» P. Kharis's poem, the verses of I. Suleiman, ph. Chanisheva, selection of verses of our readers.
«Commemorating the 70th Anniversary of «Syuumbika» magazin»: the interview with the aditor-in-chief of magazin R. Tuphitulova.
«Commemorating the 50th Anniversary of M. Galiev»: fragments from M. Galiev's book «The Book of the Century».
«Memory»: N. Saphina's article relating about Ibragim Nurullin, R. Dautov's article «The Tragedy of the Writer» devoted to the 110th anniversary of M. Galyau.
«Book Review»: Ph. Galimullin reviews A. Karimullin's book «Fortune, Fortune»; reader's letters dealt with T. Galiullin's novel 'Confession.
«Our Calendar»
The diary of the social and cultural life.
In our covers: the reproduction from R. Imashev's picture «Summer», poetess S. Graraeva.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 26.07.96 ел. Басарга кул куелды 5.09.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 $^1/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 527. Заказ Е-388.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Ренат Харис

### Гармунчы

*Профессор Фуат Гарифуллинга — олы гармунчыга*

1.

Авылда мин иң атаклы
гармунчы малай идем.
Мәктәптә дә, клубта да
борынны шактый чөйдем...
Бармаклары саен аның
мәхәббәт, диләр иде...
Язмышыма көмеш түгел,
алтыннан өлеш тиде.
Гармуным да гармун иде —
ул балкып тора иде,
итәгемдә патша кебек
горур утыра иде.
Дәртле чагымда тотынсам,
әллә нишләтә идем —
кошлар итеп сайратам да,
аттай кешнәтә идем.
Бик күп кызлар — гашыйк булып,
егетләр — көнләп көйде..
Көннәрдән бер көн авылга
яшь бер медичка килде.
Әллә халаты төсеннән —
яктырып китте авыл...
Беренче карлар яудылар...
Башланды шунда давыл.
Һавада, урамда түгел,
минем монда — йөрәктә...
Моңа чаклы булган хисләр

тузгыдылар беррәттән.
Татлы давыл, ачы давыл —
әллә ялкын, әллә боз...
Ис булып исертте мине
Һәм тилертте теге кыз.
Уйларымны утка сала,
бозлы җилдә җилгәрә...
Чарасыздан гармун тотам —
җаным җырлап җибәрә.

2.

Аулак өйләргә йөрми бу,
чыкмый бит клубка да —
ялгыз карчыкта фатирда
белмим ни эшләп ята.
Җай эзлимен очрашырга,
җай эзлим сүз дәшергә.
Очрашкачтын телем тешлим,
күрешкәч күз яшерәм.
Салкын тисен әле, диеп,
бозлы сөт тә эчтем мин.
Йөткерүләр кая инде,
ичмасам ник төчкерим.
Юри бармагымны кистем...
Һәм кердем бәйләтергә —
ни булды? дип каршы алды,
утыртты мине түргә.
Бармак киселде, мин әйтәм,
иң кирәкле бармагым...
— Бармакның кирәксезе дә
була мыни соң аның?
Бу,— димен,— бака бармагы...
(Сүз буталды ачудан)
бака бармагы бик кирәк,
мин әйтәм, гармунчыга...
— Сез гармунчы мыни? — ди бу.
Мин әйтәм, әйдә киттек,
кошлар итеп сайратамын,
кешнәтәм атлар итеп...
— Юк, юк, хәзер түгел,— ди бу,—
сез барыгыз, кайтыгыз,
клубка чыгып тыңлармын,
төзәлгәч бармагыгыз.
Кайтып киттем. Маңгаема
кышын җәйге җил бәрде.
Тизрәк гармунга тотындым —
җаным җырлап җибәрде.

3.

Менә житте көтелгән кич.
Кыз да клубка килде.
Мин ул кичтә Кирам Сати,
Фуат Гарифи идем.
Көйләрдән тезмәләр тездем,

тездем дә кабат өздем...
Гармунымны канат итеп,
бөтен авылны гиздем.
Гармунчы башка егетләр
уйнамады ул кичтә —
мин гармунлы бер сихерче
идем!.. Арттырмыйм һич тә.
Җырлаттым да, биеттем дә,
уйнаттым төрле уен —
теге кызны шаккатыру
иде исәбем-уем.
Ул да кушылып җырлады
һәм биеде кушылып...
Кулымда гармун сайрады
әкияти кош булып...
Кыз кинәт уртага чыкты.
Тынып калды барысы.
— Әйдәгез, үткәрик,— диде,—
гармунчылар ярышы!
Кул чаптылар барлык кызлар,
малай-шалай кул чапты...
Ә бөтен гармунчы егет
чыгып китте шул чакны.
Тезсмә гармун утыртып,
бер үзем калдым эчтә —
мин гармунчылар бөркете
идем шул теге кичтә!
Дулкынланудан күңелдә
барлык кыллар тибрәнде...
Гармунны киереп тарттым —
җаным җырлап җибәрде!..

4.

Нинди көйләр уйнаганмын —
хәтерләмим, тик беләм:
мин ярыштым ул вакытта
бары үз-үзем белән.

Кыз кабат уртага чыкты:
— Әй, егетләр, кайсыгыз
ала да тальян гармунын
уйнап җибәрә сызып?!.
Ярышка беркем чыкмады...
Кыз да аптырап калды...
Аннары яныма килде...
Гармунны сорап алды...
Сынап карап торды аңа.
Каешын куйды киеп.
Күзен йомды... Бармаклары
киттеләр шунда биеп...
Көйләрдән тезмәләр тезде,
тезде дә янә өзде,
язларны искә төшерде,
кайтарды җәйне, көзне...
Чәчрәде моң чыклар булып,
каз канатына кунды,

сиреньнәрдән өзелеп төшеп,
юл тузанында тынды...
Гармуннан булганын сыкты
ахыр чигенә җитеп —
былбыллар итеп сайратты,
кешнәтте байтал итеп.
Ишеттерде күбәләкнең
ул канат кагышларын...
Мин белмәдем гармунымда
андый тавышлар барын.
Гармун тынды... Кыз елмайды...
Тәкәбберлек! Чибәрлек!...
Гармунны кайтарып бирде...
Һәм мин елап җибәрдем...

5.

Очрашулар эзләмәдем
мин аның белән кабат —
күңелләрем талпынса да,
чатнады бугай канат.
Мәктәпне тәмамлагач та
артистлыкка укырмын
дигән идем... Шунда белдем:
никадәрле сукыр мин.
Остарак уйнаучылар да
башка эштә утыра...
Теге кыз да китеп барды
врачлыкка укырга.
Мин дә киттем... Мин дә алдым
җаныма якын белем.
Ләкин мәңгегә гармунга
берегеп калды күңел.
Кулларыма алган саен
менә шушы гармунны,
бөреләнгән мәхәббәтнең
искә төшә бар моңы.
Теге кызның бармагына
кагылган кебек булам —
татымый калган җылылык
кан тамырыма тула.
Елаганым искә төшә
бөтен клуб алдында,
ләкин кара булып түгел,
ә манчылып алтынга.
Ак халатлы теге кызны
күңелем кайчак эзли...
Ләкин язмыш ни өчендер
һич кавыштырмый безне.
Шундый чакта күкрәгемә
уфтану җиле бәрә...
Кулларыма гармун алам...
Гармун елап җибәрә...

*1996*



## Фәрит Яхин

# АХЫРЗАМАН ПӘЙГАМБӘРЕ

КЫЙССА. ИКЕНЧЕ КИТАП

Мөхәммәд саллалаһу галәйһи вә сәлләм ястү намазын укыганнан соң, кяферләргә һәм мөшрикләргә бәддога кылды, арадан Әбу-Җәһилнең һәм тагын да берничәсенең исемнәрен атады. Гыйбадәттән күтәрелеп чыкканда күрде: мөселманнарга Ясрип тарафында йөргән гарәпләрнең кабиләсеннән ике атлы килеп кушылды. Мөхәммәд пәйгамбәр алардан:

— Сез монда нигә килдегез? — дип сорады.

— Ганимәт малына күңел салып, сезнең яктан торып, дошманнарыгызны җиңгәнчегә кадәр сугышырга дип килдек, — диделәр. — Син безнең кан карендәшебез тиешле кеше, әниең ягыннан, — дип белдерделәр. — Шунлыктан дошманнарыңа каршы көрәшербез!

Аларны тыңлап бетергәч, пәйгамбәр:

— Без — мөселманнар, монафикъ кавемгә каршы барабыз. Ә сез Ислам динендә түгел. Арабызга имансызларны кертә алмыйбыз. Әгәр, чыннан да, безнең дошманнарыбызга каршы бергә-бергә сугышырга уйлыйсыз икән, ул вакытта Аллаһы тәгаләнең бердәнбер булуын таныгыз, аннан бүтән, аннан гайре илаһи зат юк дип әйтегез, — диде. — Ул вакытта безгә кушылырга рөхсәт ителер!

Шунда болар Аллаһы тәгаләнең бердәнбер Кодрәтле һәм Бөек илаһи зат икәнлеген танып, Мөхәммәдне аның пәйгамбәре дип, иман китерделәр һәм мөселман гаскәрләре белән бергә хәрәкәттә булдылар.

Шушы рәвешле килеп, Мөхәммәд пәйгамбәр кавеменә кушыла башлаган кешеләр мөселманнарны сугышка һәм җиңүгә дәртләндерде.

Кайнар комлыклар һәм эссе чүл буйлап хәрәкәт иткән мөселманнарга теләктәшлек тотучылар аз түгел иде. Күпләр соңгы вакытларда корәишләрнең башбаштаклыклар кылулары хакында хәбәрдар булганлыктан, Мөхәммәд пәйгамбәрнең изгелек юлында икәнлеген аңлый иделәр, шунлыктан аның җиңеп чыгасына ышанучылар хәтта мәҗүсиләр арасында да шактый күренде.

Дала-чүлнең үз кануннары бар. Гүяки бер башыннан икенче чите күренмәс кебек тоелса да, хәтта бер генә кеше дә синең ни кылганыңа

---

[1] Ахыры. Башы журналның 8 санында.

шаһитлык тотмаса да, бер тарафында уһ иткән тавыш чыкса, икенче яктан аһ авазы ишетелә, әледән-әле көченеп торган комнар серне яшерсәләр дә, нәүбәте житеп, котелмәгән җирдән беркөн барсын да ачып салалар. Бәдәвиләр дә холык-фигыльдә шушы газиз туфракларыннан үрнәк алып, аның тәрбиясендә яшиләр. Әгәренки бу сыйфатларында үзгәрәләр икән, чүл дә аларны ятсына башлый. Юккамы кешене табигать баласы, диләр!

Корәиш гаскәрләренең якынлашып килүе хакында Мөхәммәд пәйгамбәребезгә бәдәви гарәпләр хәбәр китерделәр. Мәккә монафикъларының тәвәккәл булулары, башларына бер уй керсә, аны уенга гына әверелдереп калдырмыйча, зурга кубарулары мәгълүм нәрсә. Сугышсыз инде мөмкин түгел иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең якын кешеләрен, халык алдында даншөһрәт казанган сәхабәләрен үз янына җыйды. Шушындый зур эш алдыннан ул алар белән киңәш итәргә тиеш иде. Һәркемнең сүзләренә колак салып, уртак бер фикергә килenгәндә генә, гамәлнең ахыры яхшы булачак. Киңәш өчен җыелышкан сәхабәләр дә моны төшенделәр.

— Корәишләр Мәккәдән чыктылар, алар белән очрашырга туры килер,— дип белдерде Мөхәммәд пәйгамбәр. Барсы да аңладылар: тиздән ике капма-каршы көч очрашырга, кылычка-кылыч килеп, кемнәрдер харап булырга, кайсыларыдыр тантана итәргә тиеш...

Пәйгамбәрнең һәртөрле дошманлыкны тыныч юл белән генә хәл итәргә омтылышы һәммәсенә мәгълүм иде. Ничә еллар ул шушы фикерендә торды. Җәбер һәм золымга түзде. Начарлыкка яхшылык белән җавап бирде. Таш белән атканга да аш белән кайтарырга тырыша иде. Ә хәзер — сугыш, һәм аны пәйгамбәр үзе җитәкли. Аллаһы тәгаләнең әмере ирешкәннән бирле шушы фикереннән кире кайтмас булды.

Боларны хәтере аша уздырган Әбу-Бәкер аягүрә басты. Барсының да күзләре аңа төбәлде. Аның сүзе арада иң мәртәбәлеләрдән һәм әһәмиятлеләреннән санала иде. Башында кайнаган хәтер очкыннарыннанмы, әллә инде уйлары чуалуданмы ул озак кына эндәшмичә торды. Ни әйтерен хәтта Мөхәммәд үзе дә көтә иде булса кирәк. Пәйгамбәрдән узып, артык сөйләп ташлауны әдәпсезлек санаган Әбу-Бәкер ике-өч кәлимә сүз белән генә канәгатьлек тапты:

— Бу сугыш — изге сугыш, өммәтнең горурлыгы өчен кирәк! — дип белдерде ул.

Әбу-Бәкер әйтер сүзен кыска тотканнан соң, аңа кушылып, Фәрук хәзрәтләре аяк өсте калыкты һәм:

— Йа Рәсүлуллаһ,— диде,— алар — корәишнең әгъзасы, аларның иманга килүләре мөмкин хәл түгел. Һаман да дошманлык кылырлар, ничек тә бәла-каза итәргә тырышырлар. Сугышка һаман да әзер булып тор! — дип, үз фикерен белдерде.

Фәрукның бу сүзе мөселманнарның монафикъләр белән сугышырга теләге барлыгын ачык аңлата иде.

Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм догага кулын тотты, аны укып тәмам иткәннән соң, арадан Мөкадәд бине Әл-Әсвад калыкты, сүзләре сәхабәләрнең утырышка йомгагы кебек ишетелделәр, барсы да диярлек аның әйткәннәрен җөпләгәндәй баш кагып утырды.

— Йа Рәсүлуллаһ, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән гамәл кыл һәм аның фәрманы илә йөр,— диде ул,— без исә, бәни-исраил кавеме Муса пәйгамбәргә әйткән шикелле: «Син үзең бар, дошманнарыңа каршы Раббың белән бергә сугыш!» — димәбез, бәлки синең белән барырбыз, җаныбызны һәм башыбызны Аллаһы тәгалә һәм пәйгамбәренең юлында фида итәрбез...

Сүзләренең куәте һәм кодрәте тыңлап утыручыларның күзләрен дымландырып кына калмады, ул үзе дә авыр һәм сагышлы итеп тын алды.

— Аллаһы тәгаләнең хакы өчен,— дип дәвам итте Мөкадәд бине Әл-Әсвад бераздан,— җаннарыбыз һәм башларыбыз фида булсын. Мо-

ны без иманыбыз белән белдердек, гамәлебез белән расларбыз! Аллаһы тәгалә сине хак пәйгамбәре итте, үзенең әмерен синең аша өммәтләре өстенә йөретте. Әгәр дә син безне шушы хәлебездә хәбәшиләрнең шәһәре Бәрәкел-Гимадка яу белән күндерсәң, аларны динебезнең дошманнары дип белдерсәң, буйсынырбыз!

Аның бу сүзләреннән соң Мөхәммәд галәйһис-сәлам дога укыды һәм, фикер алышу тәмам булып, монафикълар белән сугышка ниятләнделәр.

Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнән мөселманнар Раббыбыздан бу эшләр хакында хәбәрләр алуын өметләнделәр. Шушы теләкләрен белдерделәр. Киңәшмәдә сөйләгән кешеләр мөһаҗирләр тарафыннан гына иде. Әнсарилар ягыннан торып кем дә сүз әйтмәде. Әмма аларның да сугышка әзер икәнлеге күренеп тора иде. Шунда, фикерләшү тәмамланып та урыннарыннан кузгалырга ашыкмаган сәхабәләр алдына Сәгад бине Мөгаз калыкты һәм:

— Йа Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, әгәр дә әмерегез булса, мин әнсарилар ягыннан бер-ике сүз әйтер идем,— дип үтенечен белдерде.

— Әгәр дә бу сүз әнсариларның теләк-максатларына туры килә дисәгез, ярый, сөйләгез! — диде Мөхәммәд.

Сәгад бине Мөгазнең йөзе җитдиләнгән, акылы камил һәм фикере үтемле иде. Ул:

— Йа Рәсүлуллаһ,— дип һәр әйткәнен дәлилле рәвештә эректән башлап китте,— без сиңа иман китердек һәм сине Раббының безгә биргән рәхмәте дип кабул иттек, сине пәйгамбәр дип таныдык. Һәр нәрсә әйтсәң, нинди генә әмер җиткерсәң һәм таләп куйсаң, сабырлыгыбызны таптык, буйсындык, ул сүзләреңне Аллаһы тәгаләдән дип таныдык. Алардан бер генә адым да читенмәдек. Син — безнең ышанычыбыз. Һәрьяктан бары тик яхшылыкка гына өндәдең. Гарәпләр арасында моңа кадәр күрелмәгән тынычлык һәм хөрмәтне безгә бирдең. Яманлык һәм усаллыктан, бер-беребезгә күрсәткән җәбер-золым, үч-дошманлыктан аралап, арабызга дуслык һәм бәхет орлыклары чәчтең. Чын күңелдән ипандык: Аллаһы тәгалә бәндәләренең хакы өчен сине арабызга пәйгамбәре итеп күндерде. Без сиңа ышанабыз. Күңелеңдә ни бар — әмер ит, барлык әмереңне дә тотарбыз, бер генә адым да читкә чыкмабыз, бер генә кирелек белән дә баш тартмабыз, уйга да кертмәбез. Аллаһы тәгалә бездән ни-нәрсә таләп итсә, иң элек синең үзеңә белдерә. Син — Аның пәйгамбәре, безгә һаман да юл күрсәт!

Сәгад бине Мөгазнең бу сүзләре һәммәсенә дә шулкадәр тәэсир итте ки, арадан Гали бине Әбу-Талип хәтта:

— Бәрәкәтуллаһ! — дип, сокलануын белдергәнен сизенми дә калды.

Мөхәммәд пәйгамбәргә Сәгаднең сүзләре бигрәк тә хуш килде һәм ул аңа атап хәер-дога кылды һәм ачылып:

— Барчагызга да Аллаһы тәгалә хәерле гомерләр насыйп итсен,— диде.— Раббым миңа бу ике таифәне вәгъдә итте: «Йә Әбу-Суфийанның кәрванын тоткын ит, яки корәиш кавемен!» — диде. Валлаһи, аларның гаскәрләре төшәчәк җирләрне үз күзем белән күреп торырмын!

Шунда сүзләр тәмам булып, Рәсүл Әкрам урыныннан купты һәм Бәдер тарафына юл алдылар.

Мөхәммәд пәйгамбәр үзе белән Канадәт бине Әл-Ногманны һәм Мөгаз бине Әл-Җәбәлине алды. Барыр юллары якын тирә-җирне карау, сугыш мәйданы булырга мөмкин урыннарны күздән кичерү һәм серләрне саклаучы чүлдән кирәкле мәгълүматлар алып, дошман хакында хәбәрдар булу иде.

Рәсүл Әкрамның юлында очраган кешеләрнең берсе, бәдәви гарәпләре арасында шактый дәрәҗәгә ирешкән гарәп — олы яшьтәге шәех, олпат карт иде. Аның исеме тарихларга һәм риваятьләргә Суфийан бине Әз-Замири дип кереп калган. Чүлнең бер башында ике кеше тарткалашса, бөтенләй дә икенче тарафта кояш баешына күңел ихласын куеп утырган бу карт барсын да ишетеп тора, белеп бара, диләр иде. Пәйгамбәрнең

юлында нәкъ шушы кешенең очравы сер белергә килүчеләрнең эшләрен шактый җиңеләйтте.

— Сез кем? — дип сорады аннан Мөхәммәт пәйгамбәр.

Үзенә Аллаһы тәгалә тарафыннан бирелгән гомерне яшәгән, ашын ашаган, суын эчкән мондый картлар бераз кирерәк булалар. Суфийан бине Әз-Замири дә үзен шулайрак тотты.

— Ә сез үзегез кемсез? — диде ул, бер дә исе китмәгән кыяфәттә. Күренеп тора, аның өчен барыбер иде: ничек килсәләр, шулай үтеп тә китәрләр, беткән ди адашып йөрүчеләр!

Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр, үз соравына илтифатсыз гына җавап алуына карамастан, мөмкин кадәр йомшак һәм игътибарлырак булырга тырышты. Кырык яктан кырык эше чәчелеп ятса да, өлкән кешегә хөрмәтен күрсәтеп, эч серләренә үтәргә, кирәкле сүзне ишетергә тиеш иде ул. Һәркемдә үзенә күрә горурлык һәм кирелек бар. Шунлыктан хәйләсез эш йөртү мөмкин түгел, бигрәк тә сүздә, серләр биштәрен сүтәргә теләгәндә!

— Әүвәл сез хәбәр бирсәгез иде,— диде ул, катылыкка каршы йомшаклык белән,— аннан соң без әйтербез...

Мөлаем сүз таш вата диләрме? Гарәп чүлләрендә бәрелеп-сугылып йөрүче һәртөрле узган-киткәннән мондый тәртип белән әйтелгән сүзләрне ишетми күптән колаклары катылана башлаган картның хәтта күңеле дә яктырып китте. Болар кемнәр булырлар дигәндәй, кулын чал кашлары өстенә куеп:

— Максатыгыз нәрсә? Сорагыз! Белсәм, җавап бирермен,— диде ул, елмая төшеп.

— Корәиштән хәбәрең бармы? — дип сорады пәйгамбәр.

Җавабында Суфийан Әз-Замири корәишләрнең Мәккәдән кайсы көндә гаскәр белән чыгуларын һәм, әгәр дә дөрес була калса, инде кайда килеп җитүләрен сөйләп бирде. Билгеле, боларны ишеткәч, хаталана дип тә уйларга мөмкин иде. Шунлыктан Мөхәммәд пәйгамбәр тагын да сорарга кирәк тапты:

— Ә мөселманнар хакында нинди хәбәрләрең бар?

— Аларны да Мәдинәдән чыкканнар дип ишеттем,— дип, карт бәдәви шунда Мөхәммәд һәм аның яраннарының инде кайда килеп җиткәннәрен әйтеп бирде.

Аның сүзләре дөрескә чыкты. Чыннан да, мөселманнар шушы карт күрсәткән урында гаскәр белән тупланып тора иделәр.

— Мин хәбәр бирдем, инде сез кем? — дип сорады ул.

Җавабында пәйгамбәр аңа:

— Без — әһле нутфатиз,— дип белдерде. Әмма картлач бу сүзләрне «әһле маиз» дип ишетте һәм «болар әһле-маи» халкы икән дигән фикергә килде. Ул вакытларда гарәпләр Гыйрак халкын, сулары күп булу сәбәпле, әһле-маи, ягъни су халкы дип атый иделәр. Ә пәйгамбәр исә, «әһле маиз» дип, үзләрен тәһарәт белән сафланучы, чиста кешеләр икәнлеге хакында әйткән иде.

Шул рәвешле Суфийан Әз-Замири үзеннән Мәккә һәм Мәдинә якларыннан бер-берсенә каршы килүче көчләр хакында сораштырган кешеләрне фарсылар дип уйлады. Адашып килгәннәр дигән фикергә туктале, боларга артык игътибар бирмәскә булды.

Мөхәммәд пәйгамбәр исә кире, юлга чыгып, гаскәренә килде һәм намазга әзерләнә башлады.

Рамазан аеның уникенче көне ирешкән иде. Гали бине Әбу-Талипны, Зөбәйр бине Әл-Гавалины, Сәгад бине Әбу-Вәккасины һәм тагын да берничә сәхабәне Рәсүл Әкрам корәишләрдән хәбәр алырга дип җибәрергә булды.

— Бәдер коесы тирәсенә барыгыз, шунда корәишләр хакында белеп кайтырсыз! — диде ул аларга.

Пәйгамбәр әмерен җиренә җиткереп үтәү өчен алар шунда юнәлделәр. Әйтелгән урынга килеп ирештеләр һәм дөячеләрнең, су китерүче-

ләрнең кое тирәсендә мәш килүләрен күрделәр. Болар, һичшиксез, корәишләр иде.

Үзләренә якынлашучы гаскәриләрне күрүгә, болар тиз ара качу ягын карадылар; кораллары булмау сәбәплеме, бик тә курыктылар, төрле якка таралыштылар. Гали бине Әбу-Талип үзенең иптәшләре белән бу качып баручыларның берничәсен тоткын итәргә ниятләде. Куа барып, арадан икесен камадылар һәм кулга алдылар. Аларның берсе Әсләм бине Әл-Хиҗаҗның колы, икенчесе исә Гаус бине Гаснықы булып чыкты. Димәк, коедан су китерүчеләр, гаскәрне һәм малларын сугаручылар барсы да коллар гына, һәм хуҗалары да яу белән килгән дигән фикергә таянып, күп кенә кирәкле сорауларга җавап табарга мөмкинлек ачыла.

Тоткыннарны пәйгамбәр яраннары янына алып килделәр. Аларның мәҗүси булулары сәбәпле, сүзләренә дә ианырга ашыкмадылар. Мөхәммәд саллалаһу галәйһи вә сәлләм намазда иде.

Әсирләрдән сорау алу эшенә керешеп, Мөхәммәд пәйгамбәрнең килгәнен дә көтмичә:

— Сез кем? — дип белештеләр.

Болар:

— Без — корәишнең коллары,— дип җавап бирделәр.

— Санығыз күпме? — дигәнгә исә:

— Барлыгыбыз йөз кеше,— диделәр. Шушы сүзләреннән чыгып, сәхабәләр боларны Әбу-Суфийанның коллары икән дип, фикер йөрттеләр. Чөнки сәүдә кәрванының Мәккәгә исән-имин кайтып ирешкәнен белми иделәр.

Ул арада Мөхәммәд пәйгамбәр намазын тәмамлап, йөзе балкыган сурәттә сәхабәләр каршысына килде. Булып узган вакыйгаларны белешкәннән соң:

— Бу әсирләр дөрес сөйләгән. Сез аларны камчы белән суктырып сораштырдыгыз. Инде миһербансызлык итүегездән азат кылам. Аларны кыйнау кирәкмәс,— диде.

Шуннан соң әсирләрнең үзләренә мөмкин кадәр күңел йомшаклыгы белән мөрәҗәгать итте:

— Бу вакытта корәишләр гаскәре кайда?

Бине Әл-Хиҗаҗ һәм Бине-Гас бине Сәгыйтьнең коллары туры җавап бирделәр:

— Шул коеның артындагы ком тавыннан арырак урындалар.

— Корәиш гаскәре күпме күләмдә булыр?

— Без моны әйтә алмыйбыз,— дип, әсирләр тагын башларын салындырдылар. Аларның белмәвендә бер дә яшерен сер саклау теләге юк иде. Колларның бу хакта хәбәрдар булулары мөмкин эш түгел.

Һәр «белмим» дигән сүзгә камчы белән орырга әзер торган сәхабәләрне Мөхәммәд пәйгамбәр тиз ара туктату ягын карады. Бөтен эшне дә усаллык һәм явызлык белән башкарырга ярамый шул.

— Ә бер көнгә ничә дөя чалалар, күпме ризык әзерләнелә? — дип сорады Мөхәммәд пәйгамбәр. Моның нәрсәгә кирәге бар дигәндәй, сәхабәләр бу сүзләргә игътибар да бирен тормадылар. Әмма Рәсүл Әкрам ялгышмады: башкасын белмәсәләр дә, коллар болардан гына хәбәрдар булырга тиешләр! Димәк, төп сорауга да җавап табылачак. Фикерли генә бел.

— Ничек дип әйтергә,— диделәр әсирләр.— Бер көндә тугыз дөяне бугазласалар, икенчесендә унны чалалар... Бүтән көннәрдә дә шул рәвешле кабатланылып барыла.

— Алай икән...— Пәйгамбәрнең йөзе балкып киткәндәй булды.— Димәк ки, корәишләрнең гаскәрләре меңнән кимрәк, тугыз йөздән артык.

Көтелмәгән бу нәтиҗәдән сәхабәләрнең кайсысы аптырабрак калды, кайсыларының шушы кадәр зур яуга гаҗәпләнүдән күзләре шарланды, икенчеләре исә пәйгамбәрнең ни рәвешле ачык һәм дөрес фикер йөртүенә үзләренең соклануларын яшерә алмадылар. Берәүләрнең бәхете — акыл-

дан, икенчеләрнеке — кулдан, тырыш хезмәттән, өченчеләрнеке исә — матурлыктандыр. Ә боларның барсы да пәйгамбәребезгә берьюлы бөтен килеш бирелгәнлектән, аның сүзләренә колак салмый, кылган гамәлләреннән үрнәк алмый, аңа сокланмый мөмкин түгел иде.

— Аксөякләрдән һәм баһадирлардан, кабилә башлыкларыннан кемнәр бар? — дип, әсирләрдән сорадылар. Бу яктан корәишләр гарәп кавеме арасында аерылып тора иделәр. Шунлыктан аларга карата хөрмәт хисе ничә гасырлар буена яшәп килде. Үзләрен санга алып сөйлиләр, хәтта күп җирләрдә күреп, аралашып та белә иделәр. Мәккәнең абруе алар кулында диярга мөмкин иде.

— Гутбә, Шәйбә, Харис бине Гамру, әбул-Бухтури, Хәким бине Хөзам, Назир бине Әл-Харис, Әбул-Хәким бине Һишам, Өммийә бине Халәф, Нәбийә һәм Мөнбийә — Хиҗаж уллары...— дип санап китте әсирләр. Әбул-Хәким бине Һишам дигәннәре Коръәндә бәддога укылган Әбу-Җәһилнең үзе иде.

Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләре алдына чыкты һәм, барсына да белдереп:

— Безгә каршы корәишләр Мәккәдән зур гаскәр белән киләләр, без орышка әзер торырга тиешбез! — диде. Аннан соң мөселманнарның һәммәсенә карашын йөртеп алды да: — Гаскәребез арасыннан чыккан, кире кайту юлына чигенгән кешеләр бармы? — дип сорады.

Зөһрә дип аталган кабиләсе белән Шәррыйк, ягъни Әхнүс бине Зөһрә, юк-бар сәбәпләр табып, Мәдинәгә таба кайтып киткән иде. Сәхабәләр шушы хакта белдергәч, Мөхәммәд:

— Ул үзенең кавемен туры юлга кергән дип белдергән иде, туры юлда түгелләр икән... Тагын кем дә булса чигендеме? — диде.

— Гади һәм Кәгәп кабиләләре киттеләр,— дип җавап бирделәр.

Иманның ныклыгын, кешенең олылыгын, Аллаһы тәгаләне һәм аның пәйгамбәренең барлыгын белүдән тыш, сабырлык һәм күнелеңне, тормышыңны бу бурычына төрле яклап багышлау да тәэмин итә. Әгәр дә ныклыгың юк икән, ул вакытта үзеңне мин шушы дин кешесе, мин мөселман дип йөрүдән ни файда? Карендәшләрең изге юлда йөреп, Аллаһы тәгаләнең таләбенә буйсынып, зур эшләр кылганда синең почмакка сыенып калуыңнан үзеңә дә, бүтәннәргә дә ни файда? Шушындый кирәкле вакытта да карендәшләрен ташлап китәргә ничек мөмкин иде? Юк, иманның ныклыгы сүздә дә, телдә дә түгел,— йөрәктә! Ә аның көчен бары тик гамәлең генә раслый ала.

Бу хәбәрләрне сәхабәләрдән ишеткәннән соң, Мөхәммәд пәйгамбәрнең бераз кәефе кырылды, кояш кебек балкып торган йөзе сүнгәндәй тоелды. Шунда яраннарын чакыртып алды да:

— Безгә монда калыргамы, әллә инде бүтән урынга күчәргәме? — дип, алардан киңәш сорады.

Хәрби эштә башкаларның фикерен тыңлау, шуннан чыгып фикер йөртү кулайрак иде. Әлбәттә, пәйгамбәр бу мәсьәләне үзе генә дә хәл итә алыр иде, һич югы вәхи килгәнен көтеп, шуның нигезендә гаскәрләрен йөртүе уңайрак булгандыр, бәлки. Әмма һәркемгә мәгълүм бер хакыйкать бар: мәҗүсиләр сугыш уенын күктәге аллалар орышы нәтиҗәсе белән бәйле дип уйлаганнар. Әмма сугыш кебек олуг җәбер вә золым эшләрен һичбер вакытта да күкләр хәл итмәгән, моны җирдәге адәм балалары уйлап чыгарган. Орыш-талаш, бер-береңә яманлык кылу, һәртөрле начарлыклар — болар барсы да кешеләрнең үз «иҗатлары». Аллаһы тәгалә аларны менә шулардан арынырга, котылырга өнди. Ә Исламның көч алуы өчен Мөхәммәд пәйгамбәргә Хак тәгалә бүтән пәйгамбәрләренә биргән төсле туфан да, давыл да, ут та, башкасын да ярдәмче кылмады, корәиш кавемен, иманга килмәгәннәре өчен бер-бер бәла белән дә кырмады, юк итмәде, бәлки курку белмәс йөрәкләренә көч итәргә, кулларындагы кылычның үткерлеген танытырга шәһитлек мәртәбәсе тапшырды.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең киңәш соравына каршы сәхабәләр арасыннан Хаббаб бине Әл-Мөнзир күтәрелде һәм:

— Әгәр дә безнең бу эшебез вәхи белән икән, ул вакытта бүтәнчә урынга күчүебезгә һичбер теләк юк, вәхи белән кылынган гамәлне үзгәртергә, ул хакта сөйләшергә кодрәтебездән килмәс. Аллаһы тәгаләнең теләгенә буйсыныpбыз! Әмма да инде хәрби эш вәхи белән булмыйча, киңәшү ярдәмендә оештырылса, ул вакытта минем әйтер сүзем бар,— диде.

Риваятьләрне Ибне-Габбастан алып сөйләүче хәбәрләрдә шул рәвешле әйтелә ки, Хаббаб бине Әл-Мөнзирнең шушы белдерүеннән соң, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм уйга төште. Ул да булмады, аңа Җәбраил фәрештә ирешеп:

— Мондый гамәлләр вәхи белән башкарылмас, киңәш ярдәмендә хәл ителер! — дип төшендерде.

Пәйгамбәр сәхабәләре каршысында кинәт айныгандай, башын күтәрде һәм Хаббаб бине Әл-Мөнзиргә карап:

— Бу рәвешле эшләр вәхи белән булмас, киңәш белән башкарылырлар,— диде.

Бу хәбәрдән сөенгән Хаббаб:

— Ул вакытта болай итик,— дип, үз теләген һәм уйларын уртага ярып салды.— Без моннан күченик. Кое янына килик. Аның суы чиста һәм яхшы. Тәннәребезне сафландырырбыз, татлы суы белән бәдәннәребезне сугарырбыз, ат һәм дөяләребезгә сый бирербез,— диде.

Аның сүзләре һәммәсенең дә теләгенә туры килде. Киңәшләшүне шуның белән тәмам итеп, сәхабәләрнең гаскәре Хаббаб бине Әл-Мөнзир әйткән урынга күченде. Канлы бәрелеш алдыннан моннан да кулайрак фикергә килү мөмкин түгел иде.

Гали бине Әбу-Талип, иптәшләре белән барып, Бәдер коесы тирәсеннән корәишләрнең дөячеләрен һәм су ташучыларын куркытып җибәргәч, Җитмәсә, икесен кулга да алгач, ул коллар атылып-бәрелеп диярлек гаскәр эченә кайтып төштеләр.

Аһ-ваһ итеп, хәлне хуҗаларына сөйләп бирделәр. Бу вакыйгадан соң, корәиш арасында төрле сүзләр, күңел какшавы кебек галәмәтләр башланып китте. Җитмәсә, мөселманнарның ике колны кулга алулары да беленгәч, һәркем диярлек: «Хараплар гына булдык!» — дигән сүзне телләреннән ычкындыргалап, янәшәдәге иптәшләрен дә куркуга салдылар.

Бу вакытта Хәким бине Хизам үзенең чатырында ит кыздырып, ашарга әзерләнеп маташа иде, корәиш арасына төшкән хәвефтән хәбәр алды. Эче көйде. Майлары агып торган, хуш исләр чыгартып кыздырылган итне, табыныннан күтәреп, авызына китерә алмады. Ризыгының тәме бетте. Бүтәннәрне ничек каушаткан булса, хәвеф аның да котын алды. Ул да:

— Хараплар гына булганбыз икән! — дип, хәлсез калды.

Көтелмәгән бу вакыйга йокларга җыенып, чатырлар корган гаскәриләрнең тынычлыгын алды. Хәким бине Хизам да, чатырыннан чыгып, күңелен тынычландыру өчен үзенең дуслары янына юнәлде. Бәлки, алар бу мәсьәләне хәл итү мөмкинлеген белә дә торганнардыр? Хәким бине Хизам кебек каушап калмаганнардыр?

Аның йөрүеннән файда күренмәде, күңелен тынычландырырлык бер генә сүз дә ишетмәде. Һәр урында шул вакыйгаларны кат-кат телгә алу, аһ-ваһ орудан ары һични сөйләшмиләр иде.

Хәким бине Хизам, шуннан соң дусты һәм фикердәше саналган Гутбәт бине Рабига янына юнәлде. Ул да хәвефтән аһ-зар коелып утыра иде, сердәшен күргәч:

— Ай-һай, гаҗәп бер сәфәр булды да инде бу,— дип хәсрәтле башын чайкады.— Капкынга мөселманнарны кертәбез дигәндә алар үзләре өл-

герлек күрсәттеләр. Без аларны кылыч белән кисәргә уйлаганда ике кулсыз калгандай булабыз түгелме соң?

Аның сүзләрендә хакыйкать бар иде.

Шунда Хәким бине Хизамның акылы яктырып китте һәм, Әбу-Җәһил хакында Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйткәннәрен исенә төшереп:

— Тыңламаган кешегә киңәшнең файдасы юк,— дип әйтеп куйды. Моның нәрсә уңаеннан һәм кем хакында икәнлеген Гутбәт бине Рабига да төшенеп алды.

— Йа Гутбәт,— дип сүзен дәвам итте Хәким бине Хизам,— ышанасыңмы-юкмы, белмим, әмма мин сизенеп торам, бу төндә Мөхәммәднең сәхабәләре безне уратып алачаклар, аларның тоткынлыгында калачакбыз, харап кына итәрләр. Ышанасыңмы?

Гутбәтнең моны да аңламаска чарасы юк иде.

— Ышанам! — диде ул, килешеп.

Әмма шунда хәким бине Хизамның фикере яңарып китте һәм, көтелмәгән җирдән:

— Әгәр без моның шулай буласын беләбез икән, ул вакытта нигә чарасыз калырга? Мин аларның камавына ышанмыйм, чөнки аннан котылып калырга мөмкин бит,— диде, мәсьәләгә чишелеш тапкан шикелле. Әмма шунда ук дустына сораулы карашын ташларга да өлгерде һәм болай дип үтенде: — Ә котылу чарасы нинди булыр?

Әмма Гутбәт һаман да әүвәлге фикерендә калган иде әле. Ул:

— Бу төндә, таңга кадәр, Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләре безне камап алачаклар,— дигән сүздән артыгын әйтмәде.

Ул арада Әбу-Җәһил дә күренеп, аларның сүзләреннән хәбәр алды һәм:

— Аһ, шулаймы әле, син, Гутбәт, Мөхәмәд белән сугышырга теләмисеңме әле!..— дип, лаф орды да, җыела төшкән халыкка карап: — Сез барыгыз да бу төндә Мөхәммәднең безне камап алуына ышанасызмы? Шулай лыгырдыйсызмы?! — дип җикеренде.— Лат һәм Гузза хаккы өчен әйтәм, бу төндә Мөхәммәд безнең янибызга килер, әмма күрми үтеп үк китәр, безне бу төндә һичкем урап алмас, тоткын да итмәс!

Әбу-Җәһилнең шушы кадәр үз-үзенә ышануы һәм әйткән сүзләренең монафикъларга тәэсирле булуы файда итте ки, аларның күңелләре тынычланып, хәвефтән арына башладылар. Өсләренә йокы сөреме басып килә иде, таралышу ягын карадылар.

Бу кичәдә Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәләре бер комлыкка тукталдылар. Аларның аяклары тездән батты. Дөя һәм атларына кузгалырга мөмкинлек калмады. Барып җитәргә тиешле саф сулы коега әле ерак иде. Шушында гына кичне уздырырга булдылар. Әмма күпләрнең тәһарәте һәм госеле юк иде. Шунлыктан намаз укырга җай таба алмадылар.

Риваятьләрдә шулай сөйләнелә ки, бу кичәдә мөселманнарга вәсвәсә кылырга дип Шайтан аваз салды:

— И мөэминнәр, сез Мөхәммәдне тыңлап ялгыштыгыз, аңа ияреп килдегез. Чиксез малларга өметегез бар иде. Әмма ул сезне һәлакәткә дип монда китерде. Барчагыз да харап булырсыз, каннарыгыз агар,— диде.— Сез аның сүзләренә колак салдыгыз, әмма намазыгызны калдырдыгыз. Хәдис һич тә намазны алыштыра алмый. Харап ителәүегез шушыдыр!

Аның сүзләрен ишеткән мөселманнар хәвефкә төштеләр. Алынмаган тәһарәт, укылмаган намаз өчен эчләре пошты. Әмма шушы вакытта Аллаһы тәгаләнең рәхмәт күзе аларга төшеп, көтелмәгән җирдән яңгыр яварга тотынды. Сусыз зарыккан бәндәләренә һәр тамчысы нигъмәт булып иреште. Кемнәрнең юынганы юк иде, алар да канәгатьлек таптылар, һәммәсенең күңелләрен сөенеч биләде. Хәвефләре шушы яңгыр суы белән юылып алынды. Бәндәләренә Аллаһы тәгаләнең миһербанлы булуына дәлилләрнең берсе менә шушы

кичәдә сәхабәләрнең күз алдында мәйданга чыкты. Бу янгырдан соң комнар утырып, өстендә йөрерлек хәлгә килеп ныгыды.

Сәхабәләр арасыннан Гомәр бине Йасир һәм Габдулла бине Мәсгуть икесе корәишләр хакында мәгълүматлар җыю өчен ул кичәдә кяферләрнең гаскәрләре янына бардылар. Аларның тирәсендә йөреп, барсын да хәтерләргә тырыштылар. Шунда корәишләрнең үз яннарында атларын тоткан һәм бәйләгән хәлдә чишенмичә йоклаганлыкларын күреп хәйран булдылар. Сәхабәләр янына кайтып, хәбәрләрен бирделәр дә:

— Көтелмәгән һөҗүмнән куркыпмы, алар тиз үк качарга әзер халәттә яталар,— дип фикерләрен белдерделәр.

Таң белән уянган корәишләр исә аларның эзләрен күреп, эшнең асылына төшенергә тырыштылар. Арада Гутбәт бине Әл-Хиҗаҗ эзләрне тану гыйлеменә ия кемсәләрдән иде. Ул аларны караганнан соң:

— Бу Гомәр бине Йасир һәм Габдулла бине Мәсгутьнеке булганы тәгаен,— дип, нәтиҗәсен әйтеп салды.— Мөхәммәд безгә каршы үзе белән киткән корәиш гаскәрен һәм Ясрип шәһәренең сугышчыларын алып килгән, алар ярдәмендә сугышырга ниятли, бергә-бергә безнең өскә кылыч күтәрергә уйлаганнар.

Ни хикмәт, ул бу юлысы үзенә канәгатьлек табып елмая һәм хәтта сөенә дә иде. Үзенең сүзләренә кушылыр кешене күрмәгәч, барсының да аптыраган кыяфәтенә күз ташлап:

— Ясрип халкына кылыч күтәреп тә маташмыйм, каннарын да агызмыйм. Аларны тоткын итеп алам. Үтермим. Тере килеш тотып, аяк-кулларына богау һәм аркан салып, Мәккәгә алып кайтам, халыклар алдында үзләрен оятлы ясыйм. Бөтен кешеләргә күрсәтәм, кемнәр безнең белән килмәде, курыктылар, аларның күңеленә гайрәт керер, ә кемнәр безгә дошманлык тотарга теләсә, яу китерергә ниятләсә, курка калыр, гыйбрәт алыр,— дип тантана итте. Ул үзенең сүзләре чынлыкта да шулай гамәлгә ашачак дигән өметтә иде.

Бәдер коесын карарга килгән Мөхәммәд пәйгамбәр аның суын эчүне һәм аннан файдалануны бер дә мәслихәт күрмәде һәм сәхабәләргә:

— Бу мәйданда бер-бер кавемне канга батырып харап иткәннәр булса кирәк,— дип белдерде.

Корәишләрдә Мәдинә халкына түбәнсетеп карау кебек сыйфатлар бар иде. Шушы Бәдер коесын күрергә килгәч, моны истә тотып, Сәгад бине Мөгаз бу хакта сүз башлады һәм:

— Әгәр дә сугышта тоткын ителсәк, яки канибыз акса, яки үлсәк, Аллаһы тәгалә үзе сакласын, бары тик аңа гына сыенабыз,— диде. Ә инде без җиңүгә ирешеп, дошманнарыбызны кулга алсак, Ясрип халкын һич тә өлешсез калдырма. Без ике кавем, әнсарилар һәм мөһаҗирләр булсак та, бер синең артыңнан ияргүчеләр. Әгәр дә кулга кергәннән халыкка өлеш чыгарсаң, алар сине яратырлар, үзең өчен җан атып торырлар,— дип үтенде.

Аның бу сүзләре пәйгамбәрнең күңеленә хуш килде, шушы киңәшкә таянганда ул күп кенә кыенлыкларны чишү өчен үзенә юл арчыр иде. Бу хакта уйлап, Мөхәммәд киңәше өчен Сәгад бине Мөгазгә рәхмәтен белдерде һәм дога укыды.

Сәхабәләр чатыр кордылар. Алар янына кайткач, Мөхәммәд пәйгамбәр намазга утырды һәм:

— Йа Илаһи, сиңа лаеклы гыйбадәтем өчен миңа Китап бирдең, ике кавемнең берсен миңа вәгъдә кылдың, әмма алар миңа һәм әмереңә каршы килделәр,— дип корәишләрне уеңда тотып дога укыды.— Үз вәгъдәңә каршы килерлек эшләренә юл куймассың дигән өметтәмен...

Шунда корәишләрдән берничә атлының якынлашуы күренде, алар исә сәхабәләрне күзәтү өчен җибәрелгән иделәр.

Мөхәммәд пәйгамбәр арадан кызыл дөягә атланган Гутбәт бине Рабиганы күреп алды һәм догасында:

— Әгәр дә бу кавемдә хәер юк исә, бу кемсәдә бардыр, аның сүзен тотсалар иде, күңелләре шатлык һәм канәгатьлеккә ирешер иде,— диде.

Аның бу сүзләре асылда сугышырга теләмәгәнлеген һәм корәишләр белән кан коймыйча гына килешү исәбе барлыгын аңлата иделәр. Әмма баштанаяк коралланган һәм Мөхәммәдне акылга утыртырга, аның белән киткән кешеләрне кулга алып, мыскыллы рәвештә Мәккәгә китерергә ниятләгән монафикъләр гаскәре үзләренең көчләренә артык дәрәҗәдә ышана иде. Берәүләрнең иминлек теләве икенчеләрнең бәлагә омтылышын арттыра гына шул.

Үз тарафыннан пәйгамбәр илчелек күндереп, корәишләрдән солых үтенү уена килде. Ни дисәң дә, ике каршы якта да кан кардәшләр, туган-тумачалар бар иде. Сәхабәләр арасында берләренең уллары булса, корәишләр эчендә — аталары: «Бу тыңлаусыз баламны тәртипкә кертәм әле!» — дип атлыгып тора иделәр. Һәм, киресенчә. Чөнки каршылык гарәпләрнең үз арасында куерды, берәүләр иске гореф-гадәтләргә таянып, буыннан-буынга яшәп килгән йола нигезендә яшәүне кулай һәм мәслихәт күрделәр, мәҗүсилекне өстен санадылар, икенчеләр исә Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәгълиматына инандылар, Аллаһы тәгаләне генә Бердәнбер, Кодрәт иясе дип танудылар. Тарихи үсеш ягыннан чыгып караганда, һәркемгә мәгълүм, боларның беренче төркеме гарәп халкын вак кавем дәрәҗәсендә калдыру, һәлакәткә бару юлын сайлау булды исә, икенчеләре, киресенчә, дөньякүләм мәйданга чыгарга омтылу иде. Әмма моның нәрсә белән бетәсен мөгаен ул вакытта һичкем күз алдына китермәгәндер. Дөрес, гореф-гадәтне саклау халыкны халык итеп яшәтә, аны башкалар белән буталудан саклый, әмма иске йолаларга гына тотынып гомер сөрү, шул ук вакытта, үсештән читләшүгә, арттa калуга да китерә. Шулай да, тарихи үсешне тәэмин итә торган яңа йолалар мәйданга чыкмый һәм халкыңа тугры хезмәт итә башламый торып, искеләрен ташлау мәгъкуль түгел. Мөхәммәд пәйгамбәр дә Ислам диненең йолаларын, асылда, үз кавеменең гореф-гадәтләренә нигезләнеп алга чыгарды. Ул гарәпләрне бары тик мәҗүсилектән һәм халкын үсештән тоткарлаучы гадәтләрдән генә арындырды дип бу урында әйтсәк, дөрес булыр. Чынлыкта да бу шулай иде. Әмма монафикъләр моны аңлаудан мәхрүм иделәр, үзләренә ныклы ышанган хәлдә, Бәдер сугышы алдыннан мөэминнәрнең таләп иткән солыхын да кабул итәргә теләмәделәр. Юкса, кан коюлар булмый каласы иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр корәишләргә, солых сорап, илче рәвешендә Җабир бине Мөттагимне күндерде. Ул, гаскәр арасына кереп, Әбу-Җәһил белән очрашырга һәм аны сугышның кирәксезлегенә инандырырга тиеш иде. Әмма бу тырышуларның файдасыз буласын, аларны яуга гына дәртләндерәсен уйга кертеп карамаган иде.

Корәиш арасына кергәч, Җабир бине Мөттагим, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләрен аларга җиткереп:

— И киребеткән халык, хәзрәтебез сезгә шуларны белдерергә боерды: һәркайсыбыз имин хәлендә кире үз шәһәрләренә кайтып китсеннәр, безгә сезнең белән кылыч күтәреп сугышуга караганда, бүтән кавемнәргә каршы яу туплап орышу дөресрәк һәм сөеклерәк, диде. Моны кабул итеп алыгыз, кан коюсыз гына таралышыйк,— дип, теләгән монафикъларга әйтте.

Хәким бине Хәзам, моны ишеткәч:

— Әй корәишләр, Мөхәммәднең сүзе дөрес, кабул итеп алыйк,— диюгә, аңа күз кырые белән сөзеп алган Әбу-Җәһил исә:

— Юк! Бу сүзен һич тә кабул итә алмыйбыз, максатыбыздан кайтмыйбыз, үч алмыйча торып, кире борыласыбыз юк! — дип кырт кисте. Шул рәвешле корәишләр солыхтан баш тарттылар.

Ике арада булган коедан мөшрикләрнең су алырга килгәннәрен күргәч, сәхабәләрнең гайрәте күтәрелеп, аларга комачауларга ниятләделәр. Әмма аларны Мөхәммәд пәйгамбәр туктатты һәм:

— Тимәгез, алсыннар, тоткарлык ясамыйк! — диде.

Хәбәрләрдән күренгәнчә, моның хикмәте бар иде. Кемнәр шушы коедан бу көнне су алып эчтеләр, алар Бәдер сугышында яки һәлак ителделәр, яки тоткын булдылар.

Мөхәммәд пәйгамбәр корәишләргә коедан файдаланырга юл куйса да, монафикълар бүтәнчә эшләргә уйладылар. Әсәд бине Габдел-әсәд Әл-Мәхзуми, берникадәр гаскәр белән күтәрелеп, мөселманнар эчә торган коены бозарга дигән ниятто килде. Сәхабәләрне сусыз калдырып, исәбе — араларына коткы салырга иде. Әмма аларны сизенеп алган Хәмзә, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлауга, кылычын күтәрде һәм мөэминнәрне әйдәп, өсләренә ташланды. Монафикъларны уңлы-суллы куа килеп, бәрелеш башланды. Әсәд бине Габделәсәд Әл-Мәхзумине шунда Хәмзә каршы алды, кылычка кылыч килделәр. Арада Хәмзәнең батырлыгы һәм гайрәте күпләргә мәгълүм иде. Монафикъ, хәтта башын иеп, аңа бирелсә дә мөмкин иде. Әмма ул үз көчен сынап карарга уйладымы, әллә инде җанын Лат һәм Гузза кебек потлары саклый дип ышандымы, гайрәтләнә бирде. Кылыч сугышы шаяртканны яратмый, шушы кое янында ул, үзенең канына укмашып, һәлак булды.

Бу вакыйгадан хәбәр алганнан соң, корәишләр мәсьәләгә башкачарак күз салдылар, сәхабәләр белән сугышуны уен бер эш кенә дип тәкәбберләнүләреннән арына төштеләр. Әүвәле мөселманнарның гаскәре хакында мәгълүмат тупларга уйлап, күрү һәм белешү максатында күзәтүчеләрне җибәрделәр. Бу әмергә Гамру бине Ваһһап Җөмахи күндерелде. Ул китергән хәбәрләр күп кенә билгесезлекләргә ачыклык кертергә тиеш иде.

Гамру бине Ваһһап мөэминнәрнең нинди көч белән килгәнлеген чамалаганнан соң, арада кемнәр барын да белергә уйлап, аларга якынрак килде. Шунда аның күзе буылдымы, әллә чыннан да бүтән бер серләр ачылдымы, таң-гаҗәепкә калды. Күзәтчелектән кайтканнан соң, мөшрикләр арасына кереп, аларга болар хакында хәбәр бирде һәм әйтте:

— Күрдем, Мөхәммәднең гаскәре өч йөз кеше, яки шуннан аз гына артыктыр, — диде. — Әмма мине хәйран иткәне шул булды, аларга якынаеп килдем, әүвәле дөяләреннән гайре һичнәрсә күземә чалынмады. Карыйм, анда кулларына кылычтан бүтән әйбер тотмаган бер кавем җансыз рәвештә басып тора иделәр.

Аның сөйләгәннәре күпләр өчен бер саташу һәм төш кебек аңлашылды. Шулай да араларына кергән ят бер кеше төсле барсын да шиккә калдырып хәвеф узды.

— Ул җансыз кавем миңа аждаһалар төсле карап калдылар, — дип Гамру бине Ваһһап сүзен житкерүгә, ул хәвеф аларның бәгырьләренә килеп ябышты. — Корәишләрнең һәлакәте шушындадыр, — дигән сүзен дә ишеткәч, Хәким бине Хизам, аларны ташлап, Гутбәт янына киңәшуңаш итәргә ашыкты.

— Минем теләгем шул, — диде Гутбәт, Хәким бине Хизамга, — бу кан коелудан корәишне ничек тә коткарып калырга кирәк.

— И Мәккәдәге данлы Әл-Вәлид кабиләсенең юлбашчысы һәм өлкәне, синең сүзеңне һәркем тыңлый, әйткәнеңә буйсына, әгәр дә кавемебезгә бер-бер яхшылык кылмасаң, аларны бәладән коткармасаң, мәңге дошманым булырсың! — диде Хәким бине Хизам.

— Нинди яхшылык соң ул? — дип аптырап калды Гутбәт.

— Гаскәр белән идарә итүне үз өстеңә аласың һәм барчабызны кире алып кайтасың. Безнең низагыбыз Мөхәммәд белән генә, ә аның яраннары белән түгел, — диде.

Гутбәт аның сүзен кабул итте һәм дөясенә атланды. Гаскәр уртасына кереп:

— И халык, сүзләремә колак тотыгыз, — дип үтенде. — Мөхәммәд һәм аның сәхабәләре белән сугышу безнең харап кына булуыбызга китерер. Бу кан коюю безнең өстебезгә мәңге юылмаслык гонаһлар салыр.

Мин шуны әйтергә телим: Мөхәммәднең сәхабәләре кырылмас, әмма дошманлыкны кеше үтермичә дә хәл итәргә мөмкиндер. Таләпләребезне аның каршына куеп, уртак бер килешүгә килүдән дә дөресе булмас. Мин беләм, сезнең теләгегез — аларның каны һәм маллары. Мин исә сезгә Мөхәммәднең каны өчен бәһасен бирәм, маллары өчен байлыгымны тапшырам. Шуның белән теләгегезне канәгатьләндерәм. Кан бәясен акча белән түләү мөмкиндер. Әгәр дә Мөхәммәд гади кеше генә икән, ул вакытта аңа җәзасын бирербез, әгәр дә инде пәйгамбәр икән, аңа каршы кул күтәрүдән безнең бәхетебез артмас, кадеребез генә кимер. Без бу сугышка чик куярга тиешбез, шулай һәлакәттән имин калырбыз,— диде.

Аның сүзләрен ишетеп алган Әбу-Җәһил тиз ара халыкны күздән кичерде һәм: «Әгәр дә болар Гутбәт әйткәннәргә колак салсалар, минем хөрмәтем бетәр, корәиш алдында ул олуг кылынып, һәммәсе аңа иярерләр!» — дип, күңелендә кузгалган көнчелек утыннан яна башлады. Монафикъларның игътибарын үзенә җәлеп итеп:

— Сез моның сүзләрен тыңламагыз, ул юри барчагызны да бутарга маташа! — дип кычкырды.— Аның улы да Мөхәммәд тарафында, сәхабәләр арасында. Шуңа күрә бу рәвешле сөйли. Улының үлеп калмавын тели,— диде.

Әмма Гутбәт куркып калмады, Әбу-Җәһилнең үзенә шунда ук турысын әйтеп салды:

— Ә син безнең һәлакәтебезне телисең!

Шушы рәвешле корәишләр гаскәре эчендә таркаулык һәм каршылыклар барлыкка килеп, бердәмлекләре бетә барды. Берәүләр Әбу-Җәһил сүзләренә кушылсалар, икенчеләре Гутбәт ягына авыштылар. Әмма мөселманнарның җиңәчәкләренә ышаныч юк иде. Меңгә якын монафикълар явына каршы өч йөзлек сәхабәләр гаскәре берни дә эшли алмый, үзләрен һәлакәткә генә китергәннәре көн кебек ачык төсле тоелды. Сан ягыннан өч тапкыр артык булган корәишләр, һичшиксез, көчлерәк шул. Җитмәсә, күбесе баштанаяк коралланган, кайсы дөя өстендә, кайсылары атка атланганнар. Һәр төркем гаскәриләрне кабилә башлыклары, сугыш уенында алны-артны белә торган аксөякләр җитәкли иде.

Ул көнне мөшрикләр ун дөя чалдылар. Гутбәт янына елмаеп килгән Әбу-Җәһил, йөзендәге газап һәм мыскыллану төсләрен яшерергә теләп:

— Йа Гутбәт, синең сихерең һавага очты,— дип көлә башлады.— Син бик тә куркак кеше икәнсең. Гаскәрең дә Гамр бине Әл-Хазармигә күчсен,— дип кылычын кынына җәһәт кенә тыкты да, атыннан төшеп, бу әмерен җиренә җиткерергә ашыкты.

Бу сугышта каршы яклар белән буталмас өчен мөшрикләр өч байрак күтәрделәр һәм аны гаскәр башлыклары янындагы гаскәриләргә тоттырдылар. Сәхабәләрнең дә шулай ук өч билгеле Байрагы бар иде. Аларның икесен Мөхәммәд пәйгамбәр әнсариларга бирде, берсен мөһаҗирләр тоттылар. Исламда беренче башлап күтәрелгән байрак ак төстә булды. Ул өч почмаклы итеп эшләнелгән һәм сөңге очына беркетелгән иде. Орыш вакытында менә шушы байракларга карап эш йөртергә тиеш иделәр. Аларның егылуы җиңелү билгесе булганлыктан, гайрәтле һәм ышанычлы кешеләр кулына тапшырылдылар.

Сугыш башланыр алдыннан Мөхәммәд пәйгамбәр гаскәрен бер эзгә тезде. Кулында таяк иде. Кемнәр алгарак чыктылар, шуларга таягы белән төртеп, бүтәннәр белән бер сафка басарга боерды. Әмма арадан әнсари Сәвад ике адымнан да күбрәк алга чыгып, сәхабәләрдән аерылып тора иде. Мөхәммәд пәйгамбәр аны күреп алды, күкрәгенә таягы белән төртте һәм:

— Урыныңа бас! — дип әмер итте. Әмма Сәвад:

— Йа Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, бу сугыштан миңа сагыш вә кайгы иреште. Аллаһы тәгалә сине үзенең хакыйкый пәйгамбәре итте. Үч алу тиешледер! — диде.

Әйткәннәреннән соңгы сүзләре Рәсүл Әкрамның бәгыренә килеп кадалды. Таяк белән орган өчен үчләшәдер дип уйлады. Бәрелеш алдыннан

бу рәвешле бозылышып китү бер дә урынлы түгел, бердәмлекне какшата гына иде. Әмма, була бит шулай, син бер нәрсә хакында уйлап сөйлисең, вакыт тарлыгы һәм күңел сагышлыгы аркасында ашыгасың, әйтеп тә бетерә алмыйсың, ә мөрәҗәгать иткән кешең бөтенләй башкача, икенче төрле аңлый. Шуннан аралар бозылып китә. Яратып һәм зурлап әйткәнне көлү һәм мыскыллау дип тә кабул итүе мөмкин. Монда да хәл шул рәвештәрәк килеп чыкты. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең мөбарәк күкрәген ачып җибәрде һәм:

— Ал үчеңне! — дип, Сәвадкә әмер итте.

Вакыйганы күреп торучылар эшнең яманлык белән бетәсен уйлап, пәйгамбәрне яклау өчен урыннарыннан кубарга да өлгермәделәр, Сәвад ул арада йөзен Мөхәммәд пәйгамбәрнең күкрәгенә китерде һәм үбеп алды.

— Син нигә болай эшләдең? — диде Рәсүл Әкрам, сәерсенеп.

— И Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре,— диде Сәвад, теләгенә ирешүенә сабыйларча сөенеп,— мин бу көндә, шушы сугышта үлемнән имин түгел. Гомеремнең ахырында җәсәдем изге тәнеңә кагылуны теләгән идем. Морадыма ирештем,— дип белдерде.

Шунда Мөхәммәд пәйгамбәр Сәвадкә атап хәер-дога кылды һәм барча сәхабәләргә мөрәҗәгать итеп боларны әйтте:

— Мин әмер бирми торып, кылыч сугышын башламагыз һәм кяферләргә һөҗүм итмәгез. Мөшрикләр сезгә якынайгач, алар өстенә ук атыгыз һәм һәрберегез һөҗүм итәчәк урынны билгеләгез, шуңа төбәп хәрәкәт итегез. Атылган угыгыз яки бер кешегә, яки аның хайванына тиярлек булсын. Җилгә очмасын. Хата ясамагыз. Аллаһы тәгалә хакы өчен дип әйтәм, минем рухым аның кодрәте кулында. Белеп торыгыз, сезнең бу сугышта берегез дә һәлакәткә очрамас, берегез дә мәңгегә үлмәс, дин өчен шәһит иteләсез икән, урыныгыз җәннәттә булыр. Аллаһы тәгаләнең хөрмәтенә һәм рәхмәтенә ирешерсез! — диде...

Гутбәт бине Рабигадан Әбу-Җәһил куркак җан дип көлгәннән соң, аның ачуы килде. Ничек тә бу сүзне юкка чыгарасы килде. шунлыктан сугыш мәйданына иң беренче булып ул атылды, янында улы Вәлид һәм дусты Шәйбә иделәр. Гутбәт үзе хәтта үлемгә дә әзер иде. Аның шушылай тәэсирләнүендә, әлбәттә, Мәккә халкы алдында дәрәҗәсен төшерәсе килмәүдән икәнлеген күпләр төшенмәделәр, эшнең асылын батырлыкта һәм сәхабәләргә дошманлыгында күрделәр. Сүзләре һәм гамәлләре капма-каршы булганлыктан, сәерсенүчеләр дә арада бар иде.

Хәким бине Хизам моны яхшы аңлаганлыктан, Гутбәтне тыярга тырышып карады, нәсыйхәтләр бирде, әмма файдасы тимәде. Ул гайрәтен сүндермәде. Җәяүле хәлендә сугышырга ниятләде. Дәрәҗә иясе аксөякләрнең иң мәртәбәләреннән саналганлыктан, аның урыны яуның уртасында түгел, бәлки гаскәр белән идарә итүдә иде, юкса.

Әбу-Җәһил ат өстенә атланган һәм саф-саф тезелгән корәиш сугышчылары янында калкулык сыйфатында күтәрелгән җирдә иде. Гутбәт бине Рабига шулвакыт аны күреп алды һәм:

— Бу көндә минем урыным монда түгел, бәлки гаскәр эчендә! — дип белдерде. Әбу-Җәһилгә үпкәләве шушы дәрәҗәгә җиткән иде ки, әгәр дә бүтән вакыт булса, алар хәтта дошманлашкан хәлдә бер-берсенә күтәрелеп тә карамас иделәр.

Әбу-Җәһил янына корәишләрнең барча аксөякләре һәм кабилә җитәкчеләре, яу башлыклары җыелды. Гутбәт бине Рабига аларга кушылмады.

Ул вакытларда, сугыш башланыр алдыннан, гаскәр каршына чыгарылып, һәр кавемдә һәм илдә таралган гадәт буенча, ике дошман якның да баһадирлары бергә-бер очрашып, үзара кылычка-кылыч килә торганнар иде. Гарәпләрдә дә бу тәртипне яхшы белә иделәр.

Гутбәт, Шәйбә, Вәлид, корәишләрдән өч кеше, гаскәр алдына чыгуга, сәхабәләрдән шулай ук көч сынашырга өч кешене чакырдылар. Аларның бу рәвешле эш итүләре алдан ук Әбу-Җәһил белән килешенеп куелмаган иде, моны алар өчесе генә белделәр. Гутбәт өчен үзенең куркак булмавын дәлилләүгә моннан да кулай мөмкинлек юк төсле күренде. Ул һәлакәткә ирешсә дә, исән калса да, барыбер, әмма Мәккә халкы каршында сөекле ителәчәген һәм вакыйгаларны бәйнә-бәйнә бәян иткәндә батырлыгын искә төшерәчәкләрен дә уйлый иде. Гутбәтнең, яу каршына барып, сәхабәләрдән баһадирларны таләп итүе асылда сугышны игълан кылуы икәнлеге аңлашыла торгандыр. Шулай итеп, яуны Мөхәммәд пәйгамбәргә каршы Әбу-Җәһил алып килсә дә, асылда Бәдер сугышын башлаучы Гутбәт булды.

Сәхабәләр ягыннан Мөгаз, Мәгуз һәм Гауф чыктылар. Ике як та җәяүле иделәр. Шунда монафикълар:

— Сез кемнәр? — дип сорадылар.

Аларга җавапларында мөселманнар үзләренең Мөхәммәд пәйгамбәр китергән дин Исламның тарафдарлары икәнлекләрен белдергәч, монафикълар моның белән генә канәгать булмыйча:

— Без сезне белмибез, сез безнең Мәккәдән киткән кешеләр түгел,— диделәр.

— Юк. Без Мәккәдән түгел, без — Мәдинә шәһәреннән,— дип, әнсарилар үзләрен белдергәч, кяферләр:

— Без Ясрип әһеле белән сугышырга дип килмәдек. Без сезнең белән дустанә яшәргә телибез. Без бары тик Мәккәдән качып киткән кан карендәшләребезне генә эзләп килдек. Аларга акыл биреп, кире шәһәребезгә алып кайтырга исәбебез. Сезнең белән сугышмыйбыз. Алар чыксыннар,— дигән таләпне куйдылар.

Әнсарилар үз урыннарына кире кайттылар. Мөхәммәд пәйгамбәр эшнең асылын төшенгәч, мөһаҗирләр арасыннан, корәишләрнең:

— Йа Мөхәммәд, безгә кан карендәшләребезне һәм белгән кешеләребезне чыгар,— дип кычкыруларына җавап итеп Хәмзәгә, Галигә һәм Гобәйдәт бине Әл-Хариска ишарә итте. Яу алдында кяферләр белән көч сынашырга шушы батырлар чыкты.

Ул вакытта Гобәйдәт бине Әл-Харис чәчләре агарган, әмма бәдәнгә шактый нык һәм егәрен саклаган, сиксән яшьләреннән узган кеше иде. Кяферләр әүвәле аны таныдылар, Хәмзә һәм Галине дә хуш күрделәр.

Гобәйдәт белән монафикълардан Гутбәт сугышырга булды. Хәмзәгә каршы шәйбә төште. Гали исә Вәлид белән көч сынашырга алынды. Орыш башланып китте.

Арада бигрәк тә монафикълардан Гутбәт бине Рабига оста сугышты һәм Гобәйдәтне шактый күп яралады. Әмма Хәмзә белән Гали үзләренең көндәшләренә аяусыз булдылар. Шәйбә дә, Вәлид тә баһадирлыкта алардан кайтыш иделәр. Гали, кылычы белән кизәнеп, Вәлидкә кискенкискен хәрәкәтләр белән сукты, уңга-сулга күчеп-күчеп йөрде һәм, ахырда, аны шактый куркуга салып, каты яралады. Вәлид шунда Галинең кылычыннан һәлак булды. Шәйбә дә Хәмзәгә каршы озак сугыша алмады. Ул да үлемен тапты. Шунда Гали белән Хәмзә ашыгыч рәвештә Гобәйдәт бине Әл-Хариска ярдәмгә ташландылар. Аның каты яралanудан иңбашы өзелеп төшә язган иде инде. Әмма ныклыгы белән генә Гутбәткә бирешмәде. Өлгер Гали һәм батыр Хәмзә курку хисен оныткан монафикъ Гутбәт бине Рабиганы кылыч белән кадап үтерделәр, яраннары Гобәйдәт бине Әл-Харисны күтәреп, сугыш мәйданыннан алып чыктылар. Ул инде хәлсезләнгән, күп кан югалтудан йөзе агарган һәм үзенең үләсен аңлаган иде. Аны Мөхәммәд пәйгамбәр янына китереп, җиргә салдылар.

Тәнендәге яраларының күплегенә һәм киеме кан белән укмашуга да карамастан, Гобәйдәт бине Әл-Харис елмая иде. Мөхәммәд пәйгамбәр аның янына тезләнде. Яраларына саклык белән генә кагылды. Шунда батыр картлач:

— Иншаллаһ, без жиңдек! — диде.
Аңа җавабында Мөхәммәд пәйгамбәр дә:
— Иншаллаһ, аларны җиңәчәкбез! — дип белдерде.
— Йа Мөхәммәд, Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, мин шәһитме, мин шәһитләр исемлегенә керерменме? — диде, хәлен тәмам югалта барган Гобәйдәт бине Әл-Харис.
— Әйе, син — шәһит, син — җәннәтле! — дип пәйгамбәребез белдерүгә, авыр яраларының әрнүеннән узып, Гобәйдәт бине Әл-Харис тыныч елмаю белән йөзен нурландырды. Бу аның өчен һәлакәт түгел, бәлки мәңгелек бәхеткә ирешү мизгеле иде.
Шуннан соң ул вафат булды. Мөселманнар арасыннан Бәдер сугышында беренче булып, вакыйгадан күренгәнчә, Гобәйдәт бине Әл-Харис шәһит китте.
Бәрелеш башланып, монафикълар үзләренең күплеге һәм баштанаяк коралланган булулары сәбәпле, сәхабәләрне кысрыкларга, каннарын коярга тотындылар. Берничә мөселманның һәлак булганлыгын күреп, йөрәге әрнегән Мөхәммәд пәйгамбәрнең кайнар күз яшьләре бәреп чыкты. Шунда ул кыйбла тарафына борылды һәм, тезләренә авып, дога кыла башлады. Шулкадәр кулларын күтәрде ки, хәтта култыклары күренде, аркасыннан чапаны шуып төште.
— Йа Рабби, бу җәмәгатемне кырдырасың, җир йөзендә Сиңа гыйбәдәт кылучы һичкем калмас. Үзең ярдәм бир! — дип ачынды Мөхәммәд пәйгамбәр шушы догасында.
Бу хәленнән вә сүзләреннән җир-күкләр тетрәрлек иде.
Әбу-Бәкернең моңа күңеле сагышланып китте, пәйгамбәрнең шушы кадәр дә борчылуы һәм өммәтләре өчен кайгыртуыннан аның да күңеле тулды. Ул, иелеп, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең чапанын җирдән күтәрде һәм аркасына ябып, җилкәсенә уң кулын куйды да:
— Йа Мөхәммәд, Аллаһы тәгалә үзе вәгъдә иткәннәрне бирер, кавемең өстен чыгар,— диде һәм аның алдында тезләнеп, күкрәгенә башын салды.
Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр тыныч кына урыныннан кузгалды, үзенең чатырына китеп, анда бераз вакыт дөньялыктан югалып утырды. Аңа мондый вакытта комачауларга һичкем кыймый иде. Сугыш үзенең дәһшәтле уенын дәвам итте. Корәишләр бар көчләренә мөселманнарны әле кысрыклап килделәр, әле буталыштылар, кабаттан һөҗүм ясадылар. Бу вакыйгаларга күз салып торган кешеләр монафикъларның никадәр миһербансыз икәнлекләрен күрә алыр иделәр. Әмма сәхабәләрдән кеше күләме һәм корал ягыннан шактый өстен булуларына карамастан, аларда рухи егәр ул кадәр үк мактанырлык түгел иде.
Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы Тәгаләдән хәбәр алды. Шуннан соң урыныннан кузгалды. Әбу-Бәкер янына килде. Сәхабәләрнең кан коюларына, бер-бер артлы корәишләр кылычыннан һәлак булуларына ачынуына карамастан:
— Бу сугышта мөселманнар өстен чыгар, вәгъдә шулай иреште,— дип белдерде.
Әмма Әбу-Җәһил җиңеп килә иде. Әгәр дә сугыш шушы рәвештә дәвам итсә, әлбәттә мөэминнәр кырылып бетәчәк, Ислам харап булачак икәнлеген Әбу-Бәкер аңлап, ни кылырга, ни нәрсә эшләргә белми аптырап, сагышлы күзләрен Мөхәммәд пәйгамбәрнең мөбарәк йөзенә текәде. Гүяки алар икесе бер бөтен кебек иделәр. Шунда пәйгамбәребез үзенең тугры дустына хәбәр бирде:
— Йа Әбу-Бәкер, миңа Аллаһы тәгаләдән шул иреште: мең мәләкфәрештә белән Җәбраил фәрештә гаскәребезнең алгы ягына саф булып тезелде, тагын да мең мәләк белән Исрафил фәрештә сәхабәләрнең уң ягына, Микаил фәрештә шулай ук мең мәләк белән сул якка килеп бастылар!

Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр кулы белән иелеп, бер уч ком алды һәм, гүяки мәләкләргә әмерен җиткереп, шул комны корәишләр гаскәренә таба атты да:

— Шәһитләр каны өчен!..— диде.

Аның бу сүзләре үч алу таләбе буларак яңгырады.

— Мөселманнарга ярдәмгә ашыгыгыз! — дип фәрман бирде.

Бу вакытта сәхабәләргә каршы атылган Хәким бине Хизам һәм аның иңдәшләре курка калдылар. Мөхәммәд пәйгамбәрнең бер уч комы аларның өстенә тимер ләгәнгә шалтырап төшкән ташлар шикелле коелды, ул да булмады, тагын да ят авазлар ишетелеп, кемнәрнеңдер көрәшкә ташланганы аңлашылды. Бу исә сәхабәләр белән бергә мәләкләрнең дә монафикъларга каршы сугышка керүеннән шулай булды. Ахырдан, шушы вакыйганы исенә төшереп, Хәким бине Хизам:

— Ул вакытта, без боларны ишетеп һәм күреп, тәмам хәвефкә төштек,— дип сөйләгәне тарихлардан мәгълүм.

Нуфал бине Мөгавийә дә, аның сүзләрен раслап:

— Ул вакытта безнең артыбыздан тавышлар ишетелде, кемнәрнеңдер өстебезгә ташлануы күзгә чалынып китте. Шул сәбәпле барчабыз күңеленә курку керде, хәвефебез дә шуннан иде,— дип әйткәнен яза борынгы китаплар.

Ни генә димәсеннәр, әмма корәишләр шушы Бәдер сугышында, инде сәхабәләрне җиңеп килгән вакытларында, болытлар арасында саф-саф тезелеп торган һәм хәрәкәткә килгән гаскәрләрне күрделәр. Бу хәбәрләргә аңлатма таба алмаган тарихчылар моны мираж дип белдерү ягында торалар. Күк йөзендә билгесез гаскәрләрнең күренүен асылда һичбер галим дә инкарь итми, хакыйкатьтә шулай булган дип язалар, әмма сәбәпләрен генә төрлечә аңлаталар. Сугышта катнашкан ике яктагы гаскәриләр дә аларның мәләкләр икәнлеген белдерәләр, Коръәндә дә аның шулай икәнлеге әйтелә. Үзебез күрмичә, моның асылын аңлатуга алынмастан, вакыйгаларны үз тәртипләре белән язуга күчик.

Бәрелеш вакытында, бу сүзләрне тарих өчен Гали бине Әбу-Талип сөйләгән, диләр. Өч тапкыр кискен җил исте. Әүвәле чыккан җил мөселманнар өстеннән узып китте һәм мөшрикләрнең гаскәре өстенә ташланды, араларында уйнап, күпләренең күзләренә ком һәм чүп кертте, кайберләрен әйләндереп салды, акылларын буды, болары белештермичә калдылар һәм үз иптәшләренә кылыч белән ордылар, кайсыларының бу җилдән аяк-куллары тораташ булды, алар бау белән богаулангандай үзләрен хис иттеләр. Бу җил уңаена барган бөтен сәхабәләр кинәт кенә, аз санда булуларына карамастан, һөҗүмгә күчеп, корәишләрне чигендерделәр. Моңа кадәр җиңеп килгән кяферләрнең бу рәвешле артка китүләренә сөенгән мөселманнар тагын да гайрәтләнделәр. Әмма җил үтеп китте. Монафикълар бу хәлдән айнып, тагын сәхабәләрне кысрыклый башладылар. Шунда кабат җил уянды. Мөселманнарның сул тарафыннан килеп, корәишләргә яннан орды. Күзләренә тузан һәм ком кисәкләре тутырды, әүвәлгедәгечә аларның арасында буталыш тудырып, берсен икенчесе белән сугышырга этәрде. Кемнәр артларыннан килүче монафикъларның сөңгеләренә кадалдылар, кайсылары исә ялтыраган кылыч йөзеннән җәрәхәтләнделәр. Моннан файдаланырга өлгергән сәхабәләр корәишләрне сул тарафтан кысрыкладылар. Монафикъларның кайсыберләре хәвефкә төшеп, сугыш кырын ташлап качу ягын карады. Әмма бу җил дә узып китте. Корәишләр тагын үз сафларын тәртипкә салып, һөҗүмгә күчтеләр. Аяусыз һәм канлы орыш дәвам итте.

Сулдан искән кискен җил Микаил фәрештәнең мәләкләр гаскәре дип гоман кылына.

Сәхабәләрнең кабат чигенүләре башлангач, көтелмәгән җирдән тагын җил чыгып, корәишләрне уң яктан килеп болгатты. Бу юлысы да әүвәлге икесе төсле вакыйгалар булып, мөселманнар алга ыргылдылар.

Хәбәрләрдән тагын да шул билгеле: монафикълар яу белән чыкканда Әл-Әсрак алар белән барырга теләмәде, Мәккәдә калды. Соңыннан килеп сорадылар:

— Син нигә гаскәрдән качтың? — диделәр.

Ул шунда ук аклануга сәбәп тапты һәм:

— Мин бит белми дә калдым,— диде. Әмма аңа ышанмадылар. Чөнки корәишләр арасында, аңа кадәр күренмәсә дә, Бәдер сугышында Әл-Әсрак бар иде. Алар өстенә әүвәл мәртәбә җил ташлангач, ул юкка чыкты. Аннан тагын кайдандыр пәйда итте дә:

— Курыкмагыз, мин сезнең белән! — дип аларны сугышка дәртләндерде. Ә аннан соң тагын югалды.

Ә моның сәбәбе шул иде, диләр... Бәдер сугышында Шайтан ләгыйнь монафикълар тарафыннан торып, сәхабәләргә каршы сугышырга булды. Әл-Әсрак кыяфәтенә кереп, алар арасына төшеп катышты. Гайрәттә аның белән тиңләшерлек зат юк иде. Әмма шулвакыт ул күктән килеп, монафикълар өстенә Җәбраил фәрештә җитәкчелегендә мәләкләрнең һөҗүм иткәнен күреп алды. Тиз генә аларга арты белән борылды, чөнки үзен танып алырлар да, Җәбраил фәрештә аны богаулап, халык алдында фаш итәр дип курыкты, качу ягын карады. Бу мәләкләр кемне богаулап, кайсын һәлакәткә китереп узгач, кабаттан корәиш арасына керде һәм шунда ике тарафта да мәләкләр гаскәре сугышка әзер торганлыгын күргәч, тиз ара таю ягын карады. Суратткә Әл-Әсрак кыяфәтле булганлыктан, корәишләр аны Шайтан дип уйламадылар. Шунлыктан, Мәккәгә кайткач, Әл-Әсракны куркаклыкта һәм сатылуда гаепләделәр. Бичара: «Мин анда булмадым, сугышта катнашмадым!» — дип, никадәр генә акланып караса да, файдасы чыкмады. Монафикълар арасында абруен югалтты. Юкса гаебе гаскәргә иярмәвендә генә иде.

Вакыйгалар тагын да шулай сөйләнелә: әйтерләр, Әл-Әсрак сурәтенә кергән Шайтан ләгыйнь, күктән иңеп килгән Микаилнең гаскәрен күрде, Җәбраил фәрештәне арттан килер дип уйлады һәм корәишләргә:

— Исән чакта качыгыз, бу сугышта сәхабәләрне җиңәр өчен мәләкләр ирек бирмәс! — дип лаф орды.

Аның сүзләрен Әбу-Җәһил ишетеп алды, хәвефкә төшкән монафикъларына:

— Әл-Әсракның сүзен тыңламагыз, ул Мөхәммәд яклы, Гутбәт, Шәйбә һәм Вәлид каны өчен үч алыгыз, курыкмагыз! — дип кычкырды.— Моннан бер адым да чигенмәгез, үзегезне аямагыз, ирләр булыгыз. Мөселманнарны җиңәрбез, әсир итеп, богаулап, Мәккәгә алып кайтырбыз, малларын тартып алырбыз. Һәрберегез бай һәм тыныч яшәр. Һәркемгә гыйбрәт булыр, моннан соң һичкем динегездән көлмәс, үзегезне хурламас. Сабак булыр. Арадан беркем дә пәйгамбәрлек дәгъва кылмас, динегездән, ата-баба гадәтеннән аермас,— диде.

Шушыларны Әл-Әсракның үзенә мисал итеп сөйләгәч, болар бичараның акылына сыймады. Бөтенесен инкарь итте. Ахырда Әл-Әсрак кыяфәтендә Шайтан ләгыйньнең гаскәр эчендә йөргәнлеген гоманладылар. Шул көндә Әл-Әсрак Исламга күчте һәм иман китерде.

Ул мәләкләрнең чапан чалмалары кызыл, яшел һәм сары төстә, атланган атлары нурдан иде. Өзәнгеләрен тешләп чаптылар. Әгәр дә бер мөселман икенче бер кяфер белән кылычка-кылыч килеп сугышкан очрак туры килсә, ул мәләкләр шул кяфернең муенына ордылар, башлары иярләренә салынып төшә барды.

Заманалар үтеп, Сәһл бине Гамру алдында иман китергән Әбу-Әсәд исемле кемсәнәдән сорады:

— Син ни өчен Исламга керергә булдың, бер-бер гыйбрәтле хәбәрең бармы? — диде.

Әбу-Әсәд үзе Бәни-Гаффар кабиләсеннән иде. Бу кавем Бәдер тирәсендә гомер кичергәнлектән, корәишләр белән сәхабәләрнең сугышын үз күзләре белән күреп белә иделәр.

— Минем гыйбрәт итеп әйтер сүзем бар,— диде җавабында Әбу-Әсәд.— Мөхәммәд пәйгамбәрнең Бәдер сугышына шәһитларының берсемен. Рөхсәтегезгә күрә, сөйләр сүзем бар,— дип үтенде.

— Тыңларбыз,— диде Саһл бине Гамру.

— Мин агамның улы белән бергә идем,— дип сүзен башлады Әбу-Әсәд Әл-Гаффари, йөзенә сагыш томаны, күзләренә яшьле дым капланып.— Бу вакыйга шул сугыш көнендә булды. Әйткәнемчә, агамның улы белән бер калкулык башына мендек. Сәхабәләр илә корәишнең бәрелешүен карый идек. Безнең артта гына, көтелмәгән җирдән, олы кара болыт пәйда булды һәм Бәдер тарафына хәрәкәт итә башлады. Нәкъ өстебездән узганда:

— Ашыгырга кирәк, ашыгыгыз! — дигән авазны ишеттек. Болыт арасыннан нурлы ат башлары, сары, кызыл, яшел чапаннар чагылып китте. Кинәт җил чыкты. Ул, минем агамның улын аягыннан егып, аны һәлак итте. Үзем дә үлемнән чак-чак кына имин калдым. Тиз ара үтеп китмәсәләр, котым алынып, мин дә шунда үлеп, харап буласы идем. Бу болыт мөселманнар тарафына юнәлде, аннан килеп, корәишләргә ташланды. Атлары кешни, тимерләре шалтырый иде. Уйладым: бу кадәр дә җитез булырлар икән! Кяферләрне Аллаһы тәгалә сукты, дидем...

Әйтерләр: Әбу-Әсәд сөйләгән бу болыт мәләкләрнең гаскәре иде һәм алар Мөхәммәд пәйгамбәргә ярдәмгә ашыктылар.

Тагын шундый бер вакыйганы Мөхәммәд пәйгамбәргә килеп сөйләделәр. Аны әнсарилар китерде. Берсе әйтте:

— Кяферләр белән сугышканда корәишнең артына төштем, ул куркып кача башлады. Уңга китеп, кылычын миңа орды, сулга сикереп, тагын гайрәтен күрсәтте. Елгырлыкта һәм көчтә миннән өстен иде. Хәйлә кыладыр дип уйладым. Хәзер ул мине һәлак итәр, дидем. Әмма шулвакыт каяндыр ат пошкырган тавыш ишетелде, чыбыркысы яшендәй шартлады һәм кяфергә бәрде. Монафикъның күзе бәйләнде, тәне катып калды. Һәлакәтен тапты,— диде.

Боларны ишеткәч, Мөхәммәд пәйгамбәр, серне ачарга, аптырап калган әнсариларны тынычландырырга ашыкты. Чөнки билгесезлек файдага түгел иде.

— Аптырамагыз, бу мәләк гаскәрләренең монафикъларга каршы көрәшенең мисалдыр,— диде ул.

Бераздан Габдеррахман бине Гауф сугыш эченнән бер әсирне Мөхәммәд пәйгамбәргә китерде һәм:

— Мин бер тоткынны чыгардым, әмма кемнекедер, белмим,— диде.

Билгеле, кешенең әсирен үзенә нисбәт итү бүтәннең малын үзләштерү белән бер иде. Мөхәммәд пәйгамбәр мәсьәләне урында чишәргә тиеш тапты һәм, корәишне танып алып:

— Әй, Әбу-Хәбәш, сине кем әсир итте? — дип сорады.

Әмма бу туры җавап бирергә теләмәде, чөнки күп нәрсәне үзе дә аңышмыйча калган иде:

— Белмим,— дип кенә әйтә алды.

Мөхәммәд пәйгамбәр шунда:

— И, Әбу-Хәбәш, сине бер мәләк әсир итте һәм богаулады,— диде дә, Габдеррахманга карап: — Әй, бине Гауф, ал әсиреңне, тезеннән күтәр,— дип боерды.

Бу тоткын Габдеррахманга булды. Соңыннан, Әбу-Хәбәш, курыккан күңеле тынычланганнан соң, син ничек әсир төштең дигән сорауларга туры җавап бирде һәм боларны сөйләде:

— Корәишләр җиңелә башлап, чигенергә һәм качарга тотындылар. Мин дә алар белән бергә идем. Кинәт җир белән күк арасында нурдан бер ак ат өстендә гаскәри күренде. Ул миңа туры төште. Бәйләп тә куйды. Мин хәрәкәтсез калдым. Шунда безне куа килүче мөселманнар күренде. Габдеррахман бине Гауф үземне күреп алды һәм кычкырып:

«Сине кем әсир итте?» — диде, богауларыма күрсәтеп. Җавабым юк иде. Ул тагын кычкырды: «Бу кемнең әсире? Аны кайсыгыз тотты?» — дип. Һичкем белмәде. Габдеррахман бине Гауф үземне Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына китерде, ничек табуын әйтте. Сорадылар, җавап бирә алмадым, хәтерем адашкандай, телем тотылгандай булды. Пәйгамбәр исә эшнең ничек булганлыгын шунда ук ачып салды.

Кайбер сәхабәләр сугыштан соң шулай сөйләделәр:

— Без үзебезне аямыйча орышка кердек. Кайсы кяфергә куллдагы кылычыбыз белән орырга талпынсак, сукмастан әүвәл аларның башлары киселеп төшә барды,— диделәр.

Бәдер сугышында Әбу-һәрирә өч монафикъның башын чапты. Әмма аларның соңгысы ул кизәнгән вакытта ук башсыз калды. Әбу-һәрирә бары шуны гына күрергә өлгерде: кótелмәгән җирдән ак атта бер зат пәйда булды, гайрәткә һәм көчкә өстен корәишнең башын чабып, юкка чыкты. Бу вакыйга Әбу-һәриранә аптырашта калдырды. Кяфернең башын табып, аны чәчләреннән күтәрде һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең каршысына китереп:

— Мин сугышта өч корәишнең башын чаптым, әмма монысын үтерүдә катнашым булмады дип әйтсәм дә мөмкин,— диде Асыл вакыйганы пәйгамбәргә бәян итте.

— Бу — фәрештә-мәләк эше, ул сиңа ярдәгә килде, юкса үзең харап буласы идең,— диде аңа аңлатып Мөхәммәд галәйһис-сәлам.

Хәбәрләрдә шулай сөйләнелә: Бәдер сугышында, Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән, мәләкләр кеше сурәтендә дә мөселманнар гаскәрләре арасына керделәр. Сәхабәләр аларның кемнәр икәнлеген белделәр һәм рухи күтәренкелек тоеп, монафикъларны җиңәргә атлыктылар. Ул фәрештә-мәләкләр гаҗәеп дәрәҗәдә гүзәл кыяфәттә иделәр. Әмма бу хакта бүтәнчә дә белдерүчеләр бар. Аларның раславынча, мәләкләр шушы сугыш башында һәлак ителгән сәхабәләрнең сурәтләренә кереп, алар булып та көрәштеләр. Аларга корәишләрнең көчләре җитмәде, диләр.

Бәдер сугыш 624 нче елның март урталарында мәйданга чыкты. Ул вакытта гарәп чүлләре өстендә болытлар куерган чак иде. Ни хикмәт, бәрелештә катнашкан күпләр Җәбраил фәрештәне яшел чалмадан, үзенең Хәйзум исемле атына атланган хәлдә болыт арасыннан карап торганын күрделәр. Вакыйгаларны тасвирлаучылар шулай диләр, сәхабәләр монафикъларның өстенә ташлангач, Җәбраил фәрештәнең: «Хәйзум, алга!» — дигән тавышы гаскәриләр баш очында кат-кат ишетелгән. Бүгенге көн күзлегеннән чыгып боларны ничек аңлатырга буладыр, ул кадәресен белмим.

Гобәйдә, Гали һәм Хәмзә баһадирлар корәишләрдән Гутбәт, Шәйбә һәм Вәлидне җиңгәннән соң, сугыш кыры мөселманнарның шатлык авазлары белән тулды. Һәркем тантана итте. Бераз курка калган корәишләрнең җитәкчеләре беренче башлап ук-җәяләрен кордылар, сәхабәләр өстенә укларын яудырырга гаскәргә әмер бирделәр. Шулай итеп, сугыш ике якның да бер-берсенә ук атуыннан кызып китте. Мөселманнар: «Бергә! Бергә!» — дип һөҗүм иттеләр, бигрәк тә мөһаҗирләр, электән калган ачуларын исләренә төшереп һәм Мәккәдә алган җәбер-золымнарга җавап буларак, аяусыз сугыштылар. Әнсарилар алардан калышмаска тырыштылар. Бер дөягә җиде-сигез кеше чиратлашып утырып килгән, ярымйорты коралллы мөселманнар гаскәренең рухы нык иде.

Монафикълар мөселманнарның өстенә кыргый тавышлар чыгарып ташландылар. Арада Гасим бине Гауф үтә дә гайрәт күрсәтте, сыртлан кебек үрле-кырлы сикерде. Нияте — күп кенә сәхабәләрне һәлак итеп, малларын үзенә алу иде. Чөнки корәиш арасында кем ничек сугышуга карап ганимәт малын бүлешү тәртибе бар иде. Җитмәсә, Гасим үзенең каты тавышы белән кычкыра бирде:

— Әй, корәишләр, мин мөселманнарны кырып бетермичә, аның үзен әсир итеп алмыйча бер адым да чигенмәм!

Мөхәммәд пәйгамбәргә кул сузарга теләге бар икәнлеген сүзләрен ишеткән һәркем аңлады.

— Мин аны үтерермен, яки шушы юлда үзем һәлак булырмын! — дигән җикеренүләре әледән-әле кабатланып торды.

Шул вакытта бу мәлгунь сәхабәләрне шактый яраларга өлгерде, әнсарилардан Әбу-Диҗанә белән кылычка-кылыч очрашты. Һаман да шул сүзен гайрәт илә теленнән төшермәде:

— Мин ул пәйгамбәрегезне катил итәрмен...

Әбу-Диҗанә аңа сүзен тәмамларга ирек бирмичә, кылычы белән орды. Бу юлысы сыртлан сыман гайрәт чәчкән Гасимның теле киселгәндәй булды. Әбу-Диҗанәнең кылычы аның җанын кыеп үтте һәм ул атыннан асылынып төште. Тиз ара Әбу-Диҗанә аның атындагы әсбабларын үзенә алырга ниятләде. Бу теләгән җиренә җиткерим дигәндә, аңа Мөгбәд бине Ваһһап һөҗүм итте. Кылычы белән айкап сукты. Әмма Әбу-Диҗанә бирешмәде. Монафикъ тагын сукты һәм тезләренә килеп төште. Тагын күтәрелде, берничә тапкыр кылычы белән әнсарига орды. Әмма көче китте. Бәрелешү кабатланды. Бу юлысы Әбу-Диҗанә тезләре белән килеп төште. Ачуы кабарып, сикереп торды һәм Мөгбәдкә бер-бер артлы кылыч белән ора башлады. Тик аны җиңә һәм аңа яралар сала алмады. Шулай да монафикъ курка калды. Борылып йөгерде. Әбу-Диҗанә моның артыннан төште. Теге кая качарга да белмәде. Бер сулы җир күреп, шунда таба йөгерде. Килеп җиткәч, тукталып калмыйча, шул сулыкның уртасына ук кереп китте. Ул элекке кое урыны иде. Шунда качып котылырга уйлады, әмма Әбу-Диҗанә аның өстенә кылычын ташлап, шунда үтерде.

Мөхәммәд пәйгамбәргә күп җәбер-золымнар салган кешеләрнең берсе Нуфал бине Хувайлид иде. Шунлыктан бу сугышта Рәсүл Әкрам, бу кешенең һәлакәтен теләп, бер дога укыды.

Нуфал бине Хувайлид исә әнсарилардан Җаббар бине Сәхар бине Өммийәгә әсирлеккә төште. Әүвәле алар орыштылар, әмма корәишләр качып, Нуфал бине Хувайлид үзләренең җиңелгәнлеген аңлады һәм Җаббарга:

— Зинһар, әнсари, син безнең белән сугышма. Без монда әнсарилар белән орышырга дип килмәдек. Мәккәне ташлап качкан Мөхәммәднең яраннарын акылга утыртырга гына теләдек. Сезнең белән безнең арада һичбер дошманлык юк. Син мине үтермә, әсир ал,— дигән сүзләрен теленнән төшермәде,— минем канымны туганнарым дөя биреп, байлыкларын сарыф итеп, кире сатып алырлар,— дип вәгъдәләр кылды. Аның сүзләренә Җаббар биреште, малына кызыкты һәм Нуфалны әсир хәлендә үзенең чатыры янына китерде. Әмма шулвакыт Гали сәхабә бу тарафка ашыгып килә башлады. Нуфал аны күреп алды да:

— И туганым әнсари, бер кешене күз уңыма алдым, монда ашкына, теләге минем җанымны кыюдыр,— дип әйтергә-үгетләргә тотынды.

— Ул кем? — дип сорады Җаббар, моның куркаклыгын күреп.

— Гали бине Әбу-Талип,— диде Нуфал бине Хувайлид.— Кавемемне аннан да күп кырган кешене күрмәдем.

Шунда Гали аның янына килеп җитте һәм кылычы белән орды. Әмма Нуфал бине Хувайлид кулына калкан алып, шуның артына качарга өлгергән иде. Галинең кылычы аңа зыян итмичә, калканына кереп кадалды. Нуфал моңа сөенеп өлгергәнче, Гали кабаттан кылычын күтәрде һәм аны чабып үтерде. Мөхәммәд пәйгамбәр янына китте.

Рәсүл Әкрам һәммәсеннән сорады:

— Нуфал бине Хувайлидның харап булуын теләп дога укыган идем, ничек үлгәнен күрмәдем. Кайсыгыз белә?

Шунда Гали бине Әбу-Талип:

— Аны мин кылыч белән чабып үтердем! — дип җавап бирде.

Бу хәбәрне ишеткәч, Мөхәммәд пәйгамбәр шунда тәкбир әйтте һәм:

— Әлхамдүллиллаһ, Аллаһы тәгалә минем догамны кабул итте,— дип белдерде.

Хәбәрләрдән шул билгеле, бу көндә корәишләр гаскәреннән житмеш кеше һәлак ителде һәм житмеше әсир төште. Шуларның утыз алтысын Гали бине Әбу-Талип сәхабә бер үзе үтерде, шулар исәбендә данлыклы һәм аксөяк гарәпләр күпчелеген тәшкил итә иде. Аның курку белмәс батыр йөрәге һичкемне аямады, Мәккәдә күрелгән газаплары өчен үчен кайтаруы шушы иде.

Бәдер сугышында һәлак ителгән кешеләрнең берсе Өммийа бине Халәф иде. Аның улы да шунда үтерелде. Бу вакыйга мөһажирләрдән Габдеррахманның күз алдында булды. Ә алар Ислам диненең ирешкәненә кадәр, җәһәлият заманында бик тә якын дуслар иделәр. Әмма Габдеррахман иман китерде, Өммийат бине Халәф исә мәҗүсилектә кяфер хәлендә калды. Габдеррахманның исеме әүвәле Габдегамру иде, Мөхәммәд пәйгамбәр аңа бу исемне йөртү дөрес түгел дип үзгәртеп куşты.

Көннәрнең берендә Мәккә урамында элекке яхшы дуслыклары бозылган Габдеррахман белән Өммийат очраштылар. Алар бер-берсеннән канәгать түгел иделәр. Өммийат:

— Мин сиңа Габдеррахман дип эндәшмәм, чөнки ул рәвешле Исламда гына сөйләшәләр. Син атаң кушкан исемне боздың. Мин сине башкача атармын!—диде.

— Әгәр дә шулай уйласаң, теләгәнеңчә эндәш,—дип үзенең ризалыгын бирде Габдеррахман. Ни дисәң дә, элгәрерәк алар бик якын дуслар иде шул.

— Рахман дип әйткәнче, Габдел-илаһ диярмен!

Өммийат бине Халәфнең теләге Габдеррахман белән килешү иде. Шул сөйләшүдән соң Габдеррахманны Габдел-илаһ дия башладылар. Әмма аларның дуслыгы дошманлыкка да әверелмәде, кабаттан да тергезелмәде. Өммийат никадәр генә үгет-нәсыйхәтләр биреп, Исламнан чиктерергә теләсә дә, Габдеррахманның рухы нык булу сәбәпле, дусты сүзләренә буйсынмады.

Өммийат бине Халәф Мәккә монафикълары арасында иң усал кемсәнәләрнең берсе булып, инде сурәтләп үткәнебезчә, үзенең колларына, бигрәк тә Билалга гаять тә миһербансыз иде. Әгәр дә Әбу-Бәкер иманы камил Билалны бу бәладән йолып алмаган булса, эшнең нәрсә белән бетәчәген күз алдына китерүе авыр түгел.

Бәдер сугышында корәишләр җиңелеп, кайсы-кая качарга тотынгач, Өммийат бине Халәф үзенең улы Гали белән сугыш кырыннан чыкты. Бу вакытта мөһаҗир Габдеррахман, кулына корәишләр ташлап калдырган сугыш киемнәреннән колчыга һәм җөбәләрне җыеп, үз җаена кайтып килә иде, боларны күреп алды. Бу очрашуга сөенгән Өммийат бине Халәф:

— Син мине, Габдел-илаһ, берүк кенә шушы һәлакәттән коткара күр, әсирең итеп ал. Юкса бүтәннәргә очрап, алар үтереп ташларлар. Ал безнең дә сугыш киемнәрен. Үзеңә булсын. Бары тик ярдәмеңнән генә ташлама,—дип үтенде.

Габдеррахман үзенең хәтерен яңартып, әүвәлге дустын ташламаска булды.

— Ярар, сез минем әсирләрем иткелерсез,—дип, киемнәрен салдырыр өчен икесенең дә беләкләренә ябышты. Әмма көтелмәгән җирдән Билал килеп чыкты һәм әнсарилар тарафына борылып:

— Монда Исламның явыз дошманы!—дип, Өммийат бине Халәф һәм улы Гали тарафына күрсәтте. Бу вакытта мөселманнар алынган әсирләр арасыннан үзләренә күп җәберләр кылган монафикъларны эзләп табып, аларны кылыч аша уздыра, җаннарын җәһәннәмгә җибәрә иделәр.

— Әй, әнсарилар, Мөхәммәд пәйгамбәрнең гаскәре, сезнең каршыгызда мөшрикләрнең явыз рәисе, күрәсезме! Әгәр дә бу бәдбәхет җир

йөзендә яшәсә, миңа монда урын юк, мин яшәмәм! — дип, Билал бүтән сәхабәләрнең дә җыелышып килүен таләп итте. Кан үченнән кызган мөселманнар Өммийатка таба кылычларын ялтыратып йөгерештеләр. Килеп җитүгә, тураклап ташлыйсылар иде, аларга Габдеррахман каршы төште, ничек тә Өммийат бине Халәф белән улы Гали бине Өммийатны саклап калырга, үтертмәскә тырышып карады. Аларның кулларыннан тоткан хәлендә, сәхабәләргә:

— Тимәгез, тимә! Болар минем әсирләрем! — дип үтенде. Әмма мөселманнарның мәсьәләгә үз карашлары бар иде. Һәлак итмәгән очракта да, Өммийатны адәм мәсхәрәсенә калдыру ниятеннән, Хубаб бине Әл-Мөнзир аның борынын кисеп алды. Бу инде Өммийатның кол дәрәҗәсенә төшерелүе белән бер иде.

— И Габдел-илаһ, — диде үзенең һәлакәте җиткәнен аңлап Өммийат, — мине калдыр...

Габдеррахман шунда аларның икесенең дә беләгеннән кулларын җибәрде, җаннарын әнсарилар кулына тапшырды...

Бәдер сугышы мөселманнар һәм корәишләрнең тәүге олуг бәрелешләре иде. Анда корәишләрдән Мөхәммәд пәйгамбәрнең карендәшләре Габбас бине Габделмотталип, Гакыйль бине Әбу-Талип кебекләр дә әсир төшерелделәр. Сәхабәләр арасыннан ундүрт мөселман шәһит китте, шуларның алтысы — мөһәҗирләрдән, сигезе сәхабәләрдән иде.

Бәдер сугышында монафикъларның әйдәүчесе һәм җитәкчесе, барлык золым һәм җәбернең башы, Мөхәммәд пәйгамбәрне үзенең кан дошманы санаган Әбу-Җәһил дә һәлакәтен тапты. Вакыйгалар бу рәвешле булды.

Корәишләр белән сугышка кергәндә Габдеррахман бине Гауф мөһаҗир ике баһадир уртасында иде. Болар үз-үзләрен аямыйча сугыштылар һәм кяферләрне чәнчелдереп кенә бардылар. Мәгәрем ки алар булмаса, Габдеррахман бине Гауф бу яудан исән-имин чыгасы түгел иде. Бу баһадирлар кылыч орышына гаҗәеп тә маһир иделәр ки, бер генә корәиш тә ачыктан-ачык үзләренә төбәп килмәде, кылычын күтәрергә җөрьәт итмәде.

— И Габдеррахман, — диделәр шушы ике баһадир, — син Әбу-Җәһилне күреп беләсеңме?

— Аны танып беләм, яхшы аерам, бүтәннәрдән, — диде Габдеррахман.

Бу ике баһадир әнсарилардан булып, исемнәре Мөгазь һәм Мәгузь иде, әтиләренә нисбәттә аларны Харис угыллары дип атасалар да, үзара сөйләшкәндә әниләренә бәйле рәвештә Гафирә балалары дигән ат белән әйтү халык арасында нык урнашкан иде.

— Син аны безгә күрсәтерсеңме? — дип сорадылар Габдеррахман Мөгазь белән Мәгузь.

— Нәрсәгә? — диде Габдеррахман.

Кылыч белән орышудан туктамаган ике баһадир, аңа хәтта үз көчен сынап карарга да мөмкинлек калдырмыйча сугыша бирделәр һәм шул ук вакытта икесе бер авыздан диярлек:

— Без аны үтерергә дип уйладык, — диделәр.

— Ни өчен?

— Чөнки Мөхәммәд пәйгамбәрнең догасын ишеттек, ул аның җаны алынуын теләде, — диделәр.

Шулвакыт гаскәр эчендә дөягә атланган Әбу-Җәһил күренде.

— Ул монда, — дип танып алды аны Габдеррахман. Ул вакытта Әбу-Җәһил җитмеш яшьлек карт иде. — Әнә ул, дөя өстендә!

Алдан Мөгазь бине Гафирә өлгерлек күрсәтте. Мәлгуньгә һөҗүм итте. Җәяүле хәлендә дөядәге Әбу-Җәһил белән кылыч орыша башлады. Шул вакытта гаскәрләр буталып киттеләр. Мөгазь бине Гафирә ялгыз иде. Аркадашы Мәгузь килеп өлгерә алмады. Әбу-Җәһилнең аягыннан

яралап өлгерде, икенче тапкырында сукканда мәлгуньнең аягы тәмам киселеп төште. Ул да булмады, Әбу-Җәһил дөясеннән егылуга, Могазь аны чабып үтермәкче иде, артыннан Әбу-Җәһилнең улы килеп, аңа кылыч белән орды. Могазьнең сул кулына туры килеп, төптән үк диярлек өзеп төшерә язды. Кайдандыр гайрәт ирешеп, сәхабә аңа бирешмәде, үзен саклый бирде. Ит кисәгенә генә асылынып торган кулы күкрәгендә уңлы-суллы йөрде. Могазьнең һәлакәтен теләп, корәишләр төрле ягыннан ябырылдылар. Баһадир үз җанын саклар өчен курку белмәс рәвештә, канга баткан хәлендә орыша бирде. Әмма асылынып торган сул кулы аңа комачаулый иде. Могазь кинәт җиргә иелде һәм шушы өзелеп җитмәгән кулына аягы белән басты һәм капылт кына күтәрелде. Бернинди аһ ормады. Гүяки үз тәне түгел иде. Кулы шунда өзелеп, яу кырында калды. Могазь бине Гафира баһадир, кылычын кулыннан төшермичә, сугышуын дәвам итте. Ни хикмәт, ул исән калды, күп кан югалтудан егылмады. Тир, кан, тузан белән укмашып, киселеп калган кул төбе оеды. Аның шушы хәлдә дә яу кырын ташлап китмәве күпләр өчен гайре табигый хәл булып күренде. Бу — чын мәгънәсендә ирлек һәм баһадирлык иде.

Каты яраланган Әбу-Җәһилне корәишләр канга болганган хәлендә яу кырында калдырырга мәҗбүр булдылар. Аны шунда Мәгузь бине Гафира чабып үтерде.

Бу вакыйгадан соң Могазь белән Мәгузь туры Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына килделәр һәм икесе дә:

— Әбу-Җәһилне мин үтердем! — дип һәрберсе ялгыз үзләрен генә күрсәттеләр. Боларның икесенең дә Әбу-Җәһилнең һәлакәтендә катнашлары бар иде. Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр аларның икесенә дә:

— Кая, китерегез әле кылычларыгызны, — диде. Моның сәбәбе шул иде ки, әгәр тагын да бәхәсләшүләрн куертсалар, үзара орыша ук башларга мөмкиннәр иде. Мөхәммәд пәйгамбәр аларның кылычларына күз йөртеп чыкты һәм:

— Сез икегез дә Әбу-Җәһилне үтердегез, — дип белдерде, әмма аның коралларын һәм сугыш киемнәрен Могазьгә багышлады.

Соңыннан Бәдер орышын исләренә төшергән вакытта Мөхәммәд пәйгамбәр:

— Аллаһы тәгалә Гафира улларына рәхмәтле булсын, алар өммәтнең фиргавенен, кяферләрнең атаклы залимчысын үтерделәр, мөселманнарны шул мәлгуньнән коткардылар, — дия торган булды.

Әмма Әбу-Җәһилнең кораллары Могазь кулына кермәде. Аның кылычын сугыш кырында Могазь бине Гамр бине Җәмуг җирдән күтәрде һәм мәлгуньнең башына җиткән кеше дип күпләр аны уйладылар. Чөнки кемнең кылычы кемгә күчсә, шул гаскәри сугышта шул көндәшен үтерүче итеп хисап кылына иде. Күп кенә китапларда Могазь бине Гафира белән Могазь бине Гамрне бутап күрсәтәләр һәм берсенең гамәлен икенчесенә йөклиләр. Бу бары тик аларның исемнәре бер төрле, адаш булулары аркасында гына шулай хата ителә.

Бәдер сугышында сул кулын югалтуга карамастан, Могазь бине Гафирә өммәтнең иң баһадир сугышчыларыннан исәптә йөрде. Кяферләр белән орышлардан калырга теләмәде. Һәрбер бәрелештә гайрәт һәм батырлыклар күрсәтте. Тарихлар аның хәзрәте Госман хәлифә заманнарына кадәр исән-сау булуын хәбәр итәләр һәм кяферләр белән сугышларның берсендә шәһит китүен гөман кылалар.

Сугыш тәмамланганнан соң, Мөхәммәд пәйгамбәр үзе янындагы сәхабәләргә мөрәҗәгать итте:

— И батыр ирләр, кайсыгыз Әбу-Җәһилне табып, аның башын китерә, күрермен, мәлгунь ни рәвешле һәлакәтен тапты? — диде.

Шунда Мәсгуть мөһаҗир:

— Аны мин китерермен, кайда егылганын һәм үтерелгәнен күрдем, — дип урыныннан кузгалды һәм бәрелеш булган җиргә китте. Ул вакытта

бүтән сәхабәләр әсирләрнең жанын кыю һәм качып баручы мөнафикъларның артыннан бастырып килү белән мәшгуль иделәр.

Мәсгуть, сугыш булган урынга килеп, үлекләр арасыннан канга һәм тузанга укмашып яткан Әбу-Җәһилне эзләп тапты. Ул әле һаман да исән иде. Чаларган бу карт гомере буе Мөхәммәд пәйгамбәрне дошман күрде. Аны ничек мөмкин, шулай мыскыллады. Юкса Мөхәммәдне бала вакытында ук бетерә ала иде. Сәбәбе дә чыкмады түгел. Канга кан белән җавап бирү дип аңлаткан булыр иде.

Ничектер бервакыт, Мөхәммәд пәйгамбәр, бала чагында, аяк астында уралып, Әбу-Җәһилне ялгышлык белән төртеп екты һәм аның тезбашын ярды. Моны Әбу-Җәһил гомере буена онытмады, форсаттан файдалана алмавына һәрдаим үкенде. Инде менә үзе харап булып ята. Җиңәм дип килгән җиреннән һәлакәтен тапты. Авыр яралы чагында аркадаш монафикълары гына түгел, хәтта улы да ташлап качты. Үз жаннарын кадерлерәк күрделәр. Бу кадәр дә оят, бу чаклы да түбәнлекне кайчан күргәне бар иде аның? Юк шул, күкрәп яшәп тә, мескен хәлендә үләргә мөмкин икән!..

## Мәдинә тормышы

Әбу-Җәһилнең жаныннан бер мыскал әсәр калган иде. Шушы кадәр туралып та һәлакәтен таба алмыйча, тән газабыннан бигрәк үзенең халыклар алдында мәсхәрәләнүенә ачынды. Шунда аның йөзенә Мәсгуть сәхабә төбәлде. Күзләре очраштылар. Гүяки икесе ике дөнья кешеләре төсле ят бер караш белән гауга тотар кебекләр иде. Әмма алар бер-берсен аңламадылар. Тәмуг кисәве белән җәннәт сәхибе галәмнең ике аргы тараф читләрендә төсле иде.

Мәккәдә вакытында Мәсгуть шушы Әбу-Җәһилдән күп җәфалар күргән һәм бәлаләр татыган кеше иде. Мәлгуньнең үләксә хәлендә ятуы өчен мөһаҗир аңлатып булмаслык бер сөенеч хис итәргә тиеш иде, әмма куанычтан нәфрәте көчлерәк ут рәвешендә күңелен ярсытты. Жаны чыгып бетмәгән Әбу-Җәһилнең күкрәгенә тезләнде һәм сакалын умырып диярлек йодрыгына алды. Аның бу халәтен гаделсезлек җәзасын түрәдән чиксез күп татыган заманыбызның гадәти бәндәләре ахыр килеп, үзенең дөреслеге җиңеп чыкканда татыган тантанасы белән генә чагыштырырга мөмкиндер.

Кайчан Мәсгуть сәхабә шунда Әбу-Җәһил мәлгуньнең сакалына ябышты, шунда дөньялар тигезләшкән кебек булып китте. Әллә Аллаһы тәгалә нәкъ менә шушының өчен монафикъның жанын тәмам чыгарып бетерүне кичектергән идеме? Һәрхәлдә, Әбу-Җәһилнең шушы хәлендә Мәсгуть кулына килеп керүендә могҗиза да бар иде. Бер-бер кешедән чиксез гаделсезлек җәзалары тарткан һәм ахырда шул мәлгуньнең үзеннән дә түбәнлектә калырын өмет иткән, ансын да күреп, куанасы урынга, Аллаһы тәгаләнең гаделлегенә исе-акылы китеп, бөек бер рухи тынлыктынычлык халәтен кичерде ул. Әгәр аның өчен дөньяда моңа кадәр гаделлек тантанасы мөмкин эш түгел кебек күренсә, хәзер ул үзенә үзе дә ышана алмый, теләге акылына түгел, ташып чыккан ачы хисләренә буйсынды.

— Синме бу, Әбу-Җәһил, нинди хәлгә калганыңны күрдеңме! И Аллаһы тәгаләнең дошманы! Күр, Аллаһы тәгалә сине хур кабих сурәтеңә китерде, мәлгунь! — дип, Мәсгуд сәхабә эчендә җыелган ачуын чыгару өчен теленә көч бирде. Юк, ул боларны гына түгел, әллә нәрсәләрне әйтергә теле иде. Әмма кодрәтеннән килмәде, сүзләре кайнар күз яшьләре белән укмашты. Нинди генә җәзалар бирсә дә, аз кебек тоелды.

Эсселәнде, суынды. Әйтелеп беткән төсле, сүзләрен җыя алмады. Әбу-Җәһилнең сакалыннан кулын җибәрмәде.

— И адәмнәрнең мәлгуне, Аллаһы тәгаләнең дошманы! Тәмуг кисәве! Шушы сәгатең килмәс дип уйладыңмы!

Юк, аз иде, бу сүзләр генә аны канәгатьләндерә алмый. Шунда Әбу-Җәһилнең куәте кайтты һәм теле ачылды, ул һаман да кабих теле белән сөйләнде:

— Мондый да кеше галәмдә бармы, бер үзе өчен бөтен кавемен һәлак иттерде, халкын сугыштырды. Монда минем гаеп юк, болар барсы да Мөхәммәднең эшләре...

Гаепне пәйгамбәргә ташлавы белән Әбу-Җәһил җай гына Мәсгутьнең күңелен яулауга, аның миһербанын кузгатырга, шуның белән бергә үз гомерен тәмам һәлакәттән саклап калырга теләде шикелле. Бу хәлендә бүтән бер юл, башка төр чарасы юк иде. Әйтерләр, мәкерле агуын чыгарганнан соң елан, үзенең һәлакәтен сизенеп алгач: «Моннан соң сиңа һәм балаларыңа тимәмен, һәр затка үзеңне дустым дип әйтермен, миңа гына сукма!» — дип үтенер, ә асылда исә: «Бу юлысы ялгыштым, икенчесендә башыңа җитәрмен!» — дип уйлар, имеш. Яхшылыклы кешенең күңеле йомшак шул. Сайлап сөйләнгән сүз артында мәкер ятканын уена да китереп карамый, ялгышны үзеннән эзли башлап: «Кара әле, бу кешене бөтенләй белмәгәнмен икән, күңеле саф икән бит!» — дип фикерли дә, дошманына ярдәм кулын суза. Мәсгуть сәхабәнең дә күңеле менә шундыйлардан булып, ул инде явыз дошманына миһербан итәргә әзер иде.

Әбу-Җәһилнең яраларын сызландырып, Мәсгутьнең акылын айнытып, яннан салкынча җил исеп китте. Әле яңа гына якынаер кебек күтәелгән аралары ерагайды. Саташулы төш күреп, куркынып уянган кеше төсле Мәсгуть сәхабә сискәнеп куйды һәм:

— Мин сине чабып үтерәм! — дип кылычына ябышты.

Әмма Әбу-Җәһил аны бүтән яклап үзенә буйсындырырга тиз чарасын тапты. Гомере буе байлык белән рәхәт яшәгән, теләгәнен эшләгән, хәйлә һәм мәкердә тиндәше булмаган, фәрманы белән һәркемне диярлек буйсындыра алган һәм буйсындырып килгән мәлгуньне сүз белән алу мөмкин хәл түгел.

— Син — кол, ә мин — хуҗа, хуҗа кешене кол үтерү мөмкин хәл түгел. Мине үтерәчәк син дә түгел! — дип Әбу-Җәһил һәркемнең канына сеңгән, хакыйкать һәм канун итеп кабул кылынган кагыйдәне белдергәч, Мәсгуть сәхабә тагын икеләнеп калды.

— Син мине үтермә, исән калырмын. Һәркемгә әйтермен: дустым, диярмен. Моннан ары сине һичкем кимсетмәс...

Әбу-Җәһил вәсвәсәсен җай гына дәвам итте. Исән калмаган очракта: «Кол тарафыннан һәлак ителде»,— дигән хурлыклы сүзнең доньялыкта таралуыннан хәтере чиркана иде, шунлыктан менә шушы яктан гына булса да горурлыгының сынмавын җаны теләде. Әмма Мәсгуть үзенең кол дип кабул ителүен теләмәде, азатлык тәмен татыган кеше икәнлеген Әбу-Җәһил тоеп бетерми иде. Узганны искә төшерү, гарәп канунын телгә алу уңайга килмәде. Мәсгуть сәхабә кабаттан үз өстенлеген тойды, каны кайнарланды.

— Аһ кабих фиргавен! — дип, Әбу-Җәһилнең күкрәгенә басты һәм кылычын күтәрде.— Әйт, синең бу доньяи йөзендә иң зур дошманың кем? Синең дустың аталачагым юк. Шул дошманың минем иң якын дустым булыр! Синең белән дус булудан дошманыңның дусты булуны өстен күрәм! — диде.— Әйт сүзеңне, һәлакәтең минем кулымда!

— И, көтүче, син дә үзеңне өстенгә чыккан кеше дип исәплисеңме? Инде миңа да әйт, бу сугышта кем җиңде?

Корәишләрнең җиңгән булуына Әбу-Җәһилнең күңеле ышана иде булса кирәк. Юктыр, бары тик Мәсгуть теләгенә буйсындырырга гына уйлыйдыр.

— Аллаһы тәгалә һәм аның пәйгамбәре җиңде,— диде Мәсгуть.— И, мәлгунь, фиргавен хакында ишеткәнең бардыр, ул диңгезгә гарык булыр алдыннан, һәлакәтен күреп, инсафка килде, дөньялыкта ярамас эшләр кылуы өчен тәүбә итте. Син дә шушы хәлләргә төштең, әмма һаман да уең явызлыкта кала бирә...

Әбу-Җәһил дә ялгышларын танырга, үлем алдыннан булса да хакыйкатьне аңлап, тәүбә итәргә, иман китереп, Аллаһы тәгаләнең ярлыкавына өмет тотарга тиеш иде. Әмма ул андый кеше булмады, ахыргача мәлгунь хәлендә кала бирде.

— Сәхабәләренә һәм Мөхәммәд пәйгамбәренә әйт: мин бу дөньядан китәрмен, әмма белеп торсын, күкрәгемдә аңа карата иң зур дошманлык һаман да сакланыр, аннан да чирканган дошманым булмады һәм юк! — дип, Әбу-Җәһил чыраен тәреләндерде.

Мәлгунь белән артык сүзнең мәгънәсе юк иде. Мәсгуть сәхабә шуннан соң бер аһ белән кылычын айкады да Әбу-Җәһилнең муенына орды. Әмма Мәсгутьнең кылычы тупасланган, үткерлеге беткән иде. Җитмәсә, очы белән җиргә кадалып, монафикъка зыян итә алмады. Мәсгуть сәхабә икенче кат кылычын кизәнде. Шунда Әбу-Җәһил:

— И ахмак, кешенең башын чапканда соңгы теләген сорыйлар, шуны үтиләр. Аннары гына кылыч күтәрәләр,— диде. Башым биек булып күренсен, муенымны гәүдәм яныннан кис...

Мәсгутьнең кылычы кискен хәрәкәт белән сузылып, Әбу-Җәһилнең муенын кисеп үтте. Мәлгуньнең гомере белән бергә теле дә өзелде. Әле кайчан гына мөселманнарга җәбер-золым иткән, Мәккәдә корәишләрне үз вәсвәсәсенә буйсындырган баш, сакалыннан асылынган хәлендә Мәсгуть сәхабә кулында иде.

Ул аны күтәрде һәм:

— Юк, сакалыңнан сөйрәп йөртү синең өчен артык, мин әле сине җепкә тагып, пәйгамбәремә китерәчәкмен! — диде, бәгырь ачысы һаман да күкрәк читлегеннән чыкмаган иде.

Мәсгуть сәхабә, җеп табып, Әбу-Җәһилнең муеныннан урап бәйләде һәм шул рәвешле таккан килеш Мөхәммәд пәйгамбәрнең пальма агачлары яфракларыннан эшләнгән чатырына таба сөйри башлады. Килеп җиткәндә ул баш юл уңаеңда бар шакшылык, тузан һәм каннар белән укмашып, танымаслык хәлгә керде.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең хозурына ирешкәч, Мәсгуть сәхабә:

— Йә Аллаһы тәгаләнең сөеклесе, мин каршыгызга Әбу-Җәһилнең башын китердем,— диде. Йөзендә кылган эшенә канәгатьлек һәм куаныч билгеләре иде.

Пәйгамбәр бу башны күрде һәм:

— Валлаһи, бу аның башы! — дип килде, карады.— Әлхәмдулиллаһи, бу шәхес өммәтнең Фиргавене! — диде дә, Аллаһы тәгаләгә шөкерләрен белдереп дога кылды, ике рәкәгать намаз укыды.

Дин дошманының шушы рәвешле харап булуы, мыскыллы хәлдә калуы барча мөселманнар өчен дә куаныч-шатлык китерде. Милләтнең Фиргавене, аллаһы тәгалә һәм пәйгамбәренә каршы корәишләрне күтәргәч, үзенең эше һәм тоткан юлы дөрес дип уйлаган иде дә, вакыйгалар асылда бөтенләй башкача килеп чыктылар...

Аннары Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең сәхабәләренә болай дип боерды:

— Мин Бәни-һашим һәм кайберәүләрне яхшы беләм, алар вакытында Мәккәдән чыга алмадылар, корәишләр белән безгә каршы килгәндә, аларга чирканып карадылар, әмма ирекке ирешергә мөмкинлек тапмадылар. Мәккәдән дә ятсынып киттеләр. Әгәр дә сезнең кайсыгызга да булса Бәни-һашимнан бигрәк тә Габбас бине Габделмотталип туры килә икән, яки Әбу-Бухтури, аларны һәлак итмәгез! Әбу-Бухтури һичкайчан мине рәнҗетмәде, пәйгамбәр дип таныган кешеләрнең берсе, кяферләрнең эшенә каршы булды. Аны үтерә күрмәгез!

Рәсүл Әкрамның бу сүзләрен ишеткәннән соң, Әбу-Хөзәйфәнең күңелендә канәгатьсезлек хисе уянды. Мәсьәләнең асылына төшенеп тә житмәстән:

— Без үзебезнең аталарыбызны, туганнарыбызны, карендәш тиешле якыннарыбызны бу сугышта һәлак иттек. Аларны динебезнең дошманнары дип белдек. Кан карендәшлегеннән дини туганлыкны өстенрәк күрдек,— дип, үз фикерен белдерде һәм бүтәннәрне дә котырта башлады.— Аллаһы тәгаләнең ризалыгы өчен дип әйтәм, әгәр дә мин Габбасны очратсам, аңа туры килсәм, кулымдагы шушы кылычым белән телгәләп ташлыйм!

Мөхәммәд пәйгамбәргә аның сүзләре ирешкәч, баштарак аптырап калды, аннан соң хәзрәте Гомәргә карап:

— Йа Абу-Хәфисә, ишеттеңме, бу кеше нәрсә ди? Пәйгамбәрнең агасы йөзенә кылыч белән сугарга тели түгелме?—диде.

Шунда хәзрәте Гомәр кылычына ябышты һәм:

— Йа Рәсүлуллаһ, рөхсәт ит, шушы монафикъның буена кылыч уздырыйм!—дип җилкенде. Әмма пәйгамбәр аны тиз туктатты:

— Алай димә! Ул монафикъ та, кяфер дә түгел! Үзенең атасы, агалары һәм туганнары сагынуыннан шулай сөйлидер. Аның монда гаебе юк. Ул — иманы камил кеше, чын мөселман, динебез өчен сугышларның берсендә шәһит китәчәк һәм җәннәтле булачак. Аллаһы тәгаләнең сөекле затларыннан берседер!—дип белдерде. Кайчан Әбу-Хөзәйфәгә бу сүзләр килеп ирешкәч, ул ялгыш сөйләвенә оятлы булды, үкенде. Пәйгамбәр ялгышмады, дин өчен сугышта ул шәһит китте, җәннәтле булды.

Габбас бине Габделмөтталипны, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәрнең бабасы Габделмөтталипның улы Габбасны Әбул-Сир бине Кәгаб бине Гамру әсир итте. Ул әнсарилардан иде. Гәүдәгә кечкенә һәм зәгыйфь булуы сәбәбле, көч вә куәттә шактый өстен Габбасны кулга алуы бер дә ышанырлык нәрсә күренмәде. Юкса Габбас бер кизәнүдә Әбул-Сир әнсарины ега алыр иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр бу хәлне күргәч, аптырады һәм Әбул-Сирдән сорады:

— Син ничек Габбасны әсир итә алдың? Дөресен сөйлә,— диде. Моңа җавабында сәхабә:

— Миңа бер таза һәм күркәм зат ярдәм итте, аны ул богаулады. Әмма моңа кадәр арабызда андый кешене күргәнем юк иде,— диде. Шуннан соң гына мәсьәләгә ачыклык кереп, Мөхәммәд пәйгамбәр эшне аңлатып бирде:

— Сиңа ярдәм иткән зат олуг мәләкләрнең берсе иде,— дип, исемен дә атады.

Әйтер ки, куәт иясе Габбасны әсир итүенә Әбул-Сир үзе дә аптырый, әмма шул ук вакытта сөенә дә иде.

Әбул-Бухтури исә үзе әсир төшәргә теләде. Әбу-Дауд Мазини сәхабә белән якда очраштылар. Әмма узара сугышмадылар. Шунда Әбу-Дауд аңа:

— Син кулыңны тот, мин сине бәйлим,— дип белдерде.— Мөхәммәд пәйгамбәр сиңа тияргә кушмады, сине һәлак кылмыйча, исән калдыруны үтенде,— диде.

Моңа каршы Әбу-Бухтури, канәгатьлек белән ризалыгын белдереп болай диде:

— Йа Әбу-Дауд, син мине әсир итәрсең, әмма мин һәркем алдында сиңа бәйләнеп торсам, Мәккә хатыннары көләрләр дип куркам. Алар соңыннан сөйләрләр. Без башта орышкан кыяфәт чыгарыйк. Миңа ук белән атарсың. Яраланырмын һәм егылырмын.

Алар шулай килештеләр. Әбу-Дауд аны шулай әсир төшерергә тиеш иде. Тобәп ук атты. Җәясенең җебе тибрәлүдән туктарга да өлгермәде, якын арада торган Әбу-Бухтурига ук килеп тә тиде. Егылды. Әмма ук

аның йөрәгенә туры килеп, Әбу-Дауд аны бәйләргә килеп җиткән вакытта Әбул-Бухтури җан биргән иде инде.

Мөселманнар яудан соң корәишләрдән ачуларын алу өчен хәтта әсирләрне дә аямый башладылар. Күпләрнең каны куллары бәйле хәлендә акты. Мөхәммәд пәйгамбәр исә үзенең туганы Габбасның әрнүле тавышын ишеткәләп торды. Әмма аны исән калдырдылар. Барча әсирләр белән бергә бәйләп салдылар. Ачуданмы, әллә инде чама хисен онытыпмы, Габбасның кулларын артка каерып, аяк-кулларын нык итеп кысып будылар. Төн җиткәндә аның моңа һич тә түзәрлеге калмады. Куәтенә ышанып, бау һәм җепләрне өзәр өчен тарткалануларыа да зыян гына итте. Богаулары тагын да ныграк тартылдылар. Ул инде тавыш биреп кычкырудан, авыртуга түзә алмыйча акырудан башка мөмкинлек калмаганын аңлады. Аның тавышлары Мөхәммәд пәйгамбәргә ишетелеп торды. Йокысы качты. Тынычлыгын югалтты. Рәсүл Әкрамның бу хәсрәтен белеп алган сәхабәләрдән берәү, әсирләр янына килеп, Габбасның богауларын бушатты, җиңелчә генә бәйләде. Ул инде хәзер качмаска һәм зыян китермәскә тиеш иде. Авыртуы беткәч, Габбас акырудан да туктап, йоклап китте. Әмма бүтән әсирләрнең күбесе кысып богаулаудан аңсыз хәлгә җиткән иделәр. Мөхәммәд пәйгамбәр, Габбасның тавышы әсирләр яныннан ишетелми башлагач, эшнең асылын сораштырды. Теге сәхабә аңа барсын да аңлатып бирүгә:

— Бөтен тоткыннарның да богауларын йомшартыгыз! —дип фәрман бирде.

Таләп үтәлүгә, әсирләр ягыннан аһ-зар итүләр тукталды. Барсы да тыныч йокыга талдылар.

Кяферләрдән Өммийә бине Халәфнең үле тәне тәмам тапталып, телгәләнеп беткән иде. Пәйгамбәрнең әмере белән ул урынга таш һәм комнар ыргыттылар. Шуннан соң, әмер итеп, Мөхәммәд галәйһис-сәлам:

— Барлык монафикъларның мәетләрен җыеп, Бәдер коеларының берәр чокырына ташлагыз! —диде.

Шул рәвешле корәишләрнең егерме дүрт мәетен җыеп, барсын бергә, чокырга китереп ташладылар. Кутбә бине Рабиганың да мәетен сугыш кырыннан китереп, бүтән кяферләр янына, чокырга ыргыттылар. Ул баш-аяк буталып, хәшәрәт бер сурәттә ауналды. Әмма улы Хөзәйфә әтисенең шушы хәлдә туфрак астында каласына хәсрәт чикте һәм сагышка батты. Акылы шашты. Аның бу хәленә шаһит булып торган Мөхәммәд пәйгамбәр:

— Йа Хөзәйфә, әтиеңнең шушы ахыр урынын күреп, күңелеңә сагыш төште бугай,— диде.

— Аллаһы тәгаләнең хакы өчен,— диде Хөзәйфә, сагышлы йөзен пәйгамбәр тарафына куеп,— Исламга килермен дигәндә, күңелемә бер дә шик төшмәде. Әтием бик дә дөрес һәм әхлак сәхибе кемсәнә иде. Мин өмет итәм ки, ул сыйфатлар бәрәкәте белән динебез Ислам үсеш алачак. Максатымның ялгышын күреп сагышландым.

Кяферләрнең шушы рәвешлә адәм оятына калдырылуларын күрә торып та, Ислам диненең киләгәче һәм әдәп-әхлак кагыйдәләре нигезендә җәелеп китүе хакында Хөзәйфәнең уйланып сагышлануында гыйбрәт тә бар иде. Ул ни сөйләгәнен белеп һәм аңлап әйтте. Бер дә әтисенең исемен кабатлап, чәчләрен йолкып еламады. Ә бәлки аның әхлакый сыйфатларын пәйгамбәрнең исенә төшерде. Үзенең ялгышларын аңлады, Исламның өстен икәнлеген төшенде. Шунда Мөхәммәд пәйгамбәр аңа атап дога укыды.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең шундый гадәте бар иде, ул кайда җиңүгә ирешсә, шунда өч көн кунак булып, бәйрәм оештыра иде. Бәдер сугышында монафикъларны тар-мар китергәннән соң да, ул нәкъ шулай эшләде. Мәетләрне дәфен кылып, шәһитләрне гүр иясе иттеләр. Әлбәттә, монафикъларга һичбер төрле дә хөрмәт күрсәтелмәде. Аларны гарәпләрнең борынгыдан килә торган йолаларына да туры китереп күммәделәр,

сөйләп үтелгәнчә, Бәдер коесы дип аталган шушы урында иске бер чокырга барсын бергә баш-аяк болгап ыргыттылар һәм туфрак вә ташлар ыргытып, җир белән бу каберлекне тигезләделәр. Алар өчен һичбер төрле дога кылынмады, хушлашу сүзләре әйтелмәде. Әмма мөселманнар арасында аларның туганнары, балалары бар иде. Алар да бу хәлләрне күреп тордылар. Әмма кяферләр өчен хәсрәтләнү мөэминнәргә килешмәгәнлектән, бары тик гыйбрәт кенә алдылар. Дөрес, аларның күбесе Мәккәдә вакытларында күп җәбер-җәфаларны шушы туганнарыннан һәм карендәшләреннән татыганлыктан, аларның күңелендә нәфрәт хисләре сүрелеп бетмәгән иде әле. Шулай да туган-тумачаларының шушы хәлгә калуларына хәсрәт чигүчеләр дә булмады түгел. Аларына Мөхәммәд пәйгамбәр мөмкин кадәр илтифат итеп, сагышларын тарату өчен хәер-догаларын бирде.

Шәһит киткән мөселманнарга исә мөмкин булган һәртөрле хөрмәтләр күрсәтелде. Әмма аларның тәннәре юылып күмелмәде. Киемнәре салдырылмады. Киселгән, канга баткан хәлләрендә гүр иясе калдылар. Мөхәммәд пәйгамбәр әйтте:

— Аллаһы тәгалә аларны менә шушы тәннәрендәге яра эзләре һәм каннарыннан таныр, һәм Ислам дине өчен яуда шәһит китүләрен белер, җәннәтле итәр,— диде.

Шушы өч көн эчендә сөйләшенгән сүзләрнең берсе — язмыш мәсьәләсе иде. Сәхабәләр үз күзләре белән корәиш монафикъларының ни рәвешле күкрәп яшәүләрен һәм ничек хәкарәтле һәлакәткә юлыгуларын күрделәр. Шул ук вакытта Бәдердәге бу җиңү аларда батырларча һәлак булган мөселман карендәшләренең, һәртөрле җәбер-золымнар астында кимсетелеп, авыр тормышта яшәүләренә карамастан, үлемдә мәртәбәгә ирешүләренә соклану тудырды.

Шулай итеп, язмыш фәлсәфәсендә карашлар һәм фикерләр үзгәреш кичерде. Шушы дөньяның өч көнлек кенә икәнлеген Мөхәммәд пәйгамбәр мөселманнарга моңа кадәр дә аңлатып килде, Ахирәт көнендә яшәеш хакында кайгырырга кирәклеген төшендерде. Үлем һәркемгә килә, аннан һичкем качып котыла алмый. Әмма монда җәфа чигеп яшәгәнче китүең хәерлерәк. Кеше язмышы Аллаһы тәгалә кулында. Ул һәркемне дә шәһит итми, дин өчен сугышып, батырларча һәлау булу күпләргә тәтеми дә. Әгәр сиңа шәһит язмышы бирелгән икән, моның өчен сөенергә генә кирәк. Картлык көнеңә житеп, шәһитлек мәртәбәсенә дә ирешәсең икән, бу инде икеләтә бәхет. Менә шуның өчен сәхабәләрнең күбесе үзләренә шәһитләр язмышын теләделәр, менә шуның өчен дә мөселманнар Бәдер сугышында һәлак ителгән карендәшләрен мәртәбә һәм хөрмәт белән искә алдылар. Шушы хис һәм тойгылар һәрбер ислам динен кабул иткән кешенең күңеленә күчә барып, тарихта тегә яки бу халыкның алга китешен тәэмин итәчәген ул вакытта гарәпләр әле күз алларына да китермәгәннәрдер.

Дүртенче көнне сәхабәләр гаскәре Мәдинәгә кайту юлына чыкты. Мөхәммәд пәйгамбәр шунда монафикъларны күмгән чокыр янына килде һәм хөтбә укып әйтте:

— Йа Гутба бине Рабигат,— диде ул, һәрбер һәлакәтен тапкан корәишнең исемен аерым-аерым атап,— сезгә вәгъдә ителгәннәр хак булдымы, мин сезгә әйтмәдемме, сүземдә дөрес булмадыммы?! Сез кавемегезнең ярамас кешеләре идегез, пәйгамбәрегезне инкарь иттегез. Бүтән кавемнәр мине пәйгамбәр дип таныды. Ә сез ышанырга теләмәдегез! Туып-үскән шәһәремнән куып чыгардыгыз. Җәбер-золымнар күрсәттегез. Әмма бүтән кавемнәр мине үзләренә сыендырды. Алар пәйгамбәрне таныдылар, сүзләремә иярделәр. Ә сез минем белән сугыштыгыз, һәлакәтемне теләдегез! Әмма бүтәннәр мине яклап чыктылар, пәйгамбәр өчен җаннарын да фида кылдылар. Инде үзегезнең ялгышлыкларыгызны аңлау сәгатенә ирештегез. Сайланып кылана торган җирдә түгелсез.

Инде сезгә һичкем ярдәм итмәс. Кире кайтып, ялгышларыгызны төзәтергә чарагыз юктыр!..

Аның бу сүзләрен сәхабәләр ишеттеләр һәм үлгән кешеләр белән сөйләшә, акылы камилме икән дип, бер-берсенә сораулар бирделәр. Хәзрәте Гомәр шунда аның янына килде һәм:

— Йа, Рәсүлулаһ, рухсыз мәетләр белән нигә сөйләшәсез?—дип сорады.

— Сез алардан артыгын ишетүчеләр түгелсез. Сез нәрсә ишетәсез, алар да минем шул сүзләремне ишетәләр, әмма җавапларын гына бирә алмыйлар! — диде пәйгамбәр, эшнең асылын аңлатып.

Хәдисләрдән чыгып, мөэминнәр әйтерләр: «Без үлеләрдән хәбәр ала алмасак та, алар безнең нәрсә сөйләшкәнне ишетеп торырлар!»

Хәзрәте Гайшәдән шул билгеле булды, кайчан Мөхәммәд пәйгамбәр монафикъларның мәетләре ташланган чокыр янында шушы сүзләрне әйтеп, аларның үзләренә ирештерде, барчасы каты хәсрәт эчендә калдылар.

Мәетләрнең тереләр әйткән сүзләрне ишетүен раслый торган бер дәлил бар, ул да булса, тәлкыйн әйтү белән бәйле. Кабергә җәза фәрештәләре ирешү белән, җәзаланылучының Мөнкир һәм Нәкирнең гөрзи оруларыннан ачынып кычкыруларын һичбер кеше ишетмәс, әмма тәлкыйн әйтүченең сүзләрен гүр иясе ишетеп торыр һәм акылына куәт алыр, диләр.

Бәдер сугышында һәлак булган иң яшь егетнең исеме Харис бине Рабигъ иде. Сираканың малае. Әнисенең исеме Рабигъ дип аталу сәбәпле, Рабигъ улы дип кенә йөртә иделәр. Ул да Мөхәммәд пәйгамбәрнең гаскәре белән Бәдер сугышына килде. Әмма сугышта катнашмады. Яшьлеге һәм сабыйларча беркатлылыгы сәбәпле алдын-артын карап йөри белми иде әле.

Эсселәп, кое авызына ятып, шушы Рабигъның малае су эчте. Әмма, бәхетсезлек аяк астында йөри, корәишләргә дип атылган укларның берсе очып барган җиреннән чалышаеп, Харисның коега иелгән вакытында аркасына килеп кадалды. Каны суга тамды һәм ул шунда һәлак булды.

Бу хәбәрне Рабигъка җитерделәр. Әнисе моңа бик нык хәсрәтләнде, йөзенә сагыш сарылыгы йөгерде, күзләренә канлы яшь тулды. Вакыйгадан Мөхәммәд пәйгамбәр дә хәбәрдар иде.

Харисның әнисе әйтте:

— Әгәр дә улым шәһитләр исеменә кереп, җәннәтле икән, ул вакытта аның өчен хәсрәтләнмәм, әгәр дә юк исә, күзләремнән яшь урынына кан агар,— диде.

Кайчан Мөхәммәд пәйгамбәр аның шушы сүзләрен ишетте, улының шәһитләрдән икәнлеген белдерде һәм җәннәтле булуын аңлатты. Шуннан соң касә белән су сорап алды, аңа бармагын тидерде, бу су Зәмзәм суы тәменә керде. Аннан аны Харисның әнисенә һәм кыз карендәшенә эчертте, йөзләренә-битләренә сөртте. Әйтерләр: Мәдинә шәһәрендә алардан да озын гомерле һичкем булмады.

Шулай итеп, Бәдер сугышы тарих өчен һәм халыклар каршысында бик гыйбрәтле бер вакыйга рәвешендә мәйданга чыкты. Моңа кадәр пәйгамбәрнең көченә, Аллаһы тәгаләнең боерыгына вә барлыгына ышанып җитмәүчеләр үзләренең күңелләренә терәк таптылар, һич тә җиңелерлек кебек күренмәгән корәишләрнең тәкәбберлек куәтен шиңде. Әгәр дә моңа кадәр мөселманнардан көлгән булсалар, артын-алдын уйламый эш кылсалар, хәзер саклый белән гамәл итәргә тиешлекләрен аңлаучылары да арада күренә башлады.

Бәдер сугышы Исламның җиңүе белән тәмамланды, аның киләчәге барлыгын раслады. Бу орыш гарәпләрнең үз эчләрендә булды. Аңа бүтән кавемнәр катнашмады. Әмма бу аларның үз эшләре кебек кенә тоелса да,

тарихның алга таба үсеше шушы бәрелешнең дөньякүләм әһәмияткә ия икәнлеген тулысынча раслады. Мөхәммәд пәйгамбәрнең әйткәннәре дөрескә чыкты.

## Мәдинәгә кайту

Бәдер сугышында Мөхәммәд пәйгабәр үз гаскәрләрен өчкә бүлде. Аның беренчесен үз янына куйды. Алар үзләрен олуг гаскәр дип белделәр. Әгәр дә төп көчләр чигенә башласа, алар сугышка керергә әзер торырга тиеш иделәр.

Гаскәрнең икенче өлеше төп көчләрнең артына куелды. Ә төп көчләр исә яуга керделәр. Аларны шушы рәвешле бүлгәләү сугышны алып бару һәм көтелмәгән һөҗүмнәрдән саклану өчен уңай булды. Төп көчләр корәишләр өстенә ташланып, аларны качарга мәҗбүр иттеләр, әсир төшүче монафикъларны үзләреннән артта торган гаскәриләргә тапшырдылар. Шулай итеп, ганимәт малында һәркайсының өлеше бар иде.

Мәгълүм ки, ганимәт малы дип сугыш барышында һәм шул сугыш сәбәпле җиңүчеләр кулына кергән табыш атала.

Менә шушы ганимәт малы Бәдер сугышында әсирләрдән, сугыш киемнәре һәм коралларыннан тора иде. Әсирләрне кабат Мәккәдәге туганнарына сатып, билгеле бер күләмдә мал таләп итәргә мөмкин булганлыктан, аларга аерата зур игътибар бирелде. Әмма ул әсир төшкән корәишләрнең күбесеннән Мәккәдә чакларында күп җәбер-золымнар күрүләре сәбәпле, мөһаҗирләр аларның башларына җитәргә бик атлыгып тора иделәр. Әнсариләр исә бу мәсьәләдә күндәмлек күрсәтеп, Мөхәммәд пәйгамбәрнең өйрәтүләренә буйсындылар. Ә сугыш киемнәренә һәм коралларына килгәндә исә, болары ул заманнарда иң кыйммәтле җиһазлардан саналып, бай, аксөяк корәишләрнең бу җәһәттән күп кенә маллары сәхабәләргә күчте. Үтерелгән монафикъларныкы гына түгел, качып баручыларның да сугыш киемнәре һәм кораллары, башка төрле байлыклары, дөя һәм атлары мөселманнар кулына керде. Чөнки корәишләр, җиңелүләрен аңлап, һәммә нәрсәләрен ташлап, авыр кылычларын һәм сугыш киемнәрен ыргытып, кача бирделәр. Бары тик мөселманнарның кылычлары гына артларыннан куып җитмәсен!

Гарәпләрнең ул вакытлардагы гадәтләре буенча, кемнең кулына сугышта нәрсә керсә, ул бары тик аныкы гына санала иде. Шунлыктан берәүләр сугыш барышында тәннәрен-җаннарын аямыйча орышса, икенчеләре мал җыю теләкләрен канәгатьләндерергә тырыштылар. Әсирләр һәм табышлар бер кулдан икечесенә тапшырылу сәбәпле, аңа һәр икесенең дә нәфсесе төште. Мөхәммәд пәйгамбәр янында торган олуг гаскәр үзләрен һәммә гаскәридән өстен санап, ганимәт малының төп өлеше дә үзләренә тиеш дип белдерделәр. Кулларына очраклы яки тырышлык белән кергән малларны һичкем бүтәннәр белән бүлешергә теләмәде. Өлешсез калучылар исә ризасызлык белдерде. Шул сәбәпле өммәт арасында бәхәс чыгып, үзара тарткалашулар башланып китте. Моңа бары тик Мөхәммәд пәйгамбәр генә чик куя ала иде. Һәм ул боерды:

— Сугыш барышында алынган һәм кулыгызга кергән һәртөрле малмөлкәт, барчасы җыелып, бер урынга китерелсен! — диде.

Аллаһы тәгаләдән аять ирешеп, аны Мөхәммәд пәйгамбәр мөселманнарга җиткерде. Һәммәсе дә, Хак тәгаләнең ризалыгы өчен дип, инде үзләренеке саный башлаган байлыкларны китереп, бер урынга өйделәр.

Сәгад бине Әбу Ваккас шунда Мөхәммәд пәйгамбәргә мөрәҗәгать итте. Ул үзе сугышта батырлыклар күрсәткән, карендәше Гамир да һәлак булган иде.

— Йа Рәсүлуллаһ,— диде ул,— бу халык арасында баһадирлар да бар, зәгыйфьләр дә. Сез аларның һәммәсенә дә ганимәт малын тигез

бүлеп бирерсезме? Зәгыйфьләр дә батырлар кебек үк малга тигез хуҗа булырмы?

Әбу-Ваккасны шушы рәвешле нәфесе сөйләткәнен Мөхәммәд пәйгамбәр аңлый иде. Шул ук вакытта ул үзенең яраннарын гаделлек белән эш итәргә дә өйрәтергә тиешлеген яхшы белде. Шунлыктан үз фикерен ачып салды:

— Җиңүегез зәгыйфьләрнең догасы белән килмәдеме?..

Бу сүзләре: «Йә Әбу-Ваккас, батырлыгың белән мактанып, үзеңә күбрәк мал таләп итүеңне аңлыйм, әмма зәгыйфьләрнең догасы Аллаһы тәгалә каршында сөеклерәк. Алар үтенече безне җиңүгә китерде»,— дигән мәгънәдә иде. Боларны ишеткәч, Әбу-Ваккасның акылы яктырып, нәфесе артка чигенде һәм ул үзенә бәйле сугыш вакыйгаларыннан пәйгамбәргә хәбәр бирде:

— Мин карендәшем Гамирне бу орышта югалттым. Ул һәлак булды. Ә үзем исә Сәгад бине Әл-Гасны үтердем һәм аның кылычын алдым. Ул кылыч минекеме?

— Юк, син аны монда алып кил, ганимәт буларак, ул кылыч та шушы әйберләр арасында торсын,— диде аңа Мөхәммәд пәйгамбәр.

Әбу-Ваккас аны алып килергә китте. Әмма күңеле түренә нәфесе кабат оялап: «Аллаһы тәгалә боерыр, карендәшем һәлак булды, кулыма кергән малым да китте!» — дип вәсвәсәләнде. Әмма бераз җир узганнан соң, Коръәннән бер сурәне исенә төшереп, кылычны китерде һәм ганимәт маллары арасына куйды.

Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр каршындагы калкулык өстенә килде һәм Бәдер әһеленең исемнәрен атады. Бәдер әһеле дип шуларны әйтерләр, кемнәр шушы Бәдер сугышында шәһит киттеләр. Алар сигез сәхабә иделәр, аларның өчесе — мөһаҗирләрдән, бишесе әнсарилардән иде. Мөһаҗирләрдән: Госман, Талиха, Сәгад бине Әбу-Зәйд, ә әнсарилардан: Әбу-Ләбайә, Гасыйм бине Гади, Харис бине Хатип, Хувас бине Җабир һәм Харис бине Сәмәт иделәр. Иң әүвәл шулар исеменә атап ганимәт малы бүленде. Аннары пәйгамбәр Сәгад бине Гыйбәдәтнең исемен атады. Чөнки ул үз теләге белән сугышка беренчеләрдән булып керде. Беренче башлап ул кылыч орышты, каты яраланды. Шулай ук Сәгад бине Малик Сәгъдинең исемен атады. Ул яуга керер алдыннан гына һәлак булды. Аларның барчасына да Мөхәммәд пәйгамбәр өлеш чыгарды. Бәдердә шәһит китүчеләрнең туган-тумачаларына, гаиләләренә ганимәт малыннан бирелгәч, Әбу-Җәһилнең дөясен һәм кылычын үзенә алды, шуннан соң бишкә бүленгән табышның бер өлешен дин Исламның үсеше һәм ятимнәргә вә зәгыйфьләргә ярдәм өчен шулай ук үзенә алды. Мөхәммәд пәйгамбәр ул малларны соңыннан, Мәдинәгә кайткач, яуга ияргәме-юкмы дип, урталыкта адашып калган әнсариларга да бүлеп бирде, шул рәвешле аларның мәхәббәтен яулады. Калган биштән дүрт өлешне әнсариларга һәм мөһаҗирләргә, зәгыйфенә һәм батырына-гайрәтлесенә карамастан, һәммәсенә тигез итеп тапшырды.

Тагын шул мәгълүм булсын: Бәдер сугышына кадәр Зөлфекар кылыч Әбу-Җәһилнең кулында иде. Ганимәт малы буларак аны Мөхәммәд пәйгамбәр үзенә алды, әмма соңыннан Гали бине Әбу-Талипка шәхси батырлыклары һәм баһадирлык өлгеләре өчен дип, махсус багышлады. Шуннан бирле Зөлфекар кылыч Гали сәхабә кулына күчте һәм икенче төрле Ислам кылычы дип тә аталды. Аны тотканга Галинең үзен дә Ислам кылычы дигән исем белән йөртә башладылар.

Әсир калган корәишләр үз тормышлары өчен кайгырышып, язмышларын уңай хәл итүләрен теләп борчылдылар. Арадан бер кешене Әбу-Бәкергә күндереп:

— Аңа шуны җиткерсәгез иде. Ул безнең барчабызны да белә, аның кебек гадел кеше юк. Үтенечебезгә колак куеп, Мөхәммәд пәйгамбәргә бөтенебезне дә яклап сөйләсә иде. Безне катил кылмасыннар, каныбызны

агызмасыннар. Безнең өчен туганнарыбыздан сатып бирергә мал таләп итсен. Фидия кабул кылсын, каныбызга кызыкмасын,— дип үтенүен сораттылар.

Бу кеше, Әбу-Бәкергә килеп, әсирләрнең гозерләрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде һәм пәйгамбәрдән аларга карата рәхим-шәфкатьле булуны теләүләрен белдерде. Аның бу сүзләрен Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк кабул итеп алды һәм, Мөхәммәд пәйгамбәргә барсын да җиткерәсен вәгъдә кылып, әсирләргә моны тапшырырга кушты.

Аннан соң ул тоткын корәишләр хәзрәте Гомәргә шулай ук бер кеше күндерделәр һәм Әбу-Бәкергә әйттергән сүзләр кебек сөйләттерделәр. Ул да түгел, хәзрәте Фарукка бер кеше күндерделәр һәм шул ук сүзләрен-үтенечләрен җиткерделәр. Әмма Фарук хәзрәт аларның теләкләрен кабул итмәде, усал сүзләр әйтеп, үзләренә мәрхәмәт эзләмәсеннәр, диде. Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына килде. Анда Әбу-Бәкер Сыйддыйк мәҗлес корып утыра иде. Сөйләгән сүзе әсирләргә мәрхәмәт итү, аларны гафу кылу хакында булды. Ул шуларны пәйгамбәрдән теләде. Әмма Мөхәммәд галәйһис-сәлам урыныннан купты һәм мәҗлесне ташлап чыкты. Һичбер җавабы ишетелмәде.

Бераздан сөйләшүләре кабат яңарды. Хәзрәте Гомәр килде һәм Мөхәммәд пәйгамбәргә әсирләр хакында болай диде:

— Алар Аллаһы тәгаләнең һәм аның пәйгамбәренең дошманнары, алар сине ватаныңнан китәргә мәҗбүр иттеләр, үзеңне үтерергә теләп эзәрлекләделәр, өстеңә сугыш белән килделәр. Муеннарыннан чап. Аллаһы тәгалә аларның күз яшьләреннән сине бай итәр, мөлкәтле ясар. Болар кяферләр һәм халыкны һәлакәткә китерүчеләр, усаллык иясе. Араларыннан берсе минем кан дошманым, аны миңа тапшыр. Муенын өзәрмен. Гакыйльны Галигә тәгаен кыл, ул аның дошманы, үтерсен. Габбасны Хәмзәгә бир, башын чапсын! Кяферләрнең дуслыгы йөрәгебездән чыкты, Ислам дине терәгебез һәм газизебез булсын!

Хәзрәте Гомәргә дә Мөхәммәд пәйгамбәр җавап бирмәде.

Шунда Әбу-Бәкер кабат Мөхәммәд пәйгамбәргә килде һәм үгетнәсыйхәт итеп:

— Йа Рәсүлуллаһ, әсирләрнең барчасын да һәлак итмә, яхшылык һәм гаделлек белән эш йөртү кагыйдәсен ташлама! Әгәр дә аларның берсен Аллаһы тәгалә каршысына җавапка җибәрсәң, эчләреңдә ачу һәм үч алу хисе күтәрелер! — диде. Әмма пәйгамбәр бу юлысы да аңа җавап бирмәде. Аның ни-нәрсә уйлаганы, нинди гамәл кылырга җыенганы барсына да сер булып калды.

Хәзрәте Гомәр дә Мөхәммәд галәйһис-сәламгә икенче кат килде һәм әсирләр хакында фикерен кабатлады:

— Йа Рәсүлуллаһ,— диде ул.— Минем әйтер сүзем шул: боларның муеныннарыннан кылыч үткәр, башларын тәннәреннән кисеп ал. Мөселманнарның ачудан кабарган йөрәкләренә шифа бир!

Әмма ул бу килүендә дә җавапсыз калды. Мөхәммәд пәйгамбәр аның сүзен раслап яки инкарь итеп ник бер кәлимә әйтсен. Гүяки бу хакта бөтенләй дә ишетергә теләми иде.

Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк өченче мәртәбә килде. Гомәр сәхабә дә шушында иде. Мөхәммәд пәйгамбәрдән Әбу-Бәкер әсирләргә карата мәрхәмәтле булуын үтенде. Аның сүзләрен бу юлысы да ахырына кадәр тыңлагач, Рәсүл Әкрам урыныннан кузгалды. Җавап та бирел тормастан, чатырыннан мөселманнар каршысына чыкты һәм мөбарәк йөзен аларга күрсәтеп:

— Әбу-Бәкер сәхабәнең мисалы фәрештәләрдән Микаил мәләкне хәтерләтә. Ул миннән әсирләргә рәхим-шәфкать үтенә. Микаил фәрештә дә рәхим һәм шәфкать ияседер. Ул һәрдаим һәртөрле ялгышлыкларны гафу итәр һәм яхшылыклы булыр. Әбу-Бәкер дә дошманнарыбызга гафу таләп итә. Аның пәйгамбәрләр мисалы — Ибраһим галәйһис-сәлам. Ул да кавеменә рәхим-шәфкать итте. Хәтта үзен утка аткан вакытларында

кавеменә карата яхшылык теләүдән артыкны сөйләмәде. Шулай ук аның мисалы Гайсә пәйгамбәргә тарта. Ул да, үзенә һәлакәт китерүче халкының яманлыкларын күрә торып, аларга рәхимле һәм шәфкатьле булды, бары тик яхшылыклар гына теләде,— дип белдерде.— Ә Гомәрнең мисалы Җәбраил фәрештәдер! Кемнәр Аллаһы тәгаләнең әмереннән чыктылар, пәйгамбәренә җәбер-золым кылдылар, ул аларга газап иңдерде, һәммәсен җәзага тартты. Пәйгамбәрләрдән исә Гомәргә Нух галәйһис-сәлам тиңдер. Ул үзенең иманга килмәгән халкын туфан астына куйды, хәтта газиз улларының берсен һәм иң сөеклесен, денсезлеге өчен дип, көймәсенә кертмәде. Шулай ук Муса пәйгамбәр мисалына туры киләдер...

Моннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр бераз сүзсез торды һәм, кабат якты йөзен сәхабәләргә күтәреп:

— Сезнең арагызда фәкыйрь, мохтаҗ һәм зәгыйфь кешеләр бар, теләгәнегез әсирләрдән берәрсен алагыз. Әгәр дә туганнары алар өчен түләргә теләсәләр, маллы булырсыз. Әгәр дә инде аларда үчегез бар икән, үзегезчә хәл кылырсыз.

Шунда Мәсгуть сәхабә әйтеп куйды:

— Мин ишеттем, Әл-Әсһил бине Бизадан, Мәккәдә Ислам көч-куәт алды...

Әмма моңа Мөхәммәд пәйгамбәр, игътибар да итеп тормагандай, һичбер фикерен белдермәде. Бер сәгатьләп уйда утырды. Шуннан соң гына кабат телгә килеп:

— Әл-Әсһил бине Биза, ул сүзләрдән миңа шулкадәр рәхәтлек һәм җиңеллек килде ки, гомеремдә дә моннан артык сөенгәнем булмагандыр! — диде. Ахырда болай дип өстәп тә куйды:— Ничә төрле йөрәкләр бар — таштан да каты, ничә төрле йөрәкләр бар — ефәктән йомшак!

Шуннан соң Әбу-Бәкергә ишарәт ясады һәм әмерен бирде:

— Әсирләргә яхшы мөгамәләдә булыгыз, малы юк кешеләрне азат итегез! — диде.

Алар арасыннан беренче булып шагыйрь Әбу-Гузза телгә килде һәм:

— И хәзрәт, минем фәкыйрьлегем һәммәгезгә билгеле. Түләр өчен һичбер малым юк. Гаиләм фәкыйрь, авыр тормыш белән гомер кичерә. Бары тик биш кызым гына бар. Әгәр дә мине азат итсәң, һичбер вакытта да мөселманнарга каршы сугышка килмәм, һичкемгә дә җәбер-золым ясамам,— дип ант этте. Бу сүзләрен ишеткәч, Мөхәммәд пәйгамбәр мәрхәмәт итте һәм аны азат кылды.

Ул вакытта әсирләр арасындагы аксөякләрнең күбесе бер-бер төрле һөнәр серләрен белә һәм уку-язуда оста иделәр. Аларга Мөхәммәд пәйгамбәр әнсариларның балаларыннан унар-унарны шушы эшләргә өйрәтергә боерды һәм әйтте:

— Һәр әсирнең бәясе дүрт мең алтын акчадан артык булмасын һәм бер мең дирһәмнән ким куелмасын. Шушы таләпләр үтәлсә, алар азат кылыныrлар! — диде.

Шуннан соң Габбас өчен фидия билгеләнде. Әмма ул моның белән килешмәде һәм әйтте:

— Сезнең барыгызга да минем мөселманлыгым мәгълүм, бары тик корәишләр таләп иткәнгә генә бу сугышка килдем,— диде.

Мөхәммәд пәйгамбәр аның сүзләрен кире какты:

— Синең Ислам динендә икәнлегеңне Аллаһы тәгалә белә, ләкин син зур теләк белән безгә каршы сугышырга килдең. Мөселманга каршы мөселман сугышмас. Синең белән бергә туганнарың да килделәр, икесе дә: Гакыйль бине Әбу-Талип һәм Нуфал бине Әл-Харис. Алар өчен дә синнән фидия тиешле. Шулай ук хәлифәң өчен дә.

Рәсүл Әкрамның бу сүзләре агасы Габбасны аптырашта калдырды. Кулына кергән малга ихластан күңел салып, мөмкин кадәр аларны әрәм-шәрәм итмәскә, тагын да арттырыбрак җыярга тырыша иде. Кая ди ул үз җаның хакына акча түгү, әле монда бүтәннәр өчен дә аннан

суырмакчылар. Юк инде, Зәмзәм коесының суын сатып баеган Габбас бине Габделмотталип бу юлга бармаячак. Теләсә нинди хәйләне үзенең ярдәмчесе итәчәк, байлык бәрабәренә җанын фида кылачак, әмма...

— Минем ул кадәрле акчам юк, аларның барсы өчен дә мин түли алмыйм, көчемнән килми,— диде ул.— Бу кадәрле малны кайдан алырмын? Минем нәрсәм дә юк...

Аның шушы рәвешле сөйләвен Мөхәммәд пәйгамбәр елмаеп кына тыңлап торды да:

— Уйлап кара, шулай микән? — дип белдерде.— Мәккәдән чыккан вакытыңда хатыныңӨммел-Фазыйләгә алтыннарыңны бирдең һәм әйттең, әгәр мин бу сәфәрдә үлеп калсам, син бер микъдарын үзеңә ал, калган микъдарларын балаларыма тигез итеп бүлеп бир, дидең.

Бу сүзләрдән Габбас бине Габделмотталип гаҗәпкә калды, әүвәле нәрсә әйтергә дә белмәде, аннан соң:

— Моны сезгә кем хәбәр итте, бу хакта бит хатынымнан һәм үземнән бүтән һичбер кеше белми! — диде, хакыйкатьнең авырлыгы аны борчуга салган иде, серен ничек чишкәнен аңламый да калды.

— Раббым хәбәр бирде! — диде пәйгамбәр.

Габбас өчен моңнан да артык могҗиза һәм Аллаһы тәгаләнең Бер һәм Барлыгына дәлил була алмый иде.

— Алтыннарымны хатыныма калдырганны Аллаһы тәгаләдән гайре һичкем белмәстер,— диде дә,— чын күңелемнән инандым, Аллаһы тәгаләдән бүтән илаһи зат юк, шаһитмын, Мөхәммәд — аның пәйгамбәре! — дип иман китерде, хак мөселман булды.

Тагын да шул билгеле иде: Мәккәдән корәишләр гаскәре чыкканда үзләре белән, юлда ризык юнәтү өчен дип, шактый гына күләмдә алтын акчалар да алган иделәр. Моны Габбас бер кешедән ышанычка кереп, үз исеменә тапкан иде. Әмма сугыш вакытында ул алтыннар, ганимәт малы буларак, сәхабәләр кулына керде. Аларны хуҗасына ничек тә Габбас үзе кайтарып бирергә тиеш иде. Шунлыктан мөселманнарга бик тә үтенде:

— Шушы алтыннар минеке иде, аларны минем фидиям дип кабул итсәгез иде! — диде. Әмма моны кабул кылмадылар. Мөхәммәд пәйгамбәр дә:

— Әгәр дә бер-бер нәрсә кяферләрнең гаскәреннән күчкән, сугышта югалтканнар икән, ул әйберләре безгә күчкән исә, алар ганимәт малы саналырлар, фидия булмаслар,— диде.

Чарасыз калган Габбас фидияне, ягъни әсирлегеннән котылу өчен түләү хакын йөз вакыйа (үлчәм) авырлыгында алтын белән бирергә вәгъдә итте. Аның байлыгы моннан шактый күп иде. Мәккә шәһәрендә Габбас кебек зур мал ияләре бик сирәк иде. Әмма биргән вәгъдәсе белән сәхабәләр килешенгәндә Җәбраил фәрештә Мөхәммәд пәйгамбәргә хәбәр бирде:

— Һичбер пәйгамбәргә үзенең дошманнары булган кяферләрдән фидия алу лаеклы эш түгел, кирессенчә, кяферләрнең һәлакәтенә таләбен тотарга тиешледер. Кяферләр җәбер-золым ияләредер. Исламның җиңүе өчен аларның һәлакәте кирәктер... Аллаһы тәгалә газиздер, үзенең дусларының җиңүен теләр, Аллаһы тәгалә хакимдер, үзенең дошманнарының һәлакәтен таләп итәр, дусларының үзенә лаек булуын теләр...

Икенче көнне иртә белән Гомәр сәхабә Мөхәммәд пәйгамбәрнең каршысына килде. Әмма анда Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйкны елаган хәлендә күрде һәм:

— Йа Рәсүлуллаһның аркадашы, ни сәбәпле болай кайнар күз яшьләреңә юл ачтың? — дип сорады.

— Йа Гомәр, фидияга риза булдым,— дип ерак түгел үсеп утырган агачка ишарәт итте ул — сәхабәләргә тиешле газапны миңа атадылар, шушы агач төсле ялгызыма,— диде.— Аллаһы тәгаләдән хәбәр ирешмәсә, Ләүхел Мәхфүздә Аллаһы тәгалә сезгә әсирләрдән, ягъни аның дошманнарыннан фидия таләп иткәнегезгә күрә газабын тәгаен кылган иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр әсирләргә газап тиешле дип белдерде. Мөселманнар да, әсирләрне фидия белән сатарга уйлаулары сәбәпле, күпчелеге казаландылар. Аларга да Мөхәммәд пәйгамбәр:

— Сезгә дә газап тиешле,— дип белдерде.

Әмма арада хәзрәте Гомәр белән Канәдәт сәхабәләр генә корәишләргә һичбер гафу булырга тиеш түгел дип белдергәнлекләреннән, алар Аллаһы тәгаләнең газабыннан имин калдырылдылар.

Шул билгеле: әсирләрне кабат Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына китерделәр. Араларыннан Нәзыйр бине Әл-Хариска Рәсүл Әкрамның карашы усал булып төште. Моны ул сизенеп алды һәм хәвефләнде, курка калды һәм янындагы иптәшенә:

— Сезденме, Мөхәммәд миңа бик авыр караш ташлады. Күңелем сизенә, мине катил итәрләр,— диде. Әмма иптәше аның белән килешмәде:

— Син артык курыккансың, хәвефләнүең җиткән. Шул сәбәпле бу рәвешле уйлыйсың,— дип, аны юатырга керешге.

Нәзыйрга моның белән генә тынычлык килмәде, ул шунда Мөсагыйп бине Гамруга мөрәҗәгать итте һәм аннан болай дип үтенде:

— Синең миңа туганлыгың бар, Мөхәммәдкә әйт, башкаларга нинди җәза бирсә, миңа да шундыйны атасын, әгәр дә аларны азат итә икән, мине дә азат кылсын, әгәр дә аларны катил итәргә боера икән, мине дә катил ясасыннар,— диде.

Аның сүзләрен Мөсагыйп тыныч кына тыңлап торды. Аннан соң үз алдына: «Бу да үзен бүтәннәр белән тиң куярга җөрьәтләнә икән. Нигә элгәрерәк уйламаган?» — дип фикер йөртте. Хәтерендә Мәккәдәге тормышы яңарды. Ул вакытларда Назыйр бине Әл-Харис Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм мөселманнарга һәртөрле җәбер-золымнар кылуда кайбер эшләрне башлап та йөргән иде бит. Инде җәза көне килеп ирешкәч, үзен яхшылар рәтенә куярга телиме? Шулай шул, гамәлеңнең башын-ахырын уйлап кылмасаң, соңыннан аяныч хәлләргә каласың! Һәр эшеңне гадел һәм дөрес дип үлчәү башкарганда да мең ялгышасың түгелме?

Адәм баласы шулай инде ул, гайрәтле чагында ни кылганын белмичә уйлап та тормастан эшли. Ә көннәрнең берендә кӧтелмәгән җиреннән казага юлыга, әүвәл кылган эшләре өчен җәзасын тарта башлый. Үзенең кайчандыр бүтәннәргә гаделсезлек кылганнарын онытып, усаллыкларын хәтереннән чыгарып, тәүбәгә дә килмичә, нәфесенә карата мәрхәмәтлек таләп итәргә тотына. Бу хакыйкать кешелекне тарихлардан алып бүгенге көненә кадәр озата килә. Аның катнашы белән илләр җимерелә, халыклар харап була. Аның ярдәме белән берәүләр дәрәҗә алалар, икенчеләре исә мәйданнан китәргә мәҗбүр булалар. Аларны бездә күңел күзләре сукыр кешеләр, диләр. Хәтерсезлектән ул. Кемнәр үткәнен, тарихны белми һәм хәтерләми, алар киләчәкне дә аңламый, тарихи үсеш барышын да тоймый. Хәтер ул үткәнне белер өчен генә түгел, бәлки киләчәгеңне ачык күзаллауда да кирәк. Без күп телгә ала торган максат һәм теләк тәэсире сәбәпле, аларга артыгын игътибар итү аркасында бәндәләрнең күңел күзләре ябыла, кылган гамәлләрендә гаделлек югала.

Нәзыйрга Мөсагыйп боларны ничек әйтсен инде. Аңлатып торырга вакыты булмады, әмма үз сүзен белдерми калмады:

— Син, Нәзыйр,— диде ул,— сәхабәләргә күп яманлыклар кылган кеше, Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзенә дә артыгы белән җәфалар ясадың, Коръәне Кәримгә дә тел озайткан кеше син булдың, болар өчен җәзасыз калырмын дип уйладыңмы? — дип, йөзеннән чирканып, карашын алды, аны күрергә теләге юк иде.

Әмма Нәзыйр, батып барганда саламга ябышкан төсле, котылырга ярдәм итүчесе дип, аның кулларына үрелде, башка яктан сөйләп, Мөсагыйпны күндерергә уйлады:

— Әгәр дә корәишләр кулында әсир калсаң, мин сине катил кылдырырга бирмәс идем, син бит минем туган тиешлем! — дип үтенде.

Ә Мөсагыйп исә монафикъның бу сүзләренә бирешмәде. Артык сөйләшеп торырга һич тә теләге юк иде. Туган дип аталган кешесе булса да, аны берәр тапкыр якын күрдеме, ашына, сыена чакырдымы? Юк! Алай итмәде, киресенчә, мөмкин кадәр мыскылларга, көлеп гайрәтен чиктерү ягында иде. Кемнең кулына кермәс ул байлык, мал, мөлкәт. Әмма аңа карап кына тәкәбберләнергә ярамый соң? Туган туганының көтү көткәненә шат дип яшәргә ярамый шул.

— Гәрчә син шулай әйтсәң дә,— дип кырт кисте Мөсагыйп,— мин алай итмәм! Ислам дине безнең мөнәсәбәтләребезне бозды!

Аларның туганлыклары ерагайган кебек, аралары да җылынмас дәрәҗәдә суынган иде. Дөрес, Мөсагыйп асылда Нәзыйрга үлем теләми иде, әмма ул гадел хөкем көтте. Шунлыктан аны яклап бер генә сүз дә әйтмәде һәм кирәк дип тә тапмады. Алай ук каты бәгырьлеләнергә ярый иде микән?

Гали бине Әбу-Талип сәхабәгә Мөхәммәд пәйгамбәр әмер бирде:

— Нәзыйрнең муенын чап!

Шунда Мөкадәт сәхабә бу карарга каршы чыкты:

— Ул минем әсирем, йа Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре,— диде.— Ул бит минем әсирем!

Аның болай сөйләвенең сәбәбе шул иде: Мөкадәтнең байлыгы булмады, кулына әсир төшкән Нәзыйрдан фидия алып, тормыш хәлен яхшырту иде исәбе. Әмма бу ниятендә Аллаһы тәгаләнең теләгенә буйсынмау билгесе ачык күренде, аңа Раббының каһәре ирешергә мөмкин иде. Шунлыктан Мөхәммәд пәйгамбәр кичекмичә Аллаһы тәгаләгә мөнаҗәт белән бер дога әйтте һәм үтенде:

— Йа Раббым,— диде,— Мөкадәтне рәхим-шәфкатең белән канәгатьләндер, байлык иясе ит!

Рәсүл Әкрамның әмеренә буйсынып, Гали бине Әбу-Талип шунда мөнафикъ Нәзыйрның башын чапты. Бу вакыйгадан күпләр бик нык тәэсирләнде. Бигрәк тә карендәшенең күңеле киселде, сагышланып, бер бәет чыгарды һәм аны мөселманнарга сөйләде. Ахырда аның шигыре Мөхәммәд пәйгамбәргә иреште. Каршында ул әсәрне укыдылар. Күңеле йомшап китте һәм:

— Әгәр дә ул минутта шушы шигырьне ишеткән булсам, Нәзыйрны катил иттермәс тә идем,— диде.

Әлбәттә, һәркемгә билгеледер, Мөхәммәд пәйгамбәр шигырьне Шайтан чыбыркысы дип хәдисендә әйткән. Әмма сүз монда ул хакта бармый. Мөхәммәд пәйгамбәрнең гадел затлардан икәнлеге тарихлардан мәгълүм. Шунлыктан, бу шигырьне ишетеп, күңеле кузгалуы һәм йомшарып китүе бик тә табигый. Пәйгамбәрләр ялгышмыйлар. Аларны, ялгышсалар да, аяклары тайган дип кенә әйтәләр. Золым иясе кяферне катил итүе Аллаһы тәгаләнең теләге белән кылынганлыктан, Нәзыйрның башын чаптырганда ул ялгышмады. Әмма шигырьне ишеткәч, ни хикмәт, «аягы таеп китте».

Әсирләр арасында үзенең тупаслыклары белән дан тоткан, мөселманнарга Мәккәдә шактый күп җәбер-золымнар кылган тагын бер монафикъ бар иде. Аны Гутбә бине Әбу-Мөгыйт дип атап йөрттеләр. Көннәрнең берендә, Мөхәммәд пәйгамбәр Кәгъбәтуллаһта намазга утырып, сәҗдәгә иңгәч, ул аның аркасына кан-тизәк белән укмашкан дөя эчәгеләрен китереп өйде, аны хакарәтләде. Аның бу кыланышларыннан пәйгамбәр җәберләнде, бәгыре киселде, сагышланды, әмма усаллык белән җавап бирә алмады һәм алай итәргә теләмәде дә.

Бәдер сугышы вакытында Мөхәммәд галәйһис-сәлам дога укып, Гутбә бине Әбу-Мөгыйтның әсир төшүен теләде. Орыш вакытында бу мәлгуньне аты, арт сикертеп, җиргә ыргытты. Шунда Габдулла бине Сәлмә аны әсир итте.

Мәдинәгә кайтып килештә, тукталуларының берсендә Мөхәммәд пәйгамбәр үз янына Гасыйм сәхабәне чакырды һәм Әбу-Мөгыйтне

китерергә һәм башын чабарга боерды. Әмма мәлгунь бу тормышка теш-тырнагы белән ябышты, үләсе килмәде һәм әйтте:

— Бу кадәрле әсирләр арасында минем башымны чабарга сәбәп нәрсәдә? — диде, йөзе агарып, артка чигенде. Әмма Габдулла аны җибәрмәде, тезенә кабат утыртты.

— Сәбәп шул,— диде Мөхәммәд пәйгамбәр,— Аллаһы тәгалә һәм аның рәсуленә дошманлыклар кылдың!

Гутбә гафу сорый башлады һәм:

— Миңа яхшылык итсәң иде? — дип үтенде.— Кавемеңә нәрсә кылырга теләсәң, миңа да шуны эшлә, әгәр дә аларны тәмам һәлак итәм дисәң, мине дә катил ит, әгәр аларны азат кылырмын дип уйласаң, миңа да азатлык бир. Ни теләсәң, шуны кайтарырмын. Фидия сорасаң, бирермен, җаның ни тели, шуңа риза булырмын! — диде. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр аның сүзләренә колак салмады, илтифат юллап тормады, бары тик: «Башын чабарга!» — дип ишарәт кенә ясады.

Әбу-Мөгыйт өзгәләнеп-өзгәләнеп сорады:

— Йа Мөхәммәд,— диде.— Балаларым ятим кала, аларны кем сыендырыр, аларга кем ризык бирер? Рәхим-шәфкатеңне өмет итәм? Балаларымны кем сыендырыр?..

Әмма пәйгамбәр карарын үзгәртмәде. Бары тик Гасыйм сәхабәгә:

— Әмеремне җиренә җиткер! — диде.

Ул минутта Гасыйм сәхабә әзер тора иде, тезләрендә чүккән хәлендә һични белештерми калган Әбу-Мөгыйт ләгыйньнең муенына кылыч белән орды. Башы, өзелеп, туфракка маңгае белән килеп төште, гәүдәсе читкә ауды.

Мөхәммәд пәйгамбәр аның өстенә килде дә:

— Йә, ярамас кемсәнә, Аллаһы тәгалә хакы өчен, синең кебек бер генә кяферне дә белмәдем. Раббыны, пәйгамбәрен һәм Коръәнне хәкарәт кылдың. Аллаһыга шөкер, синең һәлакәтеңне миңа күрсәтте, кайнар яшьләр түккән күзләремне якты итте,— дип әйтте. Йөзендә Ислам диненең өстенлеге өчен сөенеч һәм горурлык барлыгын һәркем күрде. Һәрбер ләгыйнь үзенең һәлакәтен тапты. Моңа мөэминнәр канәгать калдылар.

Корәишләрдән Гамру бине Әбу-Суфийанны гали сәхабә әсирлеккә алды. Мөхәммәд пәйгамбәр аңа һичбер төрле хөкем дә чыгармады, Мәдинәгә китереп, аны зинданга салдылар. Әтисе Әбу-Суфийан бай кеше һәм күп кенә сәүдә малларын кулында тоткан кеше буларак, шушы малаена фидия түләп, тоткынлыктан азат итә ала иде. Әмма ул моны теләмәде, күңеле байлыкка хирыс булганга күрә, улын малыннан түбән күрде. Гамру һаман да әтисеннән ярдәм өметендә кала бирде. Зинданда гомере авырлык һәм мескенлек белән узды. Бу хәленнән Мәккә корәишләре хәбәрдар булдылар һәм Әбу-Суфийанны үгетләп карадылар:

— Күкрәктәге җаныңа тиң балаң, бәгырь параң сәхабәләрнең тоткынлыгында иңри. Аларга сораганнары кадәрле фидия биреп, улыңны әсирлектән азат кылсаң иде. Моңа без дә канәгатьлек табып, хушланыр идек,— диделәр.

Әбу-Суфийан исә аларның теләкләрен кире какты. Бәдер сугышында катнашкан улларының берсе орыш вакытында һәлак булган иде. Ул үзенең йөзенә шул хакта хәсрәтләнүе билгеләрен чыгарды, батырлыкларын исенә алып, күзләрен яшьләндергәндәй итте. Әмма үтенеч һәм киңәш биреп килгән корәишләргә:

— Ул орышта мин улымны югалттым, инде дә әсир төшкән малаем өчен акчаларымны сарыф итәсем юк. Берьюлы ике югалту теләмим,— дип кенә кырт кисте.

Гамру шул рәвешле һаман да зинданда кала бирде. Әтисенең аннан баш тарту хәбәре Мәдинә әһеленә ишетелгәч, моны улы да белеп алгач, хәле тагын да начарланды. Аның кайгысы һичкемне борчымады. Беркемгә дә кирәге юк иде. Әмма мөселманнар аны әсирлектән азат кылмадылар, зинданнан да чыгармадылар, катил итәргә дә фәрман

иремшәде. Гамру, ничек тә булса кеше җибәреп, Әбу-Суфийаннан фидия биргәнен көтеп зарыгуын әйттерергә теләде. Ата кеше улын бу хурлыкларда калдырырга тиеш түгел иде бит. Бәлки, аңа дөрес хәбәр итмәгәннәрдер? Гамруның исән-саулыгын ишетсә, үзе чабып килер, мал-мөлкәтен кызганмас. Кемне-кемне, ә ир баланы гарәпләр бәхет урынына күрәләр түгелме соң? Гамру тугач, сөйләүләренә караганда, сөенечтән Әбу-Суфийан өч көн туйлап, Мәккә халкы каршында мактанып, мин кем дип масаеп йөргән иде. Мөселманнар, Гамруны әтисенә каршы юри котыртыр өчен генә, акны карага буяп, ялганлап сөйли торганнардыр. Калдырмас аны дошманнары кулында, зинданнан чыгартыр, азат иттерер. Әтисе дә баш тартса, кемгә таянсын инде ул? Мөһаҗирләр бер-бер хәйлә кылалардыр, Гамруны Ислам диненә күчсен өчен юри шулай сөйлиләрдер? Аларга ышана торган заманмы соң хәзер, кан карендәшләрен дә Ислам өчен катил кылдылар түгелме?

Гамруның күңеле китек иде. Җай эзләде. Мәккәгә мөселманнар бармас инде? Ничек эш итәргә? Ул тәмам аптырашта калды. Шул рәвешле күп вакытлар зинданда бәхете ачылганын көтте. Мәккә тарафына сәфәр чыгучылар булса, әтисенә хәбәр бирүләрен үтенмәгән көне калмады. Әмма бу эшне үз өсләренә йөк итеп алырга теләүчеләр күренмәде. Гамру ул хәбәрне илтергә кем дә булса алынса, аңа бүләкләр вәгъдә кылды.

Сәгад бине Ногман бик карт кеше иде. Гамруның вәгъдәләрен ишеткәч, миңа Әбу-Суфийаннан куркырлык түгел, үтерсә, гомерем юлы инде артыгы белән кичелгән, офтанасы юк дип, бу эшкә алынырга уйлады. Әгәр дә сөйләшүләр һәм йөрүләре уңышка китерсә, картлыгын тәэмин итәр өчен бераз байлык кулына керәчәк, балаларына да өлеш чыгарырлык кына булачак иде.

Гамру белән килешенеп, кабиләсе һәм карендәшләреннән изге теләкләрне кабул кылып, Мәккә шәһәренә таба юлга чыкты. Әмма барыр җире хәвефле иде. Кавеме каршысында дәрәҗәсе һәм хөрмәте камил дәрәҗәдә олуг булу сәбәпле, аның хакында күпләр сагышта калдылар. Шикләре хактан да урынлы иде. Соңыннан боларны исләренә алып, үзләренә шактый кайгырышырга туры килде.

Сәгад бине Ногман Мәккә шәһәренә килеп, Әбу-Суфийан каршысына күнде. Әмма байгураның бу хәбәргә ачуы гына чыкты һәм бу сагышлы картны, тотып, зинданга салды, кавеменә хәбәр юллады:

— Улым Гамруны азат кылып, Мәккәгә китермичә, Сәгад бине Ногманны зинданнан чыгармам! — диде.

Кабиләсе Әбу-Суфийанның шушы сүзләрен ишеттеләр, аның ләгыйньлегенә таң-гаҗәеп калдылар. Бу кадәр дә мәрхәмәтсез һәм акылдан мәхрүм кемсәнәләр булса булырлар икән, дип сөйләштеләр, Ногман өчен кайгы утлары йоттылар. Мыскыллandылар. Ачу кайтару мөмкин эш түгел иде. Мөхәммәд пәйгамбәргә килеп, Гамруны үзләренә тапшыруын үтенделәр, вакыйгаларны бәйнә-бәйнә сөйләп бирделәр.

— Кяфердә мәрхәмәт булмас! — диде аларга Рәсүл Әкрам. — Алар үзләрен генә түгел, хәтта балаларын харап итәргә әзерләр, күңелләре ябык, күзләре сукыр, йөрәкләре урынында — таштыр! Мөһаҗирләргә җәбер-золым салырга җөрьәт кылып, тантанада гомер сөрүдән артыгын белмәделәр. Аларга тәмуг ишекләре ачыктыр! — дип, Гамру бине Әбу-Суфийанны шушы кабиләгә багышлады, теләкләрендә ничек, шул рәвешле аның белән гамәл кылырга боерды.

Пәйгамбәрнең сүзләреннән һәм гадел хөкеменнән күңелләре хушланды. Гамруны зинданнан чыгарып, Мәккәгә китерделәр.

— Мөселманнарны ничек үземнең теләгемә буйсындыру юлын белермен! Күрдегезме? Ни рәвешле теләдем, шулай булды! — дип, Әбу-Суфийан тантана итте, үзенең хаксызлыгы турында уйлап та карамады. Мәдинәдән килүчеләрне һәртөрле сүзләр белән кимсетеп һәм оятлы кыларга омтылып, теләсә нәрсәләр әйтте.

Сәгад бине Ногманны зинданнан чыгардылар. Озын гомер юлы үткән, күпләрне күргән, дөньяның ачысын-төчесен күп татыган ул карт шунда кавеме кешеләренә:

— Бу җир йөзендә кемнәрне белмәдем дә, кайсыларын гына очратмадым, әмма монафикъ Әбу-Суфийан кебек миһербансыз кемсәнәне һәм Мөхәммәд пәйгамбәрдәй гаделлек иясе затны тапканым юктыр! — диде.— Әбу-Суфийан артыннан иярүчеләр тәмугка керерләр, Мөхәммәд пәйгамбәр чын мәгънәсендә Аллаһы тәгаләнең олуг пәйгамбәре, аның юлыннан йөрүчеләр җәннәткә юл алырлар, мин моңа инандым,— дип, йөзенә шатлыктан күз яшьләрен йөгертте.

Мәдинәгә якынлашып килгәндә Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләрдән Зәйд бине Харисны һәм Габдулла Рувахины үзләренең җиңү белән кайтуларын хәбәр итәр өчен алдан җибәрде. Алар, атларына атланып, гаскәрдән аерылдылар һәм, икесе бергә узыша-узыша, кала юлыннан чаптырдылар. Мәдинә күренә башлагач, тукталдылар, Габдулла шунда Зәйдтән аерылды. Ул шәһәр читендәге йортларга хәбәр салырга тиеш иде. Зәйд исә Мәдинәгә туры кереп китте һәм барчаларга сөенечне җиткерергә карар кылды. Пәйгамбәрнең йорт әһелләренә барып, иң әүвәл аларга хәбәр бирергә тиеш иде.

Габдулла ат өстеннән дә төшмәстән, шәһәрнең югары очына күтәрелде һәм көчле тавышы белән аваз салды:

— Әй Мәдинә халкы, ишетегез! Әнсарилар, барчагызга иминлек ирешсен! Хәзрәте саллаллаһу тәгалә галәйһи вә сәлләм сихәт һәм сәламәт булып, мөшрикләр катил ителде. Корәишләрнең аксөякләреннән Әбу-Җәһил, Гутбә, Шәйбә һәм шулар кебекләре һәлакәтләрен таптылар! Сөһәйл бине Гамру кебек тагын да берничә кемсәләре әсир төштеләр! — дип кычкырды.

Гасыйм бине Гайда, боларны ишеткәч:

— Кемнәр-кемнәр диден? — дип сорады.

— Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәренең яраннары дошманнарын куллары бәйле килеш китерерләр,— диде хәбәр бирүче.

Габдулла шуннан Мәдинә шәһәренең читендәге һәр йортка аерым килеп, аларга шатлыкны белдерде. Әмма халык аның нәрсә әйткәнен ачык төшенмәде. Мөхәммәд пәйгамбәр үтерелгән, сәхабәләр әсир алынган дип аңладылар. Габдулланың яшь балалары гына әтиләре янына сөенешеп килделәр. Халык йөзендә, ни сәбәп, сагыш һәм билгесез кайгы иде. Алар нәрсә теләделәр, Габдулла һичнәрсә аңламады. Шулай да үзләренең җиңүләрен һәм корәишләрне, әсир итеп, Мәдинәдән китерүләрен халыкка хәбәр кылып әйтүен туктатмады.

Бу көнне шәһәр эчендә тагын да бер кайгылы вакыйга булган иде. Хәзрәте Госман бине Гаффанның хатыны, Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Оркыя вафат. Аны озатырга дип халык җыелды. Һаман да әле аны гүргә иңдермәгән иделәр.

Зәйд бине Әл-Харис, Мәдинәгә кереп, халыкка аваз салды һәм корәишләрнең Бәдер сугышында җиңелгәнен, Әбу-Җәһил кебек аксөякләренең һәлак ителүен, күпләренең әсир төшүен, пәйгамбәрнең исән-сау булуын белдерде.

Әмма монафикъләр Зәйднең сүзләрен кире кактылар һәм аңа ышанмауларын белдерделәр. Арадан Исамәт әйтте:

— Безгә шулай хәбәр иреште: Мөхәммәд пәйгамбәр сугышта һәлак ителде, сәхабәләр әсир төштеләр. Моның билгесе һәм дәлиле шул: пәйгамбәрнең дөясе өстендә бүтән кешене күргәннәр,— диде.

— Минем хәбәрем дөрес! — диде Зәйд. Шунда Исамәт:

— Мин ул вакытта шул монафикъны эзләп табам,— дип китте һәм ялганчы яһүдинең якасыннан алды да:

— И монафикъ, син халыкны тәшвишкә салдың, аларга ялган сөйләп вәсвәсә кылдың. Рәсүл Әкрам кайткач, аның хөкемен таләп итәрмен, сине калабыздан кудыртырмын,— диде.

Яһүди курка калды.

— Мин бу сүзләрне үзем дә халыктан гына ишетеп сөйләдем, диеп акланды. Мөхәммәд пәйгамбәр шәһәребезгә хәлифә итеп калдырган Либабә бине Әл-Мөнзиргә бер монафикъ сөйләгәнен тыңлап тордым. Ул әйтте: «Сезнең сәхабәләрнең инде бергә җыйналып, бер урында яшәүләренә мөмкинлек калмады. Мөхәммәд пәйгамбәрегез катил ителде! — диде. Шуны ишетеп кенә сөйләдем. Болар берсе дә минем сүзем түгел иде.

Моны ишеткәч, Зәйд кабат Мөхәммәд пәйгамбәрнең җиңү яулап кайтуын халыкка хәбәр итте. Шунда гына аның сүзләренә монафикълар да ышандылар.

Икенче көнне Мөхәммәд пәйгамбәр Мәдинә шәһәренә әсирләрне китертте. Сәхабәләр гаскәре җиңү белән кайтып керде. Әсирләрдән әүвәле кулга алынган җитмеш корәештән ул вакытта бары тик кырык тугызы гына исән калган иде. Мөхәммәд пәйгамбәр аларны кол итеп сатарга юл куймады, әмма Мәккәдәге туганнарыннан фидия таләп итеп, аларны җибәрергә рөхсәтен белдерде.

Җиңү хәбәреннән Мәдинә халкы тантана итте. Бигрәк тә ганимәт малы аларны сөендерде, чөнки күпләрнең тормышы шул табышлар ярдәмендә көйләнеп китте. Әнсарилар да, мөһаҗирләр дә үзләренең дуслыгын һәм дини карендәшлегенең ныгыганлыгын тойдылар. Әмма якында һәм шушы ук шәһәрдә гомер сөрүче яһүдиләр һәм монафикълар курка калдылар. Бәдердәге җиңү белән рухланып һәм үсенеп китеп, мөселманнар аларны кысрыклый башларга, Мәдинәдән куарга мөмкин иделәр. Әмма гаделлек иясе Мөхәммәд пәйгамбәр моңа юл куймады. Һәммәсеннән бүтәннәргә карата яхшылыклы һәм гыйззәтле булуны таләп итте. Үз өлеше саналган ганимәт малыннан мул рәвештә һәртөрле бүләкләрне таратты. Сугышка барырга теләмәгән кешеләрнең эчләре көйде.

Монафикълардан Мәккәдә Әбул-Гас бине Әл-Рабигъ, Хәдичә хәзрәтләренең кыз карендәшенең улы, сәүдәгәрләрнең берсе, зур байлыклар белән дан алган кеше иде. Халыктан вакытлыча иманәт итеп, ягъни залог ясап, әйберләрен алып тора, килешенгәнчә түләп аларны ул кемсәнәләр үзләренә кайтармасалар, боларны да сәүдәсендә файдаланып, шактый табыш җыя иде. Аның эшләре яхшы барды. Сәүдәләре уңышлы оешты. Болар өстенә ул тагын дини мәсьәләләр белән шөгыльләнеп, корәишләр арасында ата-бабадан килгән гореф-гадәтләрне яклаучы, мәҗүсилек тарафдары, кяферләрнең таянычларыннан берсе иде. Дөньяви гамәлләрен дини эшләре белән бергә бәйләп алып баруы аркасында бүтәннәр каршында олуг мәртәбәләргә иреште. Ислам дине Мәккәдә тарала башлагач, моның хаклыгын инкарь итте. Мөхәммәд пәйгамбәр аңа бабасы тиешле, ягъни хатынының әтисе булуга карамастан, Исламга иярмәде, әмма мөселманнарны бик кимсетергә дә юл куймады. Бары тик вакыйгалар артыгы белән катлауланып киткәндә генә үзенең мәнфәгатьләрен саклар өчен уртага барып кермәде, бәхәсләрдән читләшү юлын сайлый иде. Аның үз-үзен шушы рәвешле тотуыннан кяферләр файдаланып кала иделәр.

Әйтеп киткәнебезчә, Әбул-Гас бине Әл-Рабигъ бине Габделгази бине Габдешәмс, мәхәббәте төшеп, Мөхәммәд пәйгамбәрнең гүзәл кызларыннан берсе — Зәйнәпкә өйләнде. Зәйнәпне әнисе Хәдичә яхшы тәрбия белән үстерде, Мөхәммәдкә пәйгамбәрлек иңгәч, кызын да Исламга чакырды. Шулай итеп, Зәйнәп үзе мөслимәләрнең гүзәлләреннән берсе иде. Чибәрлегенә һәм холкының күркәмлегенә, яхшы тәрбиясенә күрә аның кулын сораучылар аз булмады. Әбу-Ләһәп исә, Мәккәнең дан иясе байларыннан берсе, дине белән потларга табынучы һәм Аллаһы тәгаләне инкарь итүче кемсәнә, үзенең улы Гутбә бине Әбу-Ләһәпкә Зәйнәпне сорады. Алар белән якын кешеләр булып китү Мөхәммәд пәйгамбәр өчен дә мәртәбә иде, Хәдичә хәзрәтләренә дә сөенеч китерде. Әмма

яшьләр, матур гаилә корып, бер-берсен ихлас күңелдән яратып яши башлагач, араларына Әбу-Ләһәп төште. Аның кяферлеге котырды. Мөхәммәднең пәйгамбәрлеге, кызы Зәйнәпнең, ягъни Гутбәнең хатыны мөслимә икәнлеге халыкка мәгълүм булды. Моңа исә байлыгы сәбәпле күңел күзе сукырайган, холкы шактый бозылган, эчкечелектән тәм тапкан Әбу-Ләһәпнең ачуы чыкты. Зәйнәпне кудыртты, Исламга каршы дошманлык кылырга тотынды. Бу вакыйгалар Мөхәммәд пәйгамбәрне бик нык дулкынландырдылар, күңелен сагышландырдылар һәм ул шушы монафикъ Әбу-Ләһәпкә бәддога укыды. Гутбәнә яратуы Зәйнәпне бәхетле иткән иде, әмма хатынын яклый алмавы, хурлыкка калдыруы аңа рәнҗешен кузгатты, мәхәббәте нәфрәт белән алышынды.

Тагын шул мәгълүм, аларның зифаф кичәсе булмаган иде, ягъни Зәйнәпне үзләренә алдырса да, Әбу-Ләһәпнең улы Гутбә аңа якынлык кылырга өлгермәде. Ул вакытлардагы тәртип нигезендә, кыз, кияүгә чыккач, берничә көн яңа тормышка ияләшергә тиеш иде. Вакыйгалар менә шул чакта булдылар. Мәхәббәтләре өлгереп тә җитмәстән, бер-берсенең җылы кочагын татырга да җитешмичә, ике яр аерылыштылар. Бу хәлдән Зәйнәп күңелендә авыр яралар гына калды. Кеше алдына чыгарга оялды, әмма динен ташламады.

Мөхәммәд пәйгамбәр Зәйнәпне Гутбәдән аерды, талак кылды. Шуннан соң аны Әбул-Гас бине Әл-Рабигъка кияүгә биргән иде. Монафикъ булуына кармастан, бу ире Зәйнәпнең мөслимә икәнлеген белә торып өйләнде, әмма һичбер вакыт аны кимсетмәде, кешедән яман сүз дә әйттермәде. Мәхәббәте камил дәрәҗәдә иде. Зәйнәпнең чибәрлеге һәм арада беренче күркәм кызлардан икәнлеген ул яхшы белде. Мөселманлыкка күчәр дип Әбул-Гас хакында фикер йөртеп, монафикълар алдан чарасын күрергә уйладылар:

— Син Исламга кердеңме әллә — пәйгамбәрнең кызын алдың? — диделәр. — Сине инкарь итәрбез!

Ул вакытта сәүдәне Мәккәдә үз кулларында корәишләр тота иде, мөселманнарны базарга кертмәс өчен килешүләр төзеп, Әбу-Бәкер кебек мал ияләренә дә эшләрендә чиксез кыенлыклар тудырдылар. Әбул-Гас, байлык яратучы кеше буларак, әлбәттә үз мәнфәгатьләрен Аллаһы тәгаләнең теләгеннән өстен күрде. Табышын көннән-көнгә ишәйтергә тырышлык итте. Мөслимә хатынын яратып һәм хөрмәт итеп торуына карамастан, Исламны инкарь кыла килде. Моңа Мөхәммәд пәйгамбәрнең бер дә ризалыгы юк иде. Кызы Зәйнәпкә:

— Кяфер белән гаилә корып яшәү килешми, болай Аллаһы тәгаләнең ризалыгын тапмассың, яки ул иман китерсен, яки син, аны ташлап, йортыма кайт! — дип әйтеп тә карамады түгел. Әмма кызының җавабы бер генә төсле булды:

— И сөекле атам, минем кальбемә Аллаһы тәгалә мәхәббәт орлыклары салды, мин Әбул-Гасны яратып торам: аның белән яшәвемне бер бәхет дип саныйм. Аллаһы тәгалә бәндәләрен мәхәббәт өчен хөкем кылмас. Риза итә күр, — диде. Кызының үтенече белән килешмичә мөмкинлек калмады. Әмма пәйгамбәрнең күңеленнән Зәйнәп китмәде. Ул аңа бик тә кадерле иде.

— Монафикъ белән тору авырдыр? Динеңнән язарга теләп кылыр? — дип тә карады Мөхәммәд пәйгамбәр. Монысын Зәйнәп шулай ук инкарь итте. Чыннан да Әбул-Гас бине Рабигъ үзенең хатынын ярата һәм аны мөэминә булганы өчен генә кимсетергә, иманыннан кичәргә мәҗбүр кылырга теләми, киресенчә, бу сыйфатын өстен күреп, мөмкинлекләр куя иде. Ни дисәң дә Зәйнәптә, бүтән мөслимәләр төсле үк, монафикъ хатыннарыннан һәм кызларыннан аермалы рәвештә гыйззәт вә тәүфыйк, аңлатып бетерә алмаслык рухи өстенлек, мактарлык сыйфатлар шактый иде. Әгәр дә диненнән язса, ул аларны югалтыр дип курыкты Әбул-Гас.

Мөхәммәд пәйгамбәр, Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылгач, балаларыннан бары тик Зәйнәп кенә корәишләр арасында сөекле ире белән

яшәп калды. Аңа авырлыклар һәм кыенлыклар киләсен уйлап, Рәсүл Әкрам аны үз янына чакыртып та карады. Әмма Зәйнәп күнмәде.
Мәккә корәишләре Мөхәммәд пәйгамбәргә каршы сугышка күтәрелгәч, үзләре белән Әбул-Гасны алырга һәм Рәсүл Әкрамның бүтән карендәшләренә дә кылыч тоттырырга булдылар. Шулай эшләгәндә кан өчен үч алу мәйданга чыкмасын белеп эш иттеләр. Бәдер сугышында Әбул-Гас бине Рабигъ әсир төште. Аны имин хәлендә Мәдинәгә китерделәр, зинданга салдылар. Әбул-Гас, пәйгамбәрнең хөкем карарын көтеп, фидия түләү аша азатлык алу теләгендә кала бирде.
Мөэминнәренең тормышын бөтенәйтү ниятендә пәйгамбәрдән яхшылык илә әсирләр өчен Фидия таләбенә рөхсәт бирелде. Бары тик иман китерүчеләрдән генә Фидия таләп итү дөрес түгел санала башлады. Әбул-Гас, Мәккәдәге байлыклары өчен хәсрәт чигеп, аларның кулдан ычкынуыннан куркып, иман китермәде. Чөнки корәишләр мөселманнарның малларын үзләренә тартып ала иделәр.
Мәккәдән әсирләрне таләп итү өчен Мәдинәгә Фидия күндерелде. Зәйнәп тә ире Әбул-Гас өчен сагышланды һәм, Фидия буларак бер муенса җибәреп, аны әтисе Мөхәммәд пәйгамбәргә атады. Монда бербер хикмәт бар иде. Ул муенсаны әнисе Хәдичә, атап, кызы Зәйнәпкә Әбул-Гас кочагына кергән кичәсендә бүләк итеп биргән иде. Бу аның гыйффәт-сафлыгын саклаганы өчен аталганлыгын, ире белән бәхетле тормыш, тигез гаилә коруларына теләк икәнлеген пәйгамбәр дә белә иде. Хәдичәнең муенында йөргән шушы муенса, Зәйнәпкә күчеп, берьяктан, аның дәрәҗәсен күтәрсә, икенче яктан, әнкәсенең аңа мәхәббәтен дәлилләде. Мөхәммәд пәйгамбәр дә Зәйнәптә сөеклесе Хәдичәнең сыйфатларын күреп соклана иде.
Мәдинәгә Мәккәдән Фидия килеп ирешде. Мөхәммәд пәйгамбәргә кызы Зәйнәптән муенсаны тапшырдылар. Ул аны кулына алды, күңелендә Хәдичә турындагы изге хисләре уянып, күзләренә кайнар яшьләр сытылып чыкты, бите буйлап йөгерде. Таныды, Хәдичәнең муенсасын танымыйча мөмкин идеме соң? Кайчандыр ул аларны кочагына ала һәм сөеклесенең иңнәре белән бергә үбә иде. Бу муенсаларда аның яшьлеге дә, ирлеге дә, бәхете-шатлыгы һәм сагышлы минутлары да саклана төсле иде.
Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләргә мөрәҗәгать итте, үз исеменнән сөйләде һәм әйтте:
— Йа Аллаһы тәгаләнең сөекле кавеме,— диде,— әгәр дә Әбул-Гасны азат итсәк, Фидиясе белән бергә Мәккәгә кайтарып җибәрсәк, сез ничек карарсыз?
Пәйгамбәрнең гадәтендә, бүтәннәрнең әйтелгән сүзен тыңлаганнан соң, уйлап, үлчәп бетергәч, кенә эшне хәл кылу сыйфаты бар иде. Сәхабәләр исә Фикерләрен белдерергә ашыкмадылар.
— Минем теләгем шушы иде: Әбул-Гас үзе белән бергә сезгә тиешле Фидияне алсын, әмма кызым Зәйнәпне миңа кайтарсын! — диде пәйгамбәр. Шунда гына аның ни-нәрсә хакында сагышланганын мөселманнар аңладылар.
Бу мәсьәлә барсына да билгеле иде. Кайберәүләр, Мәдинә шәһәренә: «Зәйнәп мөэминә түгел икән, шул сәбәпле, пәйгамбәрнең кызы булуына карамастан, Мәккәдә калган»,— дип сүз тараткан иделәр. Бу исә мөселманнарның горурлыгына тия, намусларын кимсетә иде булса кирәк. Шунлыктан аларның йөзенә шатлык билгеләре чыкты, бәхетләре зураеп киткәндәй иде.
Әнсарилар һәм мөһаҗирләр пәйгамбәрнең теләген кабул иттеләр. Әмма Зәйнәпнең үз теләге хакында уйлап караучы да юк иде. Әбул-Гасны яратып яшәмәсә, Мәккәдә, монафикъләр арасында калыр идеме соң ул?!
Сәхабәләр Мөхәммәд пәйгамбәрнең теләге белән килештеләр һәм Әбул-Гасны, Зәйнәпнең фидиясе белән бергә, муенсаны яңадан сөекле

хатыны киеп йөриячәгенә ышаныч итеп, Мәдинәгә кайтарып җибәрделәр. Бу вакыйга исә барсының да күңелен кузгатканлык сәбәпле, шул ук вакытта мөселманнарның горурлык хисен дә нығытты. Әмма Әбул-Гас теләмәгән, шулай да буйсынырга мәҗбүр ителгән бер шарт бар иде: ул сөеклесе Зәйнәптән аерылачак һәм аны Мәдинәгә азат итеп җибәрәчәк! Яратышып гомер кичергән көннәренә, җылы хисләр белән тулы төннәренә чик куелачак. Сагынып кайткан җиреннән, хатынының назлы кочагында иркәләнергә дә өлгермичә, алар аерылышырга тиешләр. Нигә дип әле алар, мөселманнар, башларына юк-бар уй керткәннәр, имеш, кяфер кулында мөэминә Зәйнәп тоткын хеб к, читлектәге кош төсле, ни өчен? Әбул-Гас моңа җавап таба алмады. Әмма каршы килергә хакы юк иде. Әсирлектән азат ителүенең шартларыннан берсе шушы бит! Моңа кадәр вәгъдәләрендә торып та, моннан соң ничек бозсын ди инде ул аларны...

Мәккәдә Әбул-Гаска шартны үтәмәскә боердылар. Моңа кадәр Зәйнәпне мөслимә булганлыгы өчен кимсетергә әзер торган кешеләр, аның Мәдинәгә күченеп китүендә бер-бер яшерен сер барлыгын аңладылармы, әллә инде тагын да мәкерлерәк тозаклар кордылармы, аларын ире белештермәде. Ничек тә булса сүзендә торырга, шартны үтәргә мөмкинлек эзләде.

Мәдинәдән кайтарылган муенса Зәйнәпнең күзләренә яшьләр йөгерүгә сәбәп булды. Әнисе Хәдичә хәзрәтләренең ире Мөхәммәд пәйгамбәрне өзелеп яратулары, аларның бер-берсенә тиң килүләре, әтисенә вәхи ирешә башлагач, терәк итүләре — болар барсы да илаһи рәвештә шактый күтәренке һәм адәм балаларындагыча түгел, сәмави хисләр иде.

Зәйнәп белән Әбул-Гас ни хакларында сөйләштеләр, һичкемгә мәгълүм булмады. Әмма Мәккә кяферләре фараз кылдылар: мәкер бар! Имеш, Мөхәммәд белән сөйләшенгән булырдар, әүвәле Зәйнәпне Мәдинәгә күчереп, соңрак үзе дә аның артыннан китәргә уйлагандыр!

Корәишләрнең теләкләренә буйсынмыйча, Әбул-Гас, дөягә утыртып, Зәйнәпне Мәккәдән алып чыкты. Алдан сөйләшенеп куелганча, хатынын каршыларга, Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрбиясендә үскән Зәйд бине Харис, ягъни Зәйнәпнең карендәше аталган, аның өчен җанын да фида кылырга әзер булган кеше килергә тиеш иде. Әбул-Гас Мәдинәдән чыгып китүгә, Зәйдне аның артыннан күндерделәр. Әмма Әбул-Гас сөекле хатыны Зәйнәпне ялгызын гына юлга җибәрергә теләмәде, аның белән бергә үз энесе Кинанины да сәфәргә әзерләде. Кулына ук һәм җәя алып, Кинани дөягә утырды, Зәйнәпнең артыннан иярде. Әмма аларның юлга чыкканлыгын мөшрикләр белеп алдылар һәм хәрәкәткә килделәр. Зәйнәпнең артыннан төштеләр. Аларны куып тотып, каршыларына чыктылар. Ул вакытта Зәйнәп йөкле иде. Дөясен артык куа һәм чаптыра алмады. Монафиклар күренүгә, ни хәл кылырга белмәде. Әмма корәишләр аның дөясен куркыттылар һәм ул, бер арт чөеп, Зәйнәпне җиргә ташлады. Мескинә аһылдап куйды. Карынында йөрткән баласына зыян килде.

Әйтерләр, Мәдинәгә килгәч, Зәйнәпнең йөге төште. Моңа Мөхәммәд пәйгамбәрнең хәтере калды һәм корәишләргә бәддога укыды, кызына һәм туачак оныгына җәбер ясаган кемсәнәләрнең исемнәрен әйтә-әйтә, аларны тәмугка озатуны Аллаһы тәгаләдән үтенде.

Кайчан Зәйнәпкә корәишләр ябышты, шунда аның артыннан килеп җиткән Кинани кулына ук-җәясен алды һәм, корып:

— Кайсыгыз аңа зыян итә, аны шушы минутта атып үтерәм! — дип, җәберләүчеләргә төбәде.

Монафикълар артка чигенделәр. Шунда Әбу-Суфийан, эшнең ахыры яман буласын уйлап:

— Сабыр ит, кулыңны угыңнан ала күр, сүземне тыңла,— дип Кинанидан үтенде.— Без шуны ишеттек: Мөхәммәд үзенең кызын исән-имин Мәккәдән Мәдинәгә китерергә теләгән. Әгәр дә син ук атсаң, без дә

карап тормабыз, синең белән сугышырбыз. Икегезне дә һәлак итәрбез. Бел, безнең теләгебез аны тоткын кылу, зинданга салу түгел. Максатыбыз шул: хәзер үк кире Мәккәгә кайтыгыз, йортыгызга кирәгез. Бөтен кеше дә моны күреп торсын. Барсы да тынычланып йоклагач, төнлә белән юлга чыгарсыз!

Кинани Зәйнәпкә карады. Дөясеннән егылганнан соң, аның хәле авыр икәнлеге күренеп тора иде. Барыбер ерак китә алмаячаклар, аңа хәзер ял итәргә кирәк. Әгәр дә корәишләр сүзләрендә торсалар, аларда да хаклык бар.

— Ярар, мин сезгә тимәм, сез дә сүзегездә торырсыз!—диде Кинани, шунда ук-җәясен җыеп.

Сөйләшеп, уртак фикергә килүдән Әбу-Суфийан да канәгать иде.

Зәйнәпнең Мәккәгә кире кайтканын күпләр күреп тордылар, әмма төнлә юлга чыкканын ире Әбул-Гас һәм сәфәрчеләрнең үзләреннән бүтән һичкем сизенми дә калды. Зәйнәпне Кинани, шәһәрдән чыгарып, алдан көтеп торган Зәйд бине Хариска тапшырды. Алар исән-имин генә Мәдинәгә кайтып ирештеләр.

Берничә көннән соң Әбул-Гас, хатыны хакында сагышланып, Шам тарафына сәүдә кәрванын әзерли башлады. Күп кенә корәишләр аңа үзләренең малларын бирделәр һәм аның бу сәфәреннән табыш алырга теләделәр. Ни хикмәт, Шамнан кайтып килешли, Әбул-Гасның кәрванын мөселманнар гаскәре тоткын иттеләр, малларын талап алдылар. Әбул-Гас Мәдинәгә килде һәм хатыны Зәйнәпне очратты. Сагышларыннан арынгач, кәрваны белән булган вакыйганы сөйләде. Бу хәбәре Зәйнәпне борчуга салды һәм ул пәйгамбәр әтисеннән иренә карата миһербан үтенеп килде, Әбул-Гаска мәхәббәтен, аңа тугрылылыгын сөйләде, малларын кайтарып бирүне сорады. Шушы кадәр дә үтенечләренә Мөхәммәд пәйгамбәр каршы килә алмады һәм сәхабәләренә боерды:

— Бу маллар барсы да Аллаһы тәгаләнеке, аны сарыф итү, әрәмшәрәм китерүдә дөрес күрелмәгән гамәлләр бар, үзегезгә гөнаһы алмагыз. Әбул-Гасның безгә мөнәсәбәтен һәммәгез дә беләсездер. Күрсәткән хезмәтләреннән дә хәбәрдарсыз. Әгәр дә аның малларын кире кайтарып бирсәгез, гаять тә яхшылыклы хезмәтегез дип белербез, инде дә теләмәсәгез, үз ихтыярыгыз!—диде.

Мөселманнар аның боерыгына буйсындылар. Әбул-Гас исә кәрванын кире Мәккәгә китерде һәм һәрбер кешегә тиешле бурычын кайтарып, малларын өләште дә:

— И корәишләр,—диде,—миндә кайсыгызның да булса хакыгыз калдымы, бурычымны кабул иттегезме?—дип сорады. Алар:

— Безнең каршыбызда һичбер бурычың калмады,—диделәр.

— Ул вакытта мин сезгә шуны белдерәсем килә,—диде Әбул-Гас,—шаһитларым булыгыз: Аллаһы тәгаләдән бүтән һичбер илаһи зат юк. Ул барсын да белүче һәм күреп торучы, Мөхәммәд аның пәйгамбәре, илчесе. Мин моңа чын күңелемнән инандым. Сезгә дә, белеп торуыгыз өчен дип күңелемдәгеи җиткердем. Исламча һәм Ислам дине өйрәткәнчә яшәүне бәхеткә саныйм!..

Корәишләр өчен бу көтелгән сүз иде. Мөслимә Зәйнәп белән яшәп тә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең киявс булып та, һаман Ислам динен алмавы гына, кирессенчә, аларга сәер тоела иде.

— Сездән сорадым: кайсыгызга бурычым бар, дидем. Барыгыз да юк дип белдердегез. Шулай икән, минем Исламга килүемдә сезнең яктан каршылык булырга да тиеш түгел. Шунсы мәгълүмдер: кемнәр иман китерделәр, алар моны бүтәннәр каршысында белдерергә тиешләр. Бу таләпне дә мин үтәдем,—диде Әбул-Гас, сүзләренә йомгак ясап. Шуннан соң ул Мәккәдән чыкты һәм туры Мәдинәгә юнәлде. Корәишләр аның каршысында бурычлы иделәр, Зәйнәпнең карынындагы баласын төшерүдә гаепле булулары сәбәпле Әбул-Гасның бу карары белән килештеләр.

Мәдинәгә килгәч, Әбул-Гас хатыны Зәйнәп белән кавышты. Мөхәммәд пәйгамбәр аларга каршы төшмәде. Зәйнәпне, Мәдинәгә килүгә, пәйгамбәр белән туганлыкка керү өчен кемнәр генә сорап карамаган иде, әмма ул теләмәде. Бер-берсен яратучыларга аркылы төшү һичкемнең кулыннан килмәде, чөнки ике яр үзара бирешкән вәгъдәләренә тугры булдылар.

Бәдер сугышында корәишләрнең җиңелүен Мәккәдә көтмәгән иделәр. Ни дисәң дә, шушы кадәр зур гаскәрне аларның моңа кадәр сугышка озатканнары юк иде. Баштанаяк коралланып, орыш өчен һәрьяктан әзерләнеп киттеләр бит. Алар юлга чыгуга, хатыннары гүяки гомерләрендә беренче тапкыр ирләреннән ирек алган төсле кыландылар. Әле берсендә, әле икенче йортта мәҗлесләр кордылар, ашлар ясадылар. Биеделәр, җырладылар. Төрле шигырь һәм бәетләр сөйләп күңел ачтылар. Ирләренең җиңеп һәм баеп кайтасыларына чын күңелләреннән ышандылар. Вакытлары бу рәвешле рәхәттә һәм кәеф-сафада узды ки, хәтта күпләре йорт эшләрен дә онытып, гомерләрен киләчәктә дә шушы рәвешле кунактан-кунакка гына уздырырга ниятли башладылар. Әмма хакыйкать көтмәгәндә аларның өстенә кара канатын җәйде. Кичәләренең берсендә алар ирләренең сугышта җиңелүләре хакында хәбәр ишеттеләр. Күңелләре зәгыйфьләнеп, тәннәреннән саулыклары китте. Бик каты курыктылар. Шушы хәсрәтләреннән кайсылары авырый ук башлады.

Бу вакыйгадан соң ике көн узгач кына, яуга киткән корәишләрдән беренче булып Хисаман бине Габдулла Хизагый Мәккәгә кайтып ирешге. Аның иң әүвәл биргән хәбәре дә ике кичә элгәре ишетелгән сүзнең дөреслеген раслады. Ул гына да түгел, яуда һәлак булучыларны да, әсир төшүчеләрне дә исенә алды. Мәккәне хәвеф каплады.

Бу хәбәрне ишеткәндә Сафуан бине Өммийат үзенең өендә иде. Янында мәҗлес корып утыручыларны тынычландырырга ашыкты һәм:

— Хисаманның чыннан да акылы киткәндер, ул һичнәрсә белештерми сөйли, асыл вакыйгаларны күз алдына китерә дә алмый. Аңа минем әйткәннәремне җиткерегез,— диде. Кайдалыгымны сорагыз, аны да белми ул!

Мәҗлестәшләре аның яныннан чыктылар. Хисаман бине Габдулла каршына килделәр һәм Сафуанны сорадылар.

— Минем белүемчә, Сафуан бине Өммийат үзенең өендә калган иде, һаман да шундадыр, ансын күрмәдем, әмма аның әтисенә һәм ир туганына очрадым, алар һәлак ителделәр. Сөһәйл бине Гамру, Назыйр бине Әл-Харис кебекләр әсир төштеләр. Икесен дә бер бауга бәйләгән иделәр,— дип сөйләде ул аларга, вакыйгаларны яңабаштан бәян итеп.

Бу хәбәрләреннән Мәккә халкы шаша калды. Аларның хакыйкатькә һич тә ышанасылары килми иде. Кайсылары исә ишетелгән сүзләрне ялганга чыгарып маташты, әмма Әбу-Суфийан кайтып ирешкәч, аңа ышанмыйча мөмкин түгел иде, бәгырьләре көйде.

Әбу-Ләһәп Мәккәдә калган иде. Кайгылы хәбәрләрдән соң тәмам аптырашта йөрде, Әбу-Суфийанның кайтканлыгын ишеткәч, туры аңа юнәлде һәм:

— И туганымның улы, дөресен бары тик син генә белерсең, бары тик синә гына ышанырбыз. Вакыйгалар ни рәвешле булды, сөйләсәң иде?— дип үтенде.

— Мөхәммәд һәм аның сәхабәләренә килеп җиттек, бер коры җир иде, шунда аларга каршы сугыша башладык,— дип сүзгә керешге Әбу-Суфийан, җиңелү гарьлегеннән айный алмыйча.— Кулларыбыздан кылычларыбыз төште, беләкләребезне буып бәйләделәр. Шунда мин җир белән күк арасында моңа кадәр үземә очрамаган нииндидер адәмнәрне күрдем. Сугыш киемнәре кигән баһадир җайдаклар!

Әбу-Суфийанның шушы сүзләрен ишетүгә, аның хәбәрләрен тыңлап утыручылардан Габбасның колы, ул монда Габбасның хатыны Өммел-Фазыйләне озата килгән иде, исемен Әбул-Рафигъ диләр, тыела алмады:

— Алар мәләкләр булганнардыр! — диде.

Аның бу сүзен Әбу-Ләһәп ошатмады һәм ялт кына итеп Әбул-Рафигъның йөзенә йодрыгы белән китереп салды, әйләндереп җибәреп, өстенә басты да ачуланырга тотынды, типкәли башлады. Колын болай рәнҗетүенә каршы Өммел-Фазыйлә, күтәрелеп:

— Нишләвең бу, Әбу-Ләһәп? — дип кычкырды һәм аның башына таяк белән сукты. — Хуҗасы күрмәгәч тә, аның колларына ия дип белдеңме әллә үзеңне? — диде.

Әйтерләр, Өммел-Фазыйләнең ачуы яман хәбәрдән һәм дә Әбу-Ләһәпнең болай эшләвеннән кабарган иде. Таяк белән суккан вакытында боларны берьюлы чыгарып ташларга теләде. Әбу-Ләһәпнең башын ярды, җиде көннән соң мәлгуньнең җаны җәһәннәмгә олакты.

Кяферләр гаскәренең җиңелүе хәбәре корәишләр арасында кайда гына сөйләнелсә дә, тавыш-гауга чыгарды. Берәүләрнең хакыйкать белән килешергә теләмәүләре икенчеләрнең болай да кабарган ачуларын гына кузгатты. Җитмәсә, мөселманнарга мәләкләрнең ярдәмгә килүләрен Әбу-Суфийанның сөйләве аларның хәвефләрен тагын да көчәйтеп җибәрде. Баерга һәм мөһаҗирләрне куып кайтарырга киткән монафикъларның хурлыклы төстә җиңелүләре халыклар каршысында оят иде. Вакыйгаларның көтелгәнчә бармавы хәтта үзара ызгыш-талашлар, дошманлыклар да китереп чыгарды. Әле кайчан гына аштан-ашка йөргән хатыннар болай усалланасыларын уйлап та карамый иделәр.

Бәдер сугышыннан соң корәишләр, үз җаннарын саклар өчен төрлесе төрле тарафларга качтылар. Төркем-төркем булып Мәккәгә кайттылар. Шәһәр эченә офтану һәм яшьләрдән аһлар тулды. Кайсы гаиләләрнең югалтулары зур, икенчеләрнеке аз кебек тоелса да, асылда, һәр йорттан диярлек яки аталары, яисә уллары һәлак булган, йә тоткын төшкән иде. Бигрәк тә ирләрен югалткан хатыннарның хәсрәтләре чиксез тоелды. Хәзер инде кемгә таянырлар, балаларын ничек аякка бастырырлар?

Әбу-Суфийан халык каршысына чыкты. Әбу-Җәһил һәлакәтен тапканнан соң, халыкка ул үзен баш итеп тоя иде. Бәдер сугышында аның да бер улы үлгәнлектән, хәсрәте чиксезлекне бөтеннәр дә аңлап, ни әйтсә, шуны кабул итәчәкләрен халыкның күз карашыннан ук сиземләде. Әмма аларны юатып түгел, бәлки көтелмәгәнчә:

— И корәиш нәселе, әгәр дә без сугышта һәлак булган аталарыбыз һәм улларыбыз өчен шушы рәвешле чиксез кайгы-хәсрәтләр кичереп, елап һәм офтанып бәргәләнсәк, болар хакында Мөхәммәдкә билгеле булыр, мөселманнар сөенерләр. Без алай эшләмик. Һәлак булып яу кырында калган карендәшләребез, туганнарыбыз, ата һәм балаларыбыз борынгы бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләребезне, аллаларыбызны яклап, кылычка-кылыч килделәр. Аларның тоткан юллары изге иде. Болар өчен үч кайтарырбыз. Әмма бер ай буена без үзебезнең хәсрәтле йөзләребезне, күзләрдәге яшьләребезне һичкемгә күрсәтергә тиеш түгелбез. Безнең хәсрәтебезгә дошманнарыбыз сөенмәсен. Башларыбыз горур калсын! — дип сөйләде. Ул бер ай буена елаудан тыелып тору кирәклеген игълан итте, шулкадәр заман үтеп, хәсрәтләре таралырга өлгерер диярәк фикер йөртте. Әмма ялгышты.

Халык әүвәле аның сүзләре белән килеште. Бер ай буена күзләреннән яшь, телләреннән аһ төшмәде. Чөнки барсы да ант эчкәннәр иде. Сер бирмәделәр.

Кәгап бине Ишраф исемле шагыйрь бар иде. Аның нәселе яһүдиләрдән булганлыктан, гарәпләрнең эшенә катышуны үзенә гадәт итмәсә дә, корәишләрнең Бәдердә җиңелүе аңа бик тә тәэсир ясап, мөселманнарның алга китүенә хәвефләнә башлады. Мәккәгә юл алды. Әбу-Видага исемле дустына кунакка төште. Корәишләрнең һәлакәте һәм үлгән кешеләренең хәсрәте белән көйгән рәвештә бер бәет язып, аны гарәпләр телennән бәян итеп, мәҗлескә җыелган Мәккә халкына укыды. Кемнәр тыңладылар, аларның күңелләре кузгалды. Бәгырьләре көйде. Тәкатьләре бозылды,

шигырь белән әйтелгән аһ авазына кушылдылар һәм елау-сыктау корәиш хатыннарын үзенә буйсындырды. Мәккәнең тынычлыгы китте. Берсенә икенчесе кушылды. Башларын ачып, чәчләрен йолкый-йолкый үкседеләр. Хатын-кызларның аһ-зары ирләрнең дә күңелләрен кузгатты. Кемнәр юл тузанына ятып елады, кайсылары исә, Мәккә капкасыннан чыгып, Бәдер тарафына йөз куеп үкседеләр.

— Безнең шәһәребездә бер генә ир дә калмадымы?..— диделәр алар, такылдап.— Шул Мөхәммәднең башына җитәргә кулыгыздан килерлек түгелме? Безнең батыр ирләребез һәм баһадир улларыбыз җаннарын да кызганмадылар. Ә сез куркып качкансыз...

Аларның шушы рәвешлә сөйләүләре һәм бәддога укулары, Мөхәммәднең канын таләп итүләре көннән-көнгә арта барды. Ирләре һәм исән уллары боларны ишетеп ачындылар. Әмма арадан бер генә батыр да күтәрелмәде, Мөхәммәдтән үч алырга җөрьәт итмәде. Бу хакта бигрәк тә Сафуанның каны кызды. Кемне дә булса Мәдинәгә күндерергә ниятләде.

Бәдер сугышыннан соң бер ай чамасы вакыт үтеп, Мәккәдә хатыннарның ирләрне хурлавына чик-чама калмагач, Сафуан үз янына корәишләр арасында кансызлыгы вә мәгънәсезлеге белән танылган, һәр эшне кызулык ярдәмендә кылып ташлаучы Гамир бине Ваһһапны чакыртып, аның күңеленә үтү теләгендә мәҗлес корды. Бәдердә үлеп калган кешеләрне искә алдылар. Мөселманнарны хурладылар. Алар кулында әсир булып ятканнарын хәтергә алдылар. Гамир бине Ваһһапның да улы Мәдинәдә тоткын иде. Бу сүзләр аның канын тәмам кайнатып җибәрделәр. Алларына куелган ризыкны күңелләре кабул итмәде.

— Тормышның яме, икмәкнең ләззәте бетте,— дип зарлангандай итте Сафуан, озын бер сүзне башларга җыенгандай. Әмма Гамир аңа ялгап китте:

— Минем динемә һәм гаиләмә озын гомерләр булсын... Улымны таләп итү сәбәбе белән Мөхәммәдкә һәм аның сәхабәләренә барырмын. Аны шунда катил кылырмын,— диде.— Мөхәммәднең ялгызы гына базарларда һәм бакчаларда, сарайларында йөргәнен күзәтермен, берәр ничек форсат табып, аны үтерермен! — дип, ниятен ачып салды.— Юкса, хатыннардан оят...

— Син белерсең, бу эш инде минем кулымнан килмәс, көч вә куәтем юктыр,— диде аның сүзләрен күтәреп алган Сафуан.— Әмма гаиләңне ярдәмемнән ташламамын, аларның язмышын миңа ышандыра аласың!

Алар шулай килештеләр. Гамирның инде сүзеннән кире чигенерлек чарасы калмады. Биленә кылычын элде. Шулай да, эшнең ахыры билгеле булмыйча, бу сөйләшүне һичкем ишетмәсен һәм икесе генә белсен дип сүз куештылар. Шайтаннарның шайтаны сыйфатында танылган Гамир бине Ваһһап эшне озакка калдырырга теләмәде, сәфәргә чыгуны мәслихәт табып, Сафуанның олы киңәшләренә колак салып, шул мәҗлестән соң, Мәдинәгә юнәлде.

Шәһәргә килеп җиткәч, пәйгамбәрнең мәсҗеден эзләп тапты. Аның капкасына тукталып, дөясеннән төште. Эчке таба узарга теләде һәм шунда берничә мөселман белән әңгәмә коручы Гамрел-Фәрукны күреп алды. Ул арада Гамр дә Гамирне хәтерләп өлгерде. Йөзендә һәм яшертен эш итүендә бер-бер хәйлә белән йөрү дәлилләрен сизенеп, бүтәннәргә аның кемлеген аңлатып өлгерде. Бәдер сугышында кяферләрне мөселманнарга каршы дәртләндерүләрен дә исләренә төшерде. Шуннан соң аны каулый башладылар һәм тотып алдылар. Гамрел-Фәрук исә Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына барды һәм Гамир бине Ваһһапның мәкер белән Мәдинәгә килүен әйткәннән соң, моңа карата үз фикерен белдерергә кирәк тапты:

— Аның үч алу теләгеннән, йа Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, котыла алмассың, без аны әсир иттек! — диде.

— Минем каршыма китер! — дип әмер бирде Мөхәммәд пәйгамбәр.

Шуннан соң хәзрәте Гамр бер кулына Гамирның кылычын, икенчесенә кынын тотып, монафикъны Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына китерде. Якындагы әнсариларга әмер бирде:

— Мин бу кешенең юньле уй белән йөрүенә ышанмыйм, хәвефтән имин түгелмен, пәйгамбәребезнең уңы-сулыннан басыгыз. Бер-бер усаллык белән хәрәкәт итә башласа, әзер торыгыз! — диде.

— Йа Гамр,— диде Мөхәммәд пәйгамбәр,— Гамирдән кулыңны ал, бире килсен!

Гамрдән котылгач, Гамир алга атлады һәм җәһилият заманындагыча итеп сәлам бирде. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр аның ул рәвешле исәнләшүен кабул итмәде.

— Аллаһы тәгалә миңа җәһилият тәхетен ят кылды, мәкруһ кылды, җәннәт тәхетен насыйп әйләде. Ул — сәлам! — дип белдерде. Аннан соң гына:— Нигә килдең? — дигән соравын бирде.

— Әсиремне эзләп килдем. Улым артыннан,— диде җавабында хәйләле Гамир бине Ваһһап.— Миңа яхшылык итсәң иде?..

Мөхәммәд пәйгамбәр исә бөтенләй бүтән нәрсәгә игътибарын юнәлтеп, аны дөрес сүзгә чыгарырга теләгәндәй итте һәм тагын да сорап куйды:

— Ә бу кылыч нәрсәгә?

— Аллаһы тәгаләң синә үзе белдерсен,— дип җавап бирде Гамир, мыксыллы елмаеп. Аның мәкере һәм усаллыгы йөзенә чыккан, максатына ничек тә ирешү теләгендә акылы шашына иде.

— Йа Гамир, әйт, ни өчен килдең, турысын сөйлә, ялган килешмәс! — диде соравын кабатлап Мөхәммәд пәйгамбәр. Әмма бу юлысы да монафикъ үзенең Бәдердә әсир ителгән улын эзләп килгәнен белдерде, пәйгамбәрдән яхшылык өметендә калуын әйтте.

Бу җавапка канәгатьсез калган Мөхәммәд галәйһис-сәлам аның җавабына елмаеп кына карады, мәкерен сизенгән кеше төсле кузгалып куйды. Хәйләкәр Гамир асыл ниятен белдермәячәк иде. Шунда пәйгамбәр кабат сүз башлады:

— Йа Гамир,— диде,— Сафуан белән бергә өендә нәрсә хакында сөйләштегез, нинди шарт куйдыгыз?

Гамирнең кинәттән йөзе үзгәреп китте, шулай да сер бирмәскә уйлады һәм:

— Әгәр билгеле дип беләсең икән, үзең бәян ит...— дип кенә җавап бирде. Әмма пәйгамбәрнең шунда Сафуан һәм үзенең ниләр хакында килешүләрен әйтер дип башына да китермәде.

— Син аның белән мине катил кылырга кирәклек хакында сүз куештың, бу гөнаһ гамәлгә алыначагыңны белдердең. Ә ул, үз чиратында, синең гаиләң турында кайгыртачагына ышандырды,— дип, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәллам барсын да бәйнә-бәйнә сөйләде. Бу хәбәрләрне ишеткәч, Гамир югалып калды. Сер капчыгы тишелүдән ни әйтергә дә белмәде, зәһәр теле илә сүзнең дөреслеген расларга да көченнән килмәде. Бераздан соң гына:

— Боларны сөйләшкәнебезне Сафуан һәм миннән бүтән һичкем дә ишетмәде...— дип кенә әйтә алды.

— Бар нәрсәне белеп торучы һәм ишетүче, күрүче Аллаһы тәгалә икәнлеген минем хәбәр иткәнлегем юк идеме? — диде Мөхәммәд пәйгамбәр.— Ул миңа барсын да әйтте, ул миңа сезнең серләрегезне чиште.

Шунда Гамир:

— Хактан да син Аллаһы тәгаләнең пәйгамбәре, мин моңа чыннан да инандым! Аллаһы тәгалә бер һәм бар, тиңдәше дә, ошашы да юк! Һәр нәрсәне теләдең исә, булышлык итә! Ә без һаман да наданлыгыбыз белән аны инкарь итеп килдек, ахмаклыкта калдык! Ул — хак, мин чыннан да Сафуан белән боларны сөйләшкән идем. Безнең янда һичкем юк, тыңлап торучыбыз булмады. Моны сиңа Аллаһы тәгалә хәбәр биргәненә инандым! Аллаһыга шөкер, әлхәмдүлиллаһ, ул мине хак һәм тугры юлына

күндерде, күзләрем ачылуга ярдәм итте! — диде. Аның сүзләре шулкадәр ялкынлы һәм тәэсирле иделәр ки, янында тыңлап торучы сәхабәләр барсы да хәйранга калдылар.

Моңа кадәр Фәрукның күзенә бер кабахәт дуңгыз кебек күренгән Гамир кинәт яктырып-нурланып китте. Әйтерләр ки, бәндәләрне иман нурга күмә һәм бүтәннәр каршысында сөекле итә, чөнки иманнан кешеләргә нур иңә! Бу нур — Аллаһы тәгаләнең нурыдыр, бу нур — бәхет вә сәгадәт нурыдыр! Бу нур — аталарының балаларына тапшырачак һәм нәселләрен җирдә саклаячак ышаныч нурыдыр! Менә шуңа күрә дә Ислам дине, бер һәм бар булган Аллаһы тәгаләгә инану мөселманнарны бүтән кавемнәрдән өстен итә. Аларның бәхете елдан-елга ишәя һәм көчәя генә бара. Бары тик иманнарына тугры булсыннар да бәхетләренең чыганагын онытмасыннар...

Шуннан соң Мөхәммәд пәйгамбәр барча сәхабәләренә мөрәҗәгать итте һәм болай дип үтенде:

— Мин Гамирның иманына тугры калуын теләрмен! Сез аңа Коръәне кәримне өйрәтерсез, улы Ваһһапны әсирлектән азат кылыгыз!

Әмма Гамир:

— Йа Аллаһы тәгаләнең сөекле пәйгамбәре, мин шуны үтенермен, Коръәннән әүвәле кальбемне чистартуны үземә бурыч итеп алыйм, аннан соң укырмын, өйрәнермен! Рөхсәтең белән боерсаң иде, Мәккәгә барыйм һәм андагы корәишләрне Исламга дәгъвәт кылыйм! Шунда бәгырем дә сафланыр! — дип сорагач, сәхабәләр каршы килмәделәр. Мөхәммәд пәйгамбәр исә аны улы Ваһһап белән бергә Мәккәгә күндерде, изге ниятендә Аллаһы тәгалә юлдаш икәнлеген белдерде.

Ә анда аны көн дә диярлек Сафуан көтә иде. Кемнәр Мәдинә шәһәре ягыннан килсәләр, тиз арада аларның каршысына чыгып:

— Анда киткән сер дустым бар, берәр хәбәрен әйтмәссезме? — дип сорый торган булды.

Мәккә корәишләре Бәдер сугышында һәлак ителгән туганнары өчен кайгырышып, ничек тә Мөхәммәд пәйгамбәрдән үч алырга кирәклек хакында планнар корганда, ул алар янында серле генә елмая һәм үзләрен бер-бер хәбәр белән сөендерәчәген уйлап, рәхәт хисләр кичерә иде. Гамирнең гаиләсе хакында да даими кайгыртып торды. Инде кайтыр вакыты да җитәргә тиеш иде.

Көннәрнең берендә Мәдинә тарафыннан аңа көтелмәгән хәбәр китерделәр: «Гамир бине Ваһһап мөселман булды!» — диделәр. Сафуанның моңа ышанасы килмәде, хәбәрләрен инкарь итте. Шулай да Гамирның иман китергәне үзе кайтып күренгәч билгеле булды. Ул бүтәннәрне дә Ислам диненә чакыра башлады. Сафуан аның белән күрешмәс һәм сөйләшмәс дәрәҗәдә үпкәләде. Корәишләр исә Гамир белән һичбер авыз әңгәмә кормаска ант эчтеләр.

Мәдинә шәһәрендә данлыклы шагыйрәләрдән яһүдә Гасыймә бар иде. Ул бәеттә һәм җырда гаять тә маһир кемсәнә булып, бу осталыгын исламга һәм мөселманнарга каршы файдаланды. Аның усал теле һәм елатырлык сүзләрен тыңлаган кешеләр чыннан да Мөхәммәд пәйгамбәрнең өмметеннән йөз чөерә иделәр. Әмма һичкем аңа зыян китермәде, мөэминнәр исә шигырьләренә, дикъкать итеп, колак салуны кирәк эштән санамадылар. Әмма бу яһүдә хатынның монафикъләр каршысында дәрәҗәсе шактый зур булып, олуг хөрмәт ияләреннән санала торган иде. Әтисе шулай ук яһүдиләр тәифәсеннән Мәрван исемле кеше иде.

Мөселманнар Бәдер сугышына киткәч, бу хатын Гасыймә тәмам барлык осталыкларын эшкә җикте, мөэминәләрне дә котыртты, аларның иманнарын какшатырга тырышты. Бер-бер артлы һәртөрле шигырьләр чыгарды, сәхабәләрдән һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзеннән ачы итеп көлде. Тел шакшылыгы пакизә өммәтнең күңеле сафлыгын боза башлады. Аны тыярлык һичкем табылмады. Шулай да Мәдинәдә

Гасыймәнең шигырьләреннән шактый хәбәрдар, Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм Аллаһы тәгаләгә чиксез мәхәббәт тотучы Гамир бине Гади исемле бер зат бар иде. Аны картлыгы сәбәпле яуга алмадылар.

Көннәрнең берендә Гамир бине Гади теге яһүдә хатын Гасыймәнең чираттагы шигырен ишетте, сәхабәләрнең җиңелеп кайтачакларын белдереп лаф орган бу әсәре картлачның бәгырен кисте һәм ул шунда:

— Валлаһи дип әйтәм, әгәр дә Мөхәммәд пәйгамбәр бу сәфәреннән исән-имин әйләнеп кайтса, нурлы йөзе белән шәһәребезне сөендергән көнендә шушы Гасыймәне катил итәрмен! — диде.

Аның вәгъдәсе чын йөрәктән иде. Һәм менә сәхабәләр җиңү яулап кайттылар. Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең йөз нуры белән Мәдинәне яктыртты. Гамир бине Гади исә туры шул шагыйрәгә китте, үзе белән бергә юлдаш та алды.

Гасыймәнең йортына керделәр. Ул күкрәгенә баласын тотып имезә иде. Гамир бине Гади һичбер офтанмыйча аның бу малаен кулларыннан тартып алды һәм:

— Инде синең телең киселергә, җәһәннәмгә олагырга сәгатең килде! Мөселманнардан көлүче, Мөхәммәд пәйгамбәребезне яман телең белән пычратучы син түгел идеңме?! — дип ачудан бу хатынның күкрәгенә кылычын терәде. Гасыймә аны-моны аңларга өлгермәде, котылырга дигән ният белән читкә тайпылырга уйлады. Әмма Гамир кулындагы кылычына бар көче белән басты. Гасыймәнең күкрәгеннән үтеп, ул кылыч бу хатынның аркасыннан чыкты. Ул шулай үтерелде.

Яһүдәнең йортын ташлап чыктылар һәм Гамир бине Гади туры Мөхәммәд пәйгамбәр янына китте. Алар намазда иделәр. Гамир дә тезләнде, әмма кылган вакыйгасыннан соң, күңеле какшау сәбәпле зиһенен җыя алмыйча аптырады. Моны Мөхәммәд пәйгамбәр дә сизенде һәм:

— Йа Гамир,— диде,— син ул шагыйрәне үтердеңме?

— Әйе,— диде картлач. Йөзенең борчулы икәнлеген һәркем күреп алды.— Миңа моның өчен ни булыр, Аллаһы тәгаләдән газап ирешерме? — дип офтанды.

— Юк,— диде аңа Мөхәммәд пәйгамбәр,— син Аллаһы тәгалә һәм аның рәсүле каршында ярдәмчесе булырсың,— дигәннән соң, сәхабәләргә карады һәм:— Күрегез, сезнең яныгызда, белергә теләсәгез, Аллаһы тәгаләнең һәм аның пәйгамбәренең ярдәмчесе бардыр, ул — Гамир бине Гади,— дип белдерде.

Шуннан соң гына картлачның күңеле тынычланды. Аллаһы тәгаләнең һәм пәйгамбәренең теләген тоеп эш иткәне өчен сәхабәләр сөекле күрделәр. Инде Мәдинә һәм аның тирәсендәге мөселманнар дошманнарыннан азат ителергә тиеш иде.

Мөхәммәд пәйгамбәр Мәдинәгә һиҗрәт иткәннән соң, шәһәр тирәсендә һәм эчендә яшәүче яһүдиләр белән килешү төзелде. Ике як та бер-берсенең эшләренә тыгылмаска, дошманнарына ярдәм итмәскә, ызгыш-талашлар тудырмаска, тату гына яшәргә булдылар. Әмма алга таба үзара мөнәсәбәтләре катлауланганнан-катлаулана барды. Ислам диненең көннән-көн үсеш һәм таралыш ала баруы, гарәпләр арасында дәрәҗәсе артуы яһүдиләрнең күңеленә тиде.

Яһүдиләрнең кончелеге инде сизелерлек артуга карамастан, мөселманнар моны вакытлы күренешкә генә санап, аңа артык әһәмият бирел тормадылар. Әмма эш аның белән генә бетмәде. Шушы Кинкагъ кабиләсе дип йөртелгән яһүдиләр үзара сүз чыгардылар һәм:

— Гарәпләр сугыш уеныының ни икәнлеген дә белмиләр! Җиңдек дип лаф орган булалар. Нинди җиңү ди ул. Сугыша белмәгән корәешләрне куркыттылар да тантана итәләр...— дип, һәртөрле сүзләр тараттылар. Мөхәммәд пәйгамбәрнең исемен атый-атый хәтта хурлауга кадәр барып җитүчеләре күренде. Әмма мөселманнар бу хәлләргә дә түзә бирделәр.

Кинкагъ яһүдиләре моның белән генә тынычланмады. Сүз артыннан сүзләр куертып:

— Менә безнең белән орышып карасыннар! Алар бит бездән куркалар, күрербез, кем көчле дә, кайсыбыз җиңәр! — дип үзләрен өстен чыгара иделәр. Боларны сәхабәләргә, аларның хатыннарына әйтеп, оятлы итәргә тырышалар, Бәдердәге канлы бәрелештә мөэминнәрнең җиңүен саннан чыгаралар иде. Аларның болай сөйләнүләрендә бер-бер сәбәп барлыгын алдан ук сизенеп торучылар:

— Яһүдиләр безнең белән сугышырга телиләр! Элеккеге килешүне боздылар. Алар белән бергә эш итү мөмкин булмаячак! Һәркемгә саклык кирәк. Көнчелектән каннары кызган,— дип белдерделәр. Әмма Мөхәммәд пәйгамбәр һаман да боларның сүзләренә колак салмагандай эш итте, яһүдиләрнең көнчелекләре сүрелү өметендә иде. Әмма вакыйгалар көтелмәгән яктан куерып киттеләр.

Базар көн иде. Бер мөслимә хатын шушы яһүдиләрнең мәхәлләсенә килде һәм кирәк булуы сәбәпле, алтын һәм көмештән затлы әйберләр коючының алачыгына тукталды, эшенең тәмам ителүен көтеп утырганда икенче яһүди, аның артыннан төшеп, һәм итәген кадакка беркетеп, читтән эшенең нәрсә белән бетәсен көтеп тора башлады.

Шунда бер гарәп тавыш бирде. Хатын урыныннан кузгалды, әмма кадакланган күлмәк итәге ертылып китте һәм гаурәте ачылды. Бу оятыннан мөслимә агарынды һәм кычкырып җибәрде, кая керергә белмәде. Тавышына килеп җиткән бер мөселман ир, яһүдиләрнең бу рәвешле мөслимәне рәнҗетүләрен күргәч, түзеп кала алмады, кылычын чыгарды. Гаепле кешегә таба ыргылып, аны үтерде. Әмма хатын-кызның намусын яклап чыккан бу ирнең шушы рәвешле эш итүен Кинкагъ яһүдиләре яратмадылар, һәммәсе бергә, кылычларын чыгарып, сәхабәнең өстенә килә башладылар. Ул, алар белән сугышып, һәлак булды. Бу вакыйга исә мөселманнарның һәртөрле җәберләүләргә түзәргә күнеккән бәгырьләренә сукты, сәхабәләрнең күзләренә ачу һәм үч алу кайнарлыгы бәреп чыкты. Мөхәммәд пәйгамбәрдән исә яһүдиләргә каршы яу чыгарга таләп иттеләр. Әмма эшне болай җиңел кулдан гына башкарып ташлау хаталануга китерергә мөмкин иде. Мөхәммәд пәйгамбәр үзе яһүдиләргә хәбәр салды һәм аларның кабиләләрендә дан тоткан дәрәҗә иясе кешеләрне чакыртты. Арада туган низагны тыныч юл белән хәл кылуны кирәк тапты.

Яһүдиләрнең олуг затлары килгәч, ул аларга:

— Сезнең көнчелек кылуыгыз һәм мөселманнарга дошманлык итүегез урынсыз. Әгәр дә җиңүләргә безнең кебек ирешергә телисез икән, ул вакытта сез дә Ислам динен кабул итеп, иман китерегез! — диде, үгет бирде. Әмма аның бу гадел сүзләреннән яһүдиләрнең олылары үртәлделәр генә. Алар Мөхәммәдкә:

— Әллә безне синең кавемең корәишләр кебек сугыша белмибез дип уйлыйсыңмы?! Әгәр дә безнең белән орышырга теләсәң, күрербез, ахыры ничек бетәр,— диделәр дә, шушы сүзләре илә пәйгамбәрне куркытырга теләп, урыннарыннан кузгалдылар, мәҗлесне ташлап, чыгып киттеләр.

Бу инде мөселманнарга алга таба яһүдиләр белән тыныч яшәү мөмкин түгеллеген аңлата иде. Бу инде яһүдиләрнең сәхабәләргә, хәтта Мөхәммәд пәйгамбәрнең үзенә сугыш игълан итүе иде. Бу инде аларның хыянәте иде.

Мөхәммәд пәйгамбәрне сагыш билəп алды. Шунда аңа Җәбраил фәрештә иңеп килде һәм хыянәт итүче кавемнең Аллаһы тәгаләнең дошманнары икәнлеген белдерде.

Яһүдиләрнең игълан иткән сугышына каршы сәхабәләр яу әзерли башладылар. Мөхәммәд пәйгамбәр бер гаскәр тәртип итеп, аның башына Хәмзәне куйды, Мәдинәгә хәлиф итеп Әбу-Либабәне калдырды.

Сәхабәләр гаскәре шәһәрдән чыгып, яһүдиләрнең диварлар белән ныгытылган калаларына керде. Бу хәлне күргәч, аларның күңелләренә

курку һәм хәвеф иреште. Әле кайчан гына үзләрен сугышта маһир вә оста булачак дип тәкрарлаган кушйөрәклеләрнең муеннары җилкәләренә сеңде. Мөселманнарның гаскәре аларның каласында унбиш көн торды, шуннан соң гына, Мөхәммәд пәйгамбәр яһүдиләргә әмер бирде:

— Йә хыянәтче кавем,— диде.— Сез бүгеннән шәһәрегезне ташлап китәсез, бүтән урынга күченәсез. Барча малларыгызны монда калдырасыз. Минем хөкемем буенча эш итсәгез, берегезне дә катил кылмабыз! — диде.

Пәйгамбәрнең бу таләбенә әүвәле буйсынырга теләмәсәләр дә, чарасызлыклары сәбәпле, ахырда калаларын һәм гомер буйларына җыйган, ата-бабадан килгән малларын калдырып китәргә мәҗбүр булдылар. Сәхабәләр аларның кулларын артка бәйләделәр. Барсы җиде йөз кеше иде. Берсенә дә миһербан ителмәде.

Алар Мөхәммәт пәйгамбәрдән яхшылык үтенеп карадылар, әмма ләкин ул боларның сүзләренә илтифат итмәде. Күңелендә аларны катил кылу теләге бар иде. Яһүдиләр өмет һәм үтенеч илә итәгенә ябышкач кына, пәйгамбәрнең күңеле йомшарып, аларның кулларын чишәргә боерды һәм:

— Бу рәвешле китсәләр, берәр угрыга очрап, барсы да катил кылынырлар. Аллаһы тәгаләнең җәзасы ирешсен үзләренә! — диде.

Кабат өч көн мөселманнарның кул астында торганнарыннан соң, үзара киңәшеп:

— Безгә сәхабәләр белән яшәү һич мөмкин түгел, алар белән сугышырлык хәлебездә түгелбез. Тынычрак берәр урынга күченик,— диделәр һәм шуннан соң, Шам тарафына киттеләр. Әмма маллары мөселманнар кулында калды. Эчәргә сулары булмады. Алар шул рәвешле барган җирләрендә бик күп зәхмәтләргә очрадылар, ахырда бу кавем тәмам һәлак булып бетте. Әгәр мөселманнар белән дустанә яшәүләрен дәвам итсәләр һәм аларга сугыш таләбе тотып килмәсәләр, әле хәзерге көнгә кадәр шул урыннарында тора бирерләр иде. Бу язмыш Аллаһы тәгаләгә һәм хак дин — Исламга каршы чыгулары өчен өсләренә бәла рәвешендә җибәрелде. Шушы кавемнең кирелеге һәм ахмаклыгы сәбәпле мөселманнарның бүтән яһүди кабиләләренә, гомумән яһүдләргә карашы үзгәрде. Дошманлыклары зураеп, бер-берсен күрә алмас дәрәҗәгә җиттеләр. Ә югыйсә яһүдиләр һәм гарәпләр икесе дә тугандаш халыклар, гүяки бер атаның ике баласы төсле иделәр.

Мөхәммәд пәйгамбәрдән Бәдер сугышында җиңелүләренең үчен алу өчен Әбу-Суфийан кырык кешелек гаскәр белән Мәдинә тарафына юл алды. Исәбе ничек тә булса пәйгамбәрне очратып, аны үтерү иде. Әмма Мәдинәгә керергә кыймады. Шәһәр тирәсендәге авылларны айкап йөрде. Берсендә кабул итмәсәләр, икенчесенә юнәлде. Бәхетенә күрә фикердәшләре дә очрады. Алар белән хәмер вә шәрабне авызларына коеп, ничек тә сәхабәләрне хур итәргә киңәш иттеләр. Юлларына туры килгән мөселманнарга мәрхәмәт күрсәтмәделәр, үтерә бардылар. Йортларын таладылар, бакчаларын боздылар.

Бу хәбәр Мөхәммәд пәйгамбәргә ирешкәч, ике йөз кешедән торган сәхабәләр гаскәрен күтәреп, дошманнарының артына төште. Әмма Әбу-Суфийан табанын ялтыратты.

Ислам дине бер Мәдинә шәһәрендә генә түгел, ә якын-тирәдәге гарәп кабиләләренә дә таралырга тиеш иде. Әгәр дә моңа ирешмәсәләр, дошманнарыннан саклану һәм диннең алга таба үсеше тәэмин ителмәячәген Мөхәммәд пәйгамбәр яхшы төшенде. Һиҗрәтеннән соң икенче елының ахыры һәм өченче елының башларында, сәхабәләрдән гаскәрләр төзеп, Ислам диненең куәт алып китүе өчен Мәдинә һәм аның тирәсендәге кабиләләргә юнәлде. Әмма гарәпләргә бу ошамады, алар әле һаман да Исламны кабул итәргә теләми иделәр. Мөхәммәд пәйгамбәр, ике йөз кешелек гаскәре белән иманга килмәүче Бәни-Сәлим һәм Гыйтфан кабиләләренә юнәлде. Аларның тормыш корган авылларына ирештеләр.

Әмма бер генә бәдәви гарәпне дә тапмадылар. Алдан хәбәр алып, бу урыннардан күчеп киту җаен караганнар иде.

Сәхабәләрдән берничә атлы һәм дөяле гаскәри әйләнә-тирәне күзәту һәм алар хакында хәбәрләрне барлау өчен җибәрелде. Күзәтчеләр, бер дөя көтүенә туры килеп, көтүчесеннән:

— Сәлим кабиләсе хакында хәбәрең бармы? Алар кая киттеләр? — дип сорадылар. Бу кемсәнә боларның Мәдинәдән килгән Мөхәммәд пәйгамбәр гаскәриләре икәнлеген аңлап алды. Әгәр дә дөресен әйтеп бирмәсә, эшнең ахыры начар бетәсен аңлап, үзе өчен хәсрәтләнде.

— Сәлим кабиләсе кешеләре шушы су янында кичләрен уздырдылар, монда кунган иделәр, инде хәзер кайда киткәнлекләре минем өчен мәгълүм түгел, — диде ул, акланып.

— Бу дөяләр кемнеке? — диде сәхабәләр.

— Аларныкы!

Хәбәрне Мөхәммәд пәйгамбәргә җиткерделәр. Озак уйлап тормастан, гүяки барсы да аңа алдан билгеле булган төсле, әмер бирде:

— Дөяләрен Мәдинәгә куып илтегез. Әгәр дә малларын эзли башласалар, үз аяклары белән каршыбызга килерләр! — диде.

Мәдинә шәһәре тирәсендә бер таифә җыелып, караклык һәм юлбасарлык белән шөгыльләнә башладылар. Әйтерләр, элгәре алар бу якларда күренмәгәннәр, соңгы вакытларда гына каяндыр үтеп барышлый тукталганнар. Әмма эшләрен мәкер һәм хәйлә ярдәмендә кылалар икән. Үзләре юлбасарлык итәләр, ә гаепне Мөхәммәд пәйгамбәргә һәм аның сәхабәләренә аударалар. Мөхәммәд пәйгамбәрнең моңа кәефе китте һәм сәхабәләрнең гаскәрен күтәрде. Мәдинәгә хәлиф итеп Госман бине Гаффанны тәгаен кылды. Барысы бергә дүрт йөз илле гаскәри иделәр. Аларны Мөхәммәд пәйгамбәр шул угрыларга каршы көрәшергә һәм аларны Мәдинә тирәсеннән куып җибәрергә алып чыкты.

Юлларына Җәббар исемле бер кеше очрады. Монафикъ иде. Мөхәммәд пәйгамбәр аннан угрылар хакында белгәнме-юкмы икәнлеген сорады. Җәббар дөрес сүзле кеше иде, җавап бирде:

— Мин алардан хәбәрдармын, — диде. — Әмма алар синең белән сугышырга уйлап та карамыйлар. Ул караклар синнән һәм сәхабәләреңнән куркалар. Килүегез хакында ишетүгә, таулар ягына киттеләр, — диде.

Мөхәммәд пәйгамбәр аның җавабы белән канәгать калды һәм, күңеле хушланып, аны Ислам диненә әйдәде. Җәббар исә балаларча сөенде һәм иман китереп, мөселман булды. Хәзрәте Билал аңа юлдаш һәм укытучысы итеп тәгаен кылынды.

Юлларын дәвам итеп, угрыларның таулар арасына качканын һәм анда үзләренә сыену урынын тапканнарын күрделәр. Шунда гаскәр тукталып, яу хәстәрен күрергә уйлады. Әмма яңгыр ява башлады. Мөхәммәд пәйгамбәр исә үзенең җәймәләрен бер агач төбенә җәйде һәм ял итәргә ниятләде. Шулай тынычлык табып, йокыга талды.

Таулардан угрылар мөселманнарның бер эш-хәрәкәтләрен күреп тордылар. Араларында батыр һәм көчле саналган Турәс исемле берәү бар иде. Аңа алар:

— Агач төбендәге ул кеше Мөхәммәднең үзе булырга кирәк, — диделәр. — Форсаттан файдаланып, аңа чара күрергә мөмкиндер!

Бу сүзләрдән соң илһамланып, Турәс шунда ук кылычын кулына алды һәм, сәхабәләргә сиздермәскә тырышып, пәйгамбәрнең өстенә килде, баш очына чыкты. Катил кылырга әзер иде.

Әйтерләр, адәм балаларының мәкерлегенә Шайтан үзе юлдаш булыр дип. Шуның өчен дә усаллар яшертен генә үз теләкләренә ирешәләр, угрылар да үз эшләрен тәнлә кылалар.

Мөхәммәд пәйгамбәрнең баш очында Турәснең үткер кылычы ялтырады, аһ итәргә дә өлгермичә, ул һәлак буласы иде. Әмма шулвакыт Җәбраил фәрештә килеп җитеште һәм угры Турәснең йөзенә каты итеп

орды. Мәлгуньнең кулыннан кылычы читкә очты, үзе арты белән мәтәлеп китте һәм чалкан ауды.

Кайбер риваятьләрдә шулай сөйләнер: кайчан Турәс кылычы белән Мөхәммәд пәйгамбәрнең муенына басты, әйтте:

— Бу һәлакәтеңнән сине кем коткарыр?

Аңа җавабында Рәсүл Әкрам:

— Аллаһы тәгалә! — дип әйтүгә, Җәбраил фәрештә күктән иңеп, мәкер иясенең йөзенә орды, баш-аяк әйләндереп, кылычын алды һәм Мөхәммәд пәйгамбәрнең кулына тоттырды.

Инде хәзер Турәс угры үзе чалкан ята һәм аның баш очында кылычы үз канын таләп итә иде.

— Сине үлемнән кем коткарыр? — диде Мөхәммәд пәйгамбәр, аның муенын өзәргә ниятләп.

— Әшһәдү ән-лә иләһи иллаллаһ вә әшһәданикә рәсүлуллаһ! — диде Турәс, Мөхәммәд пәйгамбәргә иман китерде. Аннан соң ант эчте, халыкка һичбервакыт зыян салмасын белдерде.

Мөхәммәд пәйгамбәр аңа кылычын кире кайтарды. Турәснең исе-акыллары китте. Никадәр золымнар кылып та, бу рәвешле күңеленә мәрхәмәт ирешкәне юк иде. Инде хәзер, кулына кылычы кире кайтарылгач, ни өчен килгәнлеген исенә төшереп, ниятенә ирешергә генә калган иде, әмма кодрәте бетте. Иман китерү шатлыгы белән күңеле нурланып, үзен бәхетле тойды.

— Ни өчен миңа кылычымны кире кайтардың? — дип сорады ул шунда Мөхәммәд пәйгамбәрдән.

— Син инде иман китердең, мөселман булдың! — диде пәйгамбәр аңа.— Ә мөэминнәр бер-берсенә җәбер-золым кылмыйлар. Син хәзер Аллаһы тәгаләгә сөекле булдың!

— Син миннән көч вә куәттә мең тапкыр өстен, изге һәм сөеклесең! — диде аңа каршы Турәс.— Гомерем буе тугры хезмәтемдә булырмын. Бер ялгышымны мең яхшылык белән кире кайтарырмын!

Ул шулай вәгъдәләр бирде, антлар эчте. Мөхәммәд пәйгамбәр аны иреклe кылды. Гаскәрен күтәреп, Мәдинә тарафына борды. Инде угрылар белән орыш кылуның кирәге калмаган иде. Унберенче көн дигәндә сәхабәләр өйләренә исән-имин кайтып ирештеләр.

Турәс исә үзенең иптәшләре янына дип тауга күтәрелде. Алар сәхабәләрнең, үзләрен эзәрлекләмичә, кире китүләренә һәм мәкер белән җибәрелгән баһадирларының максатын үтәмичә кайтуына гаҗәпсенгән иделәр. Яннарына Турәс менеп җитүгә:

— Син бит Мөхәммәдне үтерергә тиеш идең. Нәрсә булды? Нигә аңа тимәдең? — дип, төрле яктан сорауларын яудыра башладылар.

— Әйе,— диде Турәс, вакыйганы бәян итеп.— Мин аны үтермәкче идем. Теләгемә мәкер юлдашлык кылды. Аның баш очында кылычымны күтәрдем, әмма шулвакыт ак киемнән күркәм бер сурәтле зат пәйда булды вә йөземә китереп сукты. Мин әйләнеп киттем, аркам белән барып төштем. Кылычым кулымнан төште. Иманым камил, бу зат фәрештә иде. Мин аны үз күзләрем белән күрдем. Аның гайрәтенә исләрем-акылларым китте. Моңа кадәр андый көч-куәт иясе бер генә ирне дә очратканым юк иде. Мөхәммәд пәйгамбәргә, Аллаһы тәгаләнең бирлегенә һәм бар нәрсәләрнең хуҗасы икәнлегенә иман китерегез, мин дә мөселман булдым! — дип, аларны да өнди башлады.

Әйтерләр, шушы вакыйгадан соң, Мөхәммәд пәйгамбәргә бер аять иңде һәм анда золым-мәкер ияләренең дә Ислам тәрбиясеннән юллары яхшылыкка таба борылыр дип белдерелде.

Мәккә корәишләре сәүдәсез яши алмый иделәр. Бу хәл Мәдинәдәге мөселманнарга да мәгълүм иде. Шунлыктан иртәме-соңмы монафикъларның кәрван йөртәчәген белешеп тордылар. Шулай да корәишләр ерак сәфәрләргә чыгудан тыелып, үз тирәләрендә генә сәүдә эшеннән файда итәргә уйладылар. Әмма бу мәшәкатьләре вак һәм керемле түгел иде.

Сафуан ничек тә олырак эшләргә алынырга теләде. Әүвәлге бәдәви гарәпләрдән Мәдинә хәлләрен сораштырып белештерде. Аңа шул ирешт: Мөхәммәд пәйгамбәр яһүдиләр белән орышлар оештыра, аларны иманга кертергә ниятли икән, сәүдә юлларында корәишләр кәрван йөртә алалар, тыныч, имеш.

Бу форсаттан ул тизрәк файдаланып калырга уйлады. Кәрванын Шам тарафына барырга әзерләде. Аңа Мәккә байларыннан һәм дәрәҗә ияләреннән Хавитап бине Габделгузза, Габдулла бине Әбу-Рабигъ та кушылып киттеләр. Сафуан бине Өммийат үзе кәрван башына басты. Бәдер сугышында катнашмаганлыгы сәбәпле, мөселманнарның аңа карата үпкәләре юк, дип уйлады. Аны алда Шам базары, андагы затлы комач тукымалар, байлык һәм мал көтә иде.

Корәишләрнең кәрваны Мәккәдән чыкканлыгы Мөхәммәд пәйгамбәргә билгеле булды. Зәйд бине Харисны гаскәр башы итеп, аңа йөз кешелек яу тапшырды һәм Сафуанның кәрванына ирешеп, сәүдә юлын кисәргә боерды. Мәккә кяферләренең Мөселманнарга Мәккәдә күрсәткән җәбер-золымнары өчен түләү көннәре җитте.

Зәйд бине Харис гаскәрен белеп йөртте. Кәрван юлларын яхшы белгәнлеге сәбәпле, аннан качып китү, яки аларны адаштырып калдыру мөмкин түгел иде. Аның белән килгән егетләр орышка дәртләнеп тордылар.

Кәрван күренүгә, Зәйд бине Харис әмерен көтеп торган гаскәренә бер өн салды. Һәммәсе дәррәү кузгалдылар, кулларында үткер кылычларын айкадылар. Бу йөз кеше Сафуанның күзенә мең булып күренде. Малларын һәм кәрванны ташлап, барсы бердәй куркып, тизрәк качу ягын карадылар. Шул рәвешле Зәйд бине Хариска бу байлыклар калдырылды. Сәүдәгәрне куып, аларны катил итүне кирәк тапмадылар. Кәрванны Мәдинә тарафына бордылар.

Мөхәммәд пәйгамбәр бу китерелгән малларны ятим-ятимәләргә багышлады. Аларны сатып, егерме мең алтын акча китерделәр, һәркем бурычларын түләде, тормышларын яхшыртып җибәрде.

Бу вакыйга белән бәйле рәвештә Мөхәммәд пәйгамбәр Зәйд бине Харис хакында: «Гаскәр башлыкларыннан иң хәерле кеше Зәйд бине Харис, мөселман булмаган кешеләргә дә гадел, үз өлешенә канәгать итүче хөрмәт ияседер!» — диде. Чыннан да бу шулай иде. Зәйд бине Харис малай вакытыннан бирле Мөхәммәд пәйгамбәрнең тәрбиясендә үз улы кебек үскәнлектән, һәрьяктан аңа охшарга тырыша, анда нинди сыйфатлар күрсә, үзендә дә булдырырга тели иде.

Мәдинә тарафында яшәүче яһүдиләрнең олыларыннан Кәгап бине Әшраф Мәккә кяферләре белән бик дустанә кешеләрнең берсе иде. Мөхәммәд пәйгамбәр Бәдер сугышына сәхабәләр белән чыгып киткәч тә, бу хакта серне корәишләргә җиткерүчеләрнең яманы ул булды. Соңыннан да монафикъларның хәлләрен белергә ул йөгерде. Мондый сатлык кемсәнәнең мөселманнар тирәсендә йөрүе һич тә кулай түгел иде.

Кәгап бине Әшраф бик оста чичән һәм телгә беткән булуы аркасында, кунак мәҗлесләрендә катнашып, Мәккә кяферләренә үзе чыгарган бәетләрне укыды. Ул арада мөселманнарны мыскыллады, Мөхәммәд пәйгамбәрне ялганчы дип атады. Бәдердә һәлак ителгән корәишләр өчен аһ-зарлар орды. Бу назымнары монафикъларның күңеленә хуш килеп, аларны үч алырга дәртләндерде. Мәккәнең чын дустына һәм сердәшенә әверелеп китте. Киләчәктә дә алар белән бергә буласын, мөселманнарның ниятләрен хәбәр итеп торасын белдерде. Мәдинә тарафында шушындый ышанычлы кешенең барлыгы корәишләр өчен кулай иде. Әмма Кәгап бине Әшрафның эшләреннән Мөхәммәд пәйгамбәр хәбәрдар булды, Мәккә мәҗлесләрендә укыган мәрсияләреннән берничәсе Мәдинәдәге мөселманнарга да килеп ирешә. Болары сәхабәләрнең рухларын сындыру өчен дип тә махсус язылган иделәр.

Кәгап бине Әшрафның Мәккәдән Мәдинәгә кайтып, үз авылына киткәнлеге билгеле булгач, Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы тәгаләгә дога укыды. Бу шагыйрьнең мәрсияләреннән күңеле кайткан, гамәлләреннән арыган иде.

— Йа Раббым,— диде ул, Аллаһы тәгаләдән үтенеп,— Кәгап бине Әшрафның көнчелегенә һәм яла ягулы назымнарына үзең чик куйсаң иде...

Мөхәммәд пәйгамбәрнең ошбу сүзеннән соң, Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт күтәрелде:

— Әгәр дә таләбегезне белдерәсез икән, ул вакытта Кәгап бине Әшрафны мин катил итәрмен! — диде.

Шул рәвешле бу яһүди икейөзле кешенең язмышы Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт кулына тапшырылды. Ул Ислам диненә кергән Кәгапнең туган тиешле якыннарыннан берсе иде.

Өенә кайтты. Өч көн буена авызына бер генә кисәк тә ризык капмады, бер генә йотым да су эчмәде. Эченә хәсрәте җыелды һәм акылы шашынды. Бу сүзләрне ни өчен һәм нигә әйткәнлеге турында кат-кат уйланды. Әмма сүзен кайтарып алырга соң иде инде. Халыклар арасында туганына туганы кул күтәргәне моңа кадәр сирәк һәм гайре табигый хәл иде, инде Бәдер сугышында бу канун бозылды, хәзер Мәдинә йортына да шушындый ук тавыш-гауга килеп керде.

Шулай да Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт бу эшләрдә пәйгамбәрнең үзен гаепләргә теләмәде. Аның акылы яктырды һәм ни сәбәпле шулай кан карендәшләрнең дә уртак фикердә булмауларын төшенеп алды. Заманы шундый бер вакыт иде ки, борынгылык белән яңалык йөзгә-йөз очрашып, үзара инкарь итешә, орыша башладылар түгелме? Әмма борынгылык белән яңалык һич тә кешеләрнең аңыннан аерым рәвештә яшәмиләр. Алар һәркемнең күңелендә, уйлау рәвешендә, фикерләү дәрәҗәсендә һәм киләчәкне вә тарихны тоемлауларыннан туган дөньяга карашларында яши. Ислам диненең яңалыкка омтылучыларның уй-хисләренә туры килә торган фәлсәфәнең нигезенә корылган, киләчәккә алып баручы дин икәнлеген ахырда төшенеп, Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт карарга килде: Кәгапның язмышын хәл итү мәсьәләсен туганнары каршысына куярга һәм пәйгамбәргә бу хакта белдерергә!

Мөхәммәд галәйһис-сәлам аның килеп күрешәчәген һәм теләген сөйләп, рөхсәт үтенәчәген көткән иде булса кирәк:

— Йа Рәсүлуллаһ, бу турыда карендәшләрем белән киңәш кору тиешледер, рөхсәтегезме? — дип үтенүенә каршы:

— Яхшы, бу хакта Сәгад бине Мөгаз белән сөйләш, нәрсә әйтер, шул рәвешчә уртак фикер табарсыз,— диде.

Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт, пәйгамбәрнең теләгенә буйсынып, Сәгад бине Мөгаз сәхабәгә китте. Ул батырлыгы һәм акыллы киңәшче булуы белән мөселманнар арасында мәшһүр иде.

— Кәгапнең каршысына мохтаҗлыктан һәм фәкыйрьлектән зарланып барырга кирәк булыр, аннан соң үзеннән ризык үтенерсең, шуннан берәр сәбәп белән шәһәреннән чыгарып, кеше күзеннән читтә хөкемне җиренә җиткерерсең,— диде Сәгад, үз фикерен Мөхәммәд бине Мөсәлләмәткә аңлатып.

Бу киңәшен кабул иткәннән соң, Мөхәммәд сәхабә туры Әбү-Наилә Солтан бине Сәламәт каршысына юнәлде. Ул кеше Кәгапнең якын карендәшләреннән берсе иде. Шулай ук Гыйбад бине Бәшир, Харис бине Әвис, Әбү-Габбасларны чакырып, алар белән киңәш-табыш итү өчен мәҗлес корды. Алар барсы да Сәгад бине Мөгаз биргән акылны хуп күрделәр.

Ничек нәрсә эшләү хакында кат-кат уйлашканнан соң гына, Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт эшне аларча башкарып чыгарга булды. Кәгап бине Әшрафның йортына килеп, түрендә урын үтенде һәм:

— И кан кардәшем,— дип сүзгә кереште,— килүебезнең сәбәбе бар иде...
Әбу-Наилә дә шунда иде. Кәгап, туры аңа карап:
— Ни йомышыгыз, сөйләгез, мин тыңлыйм,— дип боерды.
— Мөхәммәд безнең шәһәребезгә килгәннән бирле өстебезгә күп бәлаләр өелде,— дип сүз башлады Әбу-Наилә, хөрмәт һәм игътибар белән тыңлап утырган Кәгап бине Әшрафның каршысында.— Гарәпләр илә безнең арабызда каршылыклар көннән-көн арта, тәмам дошманлык дәрәҗәсенә үсә бара. Юлларыбызга аркылы төшә башладылар. Халыкның бу тирәләрдән күченеп китәргә теләге туды, чөнки алга таба тагын да зур куркынычлар көтә безне. Мөселманнар тормышыбызга күп мәшәкатьләр тудырып кына торалар. Кешеләребез һәм гаиләләребез авыр хәлләргә калды, аңлыйсың булыр...— диде.
— Мин элгәре боларны сезгә әйтмәгән идемме?— дип көлде Кәгап бине Әшраф.— Ишетергә дә теләмәдегез. Мин сезнең атагызның улы икәнне оныттыгыз, туганнарым, имеш. Әле моның белән генә бетмәячәк, хәсрәтләрегез тагын да артачак!
Кәгапнең мөселманнарга дошманлыгы бар тулысы белән ачылды, ул аларны һәрьяктан хурлады, бигрәк тә Мөхәммәд пәйгамбәрне эттән алып этkә салды, мыскыллады. Бу сүзләрне Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт һәм Әбу-Наиләнең ачуын китерсә дә, сабырлыкта Аллаһы тәгаләнең ярдәмен үтенделәр.
Сөйләшүләре моның белән генә тәмамланырга тиеш түгел иде. Әбу-Наилә тагын да өстәп куйды:
— Шуны әйтәсем килә, берничә кеше безнең белән уртак фикердә. Мохтаҗлыгыбыз зур. Бераз ризык һәм тамак ялгарлык әйберләр сорап торырга килгән идек. Болар өчен бездән ышаныч итеп нәрсә таләп итсәң дә бирербез,— дип ышандырды.
Кәгап карар чыгарырга ашыкмады. Әбу-Наилә һәм Мөхәммәд энеләренә уйчанланган күзләрен кадап торды да:
— Ул ышаныч әйберегез нәрсә булыр икән?— диде. Тагын да уйга чумгандай утыргач.— Кулга алырлык малыгыз да калмаган, ярар, ул вакытта хатыннарыгызны ышаныч итегез,— дип, аларга ташлама ясагандай әйтеп куйды.
— Без хатыннарыбызны сиңа ышаныч малы кыла алмыйбыз,— диделәр туганнары.— Аларның сиңа кирәкләре дә юк. Яныңдагы хатының арадан иң чибәр һәм күркәм гарәп кызларының берсе,— дип бу сүзен кире кактылар.
— Ул вакытта балаларыгызны ышаныч малы итеп миңа китерерсез, диде Кәгап, башына килгән шушы фикеренә сөенеп.
Әмма монсын да Әбу-Наилә һәм Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт кабул итмәделәр һәм:
— Әгәр дә балаларыбызны сиңа ышаныч малы кылсак, бу эшебез халыкка фаш ителер һәм өстебезгә гарьлек каралыгы ябылыр. Юк-юк. Бу безнең өчен гарьлек. Үз тамакларын туйдыру өчен балаларын сатканнар, диярләр. Моңа бара алмыйбыз. Әмма безнең кылычларыбыз бар. Шуларны сиңа биреп торырбыз, ышаныч малы итәрбез, әгәр дә кабул итеп алсаң?— дип, Кәгап каршында түбәнчелек кылдылар.
Туганнарының хатыннары һәм балалары белән нишләргә булгандыр, ансын белмәделәр. Әмма шунсы көн кебек ачык иде: ул коллар белән сәүдә итеп, табышлар алган кеше, мөгаен нияте шуннан гыйбарәт булгандыр.
Энеләренең, түбәнчелек күрсәтеп, үз сугыш коралларын ышаныч малы сыйфатында тәкъдим итүен уңнан-сулдан үлчәп уйланды да ризалыгын бирде һәм:
— Әгәр дә кайчан да булса миңа килергә, ярдәмемне үтенергә кирәк табасыз икән, сезгә һәрвакыт капкам ачык,— дип, аларны озата чыгарды.

Берничә көннән соң, бу биш кеше Кәгап бине Әшрафның капка төбенә килделәр һәм тавыш бирделәр, кычкырдылар:

— Йа туганыбыз, бире кил, түбәнгә төш! — диделәр.

Кәгап аларны ишетеп алды һәм урыныннан кузгалды. Ул вакытта аның хатыны янында иде.

— Кая барасың? — дип сорады.

— Минем туганнарым Мөхәммәд белән Әбу-Наилә килгәннәр, аларны каршы алырга барам, — диде җавабында Кәгап.

Әмма хатыны аның ниятенә каршы төште һәм:

— Тукта, анда йөрмә, ышаныч итеп капкаңны ачма, — дип үтенде. Мин бу авазларыннан кан исен тойдым!

Кәгап моңа көлеп кенә карады. Хатынының сүзен кире кагып:

— Алар бит минем туганнарым, нигә курыктың? — диде.

Каршы алырга китим дигәндә генә акыллы хатыны аның итәгенә ябышты. Туганнары янына бармавын үтенә үк башлады һәм әйтте:

— Монда кал, алар сиңа кирәк түгел, тавышларыннан кан исе аңкый! Сизенмисеңме?

— Юк! Ахмак сүз сөйлисең, — диде Кәгап, хатыныннан көлеп. — Алар бер килгән иделәр бит инде. Курыкма. Мөгаен сөйләшкән сүзләребез колагыңа кергәндер. Хатыннарын ышаныч малы кылмадым, үзләренә калдырдым. Синең янда төсләре уңар дип шикләнделәр. Тынычлан, Әбу-Наилә минем туганым, әгәр дә теләгендә синең әйткәнең булса, йокыдан мине уятып маташмас иде, — дип, ятак урыныннан төшә башлады, аягына эләргә дип, башмакларын эзләде. Аларны табарга өлгермәде, хатыны тагын бер кат әйтте:

— Бер дә яхшылык белән килмәгәннәр алар. Күңелем сизенә, авазларыннан усаллык ишетелеп тора, кан тама. Яннарына чыкма берүк! — диде.

Әмма Кәгап барыбер аны тыңламады.

— Әгәр дә миннән теләнчелек кылып, ризык сорасалар, ризалыгымны бирермен, — диде дә, кузгалганда урын остеннән үзенә ияреп төшкән юрганын кире күтәрә куеп, чакыручылар янына чыкты.

Кич инеп, инде әйләнә-тирә караңгыланган, әмма төнге һава чиста һәм саф иде. Кәгап хозурланды, бер киерелеп, иркен сулыш алды. Туганнарының ни өчен килгәнлеген белешеп, сүзгә керештеләр. Әүвәле Әбу-Наилә сөйләште. Аннан соң Мөхәммәд бине Мөсәлләмәт тә катнашып китте. Шул рәвешле бер сәгатьләп әңгәмә кордылар. Шуннан Мөхәммәд:

— Әйдәгез, монда утырып торганчы, сәйранга чыгыйк. Бу матур һәм тыныч кичәдә дөнья белән хозурланыйк. Хикәятләр сөйләшик, күңеләмә бик тә гыйбрәтле бер вакыйгадан хәбәрләр килде, — дип тәкъдим ясады. Бу фикер Кәгап бине Әшрафның үзенә дә хуш килде, капка төбен ташлап, юлдан алга таба атладылар.

Сүзләре чәч алдыру һәм кистерү мәсьәләләренә кереп китте. Һәр сөйләнгәнгә барсы да канәгать кала бардылар. Шунда Әбу-Наилә, форсаттан файдаланып, чәчең калынмы дигәндәй, Кәгапнын баш очына кулын күтәрде. Туганының күңелендә һичбер шик-шөбһә юк иде. Әбу-Наилә исә Кәгапның чәчләрен кинәттән учына бөтереп алды, башын артка каерды да:

— Аллаһы тәгаләнең дошманына Раббыбыз исеменнән орыгыз, шакшы канын агызыгыз! — дип әмер бирде.

Иптәшләре тиз ара кылычларын чыгардылар, аңа каларга тотындылар. Әмма Кәгап уң-сулга тартылды. Тегеләрнең кылычлары тәненә зыян итә алмады. Төнге караңгылык та аның файдасына иде.

Мөхәммәд бине Мөсәлләмәтнең итек кунычына кыстырылган кылыч сыныгы бар иде, ахырда ул аны тартып чыгарды һәм Кәгап бине Әшрафка китереп кадады да күкрәгенә кадәр ярып төшерде. Шулвакыт Кәгап җаны чыгарылу җәзасыннан бик каты итеп кычкырып җибәрде.

Аның авазы яһүдиләрнең авылын кузгатып куйгандай итте. Төнге тынычлык ишелгәндәй булды. Һәммәсе йортларында утлар яндырдылар. Урамга чыгып, эшнең нәрсәдә икәнлеген күзәтергә тотындылар. Ул арада мөселманнар Аллаһы тәгаләнең дошманы Кәгапнең башын кисеп алдылар да, гәүдәсен канга баткан хәлендә калдырып, Мәдинә юлына төштеләр. Алар үз максатларына ирешкән иделәр.

Кәгапнең мәетен яһүди карендәшләре эзләп таптылар. Эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап, кылычларын күтәрделәр һәм мөселманнарны куа чыктылар. Артларыннан төшеп, Кәгапнең каны өчен үч алырга, мөселманнарны тураклап ташларга теләделәр. Араларында бәрелеш башланып китте. Харис бине Әвис каты яраланды. Шулай да дошманнарыннан котыла алдылар. Әмма юлда кайтканда, артык кан агудан Харисның тәмам хәле китте. Аны шул хәлендә калдырып китәргә мәҗбүр иделәр.

Кәгапнең башын Мәдинәгә алып кайттылар һәм аларның тәкбир әйтүләрен Мөхәммәд пәйгамбәр ишетте. Моратларына ирешкәнлекләрен, Аллаһы тәгаләнең дошманын катил кылуларын аңлап, яннарына чыкты. Кәгап мәлгуньнең кисек башын күреп, Раббы исеменә рәхмәтләрен укыды, теләгенең үтәлгәнлеген белдерде, бу эшне кылган мөселманнарга хәер-догаларын кылды.

Харисның каты яраланган булуын ишеткәч, аның артыннан киттеләр. Барып таптылар. Аллаһы тәгаләнең рәхмәте белән ярасына шифа иңдерелде. Харис, шактый күп кан агызуына карамастан, исән калды. Мөхәммәд пәйгамбәр аның ярасына үзенең авызыннан сулышын өргән иде, Аллаһы тәгаләнең кодрәте белән шифасы тиде, диләр.

Әвиси кабиләсеннән Кәгап шушы рәвешле җәзаланылганнан соң, Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы тәгаләнең әмере үтәлүен сәхабәләргә белдерде һәм шундый ук бер залимнең Хазраҗ кабиләсендә дә барлыгын хәбәр итте. Сәхабәләрдән берничә кеше бу эшкә алынырга тиеш иделәр. Ул залимнең исеме билгеле булды, аны Әбу-Рафигъ дип атый иделәр. Мөселманнардан Кинанәт бине Әбул-Хакыйкның туганы икәнлеге дә ачыкланды. Әбу-Рафигъның хатыны Суфийа исемле иде. Аннан Кинанәт бине Әбул-Хакыйк берничә тапкыр шундый сүзләр ишетте, ул мәлгунь кяферләр белән бик тә дустанә икән, хәтта үзенең малларын да биреп, мөселманнарга каршы монафикъларны котырта, сәхабәләргә зыяннар китереп, усаллыклар кылдыра ди. Моны белгәч, Мөхәммәд пәйгамбәрнең күңеле вәйран иде. Аның карарын ишеткән сәхабәләр Аллаһы тәгаләгә мең рәхмәтләр укыдылар, Кинанәтнең залим карендәше Әбу-Рафигъның җәзага кичектерелмичә тартылуын теләделәр.

Бу эшкә Габдулла бине Гатикә, Габдулла бине Әнәс һәм Әбу Кутадәт белән тагын да ике сәхабә алынды. Алар алдан җыелышып киңәштеләр һәм Аллаһы тәгаләнең әмерен ни рәвешле башкарып чыгару хакында уртак бер фикергә килделәр.

Әбу-Рафигъ мәлгунь Хиҗаз җиренең Хәйдәр төбәгендәге шәһәрләрнең берсендә яши иде. Сәхабәләр шунда юнәлделәр. Барып җитәрәк, тукталып, тагын киңәш кордылар. Габдулла аларга болай диде:

— Сез монда калып, мине көтегез. Капка сакчысына барып, аңа юри ялагайланыйм, безне тыныч кына үткәреп җибәрсен. Капкаларны ачтырыйм.

Аның белән килештеләр. Габдулла сәхабә, калага килеп, капкачылар янына утырды. Үз-үзен мохтаҗы бар кеше төсле тотты. Сакчылар ул арада эчкә уздылар, кичкә әзерләнделәр. Кемнәр шәһәрдән тышта иде, аларны тиз керергә чакырдылар. Габдулла да шулар белән бергә узды. Әмма ерак китмәде, сабыр итеп көтә бирде. Капкачылар бикләрне элделәр. Үз урыннарын алдылар. Әмма капка янында һичкем калмады. Караңгы төште. Капкачылар йоклап киткәч, Габдулла, качып чыкканда тоткарлык булмасын дип, бикләрне ачты, терәүләрен алды.

Әбу-Рафигъның, югары очта бер мәҗлес корып, кыйсса сөйләгәнен әйттеләр, Габдулла тизрәк шунда ашыкты. Кыйссаның бетеп килгән

вакытына туры килде. Әбу-Рафигъның затлы һәм оста телennән халык әсәрләнеп утыра иде. Кыйссадагы вакыйгалар аларга шулкадәр тәэсир иткәннәр ки, хәтта дөньяларын да онытып, төн җиткәнен дә искәрми калганнар.

Әбу-Рафигъ үзенең йортына кайтып, капка һәм ишекләрен бикләп, йокыга талганын Габдуллага сабырлык белән көтәргә туры килде. Өйләрдә утлар тәмам сүнгәч, пәйгамбәрнең әмерен үтәү ниятендә Әбу-Рафигъның капкаларыннан келәләрен төшереп, ишекләрен сиздерми генә ачып керде. Әмма йортының эчендә караңгы иде. Мәлгуньне Габдулла ничек тә таба алмады. Йокы бүлмәсенә узды. Кайда ятканлыгы күзенә чалынмады. Аптырады һәм:

— Әй, Әбу-Рафигъ! — дип аваз салды. Сүзе тыныч кына чыкса да, артыннан, аркасына терәп әйткән төсле:

— Кем бар? — диде монафикъ.

Җавап ишетелүгә, Габдулла кискен генә борылды да, селтәнеп, кылыч орды, әмма кая туры килгәнен белмәде. Әбу-Рафигъ тын да чыгармады. Габдулланың күңеле тынычлык таба алмады, йөрәге тәне буйлап йөгергәндәй иде. Тышка чыкты. Тавыш-тынга колак салды. Кузгалып йөргән һичкем күренмәде. Бераз тынычлангач, кире керде. Тагын сорады:

— Әй, Әбу-Рафигъ?

— Кем бар анда? — диде Әбу-Рафигъ. — Кем ул? Бер мәртәбә шулай сорады, җавап бирдем. Әмма ул миңа кылыч белән орды...

— Аллаһы тәгаләнең үзе! — дип, шунда ук Габдулла тавыш ишетелгән якка кылычы белән сукты. Әмма дошманының җаны чыкмады. Каты яраланса да, Әбу-Рафигъ кабат аваз бирмәскә тырышты. Габдулла караңгыда аның гәүдәсен кылыч төртеп эзләде. Әбу-Рафигъның корсагына туры килде. Кылыч очы йомшак тәненә узуга, ләгыйн тын тартты. Габдулла аның әле һаман да исән икәнлеген аңлады һәм кылычына каты итеп басты. Очы, тәнен тишеп, аркасыннан чыкты да урын җиренә төртелеп калды. Габдулла аны кире тартып алды. Монафикъ шунда ахыр тамчы сулышын чыгарды, җаны җәһәннәмгә олакты.

Габдулла качу ягын карады. Бер кыен җирдән сикереп төште, чалмасы, башыннан сүтелеп, аяклары астына килде һәм ул чалынып егылды. Аның тавышына шәһәр халкы уянды. Йортларында утлар яндырдылар. Бу арада, капкачылар аякка басканчы, Габдулла чыгып качарга өлгерде. Иптәшләре янына килеп җиткәндә шәһәр эчендә хәрәкәт күтәрелгән иде. Кемнәрдер:

— Әбу-Рафигъны кылыч белән чабып үтергәннәр! — дип аваз салды.

Эшне дусларына аңлатып биргәч, кузгалдылар, әмма Габдулла ерак бара алмады. Чалынып егылудан аягы сынган иде. Сәхабәләр аны күтәреп киттеләр. Ул алар янына бер аягында сикерә-сикерә килеп җиткән иде, алай ук зыянлы дип башына да китермәде.

Сәхабәләр Мөхәммәд пәйгамбәр каршысына килеп, вакыйгаларны бәян кылдылар. Әбу-Рафигъны катил итүләре хакында мөселманнар ишетеп, барсы бергә сөенсәләр, монафикъләр исә капкаларын кат-кат терәкләр белән бикли торган булдылар.

Һиҗрәтнең өченче елында Госман бине Гаффанга Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең кызы Өмме-Гөлсемне никях итте, җөмадий-әл-ахыр аенда аларның зифаф кичәләре булып, шуңа бәйле рәвештә сәхабәләр Госманны Зән-Нурин дип атап йөртә башладылар. Зән-Нурин дигәндә Мөхәммәд пәйгамбәрнең нурларыннан ике кызының да ире төшенчәсе бу гыйбарәгә салынган иде. Инде язып узганыбызча, Госман бине Гаффанның мәрхүмә хатыны Оркыя шулай ук Мөхәммәд пәйгамбәрнең сөекле кызларыннан берсе иде, Бәдәр сугышы вакытында Мәдинәдә шәһит китте. Һәм менә инде Өмме-Гөлсемгә бәхетле Госман хуҗа булып, «Ике нурга ия» кушаматын алды, Зән-Нураин, яки, кыскартып, Зән-Нурин, диделәр. Бу сүз үзенә күрә титул-дәрәҗә мәгънәсенә дә җиткерелде, ике

кызының да ире булуы сәбәпле Госман бине Гаффан, һичшиксез, Мөхәммәд пәйгамбәрнең иң якын кешеләре сыйфатында тагын да үстерелде. Аның урыны һәрвакыт Рәсүл Әкрамның янында булды.

Әмма бу вакыйга арадан Гомәр бине Хаттапка авыр тәэсир итте, чөнки аның чибәрлектә һәм усаллыкта тиңсез Хафисә исемле унсигез яшьләреннән тол калган кызы бар иде. Кайбер хәбәрләргә караганда, аның ире Ханис бине Хузафәт Бәдер сугышында батырларча һәлак булган иде. Шул ук вакытта талак кылынуын да язалар. Шушы чибәр кызын әүвәле Гомәр бине Хаттап инде олыгаеп барган Әбу-Бәкергә кияүгә бирергә теләде, ул баш тарткач, Госман бине Гаффанга ниятен җиткерде. Әмма ул да зәһәрлек иясе гүзәл Хафисәдән баш тартып, фазыйләттә асыл зат Өмме-Гөлсемне сайлады. Шушы хәлдән соң тәмам кәефсезләнеп калган Гомәр мәҗлесләренең берсендә, Мөхәммәд пәйгамбәргә бу вакыйгаларны хәбәр итеп, киңәшен сорады. Бәлки, әйтмәгән дә булыр иде, әмма тәмам түбәнсенгән күңеле бер-бер терәк эзләде.

— Синең кызың Хафисәгә Аллаһы тәгалә Госманнан да өстенрәк бер затны сайлады,— диде аңа пәйгамбәр, серен тиз генә чишеп бетермичә, ә аннары, бераз вакыттан соң, Хафисәне үзенә соратты. Гомәрнең күгендә икенче кояш калыккандай тоелды. Әмма зәһәрлек иясе Хафисә, килен булып төшүгә, пәйгамбәрнең хатыннары арасында тавыш чыгарды, барсын да биетер дәрәҗәгә җиткерә башлады.

Рәсүл Әкрамның йортындагы изге тынычлыкның кызы Хафисә аркасында бозылуы Гомәрнең үзенә дә ошамады, инде әйтеп кенә тыңлата да алмый иде. Шулар хакында борчылган көннәренең берсендә Әбу-Бәкердән:

— Кызымның кулын сиңа тәкъдим иткәнемдә ни өчен бер генә җавап та бирмәдең?—дип сорады Гомәр.

— Мин ул вакытта,—диде Әбу-Бәкер Әс-Сыйддыйк,—Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызыңны искә төшергәнен ишеткән идем!

— Ә нигә миңа әйтмәдең?

— Пәйгамбәрнең серен сөйләү әдәпсезлек булыр дип уйладым,—диде бу хакта сөйләшүне тәмам итеп Әбу-Бәкер.

Әйтерләр, нәкъ шушы гүзәллек һәм зәһәрлек иясенә Мөхәммәд пәйгамбәр изге сандыгын сакларга бирде, анда Корьәне-Шәрифнең язма сәхифәләре бикләнгән иде. Хафисә исә һичбер вакытта да ул сандыкны күз уңыннан төшермәде, үзенең җаныннан да кадерлерәк итеп саклады.

Әмма хәтәр хатын Хафисә, бик яшь тә булуына карамастан, көндәшләрен үпкәләткән төсле, вакыт-вакыт Мөхәммәд пәйгамбәрне дә рәнҗетә иде. Рәсүл Әкрамның моңа тәмам чыдарлыгы калмады һәм аны талак кылды. Бу хәлдән Хафисәнең әтисе Гомәр шашынып дәрәҗәгә җитте, урам уртасына утырып, башына тузан койды һәм:

— Минем дөньяда моннан соң нинди абруем калды? Кызым ике дөньяның да солтаны Мөхәммәд пәйгамбәрнең хатынлыгыннан куылганнан соң минем нинди абруем булсын?!—дип үксеп елады.

Шунда Рәсүл Әкрамга Җәбраил фәрештә иңеп, Аллаһы тәгаләнең әмерен җиткерде һәм:

— Бу дөньялыкта хатыннарың арасында аннан да чын күңелдән бирелгәне һәм намазны күп укыганы юк, синең талагың кабул ителмәде!—дип белдерде.

Хафисәгә Мөхәммәд пәйгамбәр гафу белән килде һәм никяхларын яңартты, талагын кабул итмәгәннәре сәбәпле, кавышудан тыелып тору, ягъни гыйддәт чоры таләбе куелмады.

Әтисенең кичерешләре һәм дивана хәлләргә төшүләре Хафисәне тәртипкә кертте, хәтәрлеге сүнә барып, иренең ышанычын тулысынча аклады, озын гомерләр яшәп, өммәтнең анасы дәрәҗәсенә җитеп, вафатына чаклы теленнән Корьән аятьләрен төшермәде...

Һиҗрәтнең өченче елында шулай ук тарихи бер вакыйга булды. Гали сәхабәнең һәм Мөхәммәт пәйгамбәрнең кызы Фатыймаи-Зөһрәнең ир

баласы дөньяга килде. Рәрсүл Әкрам аның колагына үзе азан әйтеп, Хәсән исемен бирде. Җиденче көнендә, корбан чалдырып, зур бәйрәм мәҗлесе җыйды. Мөэминнәрнең сөенече Мәдинәне хозурландырды. Мөхәммәд пәйгамбәр оныгы Хәсәнне җиде яшенә кадәр итәгеннән төшермәде, Исламның терәге итеп тәрбияләде. Шуның өчен дә Хәсәнне, икенче төрле, Мөхәммәд пәйгамбәрнең улы дип атадылар. Бу исеменнән тыш, Сәед, Вәли, Таһир дип тә йөреттеләр. Риваятьләрдән күренгәнчә, кырык җиде яшенәчә галим һәм мөхтәрәм зат булып яшәде, тугыз малае һәм кызлары туды. Аларны, әтиләренә күрә, Сәед нәселе дип атадылар. Казан ханлыгының соңгы сәеде — Кол Шәриф хәзрәтләре, шагыйрь, галим һәм дәүләт эшлеклесе, баһадир затның шәҗәрәсе Гали сәхабәгә барып тоташа, аның нәселеннән иде. Шулай итеп, Мөхәммәд пәйгамбәрнең нәселе борынгы дәверләрдә үк хәтта безнең Идел-Урал буйларына да килеп, илебез иминлеген һәм динебез ныклыгын саклау өчен каннарын да кызганмадылар...

Тагын да шунысы мәйданга чыкты: Бәдердә җиңгәннән соң һәм Мәдинә тирәсендә дә Ислам дине ныгый башлагач, кайбер мөселманнар, иманнары йөрәкләрен сафландырып та җитмәстән, Аллаһы тәгаләнең әмерен узып, Мөхәммәд пәйгамбәрнең фәрманнарына буйсынмыйча, үзара һәм читләргә золымнар да кылгаладылар, ара-тирә, оештырып, кече яулар белән дә табыш артыннан йөргәләделәр. Моңа Раббыбызның кодрәте килеп, мөэминнәр өстенә каза китерде. Ухуд сугышы шушы сәбәптән олуг бер вакыйга буларак мөселманнарны айнытып җибәрде. Дөрес микәнни, күңелең бәхеттән тутыга башласа, бер-бер бәладән соң чистарынып китә, диләр...

*(Икенче китап тәмам)*

*Казан, 1992—1995.*

## ШИГЪРИЯТ



**Җәүдәт Сөләйман**

### Өмет

Тәнем-җаным җитмәс,
 беләм,
Тик, иншалла,
 җитәр каным,—
Миндә туган рух тамчысын
Чишмә итәр оныкларым.

Тузганак та,
 җил дә булмас
Мин ялгаган өммәт мәле.

Фани дөнья бәгырендә
Сөләйманнар күзәнәге...

### Коелыгыз

Хәле бетеп егылган ат,—
 Дагалап интекмәгез.
 Җанына тимер кадаклап
 Атны
 интектермәгез...

Хәле бетеп егылган ат...

Күңелләр иләкләнгән чак.
Җилкән булмас — көтмәгез.
Тишкәләр генә, ялгамас —
Күңелгә сүз текмәгез...

Күңелләр иләкләнгән чак...

* * *

Сират күперләре:
Дулкын арты дулкын.
Көймә ишкәк җәйгән,
Кочып дулкын сыртын.

Дулкын уңаена
Көймә бара җайлап,
Ашыр морадына,
Булсын атна-айлап...

Янә дә бер көймә,
Алда дулкын күреп,
Ишә ишкәкләрен,
Күчәм, дип, җилкенеп.

Кайда соң бу көймә,
Чагылмый колачы?
Юкка чыкты көймә,
Күбек сытылганчы.

...Комга яткач төбе,—
Диңгез ачты серен:

Дулкын алды — упкын,
Дулкын арты — упкын,
Йә — тап Ишкәк-канат,
Йә — ят, йолдыз санап.

## Кем соң җайлар телнең җанын?

Чәбәләнгән Телем кат-кат,
Йолкып-тартып сүтмәгез,
Үрмәләр өчен үрләргә
Телне аркан итмәгез...

Чәбәләнгән Телем кат-кат...

Чәбәләнгән татар теле,
Кем соң үрер җаена?
Кемнәр җайлар Телнең җанын
Телнең үз уңаена?..

Кем соң җайлар... Телнең җанын!..

* * *

Яшьлеккә күперләр тиз туза,
Аръякта — балачак шаукымы,
Ә юллар тоташыр шикелле
Салават күпере аркылы...

* * *

Күңелне чигүләр бизәсә —
Күңеле чәчәктән димәгез,
Күңелгә чигелгән чәчкәләр
Бәгырьгә ямаулык —
Тимәгез.

## Инсайт[1]

Табак-табак колакларын
Салган борчак-күзләренә.

Ялт-йолт килә үткер пычак —
Дуңгыз
балчык эзләвендә.

Бәйләп салгач аркасына,
Мырк-мырк килде күккә карап,
Тәүге тапкыр
күрде күкне —
Күрү өчен...
соңгы кабат.

* * *

...Дуслар өчен бер сүз әйтми булмас,
кинаяләп кенә булса да:
диңгез төпләрендә калса да,
өсләренә шәһәр корсаң да —
вулкан икән — атар, атмый тормас.

Дуслар өчен шуны әйтми булмас...

* * *

Янә кайтты
меңләп еллар каккан ярларына
талгын дулкыннары Казансуның.

[1] инсайт — кинәт килгән ачыш (инглизчәдән).

Калыктылар
        таллары да ләм астыннан.
Тал үзәген
        божра-божра элмәк-еллар ...ята буып.

...Терелүме, әллә
            талпынуымы соңгы —
дулкыннары дерелдәвек
Казансуның?

* * *

Җылы сүз, дип, синнән — өметләнмим,
кояш нурларында туңсам да.

Тик нигә соң килә тоясым
күләгәңне генә булса да?..

* * *

Кояш яктысыннан бераү
    күләгәләр коя...
...Кечкенә бер күләгәгә
    күпме сылтау сыя!..

* * *

Вакыт — тырма, мин — тегермән,
икебез ике чатта —
вакыт тырмалый галәмне,
мин борчак тарткан чакта...

* * *

Синең җаның, синең егәрлек
сыямыни фани гомергә!
Җиде буын китеп карау кирәк,
җиде буын җыйган моң-җан кирәк,
синең җанны тулай күрергә...

...Үлән арасында
чак-чак күренерлек,
үсә сыек чыбык, —
җилдән өзелерлек...
...шушы нечкә сыннан
үсәр диеп имән,
кайдан белсен үлән —
үлән җанлы үлән.

* * *

Сагынам да,
тизрәк күрешүләр
булмас микән? дигән уй килә.

Йолдызларны күктән койсалар да
булмас идем җирдә ятимрәк.

* * *

Комда — мизгел: адәм эзле Җирдә...
Милләт эзе Җирдә — шигырьләр.
Көл-күмердән туган милләтләр бар,
Шигырьләрдән үреп гомерләр.

...Чыра булып телгәләнгән милләт тә бар —
Күмер булып өелә
шигырьләр...



# КАЗАННЫ САГЫНЫП ЯШӘҮЧЕ ШАГЫЙРӘ



**Фәния апа Чанышева — Уфада яшәүче шагыйрәбез, «Гомер мизгелләре», «Боз һәм ялкын» һ. б. шигырь һәм проза китаплары (башкорт телендә чыккан җиде китап) авторы.**

**Быел исә — юбилеена (сентябрь аенда Фәния ханымга 70 яшь тула) көтеп көткән татарча китабы — «Күзге чәчәкләр» дөнья күрәчәк. Хәерле сәгатьтә булсын! дип калабыз...**

**Фәния Чанышева — татар әдәбиятының күптәнге, сыналган дусты, күренекле башкорт әдибе Гыйлемдар ага Рамазановның тормыш иптәше, шулай ук Казан әдипләренең якын дусты, ихлас сердәше. Олуг бәйрәме уңае белән без бу санда тәкъдим иткән шигырьләрендә дә шагыйрәнең Х. Туфан кебек остазларга, инде мәрхүм Гыйлемдар агадай күренекле шәхесләргә, күп татар әдипләрен тудырган Башкортостан туфрагына карата җылы, самими хисләрен укучыларыбыз сизми калмас, мөгаен. Әйе, дуслык, мәхәббәт, хатын-кыз кичерешләре һәм шигърият — мәңгелек, аерылгысыз төшенчә. Казанны сагынып яшәүче матур җанлы шагыйрәгә бездән дә дуслык сәламе һәм ихлас котлау булсын!**

## Фәния Чанышева

### Тыңлагыз, Казан сөйли...

Җилләр инде яфракларның
Соңгыларын коя җиргә,
Кар аралаш яңгыр ява,
Бик ямансу әллә нигә...

Шушы соры, йончу көнне,
Белгән кебек күңелемне,
— Тыңлагыз, Казан сөйли! — дип
Таныш тавыш килеп керде.

Килеп керде... Дусларымны
Иң сагынган чакта гына,
Алып китте Казаныма,
Чаллы, Чулман якларына.

Иркәләде колагымны
Бөек Тукай сүзе белән,
Салих Сәйдәшев моңнарын
Алып килде үзе белән.

Килде миңа хәтерләүләр
Җәйләремнән, кышларымнан...
Сабый чактан, еракларга
Таралышкан дусларымнан...

Шушы моңнар озата бара
Елларымның агышына,
Алар җылы агым булып
Үрелгәндер язмышыма.

## Шагыйрь вафатыннан соң...

*Нигә болай моңсу булып китте*
*Сорыйк әле шуны таллардан.*

Х. ТУФАН.

Гелән шулай булыр кебек иде:
Дим буенда, безнең авылда,
Шаулап-гөрләп торыр кебек иде
Шигырь белән сыйлы табыннар.

Чал башыңны моңга чорнар иде
«Мәдинәкәй», «Урал», «Уел»лар,
Салмак җилдә гөлләр тибрәнерләр,
Оеп тыңлар иде муеллар[1].

Җырларыңда йөрәк яраларын
Бәйләр йомшак куллар идек без,
Нечкә күңелеңне сызландырган
«Кер чайкаучы кызлар» идек без.

Онытылмас сының. Шигъриятең
Хәтер учакларын көйрәтер,
Кем юатыр безне, кем яратыр,
Сеңелләрем дип соң кем әйтер?

Киек казлар китә: «Кыйгак, кыйгак!»
Ишетелә әллә кайлардан.
...Дим буенда күзгә салкын яңгыр,
Яшь коела бөдрә таллардан.

---

[1] Муел — шомырт.

* * *

*Гомер юлдашым Г. Рамазанов истәлегенә*

Сагышларым өйдә калсын, дидем,
Януларым җитәр ут йотып,
Ак карларга басып сүрелимче,
Торыйм әле бераз онытып.

Кар башына карлар җитәр мизгел,
Март җилләре исә аямыйча,
Кола яланнардан атлыйм кебек —
Ышыкланыр җирләр табалмыйча.

Бүген инде еламаска иде...
Минем өчен җилләр еласын,
Ап-ак булган, әнә, бар дөньясы,
Буран бурый, әйдә, бурасын!

Онытасы, онытыласы иде,
Килми икән, килми көчемнән,
Хәтта тавышыңны ишетәм кебек,
Өерелгән буран эченнән:
— Мине шулай бер дә уйламаган,
Юксынмаган көнең бармыни?

— Бүген инде еламаска иде,
Керфек очларымда кар эри...

* * *

Нинди кырыс, салкын кыш булды бу?
Йончыттылар буран-чәченнәр,
Кырыс кыштай авыр көннәремнән
Чал бөртекләр калды чәчемдә.

Яз кояшы көткән бөреләргә
Зәһәр җилләр килеп кагыла,
Тирә-якны ак чаршауга чорнап,
Кар бураны уйный тагын да.

Өзелеп көткән язым — гомерем назы
Килер, килер, ташар елгалар.
Яз шатлыгын алып килә торган
Кошчыкларым инде — юлдалар.

* * *

Быел да Дим ярларыннан ашты.
Яшел тугайларга тарала.
Без икебез тагын ике ярда:
Болганчык су кайный арада.

Сулар китәр, ятып комы калыр,
Моңы калыр инде талларда.
Аргы ярдан сиңа кул болгыймын:
— Боекма,— дим,— ялгыз калганда.

Тыңла, иркәм, син дә яз хәбәрен,
Яз хәбәре йөри җил белән:
Шыткан үлән. Кыякларын сузып,
Күтәп торган мине гөл генәм.

Имин икән, һаман түмгәгендә
Кырмыскалар эштә кайнаша.
Сыерчыклар инде бала күтә,
Яз — язлыгын итә — тамаша!


Зәңгәр күктә сабан тургайлары,
Миләшләрдә бөре ярала.
...Кара җиргә саф орлыклар чәчәм,
Ак өметләр чәчәм арага.



# Чәчмә әсәрләр

## МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВКӘ — 50 ЯШЬ

## Тауга күтәрелү



**Көннәрнең берендә**
**Азнакай төбәгенә**
**сәфәр кылырга туры килгән иде.**
**Шушы якларның даны саналган,**
**җырларда җырланган**
**Чатыр тауны күрәсебез килә.**
**Менә без Чатыр тау**
**итәгенә якынлашабыз.**
**Юлдашларым —**
**язучылар Мөсәгыйт Хәбибуллин,**
**Илдус Гыйләҗев, Марсель Галиев.**

Шушы төбәктә туып-үскән кеше буларак, Марсель тәмләп, рәхәтләнеп туган ягын мактап бара. Салават күперендәге барлык төсләр белән балкыган катнаш урманнар, басу-кырлар янәшәсенә этешми-төртешми генә сыенган нефть кудыргыч «торналар», кара карга канатыдай зәңгәрсу-кара туфрак... Үз күзләребез белән күреп тә, юлдашыбыз сөйләгәннәргә ихлас ышанып та Азнакай яклары сурәтен күңелгә сеңдерәбез. Кыскасы, Марсель сүз айгырын уйната, күңелсезләнергә ирек бирми.

Тыңлап бару гына түгел, сүзгә без дә катнашып киткәлибез. Чатыр тауның сөзәкләнеп төшкән итәгенә күз ташлагач, әйтеп куйдым:

— Һәй, мондый гына таулар безнең Саба-Теләче якларында да бар ул!

Бу сүзләрдән соң Марсель мыек астыннан хәйләкәр генә елмая, бертын фәлсәфи сулыш алганнан соң:

— Ашыкма, тауның түбәсенә күтәрелгәч сөйләшербез, — ди киная белән.

Чынлап та шулай икән! Чатыр тауның иң биек ноктасына күтәрелгәч, безнең каршыда гаҗәеп бер манзара пәйда булды. Күк гөмбәзенең дүрт ягы да шәрран ачык. Мондый биеклектә уй-хисләрең дә биектәрәк талпына башлый, күңелне күтәренке тойгылар чорнап ала. Күккә таба ыграк якынайгангамы, бирегә борынгы-тарихи җилләр исә кебек. Шулай, җил-аргамакка атланган килеш, без дүрт яктан берьюлы ачылып киткән тирә-юньне тамаша кылабыз. Аста — болын, елга киңлекләре, мәрҗәндәй сибелгән авыл йортлары... Тагын да гаҗәпләндергәне: тау итәгендә таш балбаллардай аягүрә басып торган суыр (байбаклар) иде. Алар нинди җәнлек, ни-нәрсә, каян килеп

чыкканнар — болар хакында сез шушы якларның сулышын, табигатен яхшы белгән М. Галиевнең түбәндә тәкъдим ителәчәк язмасы аша яхшырак таныштырсыз.

Иҗат доньясында һәркемнең үз тавы, үз биеклеге була. Мондый билгеләмә Марсель Галиев иҗатына бигрәк тә туры килә. Мин аның барлык әсәрләрен диярлек яхшы беләм. Казан дәүләт университетында укыган елларда ук сабакташлар, аркадашлар идек. Марсель, нигездә, шигырьләр һәм проза әсәрләре яза. Мин аның китапларын кулыма алганда иң әүвәл үземне тау итәгендә басып торган сымаграк хис итәм. Беренче битләрне укыйсың һәм серле, билгесез, мавыктыргыч доньяга сәфәр башлана...

Яңалыкка, яңа хисләргә сусап торган күңел өчен никадәрле ачышлар, фикер кайнарлыгы көтеп тора сине! Иң нык сөендергәне — Марсель сүзләрнең тәмен, кадерен тоя, аларны зәбәрҗәт ташындагы төрле төсләр-чагылышлар белән уйната белә. Ни генә димә, телбизәкләр остасы ул, сүзләрдән рәсемсурәт ясау талантына ия. Шигырьләр, хикәя яки повестьларда булсын, аның геройлары — гамьле, борчу..ы, яхшылыкка җан аткан татар кешеләре. «Тау»ның түбәсенә, иң биек ноктасына күтәрелгән саен ачышлар арта, уй-фикер офыкларың киңәя, тормыш-яшәеш катламнары тагын да ныграк төсмерләнә башлый... Моңа ышану өчен М. Галиевнең «Ул чакта», «Ерак урман авазы», «Сиңа мин кирәк», «Апрель кызы» һәм башка китапларын укып чыгу җитә.

Кыска гына сүз башында мин Марсельнең иҗатына анализ ясау, биографиясен сөйләп чыгуны максат итеп куймадым. Язучының гомер юлы, язмышы, җисми һәм күңел биографиясе — аның әсәрләрендә. Алар белән танышканнан соң авторның әйтер сүзе, фикерләре, табышлары синең дә күңел байлыгыңа әверелә.

Кайсыдыр тәнкыйтьче әйткәнчә, Марсель Галиев тормышта бераз гына кыланчыграк яшь һәм шушы нәрсә күпмедер дәрәҗәдә иҗатында да чагылыш таба. Кемгә-кемгә, миңа калса, бу сыйфаты аңа нишләптер килешеп тора бит, шайтан алгыры!

Сугыштан соң туган буын... Вакыт сиздерми генә уза тора икән. Инде менә безнең буын вәкилләре дә «илле» дигән түгәрәк сан сызыгына якынлашкан. Гомер коязының зенитта чагы. Каләмдәшебезнең иҗаттагы егет чагы. Талантлы татар егетеннән без алга таба да көчле, яхшы әсәрләр көтәргә хаклыбыз. Татар халкының язмышы хәл ителгән хәлиткеч елларда бу бигрәк тә шулай. Шөкер, милләтебезнең күпер баганалары хәзергә сау, ләкин аста — субайлар тирәсендә империя пычкы тешләренең астыртын кыштырдавын сизмәү кыен түгел.

Түгәрәк юбилеең мөбарәк булсын, каләмдәшебез! Алда безне каләм, ак кәгазь, яңа көрәшләр көтә.

Рәшат НИЗАМИЕВ.
*22 июнь, 1996 ел.*

## Марсель Галиев

# ДОГАЛЫ ЕЛЛАР

### Сөйлә, җил... Юат мине...

*Тауларга карап тау булалмасам да,*
*тауларга таянып ятканым бар.*

Безнең бакча башындагы иң биек өянкене кистеләр. Колач җитмәслек әзмәвердәй агач, доньябелән бәхилләшеп, бөтерелә-бөтерелә, гөрселдәп ауды. Мин аның эчтән җан кылы ухылдап өзелгәнен

[1] «Гасыр китабы»ннан аерым бүлекләр.

ишеткәндәй булдым. Тамырлары тирәнгә киткән түгәрәк, бирчәйгән кабыклы төбе карт агачның ак бәгыре сыман ачылып китте. Пычкы чүбен аралап, мин еллар божрасына төбәлдем. Гасырга яшьтәш агачның дымлы күзгесеннән туган елым божрасын ничек табарга? Үзәктән сырланып килә-килә, ел фасыллары кырык алты тапкыр бөтерелеп алгандыр. Менә ул, шушы тирәдә, урта бер җирдәрәк булырга тиеш. Хәтәр сугыш тынганнан соң, җир йөзенә вакытлыча тынычлык иңгән ел. Сталин исән әле, мартеннарда аның һәйкәленә дип тау-тау руда эретелә. Көлгә әйләндерелгән Хиросима белән Нагасаки җирендә беренче шытымнар чыккан ел. Нәкъ ун елдан мәшһүр шагыйрь булып кайтасы Хәсән Туфан Уралда көтү көтә. Минем әтигә утыз сигез яшь. Ил-көндә коточкыч ачлык хөкем сөрә.

Үлчәү йолдызлыгының бәрәкәтле нурлары җиргә туры караган мәлдә малай тапкан әнигә «Сталин бүләге» — биш метр сатин биргәннәр. Ачлык-ялангачлык патшалык иткән чорда бу да зур бүләк булып тоелгандыр. Әнием, бизәкле тукыманы йөзенә якын китереп, аның исерткеч хуш исеннән күзләрен рәхәт йомып, бер мәлгә хозурлык кичергәндер. Октябрьнең вак яңгырлы тымызык көнендә тәкъдирдән юаныч, җанына сабырлык сорап дога кылгандыр.

Өянкенең соңгы талпынышы да саваплы гамәлгә дучар иде — инешкә аркылы авып, аргы ярны тоташтырган күпер булып ятты ул. Ә аргы якта — минем хәтер болыннары, таулар, ак болытлы офыклар, армасуенчак җил кочагында ирек-иркенлек тәмен тоеп, йөгереп тә, мәтәлчек атып та кинәнеп туя алмаган киңлекләр...

Туган төбәгемдә табигатьнең үзе шикелле гадел карашлы кешеләр белән аралашып үсүемне олы бәхет дип саныйм. Юк, бәләкәйдән үк Парижларны күрмәдем, дөньялар гизмәдем. Әмма язмышыма үпкәләмим. Ярлы балачагым күңелле узды. Шуңа да мин яшәү дигән очраклы могҗизаның тирән дә, серле дә коесына еш тукталып карыйм — уйланам. Өметне алдагыга күчерә торып, аздан да канәгатьлек алу — миңа нәселдән бирелгән сыйфаттыр, мөгаен.

Минем өчен Эйфель манарасы — авылымның пожар каланчасы иде. Тегермән шарлавыгы — Ниагара, аръяк болын түмгәклегендә үскән аксыргаклар — балачагым пальмалары, шул тугайлар өстеннән юк сәбәптән дә сыктап әйләнгән тәкәрлекләр — адашып калган диңгез акчарлаклары иде.

«Вальпараиса, Галлапогос, Титикака, Куала-Лумпур — шәп яңгырый торган исемнәр, беләм! Әмма минем өчен Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы тагын да шәбрәк яңгырый! Кадерле булганга шәбрәк яңгырый!» — дип яза олуг әдибебез Аяз ага. Әйе, бәхәссез хакыйкать. Туган ягыңдагы инеш-күл, тау-үзән исемнәрен әйткән чакта җан рәхәт сулкылдый, сутлы тамырлар аша җиргә тоташканыңны тоясың. Ул исемнәр туган як шамаиленә язылган догалыкның аерым бер сүзләре кебек.

Дөнья картасына карасаң, Татар бугазыннан алып Карпатка кадәрге тулы бер кыйтганың елга-күлләре, тау-үзәннәренә төрки-татар атамалары кушылган. Гасырлар буена барган бөек күчешләр дә, яулап алучыларның тарих хәтерен көл итәргә адарынулары да үзгәртә алмаган бу географик атамаларны! Моңа Ходай тәгалә үзе ирек бирмәгән. Ул исемнәр шул төбәк-табигатьнең үз тыны-сулышыннан татар аһәңе белән кушылып яратылган да мәңгелек яңгыраш алган.

Алтайдамы син, Уралдамы, Байкал яисә Азов (Азак) ярында гомер сөрәсеңме — әлмисактан бирле үземнең ата-бабалар бишек иткән җиремдә мин, дип башыңны горур тотарга иде дә бит, кеше туганым, үткән зурлыкларыңны аң-зиһенеңә сыйдыра алмыйсың шул әле. Күпләргә инде моны якынча белү дә тәс түгел, ә бәлки, чит милләт горурлыгына күчеп, кан бозу гына язгандыр...

Малай чакта биниһая озын чыбыркы белән селтәнгән булып, киредән аны җыя алмыйча чуалып азапланган кебек, әллә кая таралган уйларымны хәтер йомгагына чорнап, тау өстендә ятам.

Мөкатә тавы...

Коры үләнлек арасында нәзберек-тыйнак көмешсу әремнәр яктырып күренә. Тау бите буйлап, түбәтәй-түбәтәй булып, җете чәчәкле кыргый мәтрүшкәләр сибелгән. Исе шулкадәрле дә үткен, аны, гадәттә, мунча кызып өлгерер алдыннан ләүкәгә, себерке суына салалар. Кайнар пар белән кыргый мәтрүшкә исе кызышып кушыла да... куе бальзамлы хуш искә түзә алмыйча кытыкланган мунча ишеге шартлап ачылып китә...

Тау иңенә чалкан төшеп, туарылып аккан болытларга карыйм. Мин йөзәмме, болытлармы... Сирпелеп киткән тымызык әрем исендә — яшәү дәрте, исерткеч тәм, йомшак җил пышылдавы... Ваемсыз балачактагы кебек, күңелгә тыелгысыз хис тула, тау — яшел мендәр булып, үз кочагында тирбәтә.

Менә ул минем туган ягым. Аны күрү, колачлау өчен чама белгән биеклек кирәк. Арырак — бу манзараның икенче каты башлана. Болары инде тагын да биегрәк — киртләч сукмаклы, итәгендәге кучкар-кучкар таш арасыннан җидешәр, унар толымлы чишмәләр бәреп чыкканы, куеннарыннан шәрә тезле кызчыклар кебек җитәкләшеп каеннар менеп барганы — Язулы тау, Дегет тавы, Ял таулары...

Арырак, тагын да биегрәге — офыкны иңенә күтәргән зәңгәр дулкын кәрваннары — ерак Урал кыяларының юашланган соңгы аккордлары. Боларның иң горуры, уртадан зәңгәр пирамида булып калыкканы — Чатыр тау! Тәңре тәхете!..

Шушы өч төстә, өч яссылыкта торган таулы манзарага карыйм да, сокланудан, кочагыма сыйдыра алмаудан, табигатьнең кодрәте каршындагы көчсезлегемнән, гомер кыскалыгын оныттыра торган хозурлыгыннан күзгә нәүмиз-татлы яшь килә. Шул мәлдә, әни кулы сыйпаган кебек, сизгер җил керфектәге тозлы яшь тамчысын итәге белән сыпырып ала.

Гаҗәп бит, тыйнак кына Мөкатә тавыннан әнә нинди ераклыклар күренә. Ә артында — ак күбекле карабодай кыры уртасында түм-түгәрәк гөмбәз булып, япа-ялгыз курган — Суыр тавы калыккан. Кайчандыр аның иңендә саллы гәүдәле суыр дигән җәнлекләр йөргәндер. Ни сәбәпледер бу җәнлекләр ераккарак, Чатыр тау тарафларына китеп барганнар. Үзләре урынына карсак йомраннарны калдырганнар. Шунысы гаҗәп: йомран да арткы аягына утырып, дөньяны тамаша кылырга ярата, хәвеф-хәтәр сизенсә, әче итеп сызгырып куя. Суыр да нәкъ шулай. Төсләре дә охшаш. Аермалары — песи белән юлбарыс кебегрәк. Холыклары исә чагыштырырлык та түгел. Йомран — Бонапарт холыклы, кәрлә, чәберчек, ярсу, тешләк. Суыр исә олпат җәнлек, гәүдәле булса да, үлән генә ашаганлыктан, явыз түгел. Өненә кереп качарга өлгерә алмыйча чарасыз калса, үзен рәнҗеткән кешенең күзенә карап утыра да алгы аяклары белән битен сөртә-сөртә, адәм баласы сыман үксеп җылый. Аның инәлеп җылавына да карамыйча зыян салган кеше гомерлек каргыш ала, алдагы тормышында мантый алмый инде.

Суыр — әдәби телебездә *байбак* дип атала...

Өненнән чыгып, кызгылт ком-балчыктан үзе өйгән постаментка горур һәйкәл булып баскан суыр каршында гөнаһсыз уй белән туктал син, кеше туганым! Бу җәнлекнең тарихы, нәсел шәҗәрәсе ерак гасырларга барып тоташа. Алар — мәңгелек сагында торган бакый таулар белән бер тиңдә сөйләшергә хаклы җан ияләре!

«Тарих фәне атасы» Геродот, безнең эрага кадәр 450 ел элек Һималай таулары арасында «Алтын эзләүче кырмыскалар» барлыгы хакында язып калдырган. Бу кырмыскалар эттән бәләкәйрәк, төлкедән зуррак, үзләре куе йонлы имеш. Алар Греция кырмыскалары кебек үк җирне казып оя ясыйлар, дип язган Геродот. Һәм шуларның өннәреннән алтынлы ком җыючы дард дигән халык турында да искәрткән тарихчы (дард дигән җыелма исем астында бүгенге көндә шина, кашмир, кхо, кихистан халыклары күздә тотыла).

Шулай итеп, алтын эзләүче кырмыскалар хакындагы легенда, әллә нинди әкияти сурәтләр алып, төрле кыйтгаларга тарала. Кыю сәяхәтчеләр төрле тарафларга — Грециядән башлап Кытай диңгезенә, Монголиядән алып Һиндстанга кадәр шул кырмыскаларны табу өмете белән юлга чыгалар, әмма максатларына ирешә алмыйлар. Ике мең елдан артык дәвер эчендә бу серле кырмыскаларны таба-ачыклый алмыйлар. Шул чорлар эчендә галимнәрнең фараз кылып язылган күпме хезмәтләре дөньяга туа.

Александр Македонский да Һиндстанга яу сәфәре вакытында алтын табучы кырмыскаларның эзенә төшү максатын куйган була. Ләкин ул гаскәрен бүтән юлга борып җибәрүе аркасында ниятенә ирешә алмый кайта.

Ә бу легенданың башы каян килә соң?

Әхәмәнидләр мәмләкәте чәчәк аткан бер дәвердә (безнең эрага кадәр 522—486 еллар) Төньяк Һималай төбәге аның бер өлкәсе санала. Шул төбәктә зәңгәр күзле, аксыл чәчле, сугышчан, гаярь кабилә яшәве билгеле була. Алар фарсы патшасы Дарийга күпләп алтын китерәләр һәм алтын таба торган сәер җан ияләре хакында әйтәләр. Дарий моның белән кызыксына, затлы сараена бу җәнлекләрне китертә. Бу хәбәр фарсылардан Геродотка барып ирешә һәм ул бу җәнлекләрне кырмыска дип атый.

Берничә гасыр үткәч, фарсы хакименең сараенда йонлы, гаҗәп зур кырмыскалар күрүе хакында Неарх һәм Мегасфен әйтүе буенча, атаклы Страбон да язып калдырган (безнең эрага кадәр һәм безнең эраның 64/63—23/24 елларында яшәгән).

Ниһаять, безнең чорларда бу хикмәтле кырмыскалар белән француз галиме, этнограф Мишель Пессель кызыксына башлый. Сорбонна, Оксфорд, Гарвард университетларында белем алган, Мексикада Юкатан ярымутравында джунгли арасыннан майяларның уннарча шәһәрләрен тапкан бу галим күп кенә хезмәтләрне, бигрәк тә немец галимнәренекен җентекләп укып чыга. Сөйләшерлек дәрәҗәдә булса да тибет телен өйрәнә. Һәм берничә елын Һималайга сәяхәт кылуга багышлый. Ул анда минаро дигән халык яшәгән авылларга барып чыга. Галим шакката: минаролар нәкъ европача кыяфәтле, зәңгәр күзле, аксыл чәчләр икән. Ул алар белән дустанә мөнәсәбәткә керә, гореф-гадәтләрен өйрәнә. Минаролар Будда динендә саналсалар да һаман әле, борынгы гадәтләре буенча, Бабалашен (Зур тау ата) дигән Аллага һәм әби-Лхамга (Алиһә әби) табыналар икән.

Алтын эзләүче кырмыскалар хакында Пессель күпме генә сорап караса да берәү дә ул хакта берни дә белми. Сәяхәтен дәвам итеп ул Һиндстан, Пакистан чигендәге демаркацион сызыкны үтеп чыга, моңа кадәр чит кеше аягы басмаган тарлавыклар, хәтәр кыялар аша узып, ул, үзенең юлдашлары белән, Дансар тау яссылыгына килеп җитә. Минаролар моңа кадәр бер генә европалыны да бу җирләргә аяк бастырмаган булалар. Тәкәббер немец галимнәре, әлбәттә инде, җирле халык белән җылы мөнәсәбәткә керә алмагандыр. Шуңа күрә ачыш та француз тәрбиясе алган Мишель Пессельне көтә.

Диңгез өслегеннән 4000 м. биеклектә яткан Дансар тау яссылыгына килеп чыккач, ул хәйран кала. Күз күреме җирләргә нәни таучыклар булып суыр оялары сибелгән. Минаролар аңа: «Безнең ата-бабаларыбыз шушындагы ялардан алтын комы җыйганнар. Болар — алтын табучы җәнлекләр»,— дигәннәр.

Егерме биш гасыр элек Геродот кузгаткан сер, шулай итеп, 1980 елда француз галиме тарафыннан ачыла. Оя казыганда алтынлы җирнең комын чыгарып өюче җан ияләре кырмыска түгел, ә суыр дигән җәнлекләр икән бит!

Шунысы хикмәтле: минаро телендә бу җәнлекләр б а й б а к дип атала икән...

Минаролар, кайбер галимнәр фикеренчә, борынгы бабаларыбыз скифларның нәсел башы санала. Димәк, алар Европага таба күчеш чорында кайсы таулыкларда алтын барлыгын белү өчен, суыр-байбакларны үзләре белән алып, үрчетә-үрчетә тауларга җибәрә барганнардыр. Менә ни өчен Алтайдан алып Идел-Дон арасындагы далаларга кадәр сибелгән скиф курганнарында гаҗәеп бай алтын әйберләр табыла. Скифларның «җәнлек стиле»ндә искиткеч сәнгатьле эшләнгән алтын әйберләре греларның антик сәнгатенә тиң куярлык түгелмени!

Шулай итеп, минем туган ягымның йөзек кашы булган Чатыр тау тезмәләрен туган җире иткән суыр-байбакларның нәсел тамыры әнә кая, дөньяның түбәсе — Һималай кыяларына барып тоташа.

Шушы тарихны белгәннән соң, бу үтә дә гадел, самими җәнлекләргә хөрмәтем тагын бер башка артты. Бер җәйне хәтерлим әле: кояшлы июнь көне иде. Чатыр тауның иң биек ноктасына менеп, саф җиләндә коенып алдык та, янәшәдәге таулар куенына төштек. Чаукалыкта учак яна, асылма казанда шулпа кайный. Күмер өстендә шашлык кымырҗый. Табын мул, кәеф шәп. Магнитофоннан ургылып музыка агыла. Бервакыт тау битләре буйлап тезелгән кызгылт өркәчләр артында хәрәкәт купты. Безнең ул кадәр үк явыз түгеллегебезгә тәмам ышангач, суырлар балачагалары, бөтен гаиләләре белән ояларыы кырыена чыгып яттылар. Изрәп музыка тыңлыйлар. Астарак, безнең учактан ерак түгел генә оядан чыккан суыр үрә басып сакта тора. Якын бара башласаң, бөтен гәүдәсен селкетеп, койрыгы белән көч биреп, сызгырып куя: бүтәннәргә хәбәр сала, янәсе. Мин аңа таба отыры якынаям, суыр күзгә туп-туры карап тора. Үзе чамалаган кадәр ара калгач кына ялт итеп оясына чума.

Тагын аңлашып булмады... Югыйсә, тау битендәге бөтен суырларны җыеп әйтәсе идем:

— Ничәмә-ничә гасыр буена күпме галимнәрнең, алтынга кызыгучы башкисәрләрнең хыялында йөргән, сокландырган, аптыраткан, табындырган җәнлекләр бит сез! Кышларын, озын йокыга талгач, ата-бабаларыгызның туган җире — бәллүр кар түбәле Һималай кыялары төшегезгә керәме?!

Керәдер, мөгаен...

Әгәр сезне Геродот хәзрәтләре кырмыска дип атап, күпме акыл ияләрен саташтырмаган булса, европалылар тарафыннан күптән инде кырылып беткән булыр идегез. Рәхмәт аның бөек ялгышына! Рәхмәт аның егерме биш гасыр чишелми килгән табышмагына!

Кызыгам мин сезгә, мәҗүси җаннар. Туган ягымның туграсына тере бизәк булып керәсе галиҗанәб байбаклар!..

* * *

Чишмә тавыннан караганда туган авылым кочакка сыя да бетә. Әнә, каен урманының ике тарафыннан Нөгеш, Чат сулары агып чыга да, авыл эчендә кушылып, Эстәрле инешенә әверелә. Өянке тамырларына тотынып аккан шул инеш буаларында мин йөзәргә өйрәндем. Тал күләгәсендәге серле кумырыклардан дөмберт белән балык куа идек. Бидәлгә яисә кәрҗингә эләккән балыкны җыясың, кара төстәге этләй балыгын ташлый барасың. Тегермән буасында беләк буе чуртаннар эләгә, болар безнең авыл өчен акула дәрәҗәсендә, өлкәннәр генә эләктерә ала торган патша-балыклар.

Тегермән шарлавыгыннан соң инеш тараеп, зирек куаклары арасыннан шәбәеп ага. Анда тәңкә балыклар белән бергә «кылыч балыклар» да эләгә. Уйламыйрак тотынсаң, сырты кулыңны кисә торган, үрдәк борынлы, бармак буе бу балыкларны без, нининдер хәшәрәт эләктергән кебек чирканып, суга ыргытабыз.

И җүләр чак!

Кылыч балык дигәнебез кара уылдык бирә торган затлы чөгә (стер-

ляды) булган икән. Аларның әнкәләре Камадан Ык аша безнең Эстәрлегә — тыныч суга уылдык чәчәргә керә торган булганнардыр. Маймычлары үсә төшкәч, киредән Ык аша Камага китеп барганнардыр. Без, мокыт ташбашлар, әнә шул ерак сәфәргә җыенган, киләчәктә зур үсеп, Мәскәү Кремле өстәлләренә куелырга тиешле «чөгә малайларын», тотарга чирканып, иреккә җибәргәнбез икән...

Эстәрле баш авылы яныннан башланган чишмә калын урман эченнән көн яктысы эзләп ага, үз юлындагы салкын чишмәләрне житәкләп, авылның «казлар һөҗүменә» җиткәнче сафлыгын саклап килә. Урман күләгәсе төшкән сай суда бик тә елгыр балыклар йөзә. Ярдан күләгәңне күрүгә, ук кебек атылып, әллә кай арада юкка чыгалар. Тәмле булсалар да бу балыкларны яратып бетермибез. Шул бер-ике дистә елгыркайларны тоту өчен чытырманлыкта таланып, юешьләнеп, көне буена йөрергә кирәк. Соңы күңелле, әлбәттә. Балыклы савытың белән өйгә кайтып керүең — Парижны алуга бәрабәр. Тамагың ач, әмма бәхетлесең, күзләреңдә — борынгыдан килгән кыргый дәрт булып сунарчы хисе яна. Балыгыңны чистарту, йомырка белән кыздыру эшен, ясканып, әти үз өстенә ала.

Табигатьнең сулышка иркен чаклары!

Хәзер инде ул ярларга әйләнеп кайтсаң да юк... Чат суыннан, үзебез дә белмичә, патшаларны кикертә торган керкә (форель) балыгы тотканбыз икән шул малай чакта.

Күпме күзәткәнем бар: авылдашларым балык күргәч, әсәренеп китәләр, күзләрендә мәҗүси очкын кабына, сирәк тәтегән ризыкка олы бер канәгатьлек белән тотыналар. Моның сәбәбе нәрсәдә икән, дип уйлаганым бар. Бәлки безнең ата-бабаларыбыз бу якларга күчеп килгәнче, зур сулар ярында яшәгәннәрдер. Балык аларның көндәлек-гадәти ризыгы булгандыр. Балыкка табыну, тәм хәтере буыннан-буынга бирелә микән әллә?

Күченеп килгәч, баштагы чорда зур суларны сагынып, Эстәрле инешен дә, итек тә чылатмаслык дип, көн күргәннәрдер. Агыйдел булып Агыйделне бәләкәйсетеп җыру чыгарганнар бит әнә...

Агыйдел сулары кебек  
Тар сулар булмас инде...

Әллә ничә диңгез-күлләргә ия булган, иксез-чиксез мәмләкәтле татар гына мондый җыр чыгара ала.

Авылымның нәсел башы гомер сөргән урыннарда калын нарат-чыршы урманнары шаулагандыр. Наратка табыну да буыннан-буынга күчә барган, күрәсең. Ник дисәң, авылыбызга якын гына тоташ каен-усакимән урманы, ә зиратка, гадәттә, нарат-чыршы утырталар. Каенның әсәре дә юк. Ихата буенда каен үстерү — монысы инде бөтенләй күрелмәгән хәл.

Авыл башындагы куш наратка  
атлар да бит борылып карады...

Бу җырга куш нарат каян килеп керде соң әле, безнең авыл башында өянке иде бит, куш тирәк дип язсам да була иде. Бу хакта шулай кайта-кайта уйланганым бар. Куш нарат... Бәлки минем ата-бабамнар яшәгән авыл башында чынлап та куш нарат үскәндер. Зур даулардан соң таланган, җимерелгән авылны калдырып, бәхилләшеп киткән чакта, җигүле атлар соңгы тапкыр яшьле күзләре белән куш наратка борылып карагандыр. Моны борынгы бабамнар авазын алып килгән җил колагыма пышылдагандыр, һәм мин бу күренешне ихтыярсыздан кәгазьгә төшергәнмендер...

Бәләкәй чакта хәтерлим әле: тау өстендәге зиратның иң калку урынында карт нарат бар иде. Яшенле давыл купкан гарасатлы төндә ул авыл

төште. Киң ябалдашлы, куе ботаклы, каерылып үскән дәһшәтле-мәһабәт нарат иде ул. Авылымның тере шәҗәрәсе, иң карт хәтере булгандыр, мөгаен. Төнге яшен уты күк йөзен ялмап алганда ул тарафка карасаң, тетрәп китәсең, ботаклары көчле җилдән иңрәп кайный, нарат унике башлы дию сыман талпына, йолкына, төбе-тамыры белән бөтен авылны кубарып алып, галәмгә алып менеп китәр шикелле. Тыныч кичләрдә исә, каршы як тау артында кояш баеганда, наратның бирчәйгән кәүсәсе алтынсу төскә маныла. Иңкүлектәге авылыма инде моң гына төн җәелә, ә карт нарат очында әле һаман онытылган шәфәкъ нуры көйри, шул тымызык яктылык еллар аша минем күңелемдә ажаган булып сулкылдый...

Туган авылымның исеме — Балтач.

Күңел диварына жуелмас мөһер итеп сугылган бу атаманың яралгытамыры каян килә: бал —данмы, балта — данмы? — бу мине һәрчак уйландыра иде. Украинада Балта дигән поселок, Балтача фамилиясе йөртүчеләр бар. Моның кыпчаклардан күчкәнлеге бәхәссез.

Халык телендә йөргән риваятьләр мондый: имеш, безнең авыл урынында элек кичеп чыккысыз кара урманнар булган. Юан кәүсәләренә оялаган бал кортларының гөжелдәве агач шауларын да күмеп китә икән. Эссе җәй көннәрендә агач ботаклары арасыннан тач-тач бал тамып торган. «Тачбал»лы төбәк, әнә шулай, тора-бара халык телендә «Балтач»ка әверелә, имеш. Кара урманнар булуына да, бал тамып торуына да ышанам. Әмма телдә нинди дә булса атаманың кирегә әйләндерелүе — юк дәрәҗәсендә сирәк була торган хәлдер.

Бервакыт, тарихи чыганаклар укып утырганда, мин таныш исемне күреп сискәнеп киттем, күк капусы ачылгандай булды. Балта кеше исеме икән лабаса. Ни өчен Балтычка? Күпвакыт рус теле кайбер төрки-татар сүзләрен шундый итеп имгәтә, соңыннан инде аны ата-анасы да таный алмый... Идегәйне дә әнә Идика, Идека, дип язганнар бит. Димәк аның әтисе Балтачай яисә Балтачы булып чыга. Сугыш коралы — айбалта ясаучы яки балта остасы дигән сүз. Димәк, минем туган авылымның исеме борынгыга, кыпчак-татарларга барып тоташа, дастаннарга кергән атаклы Идегәйнең әтисе — Туктамыш хан тарафыннан һәлак ителгән бәкләр бәге — Балтачы исемен йөртә. Төп урыны кайда булгандыр, Идел-йорттан башланып, Урал тарафларына кадәр җитеп төпләнә барган балтачларның элгәрләре — борынгы бабаларыбыз бу олуг шәхеснең — Балтачының исемен авылда туган һәр буын кешесе теле ачылганнан алып, телдән калганчыга кадәрле кабатларлык символ итеп, саклап калганнар.

Малай чакта серле Чатыр тау бездән бик еракта тоела иде. Тау итәгендә мәгарә бар икән, анда яраннары белән, Пугачев үзе яшеренеп яткан, йөрәксенеп эченә кергән кешеләр хәзер дә әле кылыч-ханҗәр, ук-калканише кораллар табып чыгалар икән, дип сөйлиләр, ул мәгарә минем төшләремә керә иде.

Еллар узгач, шундый бер тарихи китапка тап булдым. Себердән кайтышлый, 1722 елда Петр Симон Паллас безнең якларга да сугылып чыга. Медицина докторы, табигать фәннәре профессоры, Санкт-Петербург һәм Рим академияләре әгъзасы Симон Паллас үз күзе белән күргәннәрен бөртекләп язып барган. Яшенле яңгыр үтеп китәр-китмәстән үк, кызыгып, ул Чатыр тауга күтәрелә. Тауның уң як итәгендәге иңкүлектә берничә рудник бар, дип яза ул. Халык телендә аларны бакыр базы дип йөрткәннәр, соңыннан инде мәгарәгә әйләнгән. Паллас килгән дәвердә бу рудниклардан кыш буена мең пот руда алганнар. Йөз пот рудадан ике пот чиста бакыр чыга икән. Руданы купец Мясников кул астындагы Иштирәк бакыр кою заводына ташыганнар (бер потка бер тиен түләү исәбеннән).

Паллас Туйкә авылында кунып чыга. Икенче көнне Чалтаймас елгасын кичеп, ул иске Бөгелмә юлыннан, безнең авыл кырыеннан гына

узып китә. Балташеводан өч чакрымнар киткәч, туйралы Ялтай тау тезмәсе башланды, дип яза галим. Ул тауны бүген дә халык телендә Ялтавы дип атыйлар.

Шунысы гыйбрәтле: Паллас килеп киткәнгә җәмгысы 224 ел вакыт үткән. Шул еллар эчендә табигать ничек үзгәрә икән. Чатыр тау итәгендә, бакыр базлары казылган иңкүлектә хәзер сарык көтүе йөри, суырлар оя кора. Ә элек, Паллас килгән чакта ул төбәк менә болайрак булган:

«В теплой долине, в которой находилися рудники, много цвело Бобовнику, дикаго Миндалю, также на некоторых местах распускали свои первые цветы вишни, ракитник и Aftragalus phyfodes. Я от рудника возвратился опять в деревню, в коей меня ожидали мои повозки.»

* * *

Малай чакта без Сталин башын чөеп уйный торган идек. Һәр малай кесәсендә кимендә бер-ике медаль кисәге — «Бөек атабыз» сурәте төшерелгән, әниләргә тылда алны-ялны белми эшләгән өчен сугыштан соң «якты көн» хисабына, ягъни, бер тиенсезгә бил бөккән өчен бирелгән бүләкләр булгандыр ул. Кул тими торса, яшькелт куныклаплый торган бу медальләрнең тормышта бернинди шатлык-бәхет тә китермәсен белгәннәрдер, шуңа күрә, без сукбайларның аларны югалтып, әрәм-шәрәм итеп бетерүенә дә күз йомып караганнардыр шул өметсез алданган бичара әникәйләр...

Әмма без түшенә орден-медальләр тезгән фронтовик агайларга кызыгып, аларга үзгә бер хөрмәт белән карый идек. Хөкүмәт бүләгенә аларның һәммәсе кан коеп, зур батырлыклар күрсәтеп ирешкәндер кебек тоела иде. Бүләк биргән җирдә беркайчан да тулы дөреслек булмаган һәм булмаячакны ул дәвердә башыбызга да китермәгәнбез. Ясалма каһарманнар, ялган легендалар, мәңгегә дип куелган вакытлы һәйкәлләр... кеше аңын томалый торган данлы сәхифәләр... Болар бар да тоталитет хөкем сөргән җәмгыятьнең үз-үзен исертеп яшәү рәвешеннән килә икән.

Күз алдына китерәм: Берлинны алганда Рейхстагка беренче булып байрак кадаган Заһитов һәм аның полкташлары турында хәбәр килгәч, Сталин: «Монда да татар өлгергән...» — дип, тешен кысып, ысылдап көйгәндер. Аның сулышыннан аңлап, яуда гаярь булсалар да, Сталин сүзеннән чыга алмаган маршаллар «тарихи хата»ны төзәтергә ашыкканнардыр. Җиңү байрагын элүчеләр икәү — берсе рус, икенчесе грузин булса, бик шәп килеп чыга бит! Соңыннан, монтажлап, документаль кинога төшерәсең дә... Күкрәген пуля тишкән килеш, Рейхстагның түбәсенә кадәр менеп җитеп, гөмбәзгә байрак беркеткән Заһитовның кемгә кирәге бар! Кан белән язылган дөреслекне сөртеп ташлап була ич...

Менә ул ил батырлары, тарих анналына керәсе каһарманнар — Егоров һәм Кантария. Әгәр Сталин милләте белән чукча булса, Егоров янәшәсендә байрак тотып йөгерүче дә чукча булыр иде. «Күзгә кырып салырлык» кына чукча милләтеннән берәр солдатны фронт буйлап эзләтеп, рейхстаг ишеге төбенә минуты белән китереп җиткерерләр иде. Әгәр инде бөтенләй табылмый икән, бүтән милләт кешесен чукча итеп, батырлык хакына, тудырган анасын да оныттырырлар иде.

Кантария дигәннән... 1976 елда Мәскәүдә «Яшь әдәбиятчыларның Бөтенсоюз семинары»нда катнашырга туры килгән иде. Шул көннәрдә комсомолның үзәк комитеты бинасында күренекле шәхесләр белән очрашу үткәрделәр. Космонавт, алдынгы эшче кебекләр арасыннан икәве — Зоя Космодемьянскаяның әнисе белән Кантария истә калган. М. В. Кантария зур башлы, чәче такыр итеп кырылган, Эльбрус тау сырты шикелле борынлы таза грузин иде. Рейхстаг түбәсенә байрак элүе хакында ул саран гына, теләр-теләмәс кенә искә алып үтте:

— Командир кушты да, Егоров белән икәү элдек инде,— диде. Анлары ул Грузиядә яшәвен, ике катлы йорты, җимеш бакчасы барлыгы

турында тәфсилләбрәк сөйләде. Күренеп тора: байрак хакында артык җәелеп китмичә, тере легенда гына булып йөрисе килә, ахрысы. Бәлки аны мондый очрашуларга еш чакырып, тәмам алҗытып бетергәннәрдер, бер үк нәрсәне кабат-кабат тугылаудан тәмам туйгандыр, батырлык кылса да тыйнак табигатьледер (грузин да булсын, тыйнак та булсын!) дип, эчемнән генә аны акларга да тырыштым бугай. Ул чакта әле Заһитов турындагы документлар якты дөньяга чыкмаган иде.

Без сугышның кайтавазын тоеп үстек.

Авылда сугыш кырларыннан Европага кадәр ил-җирләр гизеп кайткан фронтовиклар шактый иде. Аксаклары, аяксызлары — безнең өчен аерым чутта йөри. Ат караучы Шәрәфи абзый сыңар аягын агачтан үзе ясап кия, очына кыршау сугылган аягы, җирне төеп, түгәрәк-батынкы эз калдырып бара. Югары оч Садыйк абзый «ак эштә» — кәнсәләрдә. Аның кием шәп: куе зәңгәр френч, шундый ук төстәге галифе. Сыңар аягы да хөкүмәтнеке. Утыргач, протез аягын сузып куйса, галифе балагыннан түгәрәк резинасы гына түгел ялтыр тимере дә күренә. Аның таягы кәкре башлы, бик матур эшләнгән. Ни гаҗәп, без малайлар өчен таякка таянып йөрүче аксак фронтовиклар гарип булып тоелмыйлар иде. Киресенчә, чын ир-ат нәкъ менә шундый булырга тиеш дип уйлап, аларга кызыгып карый идек. Үзебез дә таяк юнәтеп, аксак булып уйнап мәш килә идек.

— Судабикер килә! Судабикер!

Тавышыннан ук әллә каян танып, урамга йөгереп чыгабыз. Америка машинасы студебеккерның алгы фаралары тимер челтәрле, үзе биек, ун тәгәрмәчле, безнең «полуторка» моның янында чүгеп кенә кала. Машина үтеп киткәч, рәхәтләнеп бензин исе сулыйбыз. Ят, тәмле тоелган бу ис хәзерге Париж ислемайлары хушлыгыннан да шәбрәк тоела иде безгә, артык саф һавадан туйган малайларга.

Менә — шаулы Бөгелмә базары, һәркайда ыгы-зыгы, сату-алу бара. Ә мин хәер сорашучыларны күзәтәм. Күбесе — фронтовиклар, өсләрендә уңып, сусәреп беткән солдат гимнастеркасы. Әнә берсе сыңар куллысы, өздереп тальянда уйный, аның янәшәсендә ике аягы да бот төбеннән өзелгән, кулдан ясалган дүрт тәгәрмәчле нәни арбага утырган димме, баскан димме — гармун моңына кушылып җыр суза. Алларында — тиен акчалы пилотка. Бернинди льготалар күрмичә үлеп бетәсе мондый фәкыйрьләр күпме иде ул елларда!

Авылга еш кына кинолар килә, сугыш турында булмаса, без аны карап вакланмыйбыз. Кинода безнең солдатлар һәрчак сәләмә киемле була, сазлыкка батып пычранып беткән солдатлар ардыра башлагач, кайчан немецлар күренер икән, дип көтәсең. Безнең офицерларның погоннары да иләмсез, коргаксыган чабата олтыраты сыман калҗаеп тора, ә тегеләр ялтыр киемнән, погоннар нәфис итеп үрелеп ясалган, ике кокардалы фуражкалары текә маңгайлы. Эчендәге тимер чыбыгын киереп, без үз фуражкаларыбызны шулай текә маңгайлы итмәкче булабыз — барып чыкмый гына бит... Немецлар хәрби киемне бик зәвык белән, малай чактан ук кызыгырлык итеп, тегә белгәннәр икән шул.

Ниһаять, ике кокардалы, биек маңгайлы фуражкаларны Россия офицерларына да туксанынчы елларда киярга насыйп булды... Партизаннарны да, сугыш бетеп кырык ел үткәч, энәдән-җепкә киендерә башладылар. Кер дә кунмаган ап-ак якалы, кардай ак туннардан землянкадан чыгып киләләр, минсиңайтим... Әлбәттә, киноларда гына шул... Бик соңлап... Хәерчелектән башы чыкмаган илдә авырлыкларны сәләмә кием белән генә күрсәтү, сәнгатьтәге өтеклек культы табигыйдер, мөгаен.

«Муса» операсында Җәлилне дә бер күренештә умырык гимнастерка белән чыгаралар. Үз чорында Мусаны якыннан белгән бельгияле Андрей Тиммерманс, Казанда бу спектакльне карагач, болай ди:

— Муса болай сәләмә түгел иде. Һәрчак ак күлмәктән бик пөхтә йөрде...

Без караган фильмнардагы, укыган китаплардагы сугыш вакыйгаларында кырылган немецларның исәбе-хисабы юк иде. Безнекеләр таш яисә агач артына посып атып яталар, ә немецлар, үрә басып, пуля яңгыры астына өерләре белән кереп кырылалар иде. Фильм төшерүчеләр шулкадәр арттырып җибәрәләр, немецларга карата нәфрәт түгел, киресенчә, кызгану хисе уяна иде. Хыялда кырганбыз икән фашистларны, сугыш беткәч санап карасалар (алман халкында кеше кадере исәпле икән шул), әллә ничә ил белән сугышып та алар сигез миллионга якын корбан биргәннәр. Ә безнекеләрнең әле дә очына чыга алганнары юк... Утызмы, илleme миллион...

Минем төшкә кырык биш ел буена гел сугыш күренешләре кереп җәфалады. Баш очында граната шартлап өлгергәнче уянып китә идем. Манма тир... Мендәр коткара иде. Әгәр беркөнне уянырга өлгерә алмасам, дигән курку гел миемне бораулап торды. Шөкер, хәзер инде андый мәхшәрләр төшкә керми, ничә еллар буе караган фильмнардан йоккан опиум тәэсире каннан чыгып бара, күрәсең.

Онытырлыкмыни...

Кичләрен капка төбенә фронтовиклар җыела. Китә хатирәләр... Әллә нинди серле исемнәр — Варшава, Кенигсберг... Мин сулышымны да алмыйча, тыңлап, чирәмдә ятам. Их, без үсеп җиткәч тә шулай зур сугыш булыр микән, яу кырларында батырлык күрсәтеп кайту безгә дә тәтер микән, дип матур хыялларга бирелəм. Соңрак, Әпсәләмов романнарын укый-укый бу теләгем тагын да көчәйде. Сугыш — кызыктыргыч романтика икән лабаса! Һәлак булуың да мөмкинме?! Булсани, совет үлеме ич ул!.. Ике дә уйламыйча ашкынып, яуга кереп үзен корбан итәргә әзер империя солдатын әнә ничек тәрбияләгәннәр икән.

Ә капка төпләре башка иде...

Күршебез Нургали абзый сөйли башласа, дөньяны оныттыра да куя. Минем әти сугышка кермәгән, Мәскәүдә метро төзелешендә эшләгән. Шуңа күрә ул, сугыш сөремен Мәскәү аша гына чамалаганга күрә, бик белдекле булып сүзгә катнашмый, әйбәт тыңлаучы сыйфатында көч биреп кенә утыра.

Нургали абзый картайды инде хәзер. Тормышның нечкәлекләрен художникларча күреп, үзеннән дә, кешедән дә сәнгатьле көлә белгән тел остасы хәзер йомшады, хәтере дә какшый башлады.

Сирәк кенә кайткан арада күрешәбез дә:

— Нургали абзый, мин җиде яшьләрдә чакта син шундый бер вакыйга сөйләгән идең: күрәләтә үлемгә җибәреп, муеныңа пуля тигәч, ул мәгънәсез, яшь командирны ата язуың турында...

Нургали абзый озак кына уйланып утыра, әллә син шуларны хәтерлисең, ди. Шулай итеп, Нургали абзыйның күргәннәрен үзенә хәзер мин сөйлим...

## Нуркалей

*Бу дөнья михнәте дә мәңге тормас,*
*Шулай ук рахәте дә мәңге булмас.*
Г. Утыз Имәни

Авыл өстендә моңлы рәшә тирбәлә. Малахай колагын җилфердәтеп, язгы кар суларын чәчрәтә-чәчрәтә, урам иңләп бер малай килә. Ярты бәхеткә ирешкән юеш танаулы малай... Бер аягына нык табанлы Америка ботинкасы, икенче аягына күтәртмәле чабата кигән.

Әгәр мин, рәссам булсам, картаеп килгән бу гасырның егерме бер яшьлегенә кайтыр идем дә, шушы күренешне тымызык суратка төшерер идем.

«Ачлык патша» хакимлек иткән авыл, яңаклары эчкә батка бөкре карчык шикелле, өмет белән тулган хәсрәтле күзләрен олы юл ягына төбәгән. Гаҗәп бит: Американың бай кулы, океан аша сузылып, Эстәрле инеше буендагы Балтач дигән фәкыйрь авылны ничекләр тапкан да, үзенең ярдәмен баткак-чытырманлы, канлы-даулы Россия аркылы ничекләр китереп җиткергән диген!

— Егерме беренче елгы ачлыкта Америкадан китерелгән аш, кофе бирәләр иде. Бервакыт кием-салым өләштеләр,— ди Нургали абзый.— Иң соңыннан Сабира дигән кыз белән икәү басып калдык. Әлбәттә, икебез дә нәүмиз каласы килми. Шулай итеп, Сабирага ботинканың бер сыңарын, миңа икенче сыңарын бирделәр. Киеп йөрдек шулай, чабата белән аралаштырып...

— Үземне белә башлаганым шул елларга туры килә,— ди Нургали абзый.— Ач булгангадыр инде, күп нәрсә нык истә калган. Нәрсәдер урлап тотылган Көчтер Хөсәенне ат кырыена, тәртәгә бәйләп, авыл Советы рәисе чыбыркы белән яра-яра авыл буйлап әйләндерде. Бурлашканы өчен Кашап абзыйны, эт итеп кыйнап, бинһая юан бүрәнә белән биленнән бастырып куйганнарын хәтерлим. Яңа тәртипләр шулайрак керә башлагандыр инде авылга...

«Ат үләте» дигән афәтле шаукым Азнакай төбәгендә егерме сигезенче елны башлана. Беркем каршы сүз әйтә алмый. Ярым хәрби тәртипләр халыкның өнен алып бара. Район үзәгеннән килеп төшәләр дә, бик шикле анализлар алган булып, иң таза атларны гына чирлеләр исемлегенә кертәләр. Чатыр тау итәгендәге Уразай авылы янына галәмәт зур, тирән чокыр казыталар һәм аны киртәләп алалар. Тирә-як авыллардан китертелгән атларны шул киртә эченә кертеп, бәйләп куялар да, колагына терәп аталар. Тетрәп киткән малкай, бөтен гәүдәсе белән гөрселдәп, чокырга төшеп китә.

— Безнең атны да чирле дип таптылар,— ди Нургали абзый.— Ул чагында атсыз калу — аяксыз-кулсыз калу белән бер иде... Әти атны үзе җитәкләп китте. Аның кайтканын өчәү — әни, түтәй һәм мин, тәрәзәгә капланып, көне буе көттек. Кич белән, кояш баер алдыннан, кулына бау кисәге тоткан әти күпер тавыннан төшеп килә. Күңел һаман ышанмый әле, ул башка кешедер, безнең әти һичшиксез атка атланып кайтырга тиеш, дип йөрәк сулыгып тибә. Әмма ул безнең әти иде шул... Чыраена үлек төсе кергән, кайтып кереп, сүзен әйтә алмыйча, бик озак сәкедә утырганнан соң: «Канатсыз калган кош кебек, менә без дә атсыз калдык...» — диде. Моңа кадәр әле җылы сүз ишетергә гаҗиз булып утырган әни, түтәй һәм мин кычкырып елап җибәрдек. Әти дә, башын аска игән килеш, читкә борылып, күз яшен сөртте... Гаярь иде безнең бахбай, соңыннан белдем, аны киртә эченә кертә алмыйча шактый азапланганнар, үлем исен сизгән булгандыр, бичара. Бер мәртәбә аткач та ул әле егылмаган, күкрәге белән бәреп, чокырның икенче ягына ыргылып чыккан, аңа тагын, тагын атканнар... Шуннан соң гына чокырга мәтәлгән...— дип, Нургали абзый тын кала. Гомер дисбесенең җитмеш алтынчы төймәсен тарта башлаган абзыйның күк аязлыгы төшкән зәңгәр күзләрен моң баса, куе, ап-ак чәчләренә сагышлы каен яктысы күчә.

Ул чакта авыллардагы иң шәп атларны гына җыеп үтертү вәхшилеге таза хәлле җир кешесен аяктан егу өчен махсус эшләнгәндер, мөгаен.

Яңа казылган чокыр... Колагына терәп аткач, гөрселдәп егылган атның рәнҗүле ялварган күз карашы Нургали исемле самими малайның төшләренә кереп, күпме саташтыргандыр. Аннары инде, еллар үткәч, Нургали солдат, мондый тетрәндергеч күренешләрне кешеләр мисалында, сугыш аланнарында күргән. Фронт кануннары катгый. Хәрби трибунал карары белән хөкем ителгәннәрне дә чокыр кырыена бастырып атканнар. Гыйбрәт булсын өчендер инде, тамаша кылырга, коралсыз солдатларны да җыеп китерә торган булганнар.

— Берсендә шулай,— ди Нургали абзый,— Бобруйск шәһәре янында калкулык итәгенә чокыр казылган иде, безне каршыга тезеп утырттылар. Бераздан машина килеп туктады. Өч автоматчы кулы бәйләнгән бер солдатны төшерде. Чырае кап-кара тегенең, күзләре чем-кара, үзе чокыр кырыенда елмаеп басып тора. Фронтка барып яткан вагоннан төшеп кала икән дә бу, комендатурага кереп, мин үз эшелонымнан аерылып калдым, дия икән. Тегене кабат җыелу пунктына җибәреп, яңа частькә билгеләгәнче ике-өч ай вакыт үтеп китә. Шулай итеп бу җиде мәртәбә эшелоннан төшеп кала, сугыш соңынача шул рәвешле йөрмәкче була...

Команда буенча, өч автоматчы берьюлы атып җибәрделәр тегеңә, ә ул ничек елмаеп торган булса, шулай басып тора. Башкалар таш кебек чокырга ава торганнар иде... Ә бу берничә секунд шулай торганнан соң гына чокырга түгел, үҗәтләнеп, кырыйга ауды. Командир килеп аның гәүдәсен аягы белән чокырга этеп төшерде дә пистолеттан тагын ике мәртәбә башына атты. Һаман да әле күз алдымда тора ул бәндә, үлемнән көлеп үлде...— ди Нургали абзый.

* * *

Сөтле чәй кебек нурлы йөзле әбиләр, чуклы шәл-яулыкларын иңенә салып, төркем-төркем булып ашка баралар. Чирәмле капка төбендәге утыргычта илләр гизеп кайткан ирләр. Түбән оч парламенты шушыннан башлана... И бу газиз күренеш... Кайда соң ул, илленче елларның салам түбәле өйләре, авылның эчкерсез кунакчыллыгы, гадел ярлылыгы.

Без, агач мылтык, хәрби кепка өчен җанын бирә торган малайлар, сугыш хәлләрен сөйләгән абзыйлар эргәсендә, колакларны шомрайтып, чирәмлеккә тезелгәнбез. Без үсеп җиткәч тә шулай сугыш чыксын иде дә, орден-медальләр тагып, дөнья күреп кайтсак иде, дип аларга кызыгып карап торабыз.

Арада Нургали абзый булса, башкалар тын кала. Чөнки ул ялындырмыйча, йөгерек сүз тәмен белеп, мавыктыргыч итеп сөйли белә.

Карелия фронтына Нургали солдат авылдашы югары оч Кәшфи белән эләгә. Аларны җиңел чаңгы батальонына билгеләп, Финляндия чигенә таба походка алып китәләр. Өстә җылы кием, поляр өлкәнең паегы да мул бирелә. «Икенче тапкыр Америка ярдәмен фронтта күрергә туры килде,— ди Нургали абзый,— һәртөрле ризык салынган капта, борыч-тоз кебеген әйтмим дә инде, калак, җыелмалы стакан, теш казый торган әйберенә кадәр бар иде... Ә күпме кием, сугыш кораллары, машиналар... Ул ярдәме өчен Америкага җүнле рәхмәт сүзе бүгенге көнгә кадәр әйтелмәде бугай...»

Сугышта да, авыз ачып, командир әйткәнне генә көтеп торсаң, әз генә дә үз башыңны уйлатмасаң, бәлагә тарыйсыңны көт тә тор.

Финляндия чигенә якыная барган саен җилекләргә үтәрлек салкын җил көчәя бара. Күпләр аягын өшетеп, госпитальгә озатыла торалар. Нургали абзый, тегүче һөнәрен белгәнгәдер, җиде кат үлчәп, бер кат киcә торган кеше. Алдан ук хәстәрен күргән. 39 нчы размерлы аягына 43 ле ботинка алып, аягын җиде кат чолгавыч (бишесе җылы) белән урап чыккан була. Һәр көнне солдат башына йөз грамм аракы бирелә. Нургали абзый аны аякларын көзән җыера башлап, хәле киткән авылдашы Кәшфигә эчертә. Хәмер тәэсире беткәч, Кәшфи бөтенләй аяктан кала икән.

Нургали абзый аны шулай 300 чакрым буе чаңгысына утыртып тартып бара. Хуҗалары ташлап киткән бер авылга ялга туктагач, чистартырга дип алынган бер солдатның мылтыгы атылып китә дә, пуля Кәшфинең табаны өстендәге чөй сөяген ватып, икенче солдатның беләге аша чыгып, стенага шартлап барып керә. Тиз арада врач-санитарлар, тикшерүчеләр килеп җитә.

Нургали солдат авылдашы белән саубуллаша, чатнама суык көн, чанада әле күпме барасы бар, тиз генә өйдән мендәр алып чыга да, уртасын тишеп, Кәшфинең яралы аягын йон арасына тыга. Сызлану басылмасмы дип, авызына бер шакмак шикәр каптыра.

— Сине, Кәшфи, барыбер өйгә кайтарырлар, кулыңнан килгән кадәр минем әни карчыкка да ярдәм иткәлә инде...— дип, аны озатып кала.

Моны сөйләп, Нургали абзый тын калгач, «ярдәм иткәнме соң?» дип, аны берәү дә бүлдерми. Бары тик әче тәмәкеләрдән, өнсез сорау булып, эчкерсез төтен генә күтәрелә. Шулчак Нургали абзый учына төкереп папиросын сүндерә дә:

— Кәшфи минем үтенечне онытмаган,— ди.— Кладовщик булып эшли башлагач, түтәйгә бер кесә алабута оны биргән...

Нургали абзыйга төрле хәрби һөнәрләр үзләштерергә туры килгән. Шуның иң хәтәре — элемтәче. Әгәр шул чорда чыбыксыз телефон гамәлдә булса, йөзмеңнәрчә элемтәче исән калган булыр иде. Япан кырда, тычканны уйнаткан мәче кебек, финнәр аларны «уйнатып» кыра торган булалар.

— Бервакыт,— дип Нургали абзый сүзен башлап җибәрүгә капка төбе тын кала.— Июнь айлары иде, телефон чыбыгының өзелгән урынын эзләп киттем. Батареядан ерак түгел генә өзеклекне табып ялгадым да кайтырга чыктым. Карыйм, бәрәңге кыры, казылган казылуын да... бер-икене булса да җир ящереп калдыра дип, сапер көрәген алдым да казый башладым. Тавык йомыркасының сарысы кадәр генә берәү килеп чыкты, тагын, тагын... Котелокны тутырмый кайтмыйм, Аллаһы бирсә, дип уйлап кына бетердем, финнар ягыннан минометтан ут ачтылар. Тирә-ягымда чинашып миналар ярыла башлады, кая барырга белмәле түгел, мин суы кипкән канау төбенә йөгереп төштем дә... бөтенләй кирегә, финнар ягына таба җитмеш-сиксән метрлар чамасы йөгереп, туктап калдым. Финнар канауның безгә таба киткән ягын тетепметәләр, канау кырыендагы агачлар төбе-тамыры белән кубарылып һавага оча. Бераздан бу мәхшәр тукталды, мин сак кына үзебезнең якка киттем.

Дустым Андреянов бар иде. Болар, Нургали харап булды, дип блиндаждан карап яталар икән. Минем үле гәүдәмне алып кайтырга дип чыккан булган, юлда очраштык. Андреянов шаккатып тора, бер агач исән калмады, син ничекләр котыла алдың, ди. Канау буйлап финнарга таба йөгерүемне әйткәч, ну, хәйләкәр татар, ди.

Соңыннан котелоктагы бәрәңгене юып пешердек тә, кабыгы белән бергә ашадык.

Капка төбендәгеләрдән берәрсе:

— Бәрәңге дип, харап була язгансың,— дип куя. Китаплардан гел геройлар турында гына укыганга, без малайларга да солдатның вак бәрәңге казып йөрүе мәзәк тоела.

— Һы! Тамак йөртә кешене,— ди Нургали абзый.— Дөнья бу, туган. Безнең частьта әнә ике солдатны, азык-төлек сагында торганда өч-дүрт сохарины алып куенына тыккан өчен, хәрби трибуналга куеп, атып үтерделәр.

Нургали абзыйның полкташы Андреянов, бәлки, хәзер дә исәндер әле. «Кенигсбергка җитәрәк, гаҗәеп ныгытылган бункерга эләктек. Дустым Андреянов уцлыгы аркасында гына немецлар чолганышыннан котыла алдык»,— ди Нургали абзый.

Сугыштан соң ун еллар үткәч, Андреянов Казаннан Нургали абзыйларга кунакка килде. Без, малайлар, Нургали абзыйның теттереп русча сөйләшә белүен шул чакта күрдек. Һәм аны, үз артында, Андреяновча, «Нуркалей», дип атый башладык.

* * *

Мәзәк хәлләр... Гыйбрәтле хәлләр... Кеше гомереңең хәтер тавында үзенә бер төрле маяклар булып яналар. Нургали абзыйның «елъязмасында» андый телдән-телгә күчәрлек хикмәтле вакыйгалар байтак.

Утыз бишенче елларда яшь егет Нургалине авыл Советы секретаре итеп куялар. Шуннан ул Миннебаевка әверелә. Бервакыт аңа кинәшкә дип, түбән оч Талип абзый килә. Ул таза хәлле Шакировлар нәселеннән. Өйләнеп, башка чыкканда Талип абзыйга калай түбәле йорт тигән була. Менә шул калай түбә аркасында хәлләр башлана да инде... Район үзәгеннән атна саен киләләр дә калай түбә өчен умыртып салым салалар икән моңа.

— Нишлим, Нургали энекәш, ул каһәр суккан калай түбәне кубарып ыргытмыйча котылып булмас, ахры?!

— Болай ит син, Талип абзый, кубарып мәшәкатьләнмә, калай өстеннән салам белән яп та куй...

Шушы сөйләшүдән соң Талип абзыйның калай түбәле йорты өр-яңа арыш саламыннан «алтын» түбәлегә әйләнә.

Йөз грамм, дигән сүз чыкса, Нургали абзыйдан тагын бер мәзәк сөйләтәләр. Йөз мәртәбә ишеткән булсалар да рәхәтләнеп тыңлыйлар. Чөнки Нургали абзый һәрчак яңа төсмерләр кушып сөйли белә:

— Урыс авылында торганда, илле өченче елда бугай... Авыл Советы председателе өйгә килеп керде беркөнне, әзрәк кызмача бу. Кәшифә апагызның өстәлгә түтәрәме белән кайнар ат ите китереп куйган мәле. «Менә безнең кайбер урыслар ат ите ашамаган булып кыланалар, ә мин яратам, койрыгына кадәр кимереп бетерәм»,— ди председатель. Мин өстәлгә «чәкүшкә» чыгарып куйдым. Бүлә башлауга, теге: «Нуркалей, мне сто грамм, больше нezzя, врачи не разрешают, вот справка», дип түш кесәсеннән кәгазь чыгарды. Мин эчтән генә сөенеп, талымсыз кунакка йөз грамм куйдым. Утырабыз гапләшеп... Бераздан миңа төртә бу: «Нуркалей, только сто грамм, вот справка», ди. Тагын бүләм. Күпмедер вакыттан соң справкасын кабат чыгара кунагым: «вот видишь, только сто грамм положено, больше нezzя»,— ди. Шулай йөз граммлый торгач, Кәшифә апаңны кибет тарафына ике-өч мәртәбә йөгертергә туры килде. Тән житкәч, мәлҗерәгән кунакны өенә илтеп, бусага аркылы идәнгә аударганда да: «Только сто грамм, больше неззя», дип гырылдап йокыга китте.

Сугыштан соң Нургали абзый тегермәндә сыңар кулының бармакларын өздертә. Калган өч бармагы да чәнти бармак тигезлегендә кала. Ә минем әти алтмыш беренче елда, такта ярганда сул кулының дүрт бармагын да төптән үк өздерткән. Менә алар капка төбендә сөйләшеп утыралар:

— Син, Баян абзый, киселгән бармагыңдагы тырнакларны сизәсеңме?

— Әйе, гел исән кебек. Көн бозылырга булса кычыта башлый.

— Иртәгә яңгыр явар, ахры...

Шулай итеп алар күзгә күренмәгән тырнак төпләрен «кашып» утыра торганнар иде. Өзелгән әгъзаның да күзгә күренмәгән астраль тәне исән булуын һәм аның нерв җепселләренә тәэсир итүен без әле ул чакта белми идек...

— Менә, җәмәгать,— ди Нургали абзый,— күршем Баян абзый гомер буе минем белән ярышып яшәде. Күрәсезме, мин бармакларымның очын гына өздердем, ә ул, миннән арттырам дип, төптән үк өздерде.

Капка төбендәге утыргычта көлешү китә.

Сугыш турындагы берәр китап яисә кинофильм турында сүз чыкса, Нургали абзый «ялган» дип кул гына селти. Ул сөйләгәннәр бөтенләй башка... Сугышның асылында әхлаксызлык ята. Һәм ул кешеләрне әллә нинди сынаулар алдына куя.

Нургали абзый сөйли, менә мин аның күзләрендә чиркану күрәм: кышкы салкында бер солдат — «Васька-запевала» немец офицерының мәетен тенти. Бармагындагы алтын йөзеген салдыра алмагач, төптән үк кисеп ала, ул гынамы, хром итегенә кызыгып, мәетнең аякларын да тездән кисеп алып кайта, тимер мич каршында шуларны эретеп утыра... «Катюша»ны аннан да шәп җырлаучы юк иде взводта, үзе моңлы, ә күзләре нигә салкын микән дип йөри идем, ди Нургали абзый.

Менә мин Нургали абзыйның күзләрендә сагыш күрәм: әнә, полкташы Омск егете Нургали снаряд тутырылган әрҗә сөйрәп бара, шул мизгелдә әрҗәнең нәкъ өстенә дошман снаряды килеп төшә, коточкыч шартлау яңгырый. Нургали абзыйның күз алдында адашы вак кына кисәкләргә таркалып, һавага оча.

Менә мин Нургали абзыйның күзләрендә самими елмаю күрәм: гаҗәп күпсанлы сыер көтүе тоткан монгол юртасы янында бер солдат көзгегә карый-карый кырына. Хуҗа монгол килә дә көзгедә үзен күреп ала. Шакката бу. Көзгенең артына да чыгып карый, гомерендә беренче тапкыр үзен көзгедән күрүе икән. Солдат хәйләкәр елмая, маңгаена мөгез куеп, ике бармагын күрсәтә. Янәсе, ике сыерыңны бирсәң, көзгене алыштырга була. Монгол шунда ук риза икәнен белдереп баш селки. Совет солдаты көзгене ике сыерга алышкан, дигән данябыз әллә кайларга таралыр дип, солдатны командир тыеп кала.

Повар — Кострома егете Капустин эре тешләрен ыржайтып көлә:

— Томана да икән бу монголлар, ә?! Танк гасырында көзге күргәне юк, тьфу! Шушы чүчмәкләр безне өч йөз ел буена изеп тотканмы? Ышанмыйм, братва, билләһи ышанмыйм! Татар булса бер хәл, шулай бит, Нуркалей!

Көзгегә исе киткән монгол Капустинга елмаеп карый, аның мыскыллавын аңламый.

— Бервакыт Хинган таулары арасыннан ага торган елга буена килеп җиттек. Безгә аргы якка чыгарга кирәк. Су тирән түгел, бот төбеннән, шулкадәр тиз ага үзе... Повар Капустин атка җигүле походный кухнясы белән килә бит, дилбегә тотып артка тәпи баскан, кухня морҗасыннан төтен чыгып бара.

— Кермә суга, бетәсең! — дип кычкырабыз, кая ул, Капустин батыр... Ярдан аз гына керүгә, кухня да ауды, аты да егылды, Капустин үзе дә мәтәлде. Дулкын белән бергә бөтерелә-бөтерелә агалар. Бөтенесе харап булды, дигән идек, йөз илле метрлар киткәч, Капустин борылыштагы агач тамырларына тотына-тотына ярга чыгып ауды.

Пехотачыларны аргы якка монгол солдатлары чыгарды. Рәтен беләләр икән, каһәрләр, ун баш атны йөгән тезгене белән берсенең койрыгына икенчесен бәйләп тезделәр дә... Алдагы атта — монгол, калган тугыз атка икешәр пехотачыны утыртып чыгардылар теге якка.

— Йә, ничек, Капустин, монголлар томанамы?! — дип, ым кагам Капустинга. Шәбәргән, тез башлары умырылган Капустин, баягы мәхшәрдән аңына килә алмыйча, тасрайган күзләре белән елмайгандай итеп яр кырыенда ята.

Хәтәр хәлләр...

— Бервакыт тирән генә чокырга төшеп яттым. Һөҗүмгә әзерләнәбез,— ди Нургали абзый.— Нидер ошамадымы, ара ун метрлар булыр, алдагы окопка күчәсе иттем. Борылып карыйм, артта мин калдырган окопка бер солдат килеп кенә җитте, «Васька-запевала» икәнен таныш кына өлгердем, шул мәлдә снаряд төшеп, күз алдымда аны тетеп тә ыргытты. Кырыема нидер шапылдап төшкәнгә башымны күтәреп карасам... окоп кырыенда өзелгән кул ята, урта бармагында алтын балдак... Теге, немец офицерыннан салдырып алынган балдак...

Бусы бер хәл, мине яшәү белән үлем арасындагы сизенү тетрәндерә. Нургали абзый окопны нигә алыштырган, берничә секундтан аның гомере өзелергә мөмкин икәнен кем белгән, нинди илаһи кодрәт аны алга

этәргән? Кеше акылына сыймый торган өстен бер көч карап торганмы әллә? Кәшифә ханым белән тигез гомер итәсе, биш бала үстереп, унбиш оныгы белән милләтне баетырга тиешлеге, бәлки, тәкъдиренә язылган булгандыр. Нургали абзыйның кешеләрне яраттыра белгән шаян холыклы булуы да шул татлы һәм газаплы тормышның кадерен йөрәгә аша үткәрүеннән киләдер.

* * *

Өлкән агайларның хатирәләре «төп йортның» наратлар шавына күчкән инде. Капка төбендәге утыргычта әбиләр генә калып бара. Көндез, яшьләр эштә чакта, кунак-мазар килеп чыкса, тавык суйдырырга да ир кеше таба алмыйлар. Тәвәккәлләп пычакны үз кулларына алалар. Ат карагын да мулла итеп куйган бу заманда бу да гөнаһ саналмыйдыр, бәлки. Түбән очның фронтовик ирләреннән ак чәчле хәтер булып, бердәнбер Нургали абзый исән бүген. Мин аңа кайткан саен керәм, үземне борчып йөргән сораулар биреп, «сугыш китабы»н актарам.

Рус армиясендә элек-электән үк шундый гадәт хөкем сөргән — басып алган җирдә күпме кирәк шулай талау, көчләү өчен «день солдата» бирелгән. Бу сугышта?..

— Андый рәсми приказ булмады,— ди Нургали абзый,— әмма тыю да сизелмәде. Берлинда ничек булгандыр, Җину көнен мин Кенигсбергта каршыладым. Офицерлар вагон-вагон әйбер, хәтта машиналар алып кайтканнар, ә солдатка күпме күтәрә ала шулкадәр мал алырга рөхсәт ителгән диделәр. Безне исә... эшелоннарга төяделәр дә, каядыр алып киттеләр. Сочига, Кара диңгез буена ялга барабыз икән, дигән хәбәр таралды. Сөенештек, инде ничә ел окопта үтсен дә гомерең... Поезд Мәскәүгә килеп җитмичә кая барасын белми идек әле. Перронда себеркесен култык астына кыстырган бер карт безнең вагон янында тукталды да: «И балалар, бу сугыштан исән калгансыз инде, тегесеннән дә исән чыгарга язсын Ходай»,— диде. «Нинди сугыш?» — дип аптырап калдык. «Һе, мине белми дип уйлыйсызмы әллә. Япуннар инде, япуннар»,— дип хәйләкәр елмая картыбыз. Моны ишеткәч без тынсыз калдык.

Әгерҗе станциясендә Нургали абзый вагон ишеге төбенә туктап, бик җентекләп карап торган карчыкны күрә: «Әллә син татар әбисеме?» — дип сорый. «Әйе, балам, берәр таныш кешем кайтмасмы дип торам». Нургали абзый бердәнбер байлыгын, кесәсендәге көмеш калагын ала да: «Минем исәнлеккә дога кылырсың»,— дип әбигә бүләк итә.

— Сугышта да гаделлек юк иде,— ди Нургали абзый.— Кем окопта ут эчендә кайнаган — аларга орден-медальләр бик эләкмәде. Менә Салихны гына ал: дивизия штабында писарь булып хезмәт иткән. Мылтык тотканым булмады, ди. Аның өч «Кызыл йолдыз» ордены, «За отвагу» һәм тагын әллә күпме медальләре бар иде. Зәки абзый да дивизия командирының ат караучысы булган. Аның да өч «Кызыл йолдыз» ордены бар иде.

Бүләкләү хакында өстән күрсәтмә бирелә иде. Хәтерлим әле, Кытай ягында, «Зур Хинган» операциясе өчен бүләкләү хакында күрсәтмә килде. Анда геройга урыстан, украиннан, белорустан ничә кеше тәкъдим ителергә тиешлеге язылган иде. Тагын берничә милләт саналган, шулар арасында бер грузин да бар. Геройга куелган һәр кеше партияле булырга тиеш, диелгән... Башка милләтләрдән «батырларны» тиз таптылар, грузинга чират житкәч... Хисаплап-барлап чыктылар, бөтен дивизиягә бер грузин бар. Ул да итек тегүче, мылтыкны үз гомерендә ялгыш кына да тотып караганы юк. Җитмәсә, партиясез иде әле. Менә шуны, узган айлар числосы куеп, сәгать эчендә партия әгъзалыгына кандидат иттеләр. Характеристикада язылганнарны укысаң... бу кеше алдында баш ими кала алмыйсың. Ул — Хинган елгасын кичкәндә ничә офицерның тормышын саклап калган, ул — ничаклы япон солдатына каршы бер үзе

сугышкан, ул — күпме дошманны кырып салган... Гаҗәп инде батырлыклары... Шулай итеп, итекче грузин күз алдында Советлар Союзы Героена әверелде дә куйды.

Бер кеше — Нургали абзый мисалында минем өчен сугыш китабы ачылганнан-ачыла бара. Күп сорауларымны мин алдагыга калдыра торам, ә күп нәрсәгә әлегә сорау бирерлек акыл да җитми... Кабат алданмас өчен, хакыйкатьнең үзен явыз гасырның шаһиты булган өлкәннәрдән алып калырга кирәк.

— Кырык өченче елдан соң татарларга герой исемен бирми башладылар. Күпкә китә дип уйладылар бугай,— ди Нургали абзый.— Әгәр халык санының пропорциясе белән исәпләсәң, сугышта иң күп кырылган халык та безнең татардыр әле... Мин укып барам... Рейхстагка байрак кадаган Заһитовка да әнә күпме генерал кул куйган, герой исеменә лаек дип... Бирмәгәннәр. Генерал Чанышевка да шулай... Хәтәр үткәч, татарның да кирәге бетә...

Без Нургали абый белән «Су буеннан әнкәй кайтып килә» җырына кергән тыкрыкта басып торабыз. Мин Челтер чишмәгә төшә торган элеккеге сукмакны күз алдына китерәм. Инеш ярындагы өянкеләр дә олыгайган инде. Алар да берәм-берәм теге дөньяга китә башларлар микән? Яшь таллар ничек үсәр?.. Хәтер сукмагыннан мин үткәннәргә кайтып, гомер чишмәсенә иеләм. Анда — бала чагында моңлы азан тыңлап үскән иманлы буынның моңсу картлыгы чал күбекләрдә чагыла.

«Бу дөньяга рәнҗеми китәбез инде... Балалар кала, алар нишләр?...» Нургали абзый әйттеме моны, әллә инде хәтер иленә күчкән агайларның вакытсыз өзелгән догасын тау җиле колакка пышылдадымы? Ашыкма әле, заман, тел коеларын саклыйсы авылга иман нуры иңдер, Күк-Тәңрем...

## Без — без без идек

*Ояты бар кешедә иман бар, диде рәсүл.*
Утыз Имәни

Университетның бер студенты «Фатих Кәрим поэзиясендә сугыш темасы» дигән курс эше язмакчы булгач, Мөхәммәт ага Мәһдиев, шаяртып, аңа:

— Сез «Фатих Кәрим поэзиясендә сугышның роле» димәкче буласызмы?..— дигән. Аның болай әйтүендә гади шаярту гына түгел, астыртын киная дә салынганын ул чакта күпләр аңышмагандыр, бәлки. Әйе, без — өч буын кешеләре 1941—45 елгы сугышны башыннан кичергән ветераннар кул астында, патриотлык культын көне-төне аңыбызга-каныбызга сеңдереп яшәдек. Берәүләр сугышта булуын яшәү мәгънәсе итеп ала, күкрәк суга, икенчеләре яшьләрне үстермичә, башыннан басып торырга хокуклы дип саный, өченчеләре түшендәге орден-медальләрен калкан итеп, дәреслек даулый, мәхшәр эчендә чынлап сугышканнары исә тыйнак кына гомер сөрә иде. Шундыйлардан мин университетның журналистика бүлеге укытучысы Гази ага Кашшафны сагынып искә алам. Ул кәкре башлы таяк тотып, сыңар аягына аксап йөри иде. Сугышта катнашмавын соңыннан белсәм дә, ул минем өчен барыбер фронтовик булып тоела иде. Сугыш чорында ул «Совет әдәбияты» журналының редакторы булган. Шундый кытлык заманда, рус һәм башка халыкларның басмалары ябылган бер чорда да ул журналны саклап калган. Моны Мәскәүгә барып, Үзәк комитет каршында исбатлый алу — амбразурага күкрәк куюга бәрабәр дип саныйм. Шулай итеп журнал яу кырыннан килгән татар язучыларының әсәрләрен бастырып, аларга яшәү дәрте биреп, фронт белән тылны бәйләп, көрәштереп торучы рухи көчкә әверелгән. Муса

Җәлил, хатларында, дустым, дип Гази аганы еш телгә ала, иҗади мирасын да аңа васыять итеп калдыра. Җәлил батырлыгы хакындагы хезмәтләре, аның көрәштәшләренә ярдәм кулы сузулары — аерым бер кыйсса.

Гази ага җәелеп көлүне өнәмәгән бик җитди кыяфәтле, әмма җитдилеге ачык йөзлелегенә хилафлык китерми иде.

Менә без, булачак журналистлар, рус һәм татар группасы бергә аның лекциясен тыңлыйбыз (нинди фәннән укытканы истә калмаган). Гази ага тавышын күтәрмичә генә, һәр сүзен алдан уйлап сайлый-сайлый, кайбер рус сүзләрендәге кырт киселгән үткен авазларны түгәрәкләндереп, гади җөмләләр белән йомшак кына итеп тамак төбе белән сөйли. Кызларыбыз бик бирелеп, тыңлаган атлы булып утыралар. Ә без, егетләр төркеме, портфельләребезне өстәл өстенә бер рәт итеп тезеп куябыз да карта уйнарга тотынабыз. Аудитория кысан, укытучыбыз ике-өч адым ераклыкта гына. Әмма безнең башка чарабыз юк. Гази аганың үтә тыныч тавышы һәм фикер сөреше керфекләрне авырайтып, калгып китүгә һич кенә дә комачауламый. Шуңа күрә икенең берсен сайлыйбыз: йә йокы, йә — уен. Безне фикерсезлек белән шаккаттырып булмый. Китапханәдән кулга бирелми торган Шопенгауэр, Ницше кебек философларны да табып, ара-тирә караштырабыз. Төннәрен шәп приемниктан «Голос Америки»ны тыңлыйбыз. Ә бу очракта аудиториядә кемгә сөйләү, кемгә тыңламау хокукы тигез бирелгән. Азат Ганиев әйтмешли: чишелеш нулгә бетә...

Портфель-баррикадалар артында бер-берсен «җүләр» калдырырга дип, погон сугу бәхете тисә, җилкәгә түгел, тез башына чәпәп, кәртле уйнап утырган егетләр берничә елдан кем булачакларын башларына да китермәгәннәрдер. Мин аларны киләчәккә чөеп, дәрәҗәле кәнәфиләренә утыртып сурәтләмәкче булам. Менә ул — хаҗлы, йөрәкле, бубилы, каргалы карталарны учына түгәрәкләп тоткан группадашлар: бүлмәдәшем, молдаван егете, Кишиневның унике катлы бинасын биләгән радиокомитетның баш редакторы — Саша Дороган. Кап-кара сакаллы, төптән юан чыккан Краснодар егете — Володя Устиновский, «Советская Татария»ның баш редактор урынбасары булгач, тагын да юанаер... Группадашларына «Скотобаза!» дип эндәшергә яраткан, үзен дворян нәселеннән дип санаган, Боровичи шәһәрендә зур завод директоры урындыгын биләгәч тә мактанчыклыгын җуймас Слава Сюляргин, хәрби газетадан күтәрелеп, маршал Устиновның референты, полковник буласы Казан егете Миша Земсков, арада иң яше, почык борынлысы, СССРның һәм Россиянең иң шәп газетасы «Комсомольская правда»ның баш редакторы булып ун елдан артык эшләячәк Владик Фронин, биш елдан китап чыгарып, СССР Язучылар берлегенә кабул ителәсе — мин фәкыйрь...

Карталарны тараткан арада Сюляргин (ояла белми, эчкерсез, күзгә тасраеп карый) Гази агага сорау биреп, дәресне җанландырып җибәрә. Гази ага, әлбәттә, борын төбендә нишләп утыруыбызны сизә, әмма күрмәмешкә салыша, йөзенә күләгә чыгармый. Иллә дә сабыр кеше булыр икән. Аның артык кечелекле сыйфаты кайчак гаҗәпкә дә калдыра: бер дәрестә шәхес культы, репрессияләр турында, артык җәелеп китә алмыйча гына, әңгәмә корып алган идек. Шунда Гази ага:

— Хәзер хөкем чыгару җиңел... Заманасы шундый иде бит... Менә минем турыда Фатих Хосни «халык дошманы», дип «Кызыл Татарстан»да бер подвал мәкалә язып чыкты. Мин аңа рәнҗемим. Хәзерге көнгәчә күрешеп-сөйләшеп йөрибез...

Үзенә карата яла ягуны Гази аганың тыныч кына кабул итүенә ул чакта бик гаҗәпсенгән идем. Хәзер дә аның шул сүзләре хәтергә төшә дә: «Кичереп буламы моны?..», «Гафу итәргә мөмкинме?..» — дип үз-үземә сорау бирәм һәм катгый җавап таба алмыйча газизләнәм...

Университет елларының матур бер көне — студентлар егылып укый торган стена газетасының эленү көне иде (бизәү өлешен, рәссам сый-

фатында, мин эшли идем, университет күләмендәге газеталар арасында ел да беренче урынны алгач, Ташкент, Сәмәрканд, Бохара, Мәскәү, Ленинград калаларына, казна хисабына, сәяхәткә җибәргәннәре дә булды). Минә шул бөтен стенаны алып торган газетада минем дә «Әдәбият крематориена чималлар» дигән беренче памфлетым басылды. Анда шагыйрь Мәхмүт Хөсәеннең «Җир мәрҗәннәре» китабы хакында шактый усал язылган иде. Сонетларның шартлап тәмамланган соңгы ике юллыклары мисалга китерелеп («Карьерага хирес түрәләр үргә менеп тирес түгәләр». «Әй кешелек, бүген күр менә, татар театры үр менә!», тагын «чылана — кылана», «почмакта — кочакта», «торгач та врачка» кебек мәзәк рифмаларны җыйнап, көлкеле сюжет та корган идем бугай. Мәхмүт ага Хөсәенгә бу памфлетның күчермәсен көне-сәгате белән житкергәннәр. Ул чакта китап нәшриятында эшли иде ул. Мәхмүт ага шагыйрьләрчә көр тавышы белән телефон аша кафедра мөдирен ут бастырган. Борын беләнрәк сытып чыгарган сүзләре мондыйрак булгандыр дип фаразлыйм: «Ниндидер малаегыз анда... Мине!.. Татар әдәбияты классигын... Мине — Муса Җәлил ученигын мыскылларга җөрьәт итеп... Мин моны болай гына калдырмыйм!..»

Кафедра мөдире Юдкевич (бөтен кагыйдәләрне бозып, татар бүлегеннән журналистиканың икенче курсына җайлы гына күчергән иде ул мине) бер сәгать эчендә мәкаләне русчага тәрҗемә иттереп, көнендә утырыш җыйдыра. Мин берни белми калам. Тәнәфес вакытында тәмәке тарткан курсташларым янында ваемсыз гына басып тора идем, Гази ага килеп иңемә кулын салды да, читкәрәк алып китте:

— Әле генә кафедра утырышы булды. Теге... синең мәкаләң хакында. Мәхмүт Хөсәен бик ярсып шалтыраткан булган. Мин сине яклап чыктым. Дөрес язгансың. Тик... Турыдан маңгайга күсәк белән кизәнәсең. Тәнкыйтьтә этика булырга тиеш: чама белеп суктыру, читләтеп әйтү осталыгы... Фикерең булгач, анысы тәҗрибә белән килер...

Көтмәгәндә ишелеп төшкән бу хәбәрдән каушап мин Гази ага янында ни әйтергә белми басып торам. Мөдәррис Әгъләмнең шигырь юллары искә төште:

Мин дигәнчә генә булса икән,
Булса икән мин дигәнчә генә!
Тимерченең чүкечедәй вакыт
Килеп төшә башка — янчә генә...

Шагыйрь буларак, үзебезне даһига санап, Мәхмүт Хөсәеннән көлеп йөргән еллар иде шул. Язучылар берлегенең матур әдәбиятны халыкка житкерү бюросында эшли башлагач, Мәхмүт ага белән якынаеп киттек. Оешма өчен алыштыргысыз шагыйрь иде ул. Шәп оратор (кайбер олырак шагыйрьләребез аның шул ягыннан көнләшкәндер дә әле...). Кайчан телефоннан шалтыратма — яңгырмы-кармы, әллә кайларга чыгып китәргә солдатча әзер, залда татармы-русмы — аңа барыбер, ике телдә дә теттереп чыгыш ясый, тамашачыны үзенә карата бәлә. Соңыннан аның егетлегенә гашыйк булып чибәр кызлар уратып алалар иде. Шигърияте нинди биеклектә идеме?.. Ходай биргән сәләт микъдарын ул тамчысына кадәр иҗатына сала иде...

Бервакыт ул бездән бер айлык гонорарын (1978 ел. Профессорлар хезмәт хакы кадәр!) алды да, кәефе килеп, мине «Казан» ресторанына алып китте. Көндезге тын ресторан залының түренә кереп утырдык.

— Сиңа коньяк, миңа — боржоми. Эчү — синнән, түләү — миннән. Ашарга ни теләсәң шуны сайлый аласың! — Сугышта взвод командиры булган Мәхмүт аганың приказ тоны белән сөйләшүе ошый иде миңа. Кыстый-кыстый ул миңа коньяк эчертә, үзе капмый, умырып ашый гына. Мин эчкәнгә ул кызыша бара, шар-шар сөйли.

— Мәхмүт ага, исермә,— дигән булам шаяртып.

— Ә мин гел шулай... Мәҗлесләрдә кеше эчкәнгә исерергә өйрәнеп беттем инде.

Шулай истирәхәт кылып шәп кенә утыра торгач,— күңелем сизенгән иде аны,— Мәхмүт ага теге мәсьәләгә килеп төртелде бит:

— Хәтерлисеңдер, студент чагыңда син миңа карата тупас бер нәстә язып чыгарган идең? Ничек әле?.. Чималлармы?

— Исеме онытылган инде...— дигән булам, карлыгыбрак.

— Миңа үлеп гашыйк булып йөргән теге туташны беләсең бит, бер чорда укыдыгыз. Шул әйтә: «Газетаны җыртып алып килимме, Мәхмүт абый?» — ди. «Кагылма! — минәйтәм. Ул Марсель Галиевегез яшь әле, язучылар арасындагы көнчелекне аңламый. Үз намусында калсын! Еллар үтәр, Мәхмүт абзасының кем икәнен аңлар! Шул чакта үкенер ул һәм миннән килеп гафу үтенер. Аннары без гомерлек дус булырбыз, дим. Дөрес әйткәнменме?!

Шул мәлдә Мәхмүт аганың коньягы эчне яндырып алды. Болай гына сыйлый дисәм... Юк, берни дә онытылмый икән шул бу тормышта, бар кылганың өчен дөньялыкның йә бусында, йә тегесендә җавап тотасың була икән...

Мәхмүт аганың тавышы бөтен ресторанга яңгырый, ерак өстәлдәгеләр дә борылып-борылып карый иде. Аның тавышы әкеренәймәс микән дип, тыныч тавыш белән сөйли башладым. Ул, урындыгы белән янәшәмә тартылды.

— Беркем дә котыртмады, Мәхмүт ага. Инанганымны яздым. Үземне гаепле санамыйм да. Гафу үтенүне дә кирәк санамыйм. Хәзерге акылым белән андый әйбер язмас идем. Очрашуларга нигә Мәхмүт Хөсәенне йөртәсез! — диюче авторитетлар бар. Мин сезне хөрмәт итәм, алар сүзенә карамыйм.

— Рәхмәт аңлавыңа! — дип, Мәхмүт ага иңемнән кочып алды. Шуның белән сүзне бетердек, хискә бирелеп, җәелеп китә торган кеше түгел иде Мәхмүт ага да. Ике арада салынган күпер, җылы мөнәсәбәт ябәү рәвешен мәгънәлерәк итә шул. Мәхмүт ага шуннан соң миңа карата игътибарлы булды, юк кына әйберем матбугатта басылса да, төн уртасында булсын, телефоннан шалтырата, үзенә хас купайту белән очынып мактау сүзләрен җәлләми сибә иде.

Бишенче курска җиткәч, диплом эшемнең оппоненты Гази ага Кашшаф булды. «Иҗади...» дип аталган дипломымның баштагы 25—30 бите бүгенге татар әдәби тәнкыйтенә багышланган «теория» өлешеннән тора, калганы — газета-журналларда басылган яисә басылачак мәкалә-рецензияләрдән тупланган иде.

Җитәкчем — профессор Мансур ага Хәсәнов. Профессор булуы бер хәл, ул бит әле Министрлар советы Председателенең урынбасары да... Ул министрлыкның дәрәҗәсен, эшем төшмәгәнлектән, аңлап та бетермим, ул турыда уйлый да алмый идем. Нәшриятка барып чыккач, күпне күргәнрәк язучылар: «Кайчан диплом яклыйсың, җитәкчең кем?» — дип сорыйлар да... «Мансур Хәсәнов», дигәч, «О-оо!» — дип тел шартлатып куялар. Сөйләшүләре үзгәрә. Җитәкчем шундый мәртәбәле булгач, мин юкка чыкканнардан түгелдер, дип умыртка баганасын турайтыбрак басам. Болай да һавалы, көрпә чак, мактанырга җитә кала: «Мансур Хәсәновның ишеген тибеп кенә ачып керәбез...» — дип тотен җибәрәм. Министрлыкның кайда икәнен белешеп кенә йөргән чагым югыйсә...

Беркөнне мин, тәвәккәлләп, Кремльгә, Министрлар советына киттем. Алдан белешү, телефоннан шалтырату тәртибенә өйрәнмәгәнмен, әйтерсең лә Мансур ага Хәсәнов, бөтен эшен ташлап, көннәр буе гел минем генә көтеп утырырга тиеш.

Ишек төбендәге аерым мөнбәрдә утырган милиция хезмәткәре, йомышымны әйткәч, тоткарлыксыз үткәреп җибәрде. Тыгыз келәмле киң баскычлардан өске катка күтәреләм. Калын стеналы бу борынгы бинада салкынча һава, бөтен вак уйларыңны оныттыра торган хакими тынлык

иде. Биниһая зур тәрәзәле, затлы келәм җәелгән иркен кабинетта секретарь ханым минем белән ягымлы-йомшак сөйләште. Бөтен кергән кешеләр белән дә шулаймы, әллә безнең ише дипломник-студент хәленә керүеме — белмәссең. Һәркайда тупас-дорфалык хөкем сөргән дөньядан килеп кергәч, аның болай итагатьле могамәләсе күңелгә рәхәт иде. Мансур ага минем белән «киңәшеп тормыйча» каядыр командировкага киткән. Кульязмамны калдырып, секретарь ханым кулыннан телефон номеры язылган кәгазьне алып кайтып киттем.

Киләчәктә дә төрле җитәкчеләрнең кабинетларына, сирәк булса да, керергә туры килер. Оҗмах яисә тәмугъ ишеге янындагы сакчы сыйфатында утырган секретарь туташ-ханымнарга аеруча бер хөрмәтем нәкъ менә шушы көндә күңелемә салынып. Министр секретаре — ярымминистр, президентныкы — ярымпрезидент дәрәҗәсендә булырга тиешләр кебек тоела миңа.

Икенче тапкыр инде төгәл вакытны телефоннан белешеп, нәкъ әйтелгән сәгатькә килдем. Секретарь ханым мине Мансур ага Хәсәнов кабинетының катлы-катлы ишекләрен ачып (каушаудан буталып бетәр дигәндер инде), үзе озатып куйды. Ә мин бер дә каушамадым шикелле. Студент дөньясының ваемсыз каланчасыннан караганда бу тормыштагы дәрәҗәләр, урындыклар, кабинетлар барысы да мәзәк бер уен шикелле генә тоелган яшьлек еллары иде бу. Ә нигә каушарга, мин бит армиядә вакытта генерал, полковниклар белән янәшә кабинетта, дивизия штабында эшләгән малай... Шулай да... мондый мәһабәт кабинетка беренче тапкыр аяк басуым икән әле. Мансур ага Хәсәнов кара костюмнан, ак күлмәк һәм галстуктан иде. Түрдәге киң өстәл артыннан торып күреште. Якыннан аңа күз төшереп алгач, республиканың олы бер куласасын хәрәкәткә китерүче дәүләт җитәкчесе каршында басып торуымны хәзер генә төшенеп, елмаерга дип ачыласы иреннәрне авырттырып кысып куйдым. Кыяфәте — президиумнарда еракган түгәрәкләнеп күренгән кызгылт чырайлы түрәләрнекенә охшамаган. Үзенә килешеп торган маңгай пеләше йөзен тагын да озынчарак итеп күрсәтә. Калын кара кысалы күзлек. Кырыс, таләпчән караш. Корыч тавыш — кыскасы, бөтен рәвеш-кыяфәте белән ул америка фильмнарындагы боссларны хәтерләтә иде. Аның сул ягындагы өстәлдә бөгәрләнеп черем иткән песиләр кебек бер өер телефон аппаратлары тора. Шул телефоннар белән күпме оешмаларның кан тамырына тоташкан, югары даирә вәкарьлеге сеңгән бу кабинетта мин җитдилек кысаларына кертә алмаган таркау фикерләремне җыеп, читлектәге кош кадәр генә калдырырга тиешлегемне аңладым. Мансур аганың беренче карашка кырыс-усал күренүе сөйләшә башлагач онытыла икән.

— Карап чыктым эшегезне. Барып чыга болай булса. Минем монда әллә ни кирәгем дә юк шикелле. Менә, кереш өлешенә бераз каләм тидердем, яңадан ныклап күз йөртеп чыгарсыз. Аннары, тагын бер очрашып алырбыз...

Ул арада секретарь ханым чәй кертте. Һинд чәе! — дип, хуш исле буы «кычкырып» күтәрелгән чәйне бәллүр савыттан алган алтын кәгазьле конфет белән бер-ике йотып (икенче килүдә мин бер конфетны кесәгә шудыру кыюлыгына да ирештем бугай. Рәшит Әхмәтҗан әйтмешли: «Балага...»), лирик чигенүләрсез генә сөйләшеп алдык.

Икенче тапкыр очрашуда ул диплом эшенең кереш өлешен тиз-тиз генә карап чыкты да имзасын куйды.

— Яклау вакытында мин катнаша алмасам, борчылмагыз. Бары да тәртиптә булыр... Аспирантурада калырга теләгегез юкмы?

Мин шунда бу кабинетка теләгән чакта керә алмасымны аңлап, зур тәрәзәләрдән күренгән Казансу киңлекләренә карап көч алдым да, күңелдә кайнаган бөтен зарымны ачып салдым.

— Бик калыр идем дә, Мансур Хәсәнович, минем семья хәле... Күпме талантлы кешеләр яшәү шартлары булмау сәбәпле Казаннан китәргә мәҗбүр булдылар. Безгә дә шул язган, күрәсең...

Буталчык сөйлим. Күз алдымда — Әмәт тавы тирәсендәге фатирым... Иске йорт. Ике айлык балабыз. Хатынымның дүртенче курс имтиханнары... Әбинең, эшеннән чыгып, безне коткарырга дип Уфадан килүе... Керогаз исе. Прокатка алынган коляска. Фатир хуҗасы — марҗа әбинең кичке унда утларны өзүе... Тагын, тагын әллә нинди өметсезлекләр... Шуларны бер учка җыеп, әйтеп калырга иде дә бит...

Мансур ага мине игътибар белән тыңлады (мондый зарларны ул инде ишетеп аргандыр):

— Башта эшкә урнашырга кирәк, хәзер мин сезгә менә дигән эш табам, телевидениегә әдәбият бүлеге редакторы кирәк, — дип, ул телефон номерын җыя да башлады.

Мин, отыры әрсезләнеп, каршы килергә батырчылык иттем:

— Анда кирәкми, Мансур Хәсәнович, телевидениеда бу гасырда фатир ала алмаячакмын!..

— Алайса, күңелегезгә охшаган эш эзләп карагыз. Тапкач, миңа килерсез...

Бу кабинетка гозер белән бүтән беркайчан да керергә туры килмәде. Эш тә, фатир да ничектер үзеннән-үзе җиңел хәл ителде. Ярдәм кулын сузарга авырыксынмаган Мансур ага Хәсәнов дәрәҗәсенә таянып, кайберәүләр шикелле, аның исемен алдан йөртеп, тәрәкле үсү юлын сайларга мөмкин иде. Әмма мин әдәбият өлкәсендә тоткан урыныңны бары тик үз талантың белән генә расларга була, дип саный идем. Ләкин тормыш кагыйдәләре башка булып чыкты. Мин уйлаган чын зыялылар, чын әдәби мохит — хыялда гына икән шул.

Диплом эшем әзер, дип канатланып йөргән көннәрдә оппонентым Гази ага Кашшаф белән аңлашылмаучылык килеп чыкты. Дипломның кереш өлешен «булып җитмәгән бу...» дип кайтара да бирә, кайтара да бирә. Кай җире ошамый, ни эшләргә кирәк — өздереп кенә әйтә алмый. Мин үземнең акыл тирәнлегенең сай казанын кыргычлап чыктым — бер касмагы да калмады. Мылтык тәрәсәләр дә бүтән кагылмаячакмын бу диплом эшенә, дип, үҗәт карарга килдем.

Соңгы сөйләшүебез Гази аганың Горький урамындагы фатирында булды. Эш кабинеты җыйнак кына. Иске мебельләр. Гази аганың иң зур байлыгы — «Казан утлары»ның беренче саныннан — «Атака»лардан башлап бөртекләп җыйган журнал төпләмәләре икән.

Сүз иярә сүз чыгып, мин Гази агадан:

— Докторлык диссертациясе язарга алындыгызмы әле? — дип сорадым. Гази ага, икеләнебрәк:

— Материаллар әкеренләп туплана инде, өлгерерменме... — диде. Муса Җәлилләр янәшәсендә легендага әверелгән Гази ага Кашшаф фатирында кайчан шушылай киерелеп утыра алам әле, дип, мин аңа «акыллы киңәш» биреп калырга булдым:

— Диссертация язып күпме вакытыгызны сарыф итәчәксез, Гази ага. Аның беркемгә дә кирәге булмаячак. Сез бит Такташ, Кутуй, Җәлилләрне якыннан күреп белгәнсез. Языгыз шулар турында дөп-дөресен. Югыйсә, әсәрләрен укыйбыз, ә тормышта нинди булганнар — күз алдына китерә алмыйбыз. «Тукай турында замандашлары» дигән китапны укып чыктым әле. Тукайның сурәте дә, тавышы да, сүзе дә юк ич анда! «Тукайның борыны тирли иде» дигән бердәнбер истә кала торган җөмлә бар. Безнең Равил Фәйзуллинның да маңгае тирли. Шагыйрьне кеше буларак ачу өчен ул гына аз бит. Максим Горький әнә «Клим Самгин» белән юкка азапланган. Әдәби портретлары белән генә дә тарихта калачак ул. Нишләп безнең татар әдәбиятында бу жанр бөтенләй эшләнмәгән икән, Гази ага? Бәлки кешене ярата белү тойгысы юктыр бездә?

Гази ага эчке тойгыларын күңелендә үк сүндерә белә, йөзенә, күзләренә чыгармый иде. Сабыр гына тыңлап, уйланып утырды да:

— Диссертация язу — уен эш түгел,— диде. Мин иске рояль капкачын үрелеп ачарга азапланганда бармагын кыстырган сабый хәлендә калып, сүз йомгагын күңелемә яшердем.

Укытучыбыз Людмила Михайловна Пивоварова миңа эш белешеп куйган. Ике телдә чыга торган «Татарстан коммунисты» журналына тәрҗемәче кирәк икән. Чакырып китерде дә, минем өчен дустанә сөенеп, якамны, сәдәфләремне рәтли-рәтли:

— Обком белән турыдан-туры бәйләнешле престижный журнал,— дип сүзен башлаган иде дә...

— Аны кеше укыймы соң? — дип, үзем дә сизмәстән, укытучымны бүлдердем. Аркылы килгән соравымның урынсыз икәнен ишетмәве белән раслап, тезепме-тезә:

— Балда-майда йөзәрсең. Бәйрәм саен иң кыйммәтле тортлар, конфитләр, апельсин-лимоннар — аларга китерелә. Фатирны да тиз алырсың...

Кая барып бәрелергә белмәгән чагым иде. «Фатир» дигән сүзе колакка эленеп калды бит. Озакка сузмыйча киттем әлеге журнал редакциясенә, барып кердем Ленин томнарын тәрҗемә итүдә иң көчле белгеч саналган баш тәрҗемәче Сәгыйть ага Хафизов кабинетына. Ул мине бик игътибар белән күздән кичереп, «сынау» алды, Азнакайдан икәнемне, туганы Миргасыйм ага Хафизовның кызы белән бер мәктәптә укуымны белгәч, бераз яктырып, русча язылган өч битлек мәкалә сузды. Шуны ничек тәрҗемә итүемә карап язмышым хәл ителәчәк иде.

Кайтып карасам, теге өч битлек язмада кеше җаны-канына якын алырдай ник бер кәлимә сүз булсын. Ул елларда (1974) партия теле тормыштан тәмам аерылып, буй җитмәс биеклектә, үзенә аерым яшәгән риторикага корылган иде. Күңелне чиркандыра торган мондый нәрсәләрне тәрҗемә итә-итә мин үземнең бал корты кебек мыскаллап җыйган әдәби тел нектарын харап итмәммe? Энә очыдай нәзберек пумала белән нәфис рәсемнәр ясарга ниятләгән кулга, алаңгыр пумала тоттырып, койма буярга кушу белән бер ич бу!

Икенче көнне Хафизов агага мәкаләне кайтарып бирдем.

— Сездә эшләргә теләмим,— дигәч, Сәгыйть ага, акылындамы бу малай, дигән шикелле, өнсез калып, аптырап, бер мәл телгә килә алмыйча карап торды. Дөньяда иң кирәкле журнал чыгарам, иң бөек эш башкарам, дип йөргән агайны бу адымым белән бик рәнҗеттем ахрысы.

(Куркуым дөрес булган. Уфадан күчеп килгән Госман Садә, шушы журналда тәрҗемәче булып эшләп, җансыз тел лабиринтларында буталып, биш-алты ел буена бер генә шигырь дә яза алмыйча интекте).

Дипломны без берничә егет берьюлы якладык. Оппонентым Гази ага белән тәки аңлаша алмадык. Ул канәгатьсез, кәефсез иде ул көнне. Минем эш хакында сүрән генә сөйләде, «дүртлелек» дигән бәя чыгарды. Башка егетләрнең җитәкчеләре күккә чөеп мактап, һәммәсен бөек иттеләр. Ә минем... Гази ага ягына борылып карыйсым да килми. Ярый әле, кафедраның башка укытучылары, дәррәү кубып, эшемне «бишле»гә бәяләделәр. Яклау соңында егетләр җитәкчеләре белән кочаклашып (кайсы — кандидат, кайсы — редактор) «юарга» китеп бардылар. Мин берьялгызым басып калдым. Җитәкчең зур кеше булса да кыен икән. Мансур ага: «Яклагач, хәбәр бирерсең», дигән иде бит, ашыгып телефонга йөгердем. Портфельдә соңгы тиеннәрне җыеп алган затлы коньяк, шоколад бар. Кремль сарайлары өстәленә генә куя торган сый инде бу.

Бер талпынуда телефоннан үзе белән тоташтым. Ике арада шушындый сөйләшү булды:

— Ничәле?

— Әйбәт. Бишле.

— Шулай буласын белгән идем инде мин. Котлыйм.

— Мансур Хәсәнович, башка егетләр җитәкчеләре белән сөйләшеп утырырга дип киттеләр. Шундый көн бит бу!.. Дөнья бер генә бирелгән.

Гел эш тә эш булмас инде сезгә дә... Ни бит... Бер коньяк алган идем, икәү сөйләшеп утырырга дип...

Телефоннан ишетәм, Мансур ага көлеп куйды, сирәк була торган хәл! Күрәсең, болай туп-туры, гап-гади итеп, куштанланмыйча дәшүчене күптән күргәне булмагандыр аның.

— И-ии, Марсель туган, үземнең докторлыкны яклагач та иптәшләр белән утыра алмадым мин. Рәхмәт. Вакытның бик тыгыз чагы,— диде.

Бу тәвәккәллегемне соңыннан язучылар арасында сөйләп йөрделәр. «Мансур Хәсәновичны коньяк эчәргә чакырдыңмы? Булмас ла, шаяртасыңдыр...» — дип үчеклиләр иде.

(1991 елгы ГКЧП вакытында илне шом баскан иде. Чатнар алдыннан империя карынынннан ярсыну сөреме чыгып, бөтен кешеләрнең аңын томалады. Яңадан цензура кысаларына кереп, рухны тезләндерәсе килмәүдән кызып язган бер мәкаләмдә мин Мансур ага Хәсәновка катырак бәрелдем шикелле. Үз мөмкинлегеннән чыгып олы эшләр башкарган шәхескә карата саграк буласы калган да бит... Нишлисең, өлкәннәр әйтмешли, заманы шундый иде... Мин ул чакта бер ачы хакыйкатькә төшендем: җәмгыять икегә аерылып коралга тотынса, туган атаң белән дә баррикаданың капма-каршы ягында калуың ихтимал икән. Ә үкенү, аек бәя бик соңлап, давыл узгач кына килә).

Университетны тәмамлап бер ел үткәч, Гази ага белән Язучылар союзы коридорында очраштык. Элеккечә, соргылт бүреген, алдын артка әйләндерә язып, җайсыз итеп кигән. Кулында таягы, сыңар аягын яннан алдырып килә. Күрештек. Хәл-әхвәлләрен сорагач, ул:

— Картаела... Мемуарлар язарга гына калдык инде хәзер...— диде. Теге вакыттагы сүземә үпкәләгән икән картым, онытмаган. Югыйсә мин чын күңелдән, хак әйткән сыман идем. Фикерем киңрәк мәгънәдә иде. Мемуар дигән сүзне нишләптер өнәп бетермим. Тагын аңлашып булмады... Тәкъдир моңа вакыт та калдырмаган икән шул, Гази аганың кояшы баеп, шәфәкъ бишегенә төшеп җитәргә санаулы айлар гына калган булган (1975 елда, 68 яшендә ул донья куйды).

Инде берничә ел үтсә дә мин һаман диплом эше белән әвәрә килгән чактагы Гази аганың канәгатьсезлеген искә төшереп, сәбәбен белә алмыйча аптырый идем. Беркөнне, кинәт башыма бер фикер килде... Йөгереп диярлек бардым да, университетның архивыннан кулъязмамны эзләтеп таптырдым. Үзем битләрен актарам, үзем шигем дөрескә чыкмаса ярар иде дип телим. Юк! Сизенүем дөрескә чыкты. Беренче бүлектә мин татарның күренекле тәнкыйтьчеләрен санап киткәнмен. Арада — Гази ага Кашшаф исеме юк... Зур тәнкыйтьче дип санамаган очракта да, хөрмәт йөзеннән исемен телгә алырга тиеш идем лабаса. Сансызлык. Мәгънә, тәрбия җитмәгәнлек... Менә ни өчен хәтере калган икән Гази аганың. Үзе тел белән әйтмәсә дә мин аның йөз-кыяфәтен, күзләрендәге тыенкы рәнҗүен еллар аша үтәли күрәм. Каләм ияләренең сабый кебек, юктан да хәтере калучан икәнен белгәнмени мин ул чагында...

Тукташ, Җәлилләрне кеше итеп язарга иде дип, мин ул дәвердә сизмичә дә үз күңелемә үссендерү орлыклары салганмын икән. Билгеле бер яшькә җиткәч, күңелдә урын билгән чордашларым турында бер китап язу теләге менә хәзер өлгереп, төп максатыма әверелде.

Дини сабаклар алмасам да, динле кешеләргә мин хөрмәтемне сиздереп, аларга читтән кызыгып карадым. Туган йортымнан чыгып киткәндә һәрчак әнием, капка баганасына сөялеп, дога укып, изге теләктә кала иде. Азнакайда укыганда Салиха әбием сумкамны тотып мәктәпкә чыгып киткәндә догалы булды. Бүгенге көндә Рәкыйбә әби (хатынымның әнисе) бирәр эш майтарырга ниятләсәм, Ходайдан миңа карата игелек кылуын сорый. Шул ак яулыклы өч карчык — җир фәрештәләренең ак намазлык яктысы төшкән күзләреннән мин догалы еллар тәсмерен күрәм. Заман, тарих хакында уй-гамь йөрткәндә,

якыннан белгән чордаш-кордашларымны сурәтләгәндә йөрәк турындагы каләмемне гаделлек кыйбласыннан тайпылдырма, Тәңрем...

## Башкаламы Казан атлы ташкала?

*Мәками Хакъ шәмус әйләр*
*(Ул урынны Ходай якты итәр).*
Г. Кандалый

Казан — дөньяви шәһәрләр яшенә житкән олпат кала, күпне кичергән Башкала, юаныч-әрнүләрен тәкъдиргә салган Аккала. Аның гомер озынлыгын гасырлар божрасы билгели. Мәһабәт шәҗәрә агачының бирчәйгән буыннарына игътибар ит әле, алардан үкенечле тарих көле коела, хәтер авырайткан яфраклары борынгы риваятьләр хакында пышылдый. Тыңлый бел дә, ишеткәннәреңне акыл иләге аша үткәрә бел...

Имеш, кала салынасы хисарга (ныгытылган үр) тәүге нигез ташын бисмиллалаган мәлдә, иртә-таңда кем дә кем очрый, шуны ай-ваена карамыйча нигез ташы астына салырга хан үзе боерган икән. Каюм Насыйри «Тәварихе Казан» дигән хезмәтендә болай дип яза: «...Иртәгесен мигъмарлар иртә белән чыгып кала корырга тотынгач та күрделәр: ханның үз угълы килә. Аның артыннан янә бер эт ияреп киләдер. Мигъмарлар, ханның угълын нигез астына салырга кызганып, аның белән ияреп килә торган этне тотып каланың нигезе астына салдылар...». Төзүче осталар соңыннан ханга беркемне дә күрмәдек, эт йөгереп бара иде, шуны тотып салдык, диләр. Хан әйтә: «Бу кала һәм ханлык этләр кулына кала икән...»

Хикмәтле риваять бу!

Хан улы әлеге вакыйганы үткенәйтү, бу риваятьне истә ныграк калдыру өчен кертелгәндер. Ә менә икенче өлеше... Игътибар итегез, сарыклар яисә дуңгызлар кулына түгел, ә этләр кулына калачак, дигән бит олуг хан җәнабләре. Бу хан, һичшиксез, бөек акыл иясе, зирәк күрәзәче булган, ул әйткән фикернең асыл мәгънәсе шунда: тарихи риваятьләрдән күренгәнчә, һәр халык үзенең Җирдә яралышын нинди дә булса җанвар белән бәйле рәвештә карый. Төркиләрнең ыру анасы — бүре санала. Ә эт кавеме кулга ияләштерелгән бүре нәселеннән. Ягъни эт — бүре гаярьлеген җуйган мәхлук җанвар. Һәр хуҗага койрык болгаудан тәм-ләззәт алучы, көчле кул астында интегү-изелүне бәхеткә юраучы, юаш, күндәм эт хәленә төшкән халыкка калачак бу Казан һәм патшалык, дигән тәхет башы, олуг хан. Димәк, без — юашланган нәсел варислары. Моның белән килешү авыр, әмма хакыйкатькә күз йома алмыйсың шул.

* * *

Казан — зарлы да, шанлы да кала. Үзендә ватандарлык хисе тойган кеше Кремль диварыннан торып Идел көзгесенә күз текәгән чакларында, борынгы бабалары хатасын төзәтергә теләп, гасырлар аша өметсез талпынып куядыр. Инәлеп бер кычкырып кара: тавышың бушлыкка таралып сулкылдый да үз йөрәгеңә кайтып егыла.

Ул чакта... Казанның борын төбендә Зөя нығытмасын төзүче мәскәүлеләргә ничек ирек куйганнар?! Шаһгали ауга дип алдан, хан даирәсенең иң югары катлау түрәләрен алып чыгып киткән чакта, дәүләтнең башсыз калачагын берәү дә уена китермәгәнмени? Югары хезмәткә күчкән татар, яһүд-немец һәм башка милләтләрнең каймагы хәрәкәткә китергән, Византия һәм Шәрекъ мәктәбен берләштергән Русь дипломатиясенең үтә хәйләкәр-мәкерле, акыллы вә явыз икәнен сизмәгәннәрмени ханлыкның идарәчеләре?! Тагын шундый мең-мең сораулар...

Әмма тарихны төзәтә алмыйсың шул, аны бары тик «корсак колы» (Һади Атласи билгеләмәсе) булган галимнәр генә кәгазьдә вакытлыча «төзәтә» алалар.

Казанның егылуын, Шәрекъ капкасы аша мөселман галәменә каршы тәре походы башлануны Иван Грозный эшчәнлегенә генә бәйләп карау дөрес микән? Бәлки әле «Казан ханлыгын яулауда татарларның роле» дигән темага да берәр фәнни эш язылыр...

Шулай да... Казанның изге туфрагында тояк эзе калдырган Иван патша — булачак Грозный хакында бер-ике сүз әйтеп китик. Олуг кенәз Иван IV шаулатып унбиш яшьлеген уздырганда, нииндидер сүзе ошамаган өчен воевода Афанасий Бутурлинның телен кистертә. Менә шушылай тел кисүдән башланган вәхшилеге аның рус шәһәрләрен җимерү, чиркәүләрен талау-җимерү, боярларны мыскыллап үтерү, башка халыкларның ил-җирләренә басып керүнең башы була.

Унбиш яшьлек тинтәк малайны Казанга яу сәфәренә кузгалган полкларга ияртеп җибәрәләр. Чыныга торсын, янәсе. Булачак патша хәрби лагерьдә нинди генә мәзәк хәлләр күрсәтми. Аптырагач, ул карлы-сулы кырны ермачлатып, тырыс алып шунда карабодай чәчеп йөри. Куштан боярлар да, сакаллы сабыйга әйләнеп, моның янәшәсендә карабодай бөртеге сибеп йөриләр. Берничә көннән соң, тинтәкнең теләге буенча, чәчү чәчкән өч боярның да башларын кисәләр...

1552 елда Грозныйга егерме ике яшь тула. Аның хәрби җитәкче булырга сәләтсезлеге хакында рус тарихчылары да яшерми. Казан каласы янында ай буе берничди уңышка ирешә алмыйча, керләнеп, бетләп беткән яугирләрне соңгы хәлиткеч штурмга (2 октябрь) кузгатканда да Иван патша сәфәр өчен җайлаштырылган чиркәүдә гыйбадәт кылып утыра. Яу-кырылыш соңгы аккордларына җиткән вакытта гына аны кенәз-воеводалар мәҗбүри диярлек китертәләр. Әйе, елъязманы җинүчеләр тудыра, шулай итеп, Казанның җиңелүе бер кеше — Иван патша исеме астында тарихка кереп кала.

Сөембикә манарасы артында кояш баеган мәлдә нииндидер бер нәүмиз сагыштан күңел сыгылып килә. Тарихына битараф булмаган татар өчен генә хастыр бу, мөгаен. Француз исә күпне кичергән Бастилиясе эргәсендә шулай моңлы уйга чумадыр.

Шушындый тын кичле, тымызык бер мәлдә, күккә сирпелгән төсләрдән арынып, мин карашымны Идел ярларына төшерергә куркам. Анда — ата-бабамнар кичергән мәхшәр, канлы туй кабатланыр шикелле... Әнә ул... әсир ителгән ирләр белән яр буе тулган. Кан күреп шашкан үгезләр шикелле, рус гаскәриләренең йөзендә җиңү тантанасы, алар ягында сугышкан сатлык татарлар үз кардәшләренә карата икеләтә явызрак.

Менә гаскәриләр һәр бүрәнәгә 30, 40, 50 адәмне арканлап куялар да суга этеп төшерәләр. Бүрәнәне дулкын кагуга, гүр авазы белән илереп талпынган адәм гәүдәләре йөзтүбән әйләнеп суга чума, бәйләнгән аяклары гына үлем белән тартышып, тырпаешып кала. Коточкыч күренеш... Күктә — яндырылган-таланган ил-йортның хәрабәләре сыман умырык болытлар. Аяз офык сызыгында тулышып баеган Кояш — өнсез шаһит — дөньяның канлы күзе сыман. Бу вәхшилекне күреп бәгыре актарылган Идел, чарасызлыктан хәлсезләнеп, тып-тын гына ага. Кызгылт су киңлекләрен бүрәнәләр чирүе баскан. Һәр бүрәнәдән аркан белән бәйләнгән 60, 80, 100 аяк тырпайган. Болар хисапсыз, Әстерханга кадәр агып төшәчәк меңнәр. Казан ханлыгының канлы апофеозы. Мәетле саллар агып бара. Каргалы күктә кисәтүле аваз... Казанны үз көчебез белән генә саклый алмадык, кичерегез. Хәзер инде сезгә чират... Сиңа — Әстерхан патшалыгы, сиңа — Себер ханлыгы, сиңа — казакъ даласы, сиңа — үзбәк баласы, сиңа — кыргыз-кайсак, сиңа — Каф тау артындагы халыклар бәйләме...

Бу тетрәндергеч манзараны зур рамга тартылган картина итеп ясый алырдай рәссам безнең гасырда туар микән?! Әгәр син Тәңре тарафыннан сайланган сәләт иясе икәнсең, илаһи Күк хәтере белән тоташу нокталарын таба бел — хәсрәтле Казанымның изүе ачык, аның җир йөзендә кабатланмас золымга дучар ителгән язмыш-симфониясе нәкышьле сәнгатьтә мәңгеләштерүне көтә.

* * *

Дөньяви шәһәрләр яшенә житсә дә, мәһабәтлеге, кыяфәт-рәвеше, архитектурасы ягыннан, әлбәттә, Казан күбесе белән ярыша алмый. Рим, Париж, Лондан, Мадрид кебек мәртәбәле башкалалар бик күп ил-халыкларны яулап алу, шуларның матди һәм акыл байлыгын бер кулга туплау нәтиҗәсендә төзелгәннәр. Бу калаларны күреп кайтканнан соң империя башкаласы Мәскәү дә гадәти бер купецлар шәһәре булып кына күренә. Ә Казан турында инде әйтәсе дә юк. Чөнки ул шаулы үсеш дәверендә, Везувий афәтенә тиң гарасатка дучар булып, Помпей язмышын бүлешә.

Татарның Сарай-Бату, Сарай-Бәркә, Гөлстан, Аккирмән, Актүбә, Хаҗитархан, Үкәк, Болгар һәм башка шундый дистәләрчә шәһәрләре Хәзәр, Иран, Мисыр, Византия архитектурасы казанышлары белән баетылып, Идел төбәге табигатенә тәңгәл җирлектә, үз милли осталары тарафыннан төзелә. Казан ханлыгында да Шәрекъ һәм Аурупа төзелеш сәнгатен югары кимәлдә таш һәм мәрмәрдә чагылдыру өчен бай мөмкинлекләр ачыла. Урыны да нинди бит әле, гел күрше җиренә кызыгып яшәгән руслар аны юкка гына «оҗмах ягы» дип атамаганнар. Шәһәр төзү өчен гаҗәеп ландшафт. Күлләр, елга ярлары, дулкын-дулкын калкулыклар... Хак Тәгалә үзе дога иңдергән урын.

Күп илләрдә урта гасырларның саклану чарасы буларак төзелгән кирмән-замокларыннан арына барып, җиңел-ягымлы бизәктән торган, кешелекле, дөньяга күзен ачкан архитектура үрнәкләре туып кына килгән дәвердә... татар цивилизациясенең нигезе убыла. Үзенә генә хас архитектура үрнәкләрен чагылдырасы күп идеялар сүнеп кала һәм аны башка милләтләр үзләштереп, үз шәһәр төзелешендә үстереп җибәрәләр. Бер генә мисал: русның христиан храмнарын карыйк, кабарынкы гөмбәзләр — Көнчыгыш архитектурасыннан өлге булып кергән классик үрнәк. Руслар аны, нишләптер, «луковица» («башлы суган») дип атаганнар. Шәрекъ исә Җир-анадан Күк-ата хозурына ашкан гыйбадәтханә гөмбәзе рәвешенә тирән фәлсәфи мәгънә салган. Галәми күк гөмбәзенә фирүзә төсе белән кушылып, очлаеп тәмамлана торган гөмбәз тормыш чыганагы символы — хатын-кыз күкрәген чагылдыра.

Мәскәүнең Кызыл мәйданында күз карашын ирексездән җәлеп итәрдәй «Таш чәчәк» — Покровский соборы бар. Барма һәм Постник тарафыннан проектланып, Казан ханлыгын алу хөрмәтенә төзелгән тугыз гөмбәзле бу соборның мөселманнар ярата торган төскә манылган гөмбәзләре чалманы хәтерләтә. Бу собор Казан Кремлендәге Колшәриф мәчетеннән күчереп төзелгән, дигән караш галим-белгечләр арасында әледән-әле кабынып куйгалый. Хәтта ташларына кадәр алып киткәннәр, элегрәк собор диварының ташларында гарәп хәрефле язулар да күрергә мөмкин иде, диләр өлкән яшьтәге мәскәүлеләр.

Тиздән Казан Кремлен яңарту, төзәтү, ныгыту эшләре башланачагы хакында ишеткәлибез. Әгәр бу эш ханлык алынганнан соңгы төзелгәнне генә кайгыртуга кайтып калса, моның тарихи кыйммәте берьяклы гына булачак.

Русларның XIX гасыр шедевры саналган урамын (Храм Христа спасителя) яңадан торгызу эшенә тотынуларын аңларга була. Моның белән алар Россияне яңадан торгызу кебек символик мәгънәне гамәлгә ашыралар.

Без дә үз халкыбызның рухи күтәрелешен, милли горурлык хисе уятуны шулай ук изге догадан башларга тиешбездер. Моның өчен «Таш чәчәк» үрнәгендәге чалмалы манаралардан торган Колшәриф мәчетен, айлы нур иңдереп, кабаттан күтәрү кирәк. Тарихи гаделлекне кайтаруда бу тәүге адым булачак. Әлеге саваплы эшкә халык та, гарәп илләре дә ярдәм итәчәк.

Шәһәр архитектурасы — чор, сәясәт, хакими көчләр зәвыгының таш елъязмасы. Борын-борынгыдан галиҗәнаб архитекторлар, мигъмар-осталар олуг һөнәр иясе саналган. Алар белән патша-хан-солтан-шаһ-корольләр кул биреп күрешкәннәр. Архитектураның гүзәл үрнәкләре белән үз исемен дә мәңгеләштерәсен белгән зирәк тәхет хуҗалары атаклы осталарны төрле илләрдән чакыртканнар.

Бүген без күрә торган Мәскәү Кремлен Византия осталары төзи башлый. Болар: Аристотель Фиораванти, Антонио Солари, Антон Фрязин, Марко Руффо, Алевиз (Алоизо) Фрязин (бусы Миңлегәрәй чорында Бакчасарайда хан сараен проектлаштыра). Ә инде Санкт-Петербургның затлы бина-храмнарын, һәйкәлләрен Аурупа шедеврлары кайтавазы рәвешендә чит ил архитекторлары — Карл Росси, Монферран, Бартоломео Растрелли, Доменико Трезини, Җан-Батист Леблон, Винчеццо Бренна кебек атаклы осталар төзетә. Казанның бүген дә сокланырлык күренекле биналарын проектлаган Руш, Амлонг, Пэн, Петонди һәм башка архитектураларның исеме безнең колакка сәер тоела.

Казан революциягә кадәр Россия шәһәрләре арасында өченче урында саналган. Бу — шәһәрнең зурлыгына карап кына түгел, ә белем бирү учакларының, интеллектуаль акылның тупланышына карап та бәяләнгән. Татарның рухи хәзинәсен, хәтерен алу тәүге тапкыр ханлык җиңелгәч булса (хан китапханәсе һәм архивын Мәскәүгә алып китү күздә тотыла), икенче кизәнү 1854—1855 елларда башкарыла. Казан университетының «Шәрекъ разряды»н (факультетын) бетереп, Санкт-Петербургка күчерәләр. Моның белән бергә, бай китапханә һәм олы белгеч галимнәр дә китәргә мәҗбүр булалар.

Казанны гадәти бер провинция шәһәре итеп калдыру, башкала дигән рухны халык аңында бетерүне большевиклар гаҗәп дәрәҗәдә уңышлы башкаралар. Административ берәмлекләр, әйтик, елга пароходчылыгы, аэрофлот, тимер юл, хәрби округ һәм башка шундый үзәк идарәләр Казанның баласы гына булган шәһәрләрдә ачыла. Татар нефте акчасына Волгоград, Саратов, Куйбышев, Тольятти кебек шәһәрләр саллырак, масштаблырак төзелә башлый. Республиканың һәр тармагында кысылганлык, шартлар җитмәү сәбәпле, яшь белгечләр читкә китә тора, тере акыл хәзинәсе отыры саега бара. Биш гасырлар элек башланган бу хәрәкәтнең әле бүген дә тукталганы юк. Нәтиҗәдә — дәүләтчелек институтын төзүдә үзешчәнлек өстенлек ала бара, акыл-зиһен хәзинәсе булырлык көчләр бүтән милләтләрнең кодрәтен арттыруга хезмәт итәргә мәҗбүр.

Мин бу очеркта дөнья йөзенә таралган меңнәрчә татар галимнәрен искә алырга җыенмыйм, ә кайсы да булса тармакны башлап җибәрүче, дәреслек төзеп, үз мәктәбен булдыручы остазлар турында искә алып үтәсем килә. Ерак гасырларга китсәк, руска беренче булып әдәби проза теле һәм тарих эшләп биргән Карамзин, югары поэзия теле булдырган Державиннан башлар идек. Яисә Төркиянең хокук тарихы буенча беренче дәреслек язган Садри Максуди, шулай ук төреккә анатомия дәреслеге язган галим Ибраһим Одар бәйне искә алырга була. Ләкин без бүгенге көндә күз уңында торган кайбер шәхесләргә дә тукталыйк әле:

Әбдерәшит Бигиев — «Корыч металлургиясе» хакында чит илләрдә танылган бәһасез дәреслек төзегән, Магнитогорскида яши.

Мидхәт Даишев — профессор, шикәр промышленносте белгече, «ак ширбәт алласы», Краснодарда яши.

Рәүф Акчурин — йөзем үстерү һәм кояшлы шәраб ясау буенча фәнни кулланма хезмәтләре белән танылган, Ялтада яши.
Галия Измайлова — СССР халык артисткасы, Нәвои исемендәге опера-балет театрының баш балетмейстеры буларак, үзбәк профессиональ бию сәнгатенә нигез салучы.
Чыңгыз Әхмәров — Үзбәкстанның халык рәссамы, Шәрекъ миниатюраларына заманча сулыш биргән рәссам.
Мидхәт Булатов — Ташкентның баш архитекторы булып күп еллар эшләгән профессор, Шәрекъта архитектура гыйлеменең югары кимәлдә үскән булуы хакында Аурупа галимнәренең аңын агартырлык фәнни хезмәтләр язган шәхес.
Әле тагын хәрби өлкәдә, разведка өлкәсендә күпме хезмәт керткән татарларның исеме билгесез булып, империя карынында югалачак. Югарыда китерелгән мисаллар — диңгездән бер тамчы гына. Фән, сәнгать, промышленность өлкәсендәге көчләрне бер кулга җыйсаң, татарның мөстәкыйль дәүләтле булып яшәрлек потенциалы күз алдына килә дә баса. Менә ни өчен Ильминский кебек карагруһчылар татарга белем бирмәскә нык тартышканнар! Менә ни өчен бөтен татар диаспорасын туплап торган бер үзәк-башкала статусын булдырмау, аның архитектурасын мескен хәлгә калдыру гамәле күпме вакытлар буена эзлекле алып барыла.
Чыңгыз ханнан ук килгән империя өлгесен яралгы итеп алган рус мәмләкәтендә архитектура да хәрби режим, казармачылык, эчпошыргыч бертөрлелеккә буйсындырылган. Аерым байлар төзеткән затлы сарайлар бармак белән генә санарлык. Сталин дәвереннән соңгы архитектура үз төшенчәсен бөтенләйгә җуйды. Бер командага буйсындырылган шәрә йортлар кабы шәһәрләрне басты. Кешене хиссезләндереп, уй-гамен йокы казармалары арасында адаштырган, күндәм бер мәхлукка әверелдергән сөмсез архитектура үрнәкләре бөтен республикаларга җәелде. Бары тик Балтыйк буе шәһәрләре һәм Тбилиси белән Ереван гына үз йөзләрен саклап калдылар шикелле.
Соңгы дистә ел эчендә Казанның борынгы йортлары рәхимсез җимертелде, алар урынына тимер-бетон аламалар төзеп шәһәребезне гарипләттеләр. Үзенчәлекле рельефны исәпкә алмыйча төзелгән «шырпы каплары» бөтен шәһәр панорамасын бозып-каплап тора. Озак еллар баш архитектор булып эшләгән М. Агишев Казанны рәнҗетүдә шактый хезмәт кертте. Аның ни дәрәҗәдә сәләтле икәнен чамалау өчен ул проектлаган «Татарстан» кунакханәсен һәм консерваториянең концертлар залын күз алдына китерү җитә. Ирек мәйданын бозып торган бу «кыяр парнигы»ның, ниһаять, фасадын сүтеп, коткару эшенә керештеләр. Бу бина рәткә китерелгәч, мәйдан түрендәге элеккеге партия өлкә комитеты бинасының сорылыгы да күзгә нык ташланачак. Димәк, аның фасадына да косметик үзгәрешләр кертү кирәк булачак диган сүз.
Казан елгасының аргы ягында сазлык өстенә ком җәеп, яңа кварталлар төзү дә Агишев чорында башланды. Ком өстендәге шәһәрнең гомере озын булырмы? Күпмедер вакыттан соң, ком катламын саз суырып да, бер-берсенә Теләче районы халкы сыярлык йортлар рәте тырпайган субайлар өстендә утырып калмасмы?! Югыйсә Идел аша күпер салып, шәһәрнең яңа өлешен Ослан таулары ягына, саф һава хозурына чыгарсаң, күп калалар көнләшерлек икенче Истанбул була иде бит Казаныбыз!
Яңа шәһәрләрдән «гигантская спальня» дип көләргә яраткан инженер, үз эшенең фанатигы Марат Бибишев тылсымы белән Чаллыда бик күркәм биналар төзелде. Ә Казанда һаман зәвыксызлык, архитектура өлкәсендә башкала дәрәҗәсенә тәңгәл иҗат сизелми. Казан, сыкрап, йөзен югалта бара. Менә бу фәлән президент дәверендә төзелгән ансамбльләр! дип әйтерлек булсын өчен, кичекмәстән, башкалабыз төзелешенә аерым игътибар бирергә кирәк. Таш гомере озын да, хәтерле дә.

* * *

Йокыга талган Казансу бозында пингвиннар кебек тезелешкән балыкчылар өстеннән таң шәфәгына манылган томан күтәрелгәндә шәһәр алсу дәрьядан йөзеп барган корабка охшап кала. Бу манзараны шундый итеп хәтереңә сала күр. Башкаланы, әнкә кебек үк, сайлап алып булмый. Ничек бар — шулай кабул ит тә, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйлан. «Казан — татар шәһәреме?» — дип кинаяле сорау биргәнгә: «Казанны ничек татар шәһәре итәргә?» — дип гамьле сорау белән җавап бир.

Чорыбыз күрәзәчесе болай ди: «Идел-Урал төбәгендә су-һава-тимер юл төенләнешендә иң уңайлы үзәк — Казан каласы. Халыкара ярминкәләр үткәрү өчен иң кулай урын. Моның өчен супермаркетлар, түбәле базарлар, биш йолдызлы отельләр, заманча портлар төзегез. Менә шул чакта инде сезгә чит илләр сәламен бирер. «Казан кайда ул, Казахстандамы?» — димәсләр. Ашыгыгыз! Россия исәеп аягына басса, Мәкәрҗә ярминкәсен кабаттан торгызу эшенә керешәчәк. Кем алдан өлгерә, базар хуҗасы шул була.

Ләкин без моңа әзерме? Шәһәремә чит күз белән карыйм да йөрәк сыкрап куя. Рәсәйнең яшәү, уйлау, эшләү рәвешен алып без шәһәр төзү өлкәсендә рәтле илләрдән йөз елларга артка калганбыз икән. Хәтта безнең мактана торган чисталык ягы да шул хәлдә... Минем безнең эрага кадәр дүрт мең ел элек салынган Эфес һәм Бергам шәһәрләренең калдыкларын күргәнем бар. Урамнары ак мәрмәр таш шакмаклар тезеп ясалган, бүген дә исән, чиста. Алтын Урданың шәһәр казылмалары да шуны күрсәтә. Гомумән, дөнья йөзендәге чын шәһәрләрнең урам-тротуарлары үзлегеннән тузан чыгарып торучы асфальт белән түгел, таш плитә белән түшәлгәннәр. Шуңа күрә дә аларны шампунь белән юа алалар. Менә шуңа ирешми торып, Казанның чисталыгы хакында сүз йөртү буш хыял гына.

Әгәр без берәр илдән атаклы архитектор чакыртып, аңа нинди дә булса берәр бина, күркәм бер сарай салырга заказ бирсәк, ул башта татарның сәнгатен өйрәнеп чыгар, борынгы шәһәр урыннарында археологик казылма әйберләрен өйрәнер. Алтын Урда һәм Болгарда сугылган кирпечләрнең бүгенгедән күпкә сыйфатлырак икәнен күрер һәм аны ясауның серләре нигә җуелганын аңларга тырышыр иде. Почмаклары, кыр-кырлары уалып беткән төссез кирпечтән шәп бина салып булмасын төшенгәч, ул үз иленнән һәрберсе ипи кебек кадерләп төрелгән кирпечне сак кына китертер иде. Һәм ул яшәү өчен түгел, ә җан асрар өчен шыксыз казармалар төзүгә нокта куйдырып, төрки-татар архитектурасының борынгы үзенчәлекләренә заман сулышы өреп, яңа төзелешкә юл ачар, башкала кимәленә торырлык таш елъязманы башлап җибәрер иде.

* * *

Кызганыч, татар дигән милләт җаны, чатнап, икегә бүленгән. Укымышлы, зыялы интеллигенциянең бер өлешенә моң да, иман да әнкә сөте белән кермәгән. Болар империя кем кулында, шуның аяк бармагы булырга әзер торып, бар үчлеген үз халкына борган кавем. Шушы иң көчле ми-акыл үзәге тупланган катлауда бердәмлек булмау мөстәкыйльлеккә омтылу юлында халыкны да сүрән таркаулыкка һәмваемсызлыкка китерә. Киләчәккә күз аткан олы максат бер хәл, безгә күңел-йортыбызны чистарту, рәткә сала бару кебек көндәлек эшләрне дә хәл итәргә кирәк. Казанның урам исемнәрен алыштыру хакында сүз кузгаттык та тынып калдык. Моңа да көчебез җитмимени? Кемнәрдер, ничек бар, шулай калсын, тарих бит ул, дип демагогия, сүз боткасы

куерта башладылар. Сафсата бу! Тарих һәрчак үзгәрештә, яр ямала килә, ялгыша төзәтелә. Җитмеш-сиксән ел — вакыт өчен төкерек, әмма яралары тирән, аны төзәтерлек көч бар, халык бар.

Казанның матур бер урамы Бауман исемен йөртә. Кем ул? Кайсы халыкка нинди үлмәс эшләр калдырган? Мондый узгынчы исемнәр бихисап. Урамнарга халкыбызның сыналган, мәртәбәле шәхесләренең исемнәре бирелергә тиеш. Татарга хезмәт иткән, мәңгелек хезмәтләр калдырган бүтән миллә кешеләре — Лев Гумилев, Александр Ключарев, Михаил Худяков, Карл Фукс, Ибн Фадлан һәм башка шундый затларның исеме дә кадерле ядкарь булып чор хәтеренә уелсын иде.

Миллионнарны корбан итеп яңа җәмгыять төзегән, хакимлектән ләззәт алып калыр өчен генә яшәгән очраклы шәхесләрнең урамга бирелгән исемнәре, һәйкәлләре тискәре нурланыш — кара тәэсир, үзенә бер төрле аура тудыра. Безгә кичекмәстән алардан арынырга, рухи чистарынырга вакыт җиткәндер.

Мулланур Вахитовка һәйкәл ачкан чакта, эчке бер горурлык, күңел тулудан күз яше килгән иде. Еллар үтте. Алдыбызда һәм җирдә күп нәрсәләр үзгәрде. Карап үтәм дә, сәнгатьле эшләнгәнме бу? — дип үз-үземә сорау бирәм. Нинди күркәм урын. Тау үзе һәйкәлгә нигез югыйсә. Уйланырга дип баскычлардан күтәреләсең дә, тагын постамент... Кулын сузып, морҗа башыннан сикерергә җыенган кеше... утырып торган, фикерле һәйкәл булырга тиеш иде түгелме? Хәер, большевикларга кеше биеклегендә утырырга ярамагандыр шул.

Тарихның борын төбеннән инфантиль геройлар эзләгәнче, ераккарак күз ташлап, халык азатлыгы өчен кылыч тотып, гаярь атларга атланып, үз артыннан меңнәрне иярткән чын каһарманнар — Япанчы, Колшәриф, Бәхтияр Канкаев, Канзафар Усаев кебек асыл затларны мәрмәрдә сынландырырга иде.

Салих Сәйдәшев һәйкәле хакында да үзешчән көчләр активлык күрсәтә. Әгәр скульптор Рада Нигъмәтуллинаның ниндидер таяк болгап торган кеше сурәте-проекты тормышка ашса, без якты елмаюлы моң чишмәсе — Сәйдәш образын үтерәчәкбез. Ашыкмаска иде, бу эшне бисмилла итеп башкара алган берәр талант иясе бардыр ләбаса!

Киләчәктә, бәлки, Г. Камал исемендәге театр бинасы каршында атаклы шәхесләребезгә куелган скульптура аллеясы булыр? Шул рәткә, үз чордашлары белән бергә, Салих Сәйдәшевкә дә бюст куелса, аның рухы рәнҗемәс иде шикелле.

Ат турында татарда күпме җыр, мәкаль, канатлы сүз, әкият бар икән? Ат өстендә томырылып кыйтгаларны кичкән, яуларда, бәйрәм мәйданнарында дан алган халкым бу гадел һәм сылу хайваннарга мәңге бурычлы. Ә Казанда ник бер атлы һәйкәл булсын! Ханлыкка нигез салган Олуг Мөхәмммәткә шундый һәйкәл куелу — милләт бар, яши һәм яшәячәк икәнен раслау булмас идеме?!

Белгечләр әйтүенчә, Казан каласы җир һәм күк бәйләнешенең хикмәтле ноктасында, акыл һәм зиһен чыганагы тупланган бәрәкәтле агымда тора, монда яшәгән халыкка гуманлы миссия йөкләнгән. Тәкъдиребез шундый икән, безгә үткәннең күләгәле гөнаһларыннан арынып, якты сәхифәләргә аяк басар алдыннан, бер фалны ачып салырга кирәк. Өй иясе булган кебек, халыкның да сафлыгын кайгыртып, җир-су, урман-таулар сагында торучы Ватан Иясе була. Без аны моннан берничә гасыр элек рәнҗеткәнбездер... Сөембикә-ханбикәнең каберен табып, аның җан читлеген (сөякләрен) алып кайтып, Казан зиратына иңдерсәк һәм аңа иң күркәм урында һәйкәл торгызсак... Юк, ул кылыч күтәреп түгел, ә улы Үтәмешгәрәйнең башыннан сыйпап торган зифа, ак мәрмәр сын булып, халкына имин-садә гомер теләп дога пышылдаган Ватан-Ана мисалында мәйданга калкыр иде. Менә шул чакта гына җир-су, урман-таулар сагындагы рух иясе безгә йөз белән борылыр һәм бу каннан сугарылган шанлы

җиребезгә иман нуры иңдерелер. Тәңренең ярлыкавы азанлы Казан өстеннән саба җиле булып дәверләр ярына узар.

## Сүзсез дога

*Искә алырлар, исемеңне уртага салып.*
Г. Утыз Имәни

Моң хасиятен кем аңлата ала?

Кайсы йолдызның фатиха нуры астында туганнарга гына моңлы булу язган?

Әллә соң моң биреләсе инсанга иңдереләсе җанны Тәңре кәүсәр суларына манып аламы?

Бу — минем өчен җавап таба алмыйча гаҗизләнгән гомерлек сораулар. Шул сорауларга беренче адым — балачакка барып тоташа.

Әнә ул — тал песие кебек йомшак чәчле малай, идәндә уйнап утыра. Өстәлгә аның буе җитми. Бәлеш-коймаклар, җимеш сулары китерелеп торган табында чөкердәшеп утыручы апаларның ул аяк очларын гына күрә. Әллә нинди тәмле сүзләр табып кыстаулардан соң табын кинәттән тынып калды. «И-ии, җырлаплар да күрсәтә инде, ә?!», «Бәгырьләрне өзә инде, бәгырьләрне өзә» дип пышылдаулар гамьсез уйнап утырган малайны да сагайтты. Кайбер апалар, җыларга алдан ук әзерләнеп, тирән кесәләреннән кульяулык алып учларына йомарладылар.

Менә Чәчкә апа җыр башлады. Озын көй дулкынына башын кыңгыр салды, эчтән кабынган шикелле, бит очлары алланып чыкты. Күзләре кысылып бетте дә, кус кара керфекләр арасында калтырап торган чык тамчысыдай нур гына калды. Чәчкә апа җырлый... Кулын сузып, песине иркәләгәндәй, нәзакәтле хәрәкәтләр ясый, гүя ул үз тавышын сыйпый-сыйпый, моңын табындагыларның һәммәсенә тигез таратып җибәрә иде шикелле.

Ә бу мәлдә малайны нинди тойгылар биләде соң әле, хәер, бер уч кына кояш сыярлык сай күңелендә нинди тойгы булсын ди, бары — соклану, соклану...

Шәмдәлләрдә генә утлар яна...

Нинди шәмдәл, нинди утлар?.. Юк, әлеге сүзләр турында уйламый ул, дога тыңлагандагыча, нәни аңы җыр агышына рәхәт оеп тирбәлә, кинәнеп таркала-таркала тәрәзә кашагасындагы чүпләм сөлгеләргә күчә, түгәрәк елмаюы эре чәчәк булып ачылган яран гөлләренә сарыла, ишек өстенә эленгән догалыкка кушыла.

Чәчкә апа — табын күрке. Күпме күзләр аңа төбәлгән. Бу мәлдә Чәчкә апага үлеп гашыйк идем мин. Менә ул җырлап бетерде. Сугыш чорын кичергән апа-җиңгиләр, күз төпләрен сөртә-сөртә, сагышлы төш халәтеннән чыга алмыйча, бер мәл өнсез утырдылар. Аннары, тыйнак кына сүзләрне уртага салып, бер-берсен кабатламыйча мактарга тотындылар. Чәчкә апа исә, берни булмагандай, ваемсыз елмаеп утырган кебек. Күрәсең, бар хәсрәтен җырларына сибеп тараткан да, хәзер инде кошларын очырган буш оя кебек, җиңеләеп калган...

Үсмер егет булып аулак өйләргә йөри башлагач, мине югары оч егете Фирдәвес шаккатырды. Тумыштан аксак иде ул. Кыяфәте авылга бер: ак чәчле, ак кашлы, ак керфекле, ак йөзле, зәп-зәңгәр күзле — Әллада осталары фил сөягеннән үтә дә нечкәләп ясаган сын шикелле.

Йа илаһым! Нинди тавыш! Нинди моң аһарда!.. Юк, безнең авыл чишмәләренең генә суын эчеп үскән егет түгелдер бу! Сәмави җандыр, Җәнабе хакның тырнак очы тиеп киткәндер моның бишегенә.

Фирдәвес төне буе җырларга әзер. Тик бер шартны гына үтәп торсыннар: җырның билгеле бер урынында тын алырга тукталгач, син аның кулына хәмерле стаканны сузып өлгер. Фирдәвес хәмерне уртлап куя да тагын башлый. Гаҗәеп моң! Кирәк түгел моңа купшы заллар, кирәк түгел күкрәүле алкышлар! Табигый моң бакый дәверләрдән күчә килгән нәсел хатирәләрен уята, япан дала иркенлегенә сусаган җан, читлеген киереп, сулкылдый башлый.

Мин артык түзә алмыйм. Яратып йөргән кызымны каерып торгызам да күрше бүлмәгә алып чыгам, алдына ятып җылыйм. Көнләшүдән җылыйм. «Нигә миңа шундый моң бирмәгән Ходай! Нигә мине рәнҗеткән?! Аксак Фирдәвес миннән мең мәртәбә өстенрәк. Аның кебек җырлаучы дөньяда юк!..»

«Моңлы кеше бәхетсез була, диләр... Син кызыкма... Сиңа бүтән сәләт бирелгән...»—әнә шулай юата, баштан сыйпый Төн кызы. Ә мин, кимсенеп, күңел ярасын учыма кысып бусагадан атлыйм да, еллар ызанын саный-саный, бүгенгемә ашыгам. Ни гаҗәп, бик күп көйләрнең иң нечкә борылмаларына кадәр хәтердән белэм югыйсә, ә шуны тавышка сала алмыйм. Эчтә — былбыл, тыштан — мөгерәү... Тумыштан бирелгән бу бәхетсезлек минем җыр-музыкага тартылуымны көчәйтте генә ахрысы. Биек бусагасыннан атлап керә алмаган малай шикелле мин бу изге храм тирәсендә ымсынып йөрдем-йөрдем дә... хыялымны бөтереп алып кереп китә торган әйләнмәле сәхнәләрдән исемемне яңгыратырга булдым. Ничекме? Бик гади итеп.

Яшь шагыйрь — университетның бишенче курс студенты (ул чакта Казанның бердәнбер һәм чын университеты) борынгы йортның икенче каттагы шыр ярлы бүлмәсендә, акшарлары купкан мич капкачын ачып куйган, каен утынына ут дөрләткән дә ялкын телләренә карап, моңсуланып утыра. Күптән түгел генә өйләнгән, дөньясы тарайган. Бүтән инде мәңге гашыйк була алмас, гөнаһ булыр, ярамый, дигән самими уйлары читлектәге йөрәген юата алмый. Учактан дуамал очкыннар чәчри. Күмер араларыннан, әрнеп, шигырь юллары төшә.

Урманнарда яна,
яна,
яна сары балкыш,
Сизелми дә җиткән көз дисең.
Үзең әле һаман кырлар буйлап
Яшеллеген җәйнең,
яшеллеген җәйнең эзлисең.

Шулай итеп мин, җыр өчен дип, махсус шигырь язып утырам. Гадәти дүртьюллыклардан аермалы булсын дип, сүзләремне бүлгәләп, композитор хыялына, үзгә бер ритмга мөмкинлек калдырам имеш. Тәҗрибәсез башым белән чамалыйм: чытырманлы фикерне җыр өнәми, көйгә салынасы шигырьдә сүз аз булырга, җиңел истә калырга тиеш.

Яшьлекнең дә мәңге,
мәңге,
мәңге булырына
Ышанмадык мыни — ышандык.
Ә нигә соң синең күзләреңдә
көзләр нуры кергән,
көзләр нуры кергән уйчанлык?..

Кем бу җырга җан өрер? Кем көйчесе булыр? Бу турыда уйламыйм да бугай. Кыюланып, кайсы да булса композиторга шигыремне бирү хакында уйларга да куркам. Чөнки мин аларның берсен дә якыннан белмим. Каһәр суккан оялчанлык!..

Зур концертларда сәхнәгә тыйнак кына чыгып, пианинода җанга ятышлы итеп уйный торган музыкант ханым — Мөнирә Хәбибуллина (шагыйрь Мөнир Мазунов кызы) белән радиокомитетта танышкач, мин аңа әлеге шигырьне бирдем. Тиз генә кемнәндер яздырып алыр да, бу көй тиз арада бөтен Казанга таралыр — үземә калса, шулай уйлаган булам.

Менә шул шигырь аркасында инде мин чорыбызның мәшһүр композиторы Рөстәм ага Яхин белән танышу бәхетенә ирештем. Мөнирә ханым радиокомитетның кием элгече янында Рөстәм аганы «эләктереп» алган. Ничаклы җаена төшәргә тырышса да Рөстәм ага ул сузган кәгазьгә борылып карарга да теләмәгән. Аптырагач, Мөнирә ханым:

— Ярый, алмассыз, менә шушында укып кына карагыз инде, зинһар,— дип, ялынып диярлек үтенгәч, Рөстәм ага шигырьне кулына теләр-теләмәс кенә алган, плащының сыңар җиңен кигән килеш туктап калган да... Мөнирә ханым аны болай дип сурәтли:

— Үзе укый, үзе башын селкетә. Зур башлы иде бит Рөстәм ага. Сизеп торам, көй аңарда шигырьне укыганда ук туа башлады. Шуннан укып бетерде дә, бер сүз дә әйтмичә, шигырьне кесәсенә салып куйды. Берничә көннән инде әзер романсын тотып миңа килде.

Хәтеремдә, бу хәбәрне ишеткәч, мин бер дә сөенмәдем. Шундый мәртәбәле композиторны кузгатырга кирәкми иде. Искечә итеп, саллы көй язгандыр. Ә мин бүген студентлар табынына бәреп керәсе яшьлек ритмын көткән идем, дип үкенечле уйлап та куйдым бугай.

Танышканда Рөстәм ага йомшак кулын минем кул ихтыярына бирде. Артык ипле, төгәл, пөхтә — зыялы икәнен бөтен рәвеше әйтеп тора. Ә минем, рәтле тәрбия алмаган егетнең, бу эчпошыргыч бертөрле җөмгыятьтә «почмаклы» буласы килү, аркылы фикер әйтеп шаккатырасы килү маһирлыгының баштан ашкан чагы. Әмма Рөстәм ага каршында мин югалып калдым. Ни таләпчән композиторның шигыремдәге бер генә сүзне дә үзгәрттермәве мине чарасыз калдырды. Тынлыкка таянып басып торабыз шулай... Нинди дә булса сүз әйтсәм, аның моң тулы касәсен саксыз кагылып чайпалдырырмын сыман. Ул да мине әллә күрә, әллә күрми, күз карашы эчкерсез-самими, гүя ул күңелендәге моң сүрүе аша бу кырыс дөньялыкка бик үк чыгарга теләми иде.

— Мин сезне олы яшьтәге кеше дип уйлаган идем. «Яратырга инде соң дисең...» Сезгә болай әйтергә иртәрәк бит әле... Кызык... кызык...

— Мин аны чын күңелемнән, ышанып яздым,— дип мин акланырга керештем.

Гомереңнең актык сулышында да мәхәббәтнең соңы соңгы булып тоелмыйдыр, дигән кебек, Рөстәм ага сизелер-сизелмәс кенә киная белән елмайды.

— Көй бик тиз язылды. Андый очрак сирәк була. Гадәттә мин бик озак йөртәм. Тагын шигырьләрең бармы, җыр өчен дип язылганнары?

— Юк, Рөстәм ага. Монысы да үземне сынап карар өчен генә. Бүтән язмыйм!

Рөстәм ага бер мәл сәерсенеп карап торды. Иҗат галәмендә күпне күргән, күпне кичергән аганың күзләре: «Ай-һай, мондый авыру бер керсә, туктый алырсың микән, егет...» — дигән фикерне яшермичә эчтән елмая иде.

И авыл гыйбаты!.. Синә чынлап та олуг классикның моң канаты кагылып киткән икән бит, моны сизмичә дә аның каршындаваемсыз басып торасың. Хак тәгалә сиңа бәхетле мизгел иңдергән: икътибарлы бул, исеңдә калдыр, ашыкма, бөек аһәңсазның күзләреннән ут ал күңеленә. Юк шул, юк инде, яшьлек сабырсызлыгы чабуыннан тарта — берни ишетмисең, күрмисең, сизмисең. Асыл бәя бирә белгәнчегә кадәр әле гомер агачының кәүсәсенә күпме еллар боҗрасы урыласы бар.

Мин гел шулай, үз вакытында белергә ашыкмыйча күп нәрсәләрдән соңга калдым. Болгавыр бу тормышның үтә тыныч бер сәгате сугар да, очрашырбыз, мөсабәхә кылырбыз дип яшисең дә... Бәя биргесез затлар,

гыйбрәтле тарихын иңнәренә салып, китә торалар, мин өлгерә алмыйм, гомер ярында нәүмиз басып калам.

«Көзге моң» дип исемләнгән романсны танылган сәхнә осталары — Эмиль Җәләлетдинов, Рафаэль Сәхаби, Хәйдәр Бигичев пластинкаларга яздырдылар, зур тамаша залларында башкардылар. Хәйдәр Бигичев бу романсны янә бер башка күтәрде һәм зыялы-зәвыклы катлауның күңелен яулап алды. Мин дә шулар белән бергә әкеренләп «тәрбияләндем», җырны ярата башладым. Кайбер чакларда, тирәмдә кеше-кара югында, җитлекмәгән тавышым белән көйләп тә алгалыйм. Хөрмәткә лаек шәхесләрнең кулны кысып котлауларын тою да миңа рәхәт иде. Арадан берсе аеруча истә калган. Бик җитди, шаяртудан ерак торган галим кеше. Дус-ишләр белән театр холлында басып тора идем, янга килеп, кулны мишәрләрчә катылык белән кысты да:

— «Көзге моң»ың белән котлыйм. Классик романс. Сүзләре Маркс теориясенә туры килә,— диде.

Марксны беләм дип әйтә алмыйм. Аның хезмәтләрен төбенәчә укып чыккан кеше гомумән бар микән. Минем аптырап калуымны сизеп ул:

— Коммунизмда кайгы-хәсрәт калмас, бары тик мәхәббәт сагышы гына калыр, дигән Карл Маркс. Сезнең шигырегез шуңа туры килә,— дип аңлатуны кирәк тапты.

Бер елдан соң (1984—85), нәкъ шул ук сүзләр белән ул мине янә котлады. Мактау өлешен җиңел кабул иттем. Ләкин... Илледән өстәге ир кеше, тарихчының әкияткә ышануы... Кайгы-хәсрәт юк икән, димәк, тереклек тә беткән дигән сүз... Хәер, ышана икән, көлмик лә... Иң мөһиме — романсны кабул итеп җылы сүз әйтүенә рәхмәт. Ул ишарәләгән фикер җырның соңгы аккордларында иде:

Таҗын өзеп соңгы чәчәкләрнең
киләчәгең юрап карыйсың.
Яратмаска сине мөмкин түгел!
Яратырга инде, яратырга инде...
соң дисең...

Бервакыт Ирек мәйданында олуг шагыйребез Сибгат Хәким белән очраштык. Мин концертка бара идем. Ул һава суларга дип чыккан. Сибгат ага, гадәтенчә, йомшак кына итеп, сүзләрен мәгънәле өзә-өзә фикерен башлады:

— Яхин кичәсендә булмадың. «Көзге моң»ны Бигич җырлады. Мин күп җырлар язган кеше. Көнләштем. Җыр беткәч, зал бер мәлгә тын ала алмыйча торды. Аннары... шартлады. Алкышлар биш минут буена сузылгандыр. Сезнең ул романс калачак...

Үз гомерендә танылган композиторлар белән гаҗәеп җырлар язган аксакалның шулай эчкерсез әйтүе күңелемә шифалы уелып калды. Бүгенгедәй хәтеремдә: көзге җил иде. Сибгат ага бүреген төшереп бәйләгән иде. Юлбашчы һәйкәле янында җил гел юнәлешен үзгәртеп торганга, без әле болай, әле тегеләй борыла-борыла хәтсез сөйләшеп тордык.

Хәйдәр Бигичевнең, зур оркестрга кушылып, «Көзге моң»ны искиткеч итеп җырлавын мин Мәскәүнең Колонналы залында тыңладым. Шыгрым тулы залда Мәскәү татарлары гына түгел, руслар да, чит ил кунаклары да бар иде. Бу шигырьгә Рөстәм аганың шулкадәр дә тирән мәгънәле көй язуына мин шунда ышандым. Күңелне әйтеп бетергесез горурлык хисе биләп алды. Алкышларның кодрәте турында әйтеп тә тормыйм. Сибгат ага сурәтләгәнне Мәскәү тамашачысы да раслады.

Әлбәттә, бу романс Рөстәм аганың күпкырлы һәм бай иҗатында бер тамчы гынадыр. Әмма минем өчен ул тарихи тамчы. Шигырь һәм көй бердәй тәңгәл килгәндә генә җыр гомерле була, диләр. Шулайдыр. Кешелекле шәхес буларак, Рөстәм ага минем беренче әсәремә игътибар итте, җан иңдерде, мәрхәбә, дип, олы сәнгать дөньясына кереп китәргә

сәбәпче булды. Шуңа күрә, аңа рәхмәтле хисләрем артыккарак китсә дә гөнаһ түгел.

Күзәтергә иде: фортепиано яисә рояль янына кайсы композитор ничегрәк килеп утыра, аклы-каралы клавишаларны ничегрәк уята, беренче аккордлар тәэсире йөз-кыяфәтенә нинди нурлар булып төшә икән? Сәйдәшнең уйнаганын күрәсе иде. Яруллинны, Җиһановны, Ключаревны... Фасил Әхмәт, Ринат Еники ни рәвешле уйный, һәрберсенең үз ырымы, үз догасы бардыр?..

Рөстәм аганың фортепианода уйнаганын хәтерлим. Клавишаларга алай үк та сак-иркә кагылып, бармакларын тигезер-тигезмәс йөздереп кенә уйнаган музыкант тагын бар микән?! Йөз-кыяфәтендә мәҗүси ягымлылык. Гәүдәсен йә сулга, йә уңга салмак кына авыштыра-авыштыра бармакларын йөгертә, уйный дию генә аз, музыка тәэсирендә яши, хозурлана, яшәрә бара. Бу тылсымлы коралның ул әсире дә, хакиме дә, ул аңа ялвара да, боера да ала. Нәзберек-нәфис авазларның төсе упкын өстендә тибрәнгән пәрәвез җебе шикелле җемелдәп-җемелдәп китә, чәчәк таҗларын кытыклап, сирпелеп кенә узган таң җиле кебек саф-садәлеге җанны иркәли, ләйсән тамчыларга таркалып, ямансу тойгыларыңны өрфия томан белән биләүли.

Яхин моңы — мөлаем-назлы моң.

Табигатьнең язылмаган кануны бар: билгеле бер иҗат дәвереннән соң, елан кабыгын алыштырган кебек, төс алыштырырга, яңача фикерләүгә, үзгә бер ритмнарга күчәргә тиешсең. Бу — композиторга да, рәссамга да, шагыйрьгә дә, җырчыга да хас зарурилык. Күк тарафыннан Рөстәм ага Яхинга гомеренең соңынача җитәрлек кабатланмас моң дәрте бирелгән иде. Отыры камиллеккә ирешә барып, һәр әсәрендә яңа төсләр яңгырашы табып, кабатланмыйча, моңын беренче сафлыгында яшәтә алган композиторлар сирәктер ул дөньяда.

Рөстәм аганың да балачак хәятенә моң тылсымнары иңдергән үз Чәчкә апасы, үз Фирдәвесләре булгандыр. Халык бәгыреннән иңрәп өзелгән мондый табигый сәләт ияләре, үзләре дә сизмичә, яшь кеше күңелендә учаклар кабызалар да билгесезлектә гаип булалар. Бәлигъ булгач кына бәясен аңлап, еллар аша кайта-кайта аларны эзләп-барлап карыйсың, әмма рәхмәт әйтергә үзләре юк, ятим рухлары гына калган була. Балачактан ук музыкаль осткы салган әнә шундый билгесез осталарына карата Рөстәм ага мәрхәмәтле булгандыр.

Галәм чиксезлегендә җисемнәр әйләнеше, йолдызлар мириадасы билгеле бер көй-ритмга буйсынып хәрәкәт итә икән, димәк, бөтен тереклек ияләре җанга тойгылар аша гына тәэсир итә торган илаһи космик музыка чолганышында яши. Һәм шушы авазлар дәрьясыннан җир йөзендәге һәммә халык-милләт үз табигатенә хас чишмәне отып ала. Бу хикмәт — Күк белән Җир арасындагы илчеләргә, аерым бер моңдарларга, гасырлар аръягында исеме дә онытылырга мөмкин могҗизалы затларга — композиторларга бирелгән сирәк-гадел очраклылык. Рөстәм ага Яхин әнә шундый, учына бәхет ташы кысып туган сирәк затларның берсе иде.

Татарның киң ябалдашлы, тирән тамырлы гомер агачында сындырылган, күмерләнгән кайгы-хәсрәт, әрну-каргыш тармаклары гына түгел, биеккә үрләгән нык-сәламәт үсентеләрендә яшәүгә мәдхия, тынкы сагыш, сөю-сәгадәт рухы да бар. Рөстәм ага үз иҗатында милли төсмерләрне нәкъ менә шундый тармаклардан үрелеп алгандыр.

Милли моң адәм баласына карында яралганда ук бирелә дә, тугач инде, әнкә сөте белән сугарыла. Бишек җырлары белән үз кавеменә тугры тәрбия алган кеше күңелендә генә шушы моң чолтәре саклана, бөтен тормышына җитәрлек өлгә булып, хис-тойгыларына шифа биреп торадыр, мөгаен.

Музыкада миллилек нидән гыйбарәт? Бу хакта Рөстәм ага белән гапләшкән бар. Ул, гадәтенчә, эчке фикерен көттереп кенә, бик сак әйткән иде:

— Дала җыры бар, таулар җыры бар. Урман яисә диңгез җыры бар... Мин шул төбәктә яшәгән халыкларның үзенчәлекле моңын күздә тотам.

— Милли моңы халыкның гореф-гадәтенә, яшәү рәвешенә, темпераментына, диненә, тарихына да бәйледер, бәлки?

— Әлбәттә.

— Гаҗәп хәл: японнар, кытайлар бездән бик ерак киңлектә яшәсәләр дә моңнарыбыз охшаш бит?..

— Димәк, кайчандыр якын булганбыз. Халыкның иле-җире, теле бетәргә мөмкин. Иң соңыннан моң кала... Музыка аша да тарихи бәйләнешләрны өйрәнергә, ачышлар ясарга мөмкиндер, бәлки,—дип Рөстәм ага, артык тирәнгә кермик, дигәндәй, сүзен болайрак йомгаклап куйды.—Музыка дөньясы каршында без бик бәләкәйбез. Ул дөньяны ачарга да ачарга әле...

Идел-Йорт—без яшәгән киңлек, ике бөек-дәһшәтле дулкын—Шәрекъ һәм Гареп чәкәшеп, тормыш хасил иткән төбәк. Рөстәм ага Яхин шушы төбәкнең башкаласы—Казанда туып-үскән. Шәһәр тәрбиясендә үскән композитор—аһәңсаз халыкның бетмәс-төкәнмәс көйләреннән, Сәйдәш иҗатыннан, русның Рахманиновыннан рухи этәреш алса, Көнбатышның даһилары—Бетховен, Шопен кебек мәшһүрләрнең әсәрләреннән дә бәлзәм алгандыр. Шуңа күрә дә аның музыкасы затлылыкка, ефәк томан белән өртелгән серлелеккә, кеше җанын олылый торган аһәңнәргә бай. Аның сыгылмалы музыкасын Париж залларында да, кара урман эчләрендә дә, дала киңлекләрендә дә, ак чалмалы кыялар эргәсендә дә йотылып тыңларга була. Аның көйләре французыңны, японыңны, инглизеңне, испаныңны да татарга әверелдереп тыңлата алу хасиятенә ия.

XX гасыр урталарында Европаның ак рояльләре, җиз органнары клавишларын таптап, афәтле какофония—негрлы Американың гарасатлы җилләре бәреп керде. Африкалыларны бакый заманда ут белән бергә яратылган, җан адашырлык джунглилардан чыгарга, биеккә омтылган дәртле-ялангач көйләре эссе экваторга хас иде. Төньяк ярымшарда, салмаграк яшәү рәвешенә күнеккән кавемнәрнең ул канын исертте; уйгамьсез калдырып, җенси котыртып, түсле утлар гаммасында бөтереп, яшь буынның рухи халәтен талкый-тарката торган кыргый рок-музыка тантанасы булып чыкты. Классик музыка тәмен, милли төсмерләрен тәмам җуя язган Европа, айнып, бу шаукымны Россия киңлекләренә таба борып җибәрде дә үзе утырып уйлана башлады. Рухи яраларга дәва, шифалы моң кирәк иде. Моның өчен, тәкәбберлегеңне онытып, яңадан ак сакаллы Шәрекъкә борылу, фәлсәфә ташын, тел ачкычларын, диннәр бишеген биргән бабаңны тану, һәм, сабыйлык чорында ул биргән аһәңнәрне кабаттан искә төшереп терелтү мәгъкуль иде.

Соңгы елларда Стокгольм, Рим, Вена, Берлин кебек шәһәрләрнең олуг залларында татар моңын тыңлап хәйран калалар. Нинди тирәнлек, нинди мөлаем сыгылмалык—пентатониканың бөек яңгырашы! Төркитатар дөньясының бик борынгы тарихын-сәнгатен кузгатып үзебез кечерәеп калмыйк, дигән гаделсез шик аркасында битараф калырга күндерелгән Европаның галим-голәмә даирәсе, атаклы музыкантлар, белгечләр аһ итteләр: «Без моны нишләп соң элегрәк белмәгәнбез?!»

Заманында Көнчыгыш Европаны тетрәтеп, Әдрән диңгез ярларына җитеп, чыдам атларының кайнар тоягын чылаткан татарлар хәтәр корал белән түгел, ә милли музыкасы белән бүгенге көндә Көнбатышны тез чүктерергә сәләтле. Гасырлар буена бик күп шәһәрләре җимерелеп, сәнгати байлыклары чәчелеп-туздырылып, таланып беткән халкымның утка-суга бирешми торган күңел хәзинәсе—галибанә моңы сакланып калган. Моны халык иҗаты дәрьясыннан күтәрелгән, соңгы илле ел эчендә мәйдан тоткан бер плеяда композиторлар, чын сәнгать әһелләре расладылар һәм үз иҗатлары белән бу ганимәтне тагын да баетты. Шулар арасында Рөстәм ага Яхин—төрле музыкаль жанрдагы әсәрләре—бибәһа мирасы белән аерым урын тота. Аның арфасына аяусыз вакыт җиле дә яратып кына кагылыр, Аллаһы боерса...

Без көн дә иртән Дәүләт гимнын ишетәбез. Милләтне олы эшләргә өндәп, Казан мәкаме, сүзсез дога булып яңгырый ул. Таң нурларыннан үрелгән бу мелодиядә Рөстәм аганың йөрәге тибә.

Йәгез, шундый чордашыбызның солтанатлы рухы каршында тынып калыйкчы бер мәлгә!

Татарның ул — бәхетле сагышы...

## «Мин яшим әле!»

*Егылмас борын син башыңны сәҗдәгә куй.*
Утыз Имәни

Башка туфрак кирәк иде бу гөлгә...

Бик күптән туган иде бу шигырь юлы. Җанның ирекка, гаҗәеп илләр күрергә сусап алгысынган, ак болытлар агып барган киңлекләргә нәүмиз тартылган мәлендәме? Әллә инде кысан чүлмәген тамырлары белән киереп ваткан, һәм шуның белән үзен үлемгә дучар иткән гөлгә ис-акылым китеп карап торгандамы? Хәтерләмим... Нигәдер әлеге шигырь юлын алга таба дәвам итә алмадым. Гомернең азагын күрәсе килмәгән кебек, күңелнең дә бу шигырьне тәмам итеп, үзеннән аерасы килмәгәндер, мөгаен.

Башка туфрак... Юк, ил читенең теге ягында калырга минем кыюлыгым җитмәде: авылым табигате, тыйнак инеше, җилләрне көрмәкләндереп уйнаган таулары, әти-әни йорты төшләремә кереп мине рухи сулышсыз калдырган булыр иде. Бары тик шәһәрдә, таш арасында туып үскәннәр генә мондый самими хистән азат буладыр.

Заманында чит илдә калучылар турында нәфрәтләнеп уйланганым хәтердә. «Ни җитмәгән?» дигән мәгънәсез-беркатлы караш минем дә аңыма сеңеп өлгергән булган. Бик күп нәрсә җитмәгән икән шул безгә, бик күп нәрсәдән мәхрүм калып, гомерне заяга сарыф иткәнбез. Яшәвебезнең күп өлеше җан асрау гына булган икән.

Язмышлар... Тарихларга кергән язмышлар. Менә ничә гасыр инде татарлар үз ватаны читен атлап чыга да, башка халыкларны көчәйтеп, мәртәбәле эшләргә тотына. Әгәр безнең үз дәүләтебез таркалмаган булса, бер йодрыкка тупланып, үз халкыбыз исеменнән дөньяга нинди олуг шәхесләрнең исемен таныткан булыр идек. Күпме асыл ул-кызларыбыз мәйдан учларында һәйкәл булып калкыр иде. Кызганыч, һаман сибәбез, һаман сибеләбез. Татарның тарала башлавына инде ничә гасыр!

Язмышлар... Дәүләтле халыктан чыккан шәхес кайсы гына илдә яшәмәсен, ул барыбер дәүләтле кала. Үлгәннән соң да аның табутын үз иленә алып кайтып җиргә тапшыралар.

Милләтнең асыл улларын барлап тору кирәкле шәйдер. Россиянең тамак төбенә аркылы килгән татар халкының тирәндә тектоник тетрәүләре сүнмәгән әле, вакыт-вакыт уяна да, вулкан уты кайнаган бәгыреннән чыгарып, талант иләрен дөньяга ыргыта. Шундыйларның берсе — Рудольф Хәмит улы Нуриев. Гүзәл сәнгате белән Ауропаны тез чүктергән, җиһанга танылган балет остасы.

**Рудольф Нуриевның Парижда чыккан китабыннан.**

***Гадәттә, кешенең туган авылы яисә шәһәре була. Миңа язмыш юлда туу кебек сирәк очракны әзерләп куйган. Әнием Кызыл Армия сафларында политрук булып хезмәт итүче әткәм янына барырга чыккан. Үзе белән ул өч апамны — Роза, Резеда һәм Лиданы да иярткән. Шулай итеп, мин 1938 елның март аенда, Иркутск белән Владивосток арасындагы юлда, поездда туганмын.***

***Берничә елдан соң әтиемне Мәскәүгә күчерәләр. Гаиләне дә ул үз янына алдыра. Икенче бөтендөнья сугышы башлангач, әтиебез шуннан сугышка китә. Яу***

*кырыннан исән-имин кайтып кергәндә аның күкрәге тулы орден-медальләр иде.*

*1946 елга кадәр безне — дүрт баланы әниебез күп газаплар белән карап үстерде. Сугышның беренче елында ук Мәскәүдәге йортыбызны бомба төшеп яндырды. Шуннан соң без Урал якларына — Башкортстанга кайтып киттек. Монда күчү туган якларга кире кайту кебек булды. Чөнки әтием тумышы белән шушы төбәктән иде...*

* * *

1961 ел. Ленинградның С. М. Киров исемендәге опера-балет театры Франциядә спектакльләр күрсәтә. «Пари-матч» журналы хәбәрчесе Оливье Мерлен Парижда бу театр куйган спектакльләрнең иң югары ноктага ирешкәне «Баядерка» булды, дип яза. Балет дөньясында егерме өч яшьлек Рудольф Нуриевны табу фантастикага тиң ачыш, ди ул.

«Йөзләп «кировчы» арасында ул бердәнбер йолдыз иде. Һәр тамашадан соң бөтен рус труппасы, автобуска күндәм генә утырып, Республика мәйданындагы кунакханәгә кайтып китә. Ләкин һәр кичтә «Лебединое озеро»дан Зигфрид яисә «Жизель»дән Альберт алардан аерылып кала. Минем опера һәм балеттан дусларым — Клара Сэн, Пьер Берже, Марио Буа, Клер Мотт, Пьер Лакотт, Жан-Пьер Бонфу Рудольфны Сен-Жермен-де-Пре кварталының шаулы төнге тормышы белән таныштыралар. Әлбәттә, бу гафу ителмәслек саксызлык булган.

Рудольфның йөрәгендә каршылыклы уйлар кайный. Әллә соң шәһәрләр шәһәре Парижда торып калыргамы? Илгә кире кайтса, алда нинди язмыш көтә аны? Күпме талант ияләре ачыла алмыйча сулып калды каһәрләнгән илдә. Яшәү бер генә бирелгән. Шул кыска гомердә үзеңне раслап каласы иде бит! Нинди авыр елларда да сыкранмыйча үстергән газиз әнкәсе, апалары исенә төшкәч, аның күзенә яшь килә. Бу аерылу мәңгегә булырга мөмкин шул. Кичермәсләр, шикләнү, сагаю, шәхесне салып таптау әхлагын байрак итеп алган бу илдә кичермәсләр аның бу адымын.

16 июньдә Парижның Бурже аэропортына килгәндә Рудольф Нуриев шундый уйлар белән гаҗизләнә.

Ләкин ул барыбер чит илдә калу хакында катгый уйга килмәгән була. Ирекле, хөр фикерле, үзе кебек яшь сәнгатькярләр белән аралашу, төнге Париж барлары — бөтенләй бүтән дөнья Рудольфның алгысынган хыялларына яңа канат куйгандыр. Ауропадан аерылу түгел бит әле бу, Лондонга очасылары бар, андагы зур сәхнәләрдә тантана итеп, Шекспирлы, Байронлы илдә үз көчеңне сынап карарга була. Шушы уй-өмет аның сулышына иркенлек бирә. Сизенә югыйсә, Париж шаукымы болай гына үтмәячәк, үткен күзләр аны күптән эзәрлекли, баш очында мәкерле болытлар куера.

Ә бу көннәрдә хәтәр оешмаларда инде аның исеме төрләнә, Париж-Мәскәү арасында яшерен хәбәрләр йөреп тора. Менә СССР Мин. Сов. каршындагы КГБ председателе А. Шелепинның КПСС ҮКына юллаган язмасыннан: «3 июня сего года из Парижа поступили данные о том, что Нуреев Рудольф Хамитович нарушает правила поведения советских граждан за границей, один уходит в город и возвращается в отель поздно ночью. Кроме того, он установил близкие отношения с французскими артистами, среди которых имелись гомосексуалисты. Несмотря на проведенные с ним беседы профилактического характера, Нуреев не изменил своего поведения...»

«...Комитет госбезопасности по согласованию с Комиссией по выездам за границу при ЦК КПСС в тот же день дал указание резидентуре КГБ в Париже об отзыве Нуреева в СССР.

8 июня сего года резидент КГБ в Париже доложил, что Нуреев прекратил ночные отлучки, улучшил свое поведение, в связи с чем посол принял решение воздержаться от откомандирования его в СССР...»

Ул көндә аэропортта булган хәлләрне үз күзләре белән күргән Пьер Лакотт «Гранд-Опера» журналында болай дип яза: «Мин иртән тугызда килдем. Артистлар труппасы анда иде инде. Алардан кала совет илчелегеннән килгән вәкилләр гадәттән тыш күп иде. Алар арасында полиция функциясен үтәүчеләр дә хәтсез булгандыр. Труппа җитәкчесе мине сәламләде һәм Нуриев белән бергә кофе эчәргә чакырды. Барысы да тыныч, Рудольф юкка гына хәвефләнгән икән. Лондонга самолет ярты сәгатьсез кузгалмый әле. Аларны озатмыйча кузгалмам дип уйладым.

Кинәт залдан ниндидер дулкын узгандай булды. Мин берни дә аңышмыйча Рудольфка карадым. Ниндидер бәндә аның белән сөйләште дә китеп барды. Рудольф ап-ак булып миңа текәлде: «Яңа гына килеп әйттеләр... Коточкыч... Бар да бетте... Мине СССРга кайтаралар. Бүтән мин беркайчан да бии алмаячакмын. Коткар мине! Себердә черетәчәкләр!» Ул моны шыпырт кына әйтте, әмма шулкадәр кайнарланып сөйли, миңа калса, ул бар көченә кычкыра иде сыман. Труппа Лондонга китәргә тиеш бит югыйсә, ул әйткәннәргә ышану мөмкин түгел иде. Минем икеләнеп торуымны күргәч, Рудольф кесәсеннән кечкенә хәнҗәр (кечә мин бүләк иткән идем) чыгарды: «Ярдәм итмисең икән — үз-үземне үтерәм!.. Менә билет — Лондонга түгел, ә Мәскәүгә!»

Нишләргә белми чарасыз басып торам. Рудольф «Коткар мине!» дип, яшь тулган күзләрен төбәп, әрнеп ялына. Шунда мин аның җитәкчесенә барып, Рудольфның тәртипле, менә дигән кеше икәнен исбат итәргә тырыштым. Ул болай диде: «Мсье Лакотт, аны беркем дә шелтәләми! Эш шунда — әнисе каты авырып киткән. Аңа тиз арада кайтырга кирәк...»

Дөреслек кем ягында? Бер якта — гамьсез чырайлы труппа директоры, илчелек вәкилләре, тәрҗемәчеләр. Икенче якта — калтырап, истерикага бирелергә торган Рудольф. Ниһаять, мин төшенеп алдым: ул хаклы булырга тиеш.

Менә Лондон самолетына утырта башлау турында хәбәр иттеләр. Артистлар Рудольф янына килеп «Сау бул!» димиләр, гүя бәхилләшәләр иде. Кемнәрдер, башка беркайчан да күрешә алмаячагын сизгән кебек, елый.

Шунысы мөһим: шик уятмас өчен мөмкин кадәр тыныч күренергә кирәк. Рудольфны транзит залына алып кереп китсәләр — бетте дигән сүз. Нейтраль зонада аңа инде берәү дә ярдәм итә алмаячак. Хәзер нишләргә соң? «Пари-матч» журналисты Оливье Мерленның мотоциклы аэропорт бинасы каршында тора икән. Әйт Рудольфка, минем мотоциклга таба йөгерсен, ди. Кая ул, тышкы ишеккә җиткәнче үк «фәрештә-сакчылар» эләктереп алачаклар үзен.

Сиздермичә генә кәгазь кисәге алып, телефон номерлары яздым. Кем дә булса полициягә хәбәр итсә... Шулай ук мин Андре Мальро (танылган француз язучысы, мәдәният министры), Рудольфны яхшы белгән Клара Сэн турында да уйладым. Язуны кемгә тапшырырга? Безне стена булып совет кешеләре уратып алган. Янәшәдә берәү утыра. Бизнесмен яисә туристка охшаган. Мин аның янына утырдым да, ботинка шнурын бәйләгән булып, язуны аңа төрттем. Таныш түгел кешем китеп барды. Әйләнеп килгәч, бар да тәртиптә, дигәнне аңлатып ым какты. Җиңел сулап куйдым. Ә баш очында галәмәт зур сәгать, аның уклары Рудольфны алып китәсе хәтәр мизгелгә отыры якынлаша бара. Мин совет кешеләренә елмайган булам, алар инде тынычызлана да башладылар. Рудольф елый да елый.

Менә бераздан тәрҗемәче минем янга килде:

— Саубуллашыгыз да... Биш минуттан утырту башлана...

Ул сүзен очларга да өлгермәде, аэропортка давыл булып Клара Сэн бәреп керде. Ул туп-туры безгә таба килә иде. Сакчылар аңа юл бирделәр. Клара артыннан тагылып диярлек ниндидер ир кеше ияргән иде. Клара мине үпкәндә колакка пышылдап өлгерде: «Рудольфка әйт, ул

минем артымдагы кешегә ташлансын. Ул полисмен. Рудольф аңа «И вант то ве фрее!»— дип әйтергә тиеш».

Мин Рудольф янына бардым. Совет кешеләре тын калып торалар. Максатларына ирешергә аларның бит секундлар гына калды. Рудольфны кочакладым да, шик салмас өчен кычкырып: «Күрәсеңме кем килде?! Клара үзе! Үбеп саубуллаш!»— дидем. Рудольф нәрсә эшләргә кирәген шунда ук төшенеп алды. Кларага таба юнәлде дә, кинәт француз полисменына таба ыргылды: «Минем азат буласым килә!» Совет җантимерләре аны каерып алырга теләделәр, әмма Рудольф җан-фәрманга карыша башлады.»

1961 елның 16 июне — Рудольф Нуриев өчен тарихи көн, бөек сәнгатькә хәлиткеч адым. Көнбатыш матбугаты моны «Азатлыкка сикерү» дип бәяли, ә совет пропагандасы аңа «Ватанга хыянәт итү» дигән кара мөһер суга. Ленинград суды Рудольф Нуриевны 7 елга ирегеннән мәхрүм итү турында карар чыгара.

Соңгы мизгелдә, аэропорттан да көчләп алып киткән булырлар иде, ләкин француз полисмены нык тора:

— Варварлар илендә түгел, без — Франциядә, әфәнделәр,— ди.— Бездә кеше хокуклары белән санлашалар. Рудольф Нуриев гуманлы илдә калырга теләгән, без аның теләгенә каршы килә алмыйбыз.

Парижның кояшлы аэропортында ирекkә сусаган җан өчен барган тартышу КГБ председателе А. Шелепинның КПСС ҮКына юллаган язмасында болайрак чагыла: «Докладываю, что 16 июня 1961 года в Париже изменил Родине Нуреев Рудольф Хамитович, 1938 года рождения, татарин, беспартийный, артист балета Ленинградского театра им. Кирова, находившийся в составе гастрольной труппы во Франции...»

Шулай итеп, кесәсендә тиеннәре генә булган Рудольф Нуриев атаклы Париж шәһәренә язмышын куя. Егерме җиде ел буе аның исеме афишалардан төшмәс. Йөз елга бер генә туа торган могҗиза, «оча торган татар» «Елисей кырындагы театр»да осталыгын күрсәтә башлый. Совет илчелеге гебешникларының «сатлык җанны үтерү белән янаулары, вакытлы фатир, француз компартиясе боевиклары шаулашып спектакльне өзәргә тырышулары... Министр-язучы Мальроның Мәскәү белән араны бозасы килмәве, Президент де Голль әмере белән Нуриевне «Гранд-Опера»га алмаулары...

Әнә шулай итеп Аурупа талантны сындырып сыный.

Копенгагенга күчкән Рудольфка 1962 елда Лондонның король балетыннан чакыру килә. Бу атаклы коллективта Нуриев ун ел буе балерина Марго Фонтейн белән бии. 1971 елда бөек балерина сәхнәдән китә. Егерме елдан соң ул рактан үлә. Үләренә бер ай кала Нуриев Панамага килә. «Чын мәгънәсендә мин дүрт кешене яраттым, ди ул. Театр тәнкыйтьчесе Найджел Гослинг һәм аның хатыны балерина Мод Ллойдны. Биючеләр Эрик Брюн, Марго Фонтейнны».

**Рудольф Нуриевның Парижда чыккан китабыннан.**

***Эвакуация вакытында без урыс гаиләсе белән бер йортта яшәдек. Урыслар белән яшәдем диюем укучыда кайбер сораулар да уятырга мөмкин. Алдан ук аңлатып китим: без — Нуриевлар нәселе — татардан чыкканбыз. Минем әнием Казан дип аталган гаҗәеп матур, борынгы шәһәрдә туып үскән. Димәк, мин мөселман өммәтеннән булам. Мин үземнең татарлыгымны җаным-тәнем белән тоям. Безнең тамырларыбызда кан тизрәк ага дип әйтимме, кай ягыбыз беләндер без урыслардан аерылыбрак торабыз. Борынгы ата-бабаларыбыз күчмә кабиләләрдән булгангамы, әллә инде башка сәбәптән, татарларның холкы бөтенләй үзгә. Бер яктан, борынгы җайдаклар кебек кырыс халык, икенче яктан исә күңелебез артык нечкә. Мондый сыйфатларның кушылмасы урыс халкына бик ук хас түгел. Бәлки, алда әйтелгән сыйфатларга ия булганга күрәдер, мин үземдә Достоевский персонажлары белән рухи уртаклыкны тоям...***

* * *

Рудольф үсмер чагында Ленинградның А. Я. Ваганова исемендәге хореографик училищесына эләгә алмый, бу бәхеткә ул соңлап, унҗиде яшендә генә ирешә. Шуңа күрә ул әрәмгә үткән елларын кайтару өчен ашыга: күп укый, өйрәнә, кирәксез санаган лекцияләргә йөрми, тәвәккәлләп, Мәскәүнең Зур театрындагы балет дәресләренә барып кайткалый. Тумыштан бирелгән талант өстенә аяусыз хезмәт куюы үзенекен итә: Россиянең бөтен балет мәктәпләре конкурсында ул могҗиза күрсәтә, сәхнәдә давыл булып бөтерелә, бөркет булып оча, сәнгатьле биюнең сокландыргыч үрнәген күрсәтә. Шунда ук аңа мәртәбәле театрлардан чакыру килә. Мәскәүнең Зур театрын да кире кагып, ул Ленинградның Киров театрын сайлый һәм ялгышмый. «Зур театр, минемчә, артистларның тулысынча ачылу мөмкинлеген кыса,— дип яза ул.— Аларны рекордлар куя торган корыч мускуллы атлетларга әверелдереп, хезмәт итәргә алынган сәнгатькә карата тирән хисле мәхәббәтне үтерә, җансыз итә».

Ләкин совет чынбарлыгы һәркайда бердәй кануннардан тора. Киров театрында да ул үзенчә көн күрә, бәйсез рухына мәйдан эзли, чит ил сәнгатькярлары белән аралаша. Аның бу холкын, әлбәттә, хупламыйлар. Тәртә арасына керергә теләмәгән чыгымчы тайны ничек булса да тышауларга телиләр.

Еллар үткән саен мин гел бер сорауга әйләнеп кайтам: әгәр Рудольф Нуриев шул чакта Франциядә калмаган булса... Аның шанлы исемен бүген ишетер идек микән? Ул дөньяви биеклегенә ирешә алган булыр идеме? Ай-һай, көнләшү, аяк чалу, идеологик шик милли сыйфатка әверелгән җәмгыятьтә ерак бара алмаган булыр иде, бетерерләр иде егетне. Аның янәшәсендәге ун башка түбән берәүне күтәреп, әллә ничә лауреат итеп күккә чөярләр, үз вакыты җиткәч сабын куыгы сыман шартлап, юеше генә кала торган дан иясе итәрләр иде. Сәнгать дөньясының сәхнә артында аяусыз уен бара, чын шәхесләрне бөтереп алып, билгесезлек ярына ташлый торган гаделсез уен ул.

Париж биеклегеннән караганда бу ваклыклар артта кала. Алда көрәш, көрәш, көрәш. Аурупа да кочак җәеп каршыламый, аңа үзенең кодрәтеңне раслап күрсәтергә кирәк. Шунда гына ул зыялы реверанс ясаячак. Исән чакта тормышның бөтен мөмкинлекләреннән дә файдаланып калырга кирәк, дигән максат куйган Рудольф — «Чыңгыз хан токымы», даһи буларак, дөньяның иң затлы сәхнәләрендә фантастик сикереш ясый.

Голланд журналисты Хенк ван дер Мейденның Нуриев турында язган күзәтүләре кызыклы. Ул үз заманында Амстердамның «Милли балет»ында импрессарио булып эшли, төрле илләрдә Нуриев турнеларын оештыра.

«Гастрольләрдә янәшә яшәдек. Ул миндә кунакта еш була иде. Без әле ачуланышабыз, әле татулашабыз. Бер-беребезне каһәрләп бетерәбез. Аннары бергә утырып эчәбез.

Нуриев — кыргый? Нуриев белән аралашу мөмкин түгелме? Мин аны башкача дип беләм.

Бер кичтә без өчәү Франкфурт-на-Майненың интим ресторанында утырдык. Рудольф Мария Бове белән «Корсар»да па-де-де биеп чыккан иде. Төн урталары җиткән, ресторанда тик без генә идек. Нуриев бүре кебек ач, чөнки ул биер алдыннан бер тәгам дә ризык капмый иде. Антрекотны ул шундый ләззәтләнеп ашады, аннары сарык итеннән котлетлар китертте. Тарелкасын күтәреп, калган маен эчеп үк куйды да: «Татарлар шулай ярата»,— диде. Без ул көнне күп эчтек. Рудольф гәүдәне саклый дип аракыны су урынына чөмерде.

Ул кичтә аның кәефе бик шәп иде. Мария Бовеның һәртөрле шаяртуларыннан кызлар кебек чыркылдап көлде. Тормышта ул хатын-кыз

кебек йомшак иде. Сәхнәдә исә — Тарзан. Чын ир. Йомшак холыклы дисәң дә... кайчакларда ул «шартлый», өзгәләп ташлардай була, һәркемгә җикеренә, биючеләрне, музыкантларны пыр туздыра.

Ә бу кичтә ул шундый тыныч, үз-үзе булып калган иде. Ресторанның хуҗабикәсе: «Карап килим әле, кызым уянмады микән»,— дип икенче катка күтәрелә башлагач, Нуриев сагышлы елмаеп куйды. «Себердә мин апаларым белән мич башында йоклый идем. Без дә шулай баскычтан күтәрелә идек тә, бер-беребезгә сыенып җылына идек».

Мин шунда бер нәрсәгә төшендем: бу суперйолдыз тормышта бик тә ялгыз һәм үзенең беркемгә билгесез үткәнен ничекләр сагынадыр... Хәзер ул әнә һәр кичтә, нервылар киеренкелегеннән ычкыныр дәрәҗәгә җитеп, осталыгының иң югары үрнәген күрсәтергә тиеш.

Арганмы ул, авырыймы, йокысызлыктан иза чигәме — аңа һәрчак формада булу мәҗбүри. Чөнки ул — бөтендөнья улы.

Нуриев — супермен.

Дөнья йолдызы!

Ул шыгрым тулы заллар җыя. Үзенә табынган хатын-кызлар ыргыткан кулъяулык, перчатка ише әйберләрне кагып кына төшерә. Горур, тәкәббер идол, аның вәкарь белән мыскыллы елмаюы тамашачыны җүләрләндерә, Антик каһарман, илаһи гәүдә торышы, башның гаҗәеп ыспай куелышы, утлы күз карашы... Хатын-кызлар, экстазга бирелеп, һуштан язалар...

Андый чакта ул сагыштан бүре булып уларга әзер шикелле тоела иде. «Мин һәр көнне биергә тиеш!» дип, ул тормышын, үз-үзен яндырып бетерүгә корган иде. Бервакыт Брюссельдә шундый хәл булды. Нуриевның кыяфәте качкан. Температурасы бик югары, грипп. «Син иртәгә биергә уйлыйсыңмы?»— дип сорыйм. Җавап катгый: «Әйе!».

Поездда ул калтырый башлады, одеал бөркәнде, башына яулык бәйләгәч, карчыкларга охшап калды. Килеп җитеп, кунакханәгә урнашкач, үле кебек, тахтага ауды. Мин табиб чакыртырга уйладым. Нуриев мәсьәләне башкача хәл итте. «Биниячәкмен! Бельгиянең иң шәп массажистын чакырт!»

Кичен Нуриев сәхнәгә чыкты. Аның пары — «Гранд-Опера» биючесе Ноэль Понтуа ул көнне гомерендә дә онытмас. Беренче актта Нуриев Аполлон ролен башкарды. Икенче актта — па-де-де. Сәхнә артыннан күзәтәм, хәле начар моның, аягында чак басып тора. «Хәлең ничек?»— дип сорыйм антракт вакытында. «Җәһәннәмгә олак!»— дип кычкыра бу. Мин аңа, үзе яратканча, лимонлы чәй китерәм.

Па-де-де биегәндә Нуриев соңгы сулышларын ала сыман иде. Залдан сыек кына кул чабулар, пышылдаулар ишетелә. Ноэльгә аның өчен дә тырышырга туры килде. Зал балеринаны көчле алкышларга күмде. Нуриев моны сәхнә артыннан карап торды, күзләрендә ярсу ут кабынды.

Па-де-де соңында алар парлап чыктылар. Рудольф Ноэльне өскә чөйде дә... ул аны очышта тотып алырга тиеш иде. Ләкин Рудольф кулларын салындырды, Ноэль лапылдап идәнгә егылып төште. Зал «аһ» итеп куйды. Рәтләр арасыннан: «Юри шулай эшләде...»— дигән сүзләр узды. Ноэль исә берни булмагандай ахырга кадәр биеде. Зал аның көчле рухлы булуын бәяләп, көчле алкышларга күмде.

Пәрдә төшкәч, Ноэль, тез капкачын уа-уа, грим бүлмәсенә көчкә барып җитте: «Ни өчен алай эшли ул? Ни өчен мине ташлады? Бүтән беркайчан да аның белән биемим!».

Бер сәгатьләп вакыт үткәч, Нуриев грим бүлмәсенә килеп керде. Караңгы чырай белән каш астыннан карый: «Ишеттеңме, аны ничек

алкышладылар, ә?!»—дип кычкырды. Ул сабый бала кебек үпкәләгән иде. Чөнки аның моңа кадәр әле болай уңышсыз чыгыш ясаганы юк иде. Шул кичтә ул Ноэльдән гафу үтенде.

Нуриев хатын-кыз парларын махсус шулай кулыннан төшереп җибәрә, дигән фикер балет дөньясында нык тамыр җәйгән иде. Артистның уңышы, даны мәсьәләсендә ул башкаларны кичерми, бигрәк тә танылган балериналарны күрәлми иде. Әгәр инде узарга теләсәләр, ул ярсудан кайнап чыга иде.

«Оча торган татар!»

«Нуриев! Нуриев!!—дип үкерә тамаша заллары. Бию бетүгә, зал аягүрә басып, алкышлардан шартлый. Бары тик җиңәргә, җиңәргә омтылган гладиаторны Аурупа заллары әнә шулай алкышлый. Шундый уңышларга ирешмәсә, ул күптән үлгән булыр иде».

**Рудольф Нуриевның Парижда чыккан китабыннан.**

***Соңрак, гаиләбез Уфа шәһәренә күчеп килгәндә миңа биш яшь иде. Баштагы елларда без әтиемнең энесе фатирында яшәдек. Зурлыгы өчкә өч метр гына булган бер бүлмәле фатирда без ике гаилә сыешып, тату гына гомер сөрдек. Ул чакларда хәтеремә иң уелып калганы—өзелеп ашыйсы килү, көн белән бергә туган ачлык иде. Әнием без—дүрт баланы ачтан үтермәс өчен, өйдәге барлык әйберләрне дә сатарга мәҗбүр булды. Әтиемнең киемнәре, ястык-мендәрләр, урындыклар, тегү машинасы һәм шуның ише башка әйберләр базарга чыгарылды. Өйдә тик бер радиоалгыч кына сатылмыйча калды. Аннан еш кына музыка тапшыралар, без исә музыкасыз яшәүне күз алдына да китерә алмый идек.***

***Радио миңа серле зур дөньяга чыгу өчен тылсымлы тәрәзә кебек иде. Музыка тәэсиренә бирелеп мин авыр тормышыбыздан онытылып ала идем. Күңелем хыял белән тула, әллә нинди ераклыклар балачак томаны артыннан үзенә чакырып, мине татлы рәхәтлектә адаштыра иде. Музыканы артык бирелеп ярату минем биюгә булган һәвәслегемә дә тәэсир иткәндер. Биюгә гашыйк иткән иң беренче кеше—Роза атлы апама мин гомерем буе рәхмәтлемен. Шул ярлы гына өйдә башланган бию зәхмәте, мине бөтереп алып әллә кайларга алып китәр, дип кем уйлаган ул чагында. Шулай итеп, балет сәнгате минем гомер юлымда котелмәгән борылышлар ясаган язмышыма, тормыш мәгънәсенә әйләнде.***

«Миңа аның Лондондагы викториан стилендә төзелгән галәмәт зур йортында булырга туры килде. Без XVII гасырның гаҗәеп өстәле артында төшке ашны ашадык. Бу өстәл тирәли утызлап кеше утырып булыр иде. «Мин монда гел ялгызым булам»,—диде Нуриев. Бөек артист байлык, затлылык, гүзәл кызлар, көнчел дус-ишләре чолганышында яшәсә дә, барыбер гадилеккә омтыла иде. Минем шәһәр читендәге йортта, тар солдат караватында еш кына кунып калгалый иде,»—дип яза Пьер Лакотт.

Бер якта—талантның кабатланмас бәхете: континентлар, зур залларның күкрәүле алкышы, бер гомердә сирәк була торган очыш-бөеклек. Икенче якта—шәхеснең дөнья белән бергә-бер калган сагышлы ялгызлыгы...

Ничә еллар буена ул әнкәсе, туганнары белән күрешә алмый. Хатлар язып карый—җавап килми. «Сәнгать кешесе кайда тели—шунда яшәргә тиеш, мин сәясәткә катышмыйм»—дип, ул төрле илләрнең матбугат битләрендә чыгышлар ясый. Аның искиткеч биюен президентлар, корольләр карагандыр. Аны затлы сарайлар кабул итеп, аллалар ризыгы белән сыйлаганнардыр. Әммә дөньяның фани байлыгы сагыну хисен баса аламыни! Әнисе белән күрештерүне үтенеп, ул СССР җитәкчеләренә мөрәҗәгать итә. Ләкин юкка, аның бәгырь авазы Кремльнең канны күп күргән калын диварларына бәрелеп челпәрәмә килә. Дәрәҗәле илләрнең президентлары аның үтенече буенча Мәскәү түрәләренә чыгалар. Ниһаять, 1988 елда гына аңа 72 сәгатькә туган иленә кайтып килергә рөхсәт итәләр.

«Хыянәтче» улы өчен күпме йокысыз төннәр кичергән, таныш-белешләренең астыртын хөкеменә дучар ителгән булган, махсус органнар тарафыннан туктаусыз эзәрлекләнгән Фәридә ханым бу еллар эчендә тән һәм җан сәламәтлеген җуйган була инде. Авыру ана улын күрә дә, күрми дә... «Әни мине танымады...» Бу — Рудольф Нуриевның әрнүле бәгырь тавышы.

Уфада аңа бирелгән сәгатьләр йөрәк тибешеннән тизрәк үтеп бара. Хыялында малай чагына кайта-кайта ул беренче тапкыр бию сәнгатенең әлифбасын өйрәнгән хореографик училищега ашыга. Менә таныш бина, таныш тәрәзәләр. Аны хәтерләгән укытучылар исәннәр микән? Кайчандыр шушы стеналар эчендә тагылган «Үҗәт татар малае»на әверелеп, ул бусагадан эчкә үтә алмый. Алдан әзерләнгән, идеология сөреме күзләренә чыккан укытучылар аны ишектән үткәрмиләр. Малайчак дөньясы үкенечле кара пәрдә артында кала...

Илледән узгач кешедә кан кычкыруы, җирсү башлана, хис һәм акылы тәңгәл килгәннәр милли тамырларын эзләп, үз халкына кайтып төшәләр. Фантастик байлык һәм дан биеклегеннән торып, үзен дөнья улы дип санаган, күпме илләр кочагын җәеп каршы алган Нуриевның мондый тойгыларга күнеле саңгырау калырга да бик мөмкин иде. Ләкин аның дөньялыкта бирелгән ганимәтләр астында саф татарлыгы бөтенләй йомылып бетмәгән иде. Туксанынчы еллар башында аның Казанга тартылуы да юкка булмагандыр. Бу чорда инде ул биюче буларак балеттан китү алдында тора, әмма калган гомерен сәнгатьтән башка күз алдына китерә алмый иде. Шуңа күрә ул Нью-Йоркта дирижерлык курсларын бетерә. «Голгофага өч юл белән»,— ди ул, үзенең биюен, хореография, дирижерлык сәнгатен күздә тотып. Укуын ул Вена филармония оркестрының баш дирижеры Вильгельм Хюбнер кул астында дәвам итә. Венаның Ауэрспарг сараенда беренче мәртәбә пульт артына баса. Ул дирижерлык иткән оркестр Чайковский, Стравинский, Гайдн, Моцарт көйләрен башкара.

Рудольф Нуриев Ауропада иҗат иткән ике дистәдән артык ел эчендә әкияти байлыкка ирешә. Кариб диңгезендә Сен-Бартелеми, Урта диңгездә Ли-Галли утраулары, Париж, Нью-Йоркта фатирлар, Лондонда — йорт, Монте-Карлода ранчо-виллалар, Пенсильвания штатында ранчо, бер-берсе миллион долларлар торган картиналар, затлы җиһазлар... Аның америкалы адвокаты белдерүенчә, 1975 елда Рудольф Нуриев васыять төзи. Алты ышанычлысы идарә итәргә тиешле мирас ике фондка бүленә. Берсе — Лихтенштейн башкаласы Вадуцта, Монакога күчеп килгән апасы Розаны, Казандагы Резедәне һәм аларның балаларын тәэмин итәргә тиеш була. Икенчесе АКШта — Россиянең яшь балет биючеләрен Америка һәм Ауропа балеты казанышлары белән таныштыру өчен файдаланырга тиешле була...

Ауропа талантны бәяли белә. Әмма «Минем яшәү урыны — сәхнә» дияргә яраткан Рудольфның бу байлыклар белән хозурланырга вакыты калмый. Ул бөтен гомерен сәнгатькә багышлый.

Менә шушындый һәрьяклы әзерлекле сәнгать әһле әнисенең туган шәһәренә иҗади хыяллар белән кайтып төшә. Ләкин татар оркестрын һәм балетын дөньяга алып чыгарга сәләтле шәхесне Казан шаулатып каршы ала белмәде. Ныклап эшкә керешкәнче, бәлки, ул үзе дә реклама теләмәгәндер. Әллә соң яраннары да Нуриевның үз халкының улы булып танылуыннан курыктылармы? Бүгенге көндә бөек артистның мирасы аукционнарда коточкыч суммаларда сатылган чакта моңа беркемнең дә каршы килә алмавын күреп җан әрни, шөбһәле уйлар башка килә... Димәк, күп нәрсә алдан уйланылган, хәл ителгән. Алкышлар белән күккә чөелгән Нуриев — бөек, даһи, әмма кемнәрдер кулында — кол...

Илле дүрт яшьлек Рудольфка тәңре тагын бер дистә ел гына өстәгән булса да аның киләчәк язмышы үз халкы белән үрелеп китәр, «төп йорты» да чит кавем арасында, Париж читендәге Сент-Женьев-де-Буа каберлегендә булмас иде...

* * *

Мөмкинлек кенә алсын татар... Кодрәтлеләр ярып чыга да үзен дөнья каршында раслый, тантана итә. Узган гасырлардан ук шулай килә. Урыска кучкән морзалар арасыннан галимголямә, әдәбият-сәнгать әһелләре генә түгел, тәхет тоткан патшаларга кадәр бар. Шушы көчле дулкын астында күмелеп калмас өчен Россиядә яңа идеология кирәк булган. Бер яктан, татарның үткәнен кимсетеп, аның рухын сындыру, икенче яктан «татар золымы»н уйлап чыгарып, аны гаепле итү, үзенең яулап алу, тәре походларын аклап, игътибарны читкә юнәтү. Татарны белемгә якын җибәрергә ярамый, безгә мәхлук, сугышчы янсә эш аты татары кулайрак, дигәннәр патша сатраплары. Һәм шушы сәясәтне гасырлар буе уңышлы рәвештә алга сөргәннәр. Тарихны яшерә алмыйсың. Кайсы халыкка кодрәт өстәп, күпме микъдарда кан биргәнбез — без моны белеп торырга тиешбез. Ул кан тамчылары безнең йөрәкләрдә сулкылдап яна...

Күр инде... Билгеле бер кавем үзенеке генә итеп урап алган элитар сәнгать төренә ни булды соң әле? Парижның балет театрын Рудольф Нуриев җитәкли. Ла-Манш аша кул гына суз — Лондонның король театрында Казан егете Ирек Мөхәммәдев дан казана. Моңарчы күрелмәгән модерн-биюләр салган Лилия Сабитова Берлинда балет спектакльләре куеп кайта. Гаҗәп бит, иң нәфис сәнгать төрендә, Ауропаның мәртәбәле өч иле балетында «кыргый татарлар» хакимлек итә!

Рудольф Нуриев Ауропа балетына моңарчы берәүнең дә хыялына кермәгән яңалык китерә. Ул ир-егет ролен калку итеп алгы планга чыгара. Шуның белән балет сәнгатендә яңа мәктәп тудыра. Дөньяви дан... шөһрәт... моны иңендә күтәрә алу өчен дә әзерлек, нуриевча холык-фигыльгә ирешү кирәктер. Бервакыт, төп рольне биегәннән соң Парижның югары зәвыклы тамашачылары, аягүрә басып, Рудольф Нуриевне ярты сәгать буе алкышлап торалар. XX гасырда тагын кемгә тигән мондый бәхет! Бу вакыйга Гиннесснын рекордлар китабына кертелә.

Сәхнәдә ул — сокландыгыч, бәхетле. Пәрдә ябылуга исә хәлсез гәүдәсен кая куярга белми. Хәтәр авыру аны эчтән тарката бара. Сүнә баруын тоя, әмма бирешергә теләми. «Шәп бит дөньяда яшәү!» — дип үз-үзен юата, иҗатында фидакарьләрчә янып, авыруын җиңәргә тели. Бәлки таланты хакына Тәңре мәрхәмәт күрсәтер, могҗиза булып, савыгып китәрмен дип тә үз-үзен ышандыргандыр. СПИД вирусын ул тәнендә 13—14 ел йөртә. Шәхси табибы Мишель Канези аның көчле рухына, үз-үзен аямавына шакката.

1992 елның 8 октябре, Парижның «Гранд-Опера» сәхнәсендә «Баядерка» премьерасы бара. Бу спектакльне куярга Рудольф Нуриевка Россиядән Нинель Курганкина да килеп ярдәм иткән була. Нәкъ 31 ел элек шушы сәхнәдә яшь Рудольф — «Оча торган татар» Ауропаның сәнгать күгендә йолдыз булып кабынган иде бит. Ә бүген аның шәүләсе генә калган... Нуриевны тәхеткә утыртып сәхнәгә алып чыгалар. Парижлылар сизенәләр — бу инде бәхилләшү... Сүнеп барган йолдыз нуры күзләрендә яшь булып ялтырый. XX гасырның атаклы биючесе һәм хореографы 1993 елның 6 гыйнварында Сена елгасы буенда, Лувр каршындагы зиннәтле фатирында дөнья куяр.

Ә бүген... Сәхнәдә ул тагын бер мизгелгә онытылып, алкышлар яңгырыныннан ләззәт ала. Франциянең мәдәният министры Жак Ланг аңа Почетлы легион командоры дигән бүләк тапшыра. Сулышын тыеп, тын калган залга Нуриев болай дип кычкыра:

— Ye su is enkore vivat! (Мин яшим әле!)

«Үз халкым булганда...» — дип өстәр өчен аңа берничә ел җитми калды.

## Ике урман чигендә...

*Хыялы тарихның нәкъеше улды,*
*Сүзе — дилдә, хыялы күздә калды.*
Г. Кандалый

Төнге дала... Караеп күренгән балбалның мең еллар буена җил-су-кояш ашаган таш чыраен учак шәүләсе ялмап-ялмап ала. Якында гына тышаулы атлар пошкыра. Учак тирәли яугирләр тезелеп яткан. Садакларында — уклар, кыныларында үткен кылычлар черем итә. Бары тик сакчы гына керфек какмый, учакка кизәк өсти-өсти үзалдына моңланып утыра. Бераздан ул да, япан дала күкрәгеннән сирпелгән әрем исеннән изрәп, калгып китә. Ә офык артында — бөек Урда йорты, олуг ханның Алтын таш сарае. «Уяу бул! Уяу бул!» — дип пышылдый күпне күргән балбал. Аның сагаюы учак ялкынына күчә. Үрсәләнгән ялкын — учакның сары җаны...

Сарыҗан... Сарьян... Борынгыдан килгән әнә нинди мәгънәле исем кушканнар икән аңа. Сәер дә, серле дә. Бер ишетүдә хәтергә уелып та кала. Әдәбиятта үз тәхетен тоткан проза остасы Хәсән Сарьян тормышта да, исеменә хас булганча, үзенчәлекле шәхес иде. Мин аны беренче күрүдә ошатып та бетермәдем шикелле. Кырыс күренә. Төмсәрәк чырай. Аз сүзле. Кара кысалы калын күзлек, кара чәч, үҗәт кысылган иреннәр, каш арасыннан маңгайга таба үрләгән таләпчән ике җыерчыкны да өстәгәч, тиз генә якын мөгаләмәгә кереп китәрдәй, күңел капкалары шар ачып ташланган беркатлы шәхес дип уйламыйсың аны. Тавышы нечкә дә, калын да түгел. Музыка белгечләре аны нинди тембрга да кертергә белмичә аптырарлар иде.

Нәзберек гөл шытымын иң нечкә тамырларына кадәр имгәтмичә казып алган кебек, һәр сүзне ул кадерләп, күкрәк эченнән ала, җеген-җеккә китереп, ашыкмыйча әйтә, нәкъ язуындагы кебек, тулы җөмлә белән сөйли. Тавышыннан талгын җил канатыннан саркып киткән әрем тәме килә төсле...

Гадәттә, роман-повестьлар укыганда аны язган әдипнең йөз-кыяфәтен үзеңчә күз алдыңа китерәсең. Китап битендәге вакыйгалар аша хәтта тавышына кадәр ишеткәндәй буласың. Ә инде үзе белән чынбарлыкта күреп танышкач, күңелеңдә яралган сурәттән шактый аермалык күреп нәүмизләнәсең. Бары тик ныклап аралаша башлагач кына бу аерма бетә, килешәсең, күнегәсең.

Хәсән Сарьянның бикле күңел дөньясын аз гына булса да ачып карау, аңлау өчен шактый аралашырга, төнге Казан урамнарын бергә гизәргә, озын юлларга чыгарга, иҗади бәхәсләр белән шаулы яшәп алырга кирәк иде әле.

Бервакыт Лаеш районына чыгып киттек. Өчәү идек: арабызда иң өлкән икәнен тамак кырып куюы белән искәрткәләгән Сарьян абый, шәһәр ераклашкан саен мәҗүси елмаюы күзләренә күчә барган шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов һәм исеме халыкка билгеле шәхесләр эргәсендә берничә көн яшәп алуны бәхеткә санаган мин фәкыйрь.

Атабай, Сараландагы көннәр аеруча истә калган. Яшьтәшләр булярак, авыл советы рәисе Вазыйх абзый белән Сарьян шунда ук уртак тел таптылар. Тормыштагы кызыкларны күрә белүче, фикерле, иҗади күңелле иде рәис. Рәхәтләнеп, чишелеп бер сөйләшеп утырырга бик тә сусаган булгандыр ул. Зур көймә белән табигать хозурына чыккач, шәһәрнең таш киеменнән котылган Хәсән Сарьян да иркенәеп, берьюлы ачылып китте. Мин ул чакта океан-диңгезләр күрмәгән әле, Кама белән Идел кушылган урында, аргы яры зәңгәр томаннар артында югалган чиксез киңлекне акылыма сыйдыра алмыйча хәйран калып йөрим. Көчле дулкыннар тетрәткән яр гүя Идел-йорт сыйган материкның иң кырый ноктасы. Каршыда — чиксезлек... Ә табын янында Вазыйх абзый белән Сарьян авызга-авыз. Әңгәмә арасында бүленеп Хәсән Сарьян кызыклы санаган сүзләрне блокнотына төшереп бара. Шунысы гаҗәп: рәсми кәгазьме, кулъязмамы — нинди генә булмасын, ул искиткеч төгәл, камил итеп, баш хәрефләрнең койрыкларын купшы бөтереп, иренмичә, күзне иркәләрлек итеп яза. Үземнең исә җомга көнне язган хәрефләр шимбәнекенә бөтенләй тәңгәл килмәскә мөмкин. Кәефкә карап үзгәрмәгән язу рәвеше холык ныклыгын белдерәдер, мөгаен.

Вазыйх абзый ул көнне өенә кайтып тормады, безнең белән бергә кунакханәдә калды. Төне буе сөйләшеп чыктык. Икенче көнне дә ул очрашу оештырды. Ләкин ни хәл итәсең, барыбер, Сараланнан китәр көн җитте. Саубуллашкан чакта рәиснең күзендә ирләрчә яшь күренде.

— Шагыйрь булып тугансың син...— дип Сарьян да, аерылышасы килмичә аның кулын кысып торды.

Клублар шыгрым тулы була иде ул елларда. Кичәне Хәсән Сарьян ачып җибәрә (тел ачкычы өчен дип, сәхнәгә чыгар алдыннан бер стакан тулар-тулмас акны салып куя, монысын инде алдан хәстәрләп торабыз). Әдәбиятның үткәнен-бүгенгесен тәфсилләп, үтемле итеп сөйләп, халыкны әзерләп бетергәч, безгә чират җитә.

Иң соңыннан Мөдәррис Әгъләмов чыгып, трибунага олпатларча таяна. Трибуна аның Тукай буйлык гәүдәсенә чамалап эшләнмәгән, бераз биегрәк. Залдан караганда калкып торган ике терсәк арасына чумган ялтыр пеләше генә күренәдер. Ә кырыйдан аның кыяфәте — Чили шагыйре Пабло Неруданың бераз кечерәйтелгән рәвешен хәтерләтә. Җиңел-ябык гәүдәдән борынгы шагыйрьләрдән килгән кодрәтле тавыш ургылып чыгуга, сүз хасиятеннән зал сыгылып, сулышын тыя.

Сөембикә кебек гүзәл хатын
Кыйссаларга кереп калырлык.
Авылыңда шундый чибәр барда
Ирләреңә бирсен сабырлык!

Мишәр карчыгы «Канәт әби...»не сөйләгәндә өлкәннәр күзендә яшь күренә. Сарьян абыйны күзәтәм: Мөдәррисне ул һәрчак, беренче тапкыр күргән кебек, бирелеп тыңлый.

Болгавыр тормышта гөнаһсыз гына алдашырга, уйнарга яратса да Мөдәррис иҗатында бакый сүз изгелегенә хыянәт итми, җанын актарып ташлап яза. Юк, язмый... әзер шигырьне фәрештәләр кулыннан үрелеп кенә ала сыман.

Атабай тугайлары бүгенгедәй күз алында. Сентябрь җиле... Чалып аяктан егарга теләгәндәй дулкыннар ярга сикерә. Кодрәтле су шавын тыңлап, Мөдәррис Әгъләмов белән яр буенда йөрибез. Без яшь әле, утызга да җитмәгән. Тукай яшеме? Анысы Ходай тәгалә тарафыннан иңдерелгән бәхетле ялгыш. Егерме җидедә бөеклеккә ирешү бүтән кабатланмаячак...

Мөдәррис Кандалыйлардан, Бабичтан шигырь юллары китерә. Кол Гали, Хафизларны искә ала. Минем Гарсия Лоркалар, Евтушенколар

белән женләнгән чак. Каян соң әле бу сандык төбеннән «нафталинлы шигырьләр» тартып чыгара, архаизм, дип Мөдәрристә эчтән көлебрәк карап куям. Ә ул шигъриятенә керәкле көй, сулыш, сүз егәренең асыл микъдарын Шәрыкъның дастани тирән тамырларыннан алырга икәнен үз акыл-зиһене белән шул чакта ук төшенгән булган каһәр! Бисмилласыз чорда яшәү рәвешең рәтле күренмәскә дә мөмкин. Әмма уй-гамь олпатлыгы аңа тумыштан бирелгән: иң мөһиме — эчке дөньяң шигъри догадан тукылган ак намазлыклы булсын...

Атабай тугайлары... Җете зәңгәр сентябрь күге... Учак-табын янына түгәрәкләнәбез. Хәсән Сарьян, хискә бирелеп, Вазыйх абзыйның иңеннән кагып-кагып ала:

— Шагыйрь син, билләһи! Шагыйрь! Киттек безнең белән Казанга.

Вазыйх абзый көлә, үрелеп ярга таба карап-карап ала. Анда биниһая зур көймәсен аның дулкыннар чылбырыннан өзеп алып китәргә теләп кыйный-йолка-чайкалдыра.

Шуннан соң ун еллап вакыт үтте микән, бер көнне редакция коридорында мине бер кыз туктатты (йөз-кыяфәте, керфекләренә кадәр «илһам колы» икәне сизелеп тора):

— Сез безнең авылга — Сараланга килгән елны миңа сигез яшь иде. Сезне кунак иткән Вазыйх — минем әтием иде,— диде.

— Шулаймыни! Сарьян абый әтиеңне чак шагыйрь итми калды ул чакта,— дим, көлеп.

— Әти язмады инде. Үз урынына мине җибәрде Казанга,— диде эчкерсез елмаеп, университет студенты, зәңгәр күзле кыз.

Саралан кызы — Илсөяр Иксанова, берничә елдан, татарның кабатланмас шагыйрьләре йолдызлыгына үз моңы белән кушылыр.

* * *

Киченәләр үткәреп Мари ягында, Бәрәңге районында йөрибез. Халкыбызның мең еллык әдәбият тарихын кыска, үтемле итеп сөйләп чыккан Хәсән Сарьянның тоныкк тавышын еллар аша аермачык ишетәм. Кәефе килгәндә ул төрек акценты белән сөйли башлый, аннары, «онытылып китеп» бөтенләй төрекчәгә күчә торган иде. Кызганыч, ул елларда аңа иптәш кеше арабызда юк, «төрек» дигән сүзне дә сагаеп, як-якка каранып кына әйтә торган идек. Үзе әйтүенчә, төрекчәгә аны балачакта әнисе өйрәткән булган. Җитмешенче елларда шушы телдә бер иркенләп сөйләшеп, үзен сынап карау өчен аңа турист буларак Төркиягә бару бәхете дә тәтегән иде.

Мәктәп укучылары каршында да ул төрекчә шигырьне укымыйча калмый иде:

> Йолк-йолукъ юрелер шаирләр,
> Багъырлар йылдызлара...

Менә ул Төркиядә балаларның бик ярлы шартларда, интегеп яшәүләре, бәләкәйдән үк авыр эшкә дучар ителүләре хакында сеңдереп сөйли. Укучылар аның авызына карап сулышсыз калганнар. Төрекнең бәхетсез балаларын җәлләп күңелләре тулган, кайсылары менә-менә җылап җибәрерләр шикелле.

Без, Рәдиф Гаташ белән, пәрдә артына чыгып китәбез, арттыра бу! дип, түзә алмыйча авызны тотып кына көлешәбез.

Үземнең башлангыч мәктәптә укыган елларымны искә төшерәм. Капиталистик илләрдәге хәерчелек, балаларның рәтсез тормышы хакында сөйләгәндә «нигә безнең якка чыкмыйлар икән ул бәхетсез балалар?» дип аптырап уйлана идем. Чик буеннан сәләмә киемле төркем-төркем балаларның безнең илгә таба агылуы күз алдыма килә иде. Үзем чит ил балаларын кызганган булам, ә үземнең бозда шуарга юньле тимераягым

юк, китаплар салырга рәтле сумкам юк, тагын әлләниләр юк. Юклыгын-ны онытып, иң бәхетле илдә яшибез, дигән сөенү генә бар...

Укучылар белән очрашудан соң, Рәдиф Гаташ:

— Алай ук түгелдер инде, Сарьян абый, бигрәк бетереп ташладың Төркияне?! — диде. Сарьян абый бер сүз дә дәшмәде, борын эченнән «кыңг» итеп, күзлек кысасын төзәтә-төзәтә, арлы-бирле йөренде дә, бераздан соң гына:

— Төркияне барып бер күргән кеше икенче тапкыр бармыйча түзә алмый. Дөресен сөйләсәм, юлымны ябам бит...— диде.— Төрки халык-лар арасында бердәнбер бәйсез ил бит ул,— дип әллә ниләр сөйләргә җыенган сыман булды да, кәефсезләнеп, туктап калды. Күңелендәген ачып салмыйча, вакытында тыела белү утызынчы елларда туып үскән-нәргә гомумән хас сыйфат шикелле тоела миңа.

Уйлаганбызмыни... Төркиянең Измир, Конья, Анкара, Истанбул ке-бек калаларын тамаша кылып йөрербез дә (1985 ел), Рәдиф Гаташ белән шунда Хәсән Сарьянны еш кына искә алырбыз дип кем уйлаган... Төрки-янең көнкүрешендә, архитектурасында гасыр-дәверләр чиратлаша. Йөз-ләрчә манаралардан иртәнге-кичке азан — ислам моңы яңгырап шәһәр-ләр өстенә изге нур сибә. Кая барсаң да бер тел — төрек теле... Чибәр, горур халык. Яшь егетләр «Мин төрек!» дип күкрәк кагып торалар. Үз дәүләте булган халыкның күз карашы, гәүдә тотышы, буй-сыны, рухы башка икән шул. Кызыгасың, көнләшәсең, чагыштырып карыйсың да... үз халкыңның язмышын уйлап, эчтән әрнеп, өметсезләнергә генә кала.

Ә теге чакта Сарьян күргән малайлар киләчәктә бизнес эше ачарга дип Алманиядә акча туплыйлардыр. Кая карама төрек малайлары сату итә, туфли чистарта, фаэтоннарга утыртып туристларны йөртә. Телләре дә, куллары да уйнап тора. Француз белән французча, инглиз белән инглизчә, алман белән алманча теттереп сөйләшәләр. Бәләкәйдән үк кыюлыкка, телгә, эшләп алган акчаның тәмен белергә өйрәнеп үсәләр ич төрекнең күмер күзле малайлары!

Хәсән Сарьян үзе дә боларның эшчәнлегенә сокланып йөргәндер. Ул таза, нык гаиләдә, бәләкәйдән үк һөнәргә өйрәнеп үскән. Уфа татар-ларының матур табигатьле Илеш төбәген ул еш сагына, җае чыкканда кайтып килергә тырыша иде. Туган йортының фотосын да күрсәткәне бар. Фронтоннары агачтан чигеп эшләнгән, мансардалы байлар йорты булып истә калган. Хәсән Сарьян әле Уфа университетында укытып, башлап язучы булып йөргән чакта Мостай Кәрим:

— Октябрь революциясе булмаса, без язучы түгел, ә Сарьянда батрак буласы идек,— дип юкка гына шаяртып әйтмәгәндер.

Кай арада еракка кителде, вакыйга Бәрәңге районының шыңгырдап торган нарат клубында бара иде бит әле. Хәсән Сарьянга куппылык, купайту хас түгел, гадел итеп, саран гына мактап безне халыкка тәкъдим итә. Иң соңыннан сәхнәгә Рәдиф Гаташ чыга. Аудиторияләрне күп күргән, тәҗрибәле, сүз куәсен чамалый белгән шагыйрь. Аның һәрчак кулланып, тамашачының күңелен ача торган серле ачкычы бар:

— Иптәшләр, мин сүземне су эчүдән башлыйм әле! — дип ул стаканга тотына, бер йотым гына уртлап куя. Шул мәлдә залдан җиңелчә көлү дулкыны уза, ике арада якынлык урнаша. Гаташ, башын чөеп, көр тавыш белән «Ирләр булыйк!»ны сөйли башлый. Озын кулын нәзакатьле сузган, әйтерсең лә учына көзге яшереп, шуңа карап укый.

Кичәләр шулай бер җай гына бара иде, өченчеме көнне нәтабигый хәл булды. Хәсән Сарьян, гадәтенчә, беренче булып трибуна артына чыкты да:

— Иптәшләр, мин сүземне су эчүдән башлыйм әле...— дип бер тын калып, күз кырыен гына Гаташка төшереп алды. Рәдиф Гаташ коелып төште, ризасызлык шәүләсе күзлек пыялаларына кадәр җәелде. Үз чираты җиткәч, ул трибуна янына авыр сулап килде дә, ачкычын югалтып, бикле ишек катында чарасыз калган шикелле бераз таптанып торды, аннары элеккеге кыюлыгын җуйган тавыш белән шигырьләрен сөйләүгә күчте.

Соңыннан инде, әлбәттә, аңлашу булды.

— Ул бит минем табыш, мин аны ничә еллар инде дога кебек кулланам,— дип, Гаташ Хәсән Сарьянның әле уң ягына, әле сул ягына чыгып, кулын селки-селки аңлата. Сирәк шаярта торган Сарьян канәгать калып көлә. «Сине сынап карамакчы идем...» — ди. Дусларча үпкәләшүнең соңы тирәнгә китә димени, айлы төн безне үз кочагына ала.

Бәрәңге поселогы да, Йошкар-Ола кибетләре дә гаҗәп бай, киемсалым дисеңме, башкасымы — хәтта лимонга кадәр сатуда бар (1978 ел бит бу!). Бер кибеттә без «Казан хәерчеләрен» сатучы ханым: «Әллә артислар килгән инде?..» — дип ягымлы елмаеп каршы алды. Төрле тәм-томнар арасында күзне кызыктырган цейлон чәенең бер кулга икешәр генә кап бирелүен белеп алгач мин, бөтен сәләтемне эшкә җигеп, сатучы ханымны авызыма караттым. Казаннан зур концерт әзерләп киләчәкбез, иң шәп урынга билет сезгә, имеш. Ниһаять, минем тел юмартлыгы өчебезгә дә унар кап чәй белән бәһаләнде.

Урамга чыккач, Хәсән Сарьян мине мактап бетерә алмады: — Күз алдында бер башка үсеп киттең. Синең белән юлга чыгарга була икән!..

— Шәп! Чәй хакына гөнаһсыз алдашырга ярый,— диде Рәдиф Гаташ.

Шулай кәефле сөйләшә-көлешә якындагы ипи магазинына килеп кердек. Кердек тә, бер-беребезгә карашып, аптырап калдык. Бер кырыйда зур-зур тартмаларда чүмәләмә өелгән цейлон чәе тора, бу кадәрле байлыкны минем гомеремдә дә күргәнем юк иде. Сатучы белән безнең арада шундый сөйләшү булып алды: «Бу чәйләр сатыламы?» «Күргәзмәгә куймаган идек, абый җаннарым, сатарга дип куйдык...» «Ничә кап алырга мөмкин?» «Кесәгезгә карап инде, хет яшниге белән алып китегез, абый җаннарым...»

Минем шунда ук кикрик шиңде, базарым төште. Юлдашларым миннән көләргә тотындылар. Боларга кушылып, үз-үземнән көлеп кенә мин хәлемне җиңеләйтә ала идем.

Көлүне читкә куеп, җитдирәк уйлансаң сәер чынбарлык ачыла: безнең республика миллионнарча тонна нефть озата, иген кырларын таптап зур-зур заводлар кора, ә кибетләрдә фәкыйрь җил уйный. Бәрәңге иккән мари ягында исә шартлар башка... Мәскәүчә тәэмин ителгән кибетләрдә — апельсин-лимон, һинд чәе. Татар, бичара, җелеген суырган саен дәртләнебрәк эшли, үзеннән көлгән саен сөенебрәк югарыга рапорт бирә. Бу турыда ачынып сөйләшүдән ары китә алмый идек шул без ул чакларда.

Ә шулай да... Калын мари урманнары белән уратып алынган татар төбәген яраттык без. Ул карлы кичләрнең кәгазьгә сыя алмаган күпме хатирәләре кем белән дә бүлешеп булмый торган сагынуга әйләнеп калгандыр... Без китәсе көнне эре-эре кар ява иде. Йошкар-Ола автобусына кереп утырдык. Күңелдә ниндидер моңсулык. Күперенке башлык кигән чибәр-чибәр кызлар тәрәзә янынннан үтеп-сүтеп тора. Их, кичә кайларда идегез микән сез, чибәркәйләр?.. Ирексездән шушындый юллар хәтергә төште:

Салмак кына йөзеп калды
без тотмаган балыклар...

Үз эченә йомылып, төксе генә утырган Хәсән Сарьян кинәт башын күтәрде дә:

— Шәп сүзләр! Шигырь ич бу! — диде.

Энциклопедик хәтерле Рәдиф Гаташ шунда ук бу юлларның Роберт Әхмәтҗанов шигыреннән икәнен әйтеп бирде. Шигъриятне ярата иде Хәсән Сарьян. Бервакыт Казаннан «Елочка» (хәзерге «Банк-клуб») кафесында кәеф-сафа корып утырабыз. Арада — Ерак Көнчыгыштан хәрби хезмәт срогын тутырып кайткан яшь офицер — Зиннур Мансуров та бар. Аның яшь шагыйрь икәнен дә белгәч, Хәсән Сарьян: «Син мени инде ул

ана турында тетрәндергеч шигырь язган Мансуров?..» — дип, аның «Казан утлары»нда чыккан циклыннан шундый юлларын хәтергә төшерде:

Ник ашыктың, әни,
туй күлмәгең
син иkенче тапкыр киярга?
«...Туй күлмәгем белән...
җир асты да
якты нурлы булсын...» — диярга.

Лейтенант-шагыйрьнең үз авызыннан кабат-кабат сөйләтеп ул шушы шигырь моңында хозурланып утырган иде ул көнне.

Әдәби бәхәсләр вакытында масаебрак киткән без яшьләрне Хәсән Сарьян: «Галимҗан Ибраһимовны узуы җиңел, тик аны башта куып җитәргә кирәк әле...» — дип оялтып куя иде. Телгә аерата сизгер, аз гына төгәлсезлектән дә рәнҗи торган әдипнең беренче проза китабыма әчке рецензия язарга алынуы минем өчен бәхет иде. Шул кульязмамны алырга дип мин аның дачасына бардым. Төп сүзгә керешкәнче ул кыл кебек бер эздән чигелгән кадак башларына кадәр күрсәтеп, үзе төзегән йортны үтә бер тәм-ләззәт белән аңлатып, таныштырып йөрде. Агач эшенә дә оста икәнен мин аның «Әткәм һөнәре» повестыннан укып та, болай ишетеп тә белә идем. Сарьян абый өчен монда иң яраткан урын — бакчаның өй каршындагы почмагы иде, ахрысы. Инглизләр тигәллеге белән кырт кисеп калдырылган кыргый үләнлек, кырыйда мәһабәт имән үсеп утыра. Берәү булса, күләгә төшерә дип, имәнне кисеп, төбе-тамыры белән каерып алып анда җиләк-җимеш утыртыр иде.

— Дача җире алу белән күпләр кисеп ташладылар,— диде ул.— Сал аягыңны! — дип, үзе дә чишенеп, үлән өстенә җәелеп утырды. Имән күләгәсе төшкән бу нәни генә оазиста һәр үлән санаулы, һәр чәчәк үзенчә матур-кадерле иде.

— Печәнен, курпысын чабып торам,— диде Хәсән Сарьян. Минем өчен сәер тоелды: шушы уч төбе кебек җирдә печән чап, имеш. Ул чакта минем әти-әни исән, авылыма кайтып, җәй саен киерелеп печән чабам. Туган нигезең булгач, урман-болыннарга да үзеңне хуҗа итеп саныйсың. Хәзер инде менә печән чоры җитсә, җан талпына, чалгы жыры төшләргә керә, печән чабасы килеп кул кычыта башлый. Кайтып кына булмый, нигез беткән, ара өзелгән. Менә кайчан аңладым мин Сарьян абыйны. Чалгы тавышы аның еракта калган хатирәләрен уяткандыр, шушы кульяулык кадәр җирдә печән чапкан мәлдә туган ягы тугайларын искә төшереп юангандыр. Төннәрен, исән калдыруына рәхмәтле булып, талгын җилдә шаулаган имән төбендә моңаеп утыргандыр.

Без ул көнне урман аланнарында кузгалак өзеп каба-каба сәгатьләр буе сөйләшеп йөрдек. Күптән түгел генә аның яңа повесты «Бер ананың биш улы» басылып чыккан иде. Үзең яратып язган әсәрне халык хөкеменә тапшыру — язучы өчен сирәк килгән бәйрәмдер. Гадәттә, дача киемнәреннән генә йөрергә яраткан Сарьян абый ул көннәрдә саргылт төстәге яңа плащ киеп, кулына дипломат тотып нәшриятка килә иде. Бөтенесе дә кулын кысып котлыйлар. Аның йөзендә — әчке магърурлыгын чак тыеп торган канәгатьлек һәм шул ук вакытта үзе генә белгән ризасызлык та чагыла. Повесть редакторлар тарафыннан кыркылып, төзәттерелмәсә, нәкъ ул язганча басылса, тәэсире тагын да көчлерәк буласы иде. Кызганыч, заманасы шундыйрак иде шул... Бу әсәрен ул, басылып чыкканчы, кульязма килеш миңа укыткан иде. Фаҗигале симфония кебек үтә камил, тетрәндергеч әсәрнең вакыйгаларын онытырлыкмыни: бәхетле гаиләдә берсеннән-берсе таза, чибәр биш малай үсә. Сабан туйлар, авылның самими гадәтләре, Агыйделдән сал агызулар... Шулай кинәнеп яшәргә килгән егетләр тормышның кайсыдыр борылышында төрле сәбәпләр аркасында әчкечелек агуына биреләләр. Дүрт ир-егет котылгысыз үлемгә

дучар була. Әсәрнең соңы ананың хыялыйлануы белән бетә иде. Журналда чыксын өчен нинди генә шартларга күнмисең, Хәсән Сарьянга да повестьтагы персонажларны кабаттан терелтү җинел бирелмәгәндер... Әмма бер юаныч бар: әсәрнең төп нөсхәсе исән кала, вакыт аны яңадан соратып ала, күтәреп чыга. Тик... үз вакытында нидер барыбер өзелеп калган була.

«Бер ананың биш улы»нда саллы каләмле әдип җәмгыятьтә кеше җанын таркатырга үрелгән астыртын көчләрне алдан сизенеп, тормышны кырыс чынбарлыгы белән сурәтләп бирде һәм шуның белән сиксәненче еллар прозасында иң көчлеләр рәтенә басты.

Бүген менә Идел ягыннан дымлы сулыш сирпелгән урманда гәп корып йөргәндә дә безнең уй-гамебез, сүз сөреше һаман шул әдәбияттан ерак китә алмый иде.

— Сукырлар турындагы повестыгызны кайчан язасыз инде, Сарьян абый?

— Чират шуңа җитте инде. Тиздән тотынам. Көзгә...

Малай чакта аны тома сукырлардан гына торган артистлар труппасына алалар. Шулар белән ул концертлар, спектакльләр куеп, авылдан-авылга йөри. Сукырлар гаҗәп кызык халык, бөтенләй бүтән дөнья, аларга көн дә бер, төн дә бер, дип, мавыктыргыч итеп, күп тапкырлар сөйләгәне бар иде аның.

— Труппа җитәкчесе көчле ихтыярлы кеше иде, шуны Казан урамында очратып исәнләштем. Сукырлар колакка сизгер була бит. Тавышымнан таныды, унҗиде ел үткән бит югыйсә... «Сарьян энекәш, син ич бу! Үскәнсең, үскәнсең...» — дип, буемны чамалап, баштан сыйпап алды.

Хәсән Сарьян үзе әйткәнчә, «утырып яуган яңгыр кебек» тел белән ашыкмыйча, ипле итеп, һәр күренешнең күләгәсенә кадәр метекләп, нечкә җеп белән үрә-үрә яза белә иде. Әсәрен укыганда тел хасияте сиздермичә дә сине олыгайта бара, кайчакларда бу тәэсиргә бирешәсе килмичә, күңелдәге яшьлек таеның дөрес кагыйдәләр кысасыннан читкә сикереп, үзенчә юл сабарга теләп үрсәләнүе дә гаҗәп түгел...

— Үсмер чак хатирәләре... Романтик рухта язарга кирәк инде бу әсәрегезне,— дип акыл саткан булам. Хәсән Сарьян дәшмичә, баш кына селкеп куя. Күңелендә инде аның тере образлар яши, мәйданга чыгарга омтыла, әмма язучының ак кәгазь каршында туачак газаплы мизгелне сузып, ашыкмыйча, ләззәт кичергән чаклары иде күрәсең. Ничә еллар буе җаныннан аерырга кызганып йөргән бу әсәрне язарга өлгерә алмаячагын, ул вакыйгаларны бүтән беркем дә, беркайчан да яза алмасын без ул чакта уебызга да китерә алмый идек шул. Көне нинди иде бит... Кояшлы хозурлыктан кинәнгән көндә без бу дөньяга мәңгегә килгән кебек, «Алла бирсә»не дә онытып, уй-ниятләребезне уртаклашып йөрибез.

Кошлар авазына күмелгән каенлы-усаклы урманны кинәт тоташ наратлык алыштырды. Хәсән Сарьян тукталды да:

— Менә монда чик сызыгы...— диде.— Сизәсеңме, һавасы кинәт үзгәрде. Бәлзәм,— дип, ул наратлыкка кергәч, күкрәк тутырып сулыш ала башлады. Җиз кәүсәле мәһабәт наратлар арасында чынлап та әллә нинди иркенлек, җанны иркәли торган саф тынлык иде.

— Менә, шушында һава кырт киселә,— дип ул яңадан мине каенлы якка алып чыкты.— Аерманы сизәсеңме? — Ике арада һава чиге булуына ул мине сабыйларча үҗәтлек белән төшендерергә кереште.

Ике урман арасы...

Туган җиренең елгаларын кан тамырлары белән чагыштырып язган әдипнең йөрәгендә тетрәнүләр бармы — бер үзе генә беләдер. Зарлану гадәте аңа хас түгел. Әнә бит ул, вакыт-вакыт күзлеген сала да чигәләрен кысып тора (кан басымы югары булган кешеләргә хас сыйфат-гадәт).

Уфа — Казан арасы...

Бу ара Хәсән Сарьян өчен ерак та, якын да түгел, бу ара әдипнең бәгыре белән тоташкан. Менә бүген дә ул хатирәләргә бирелде, язучылар

арасындагы эчкерсез мәзәк хәлләрне көлә-көлә сөйли, Уфа университетында укыткан еллары искә төшкәч, ачынып бер-ике сүз әйтеп куя да үз эченә йомыла. Тел хасиятенең тирән тарлавыкларына төшә белгән әдипкә гыйлемлек сәләте тумыштан бирелгән. Аңа бәрәкәтле мәйдан гына кирәк булган. Ләкин утызынчы елларда төптән киселгән чын зыялылар урынына килгән үзешчән, мөтәгалимнәр арасында ул ышанычлы терәк таба алмый. Милләтләрне аерып, тарихтан олы баба эзләп, мирасны бүлешеп кайнашкан фәһемсез вә фәнсез даирәне ташлап Казанга күчәргә мәҗбүр була.

Әдәбиятчылар арасында да җанына урын таба алмый. Олыны олы, кечене кече итеп, кемгәдер ачылып китәргә ниятләп талпынып та куя, тагын сагаеп, үз кабыгына яшеренә. Мондый чакта ул ягымсыз, мыжык булып тоела. Әчтән, күңеле сыкрап торганда ничек инде ваемсыз сүз сөрешенә кушылып китә алсын. Кемгә сыенасың. Тарих тәмен җуйган өлкән әдипләрнең дә халык язмышына караган хәтере шушы гасыр белән генә чикләнә... Әллә соң һәркем эчтән, аерым-аерым гына сызамы? Йә, кем бар?! Мондый өметсез мәлләрдә, иңендәге ташны кагып төшереп, Сары җан кычкырып җибәрер шикелле... «Уйсыз да, буйсыз да, Алласыз да, мулласыз да әдәбият быргычылары, ишетәсезме?! Юк, мин кычкырмыйм, күңелемнән генә әрнеп эндәшәм... Юк, сезгә түгел, үз-үземә... Кичерегез...»

Ике халык арасы...

Сарьян сагынып Уфага бара да күңелсезләнеп кайта. Ике халыкны аерган сызык, упкын булып, киңәйгәннән-киңәя бара. Бер башы Уралда, Казакъ далаларына терәлгән, икенче башы Иделгәчә җиткән олы дәүләт булып яшисе бер тел-лөгать агачындагы ике җимеш бит без югыйсә, татар-башкорт кавеме. Ни җитми? Кем бүлә? Кем дигәне ике араны болгатып торучы бер өер. Держава кулы аларны үсендереп тора. Аерылганны аю булып, бүленгәнне бүре булып яшерен генә бугазлап бара.

Ике халык арасы... Әз генә бу ара җылына башладымы, бәләкәй «Идегәйләр» калкып чыга. Юк, болар кылыч тотып ияргә утырырлык та, җәя тартырлык та хәлдә түгел. Болар — «Икенче Рим» учыннан төшүгә туфрак буласы астыртын мәхлүкләр, алданган бичаралар... «Ник берегез дә эндәшми? Мин дә дәшмим...» Сары җан карашында — әрнү-кисәтү, рәнҗү-шелтә-чарасызлык... Ә эчтә — гомер кыясы убылганнан убыла бара...

Ике урман арасы...

Сарьян абый кайсы якка чыгыйм икән дип икеләнгәндәй туктап калды, тагын чигәләрен кысып торды. Әллә авырыйсызмы? дип сорау бирмәсен дигәндәй, күз төпләрен сыйпап алды да, акланган сыман:

— Безнең яшьтә шулай инде, кул белән тигезләп тә карыйсың, җыерчыклар арткан нан арта гына бара,— диде.

— Кая әле сезгә картаю турында уйлау.

— Безнең нәсел озын гомерле. Кимендә туксанга кадәр яшим әле мин,— дип, Сарьян абый үз-үзен юаткан кебек әйтеп куйды.

Кинәт ул беләгемнән кысып тотты:

— Ишеттеңме, күке кычкырды?!

Әллә кычкырды, әллә юк, мин ул әйткәч кенә кайтавазын ишеткән кебек булдым.

— Бу вакытта күке кычкырмый, сакаулана,— дип, ул, эчтән нидер юраган-сораган кебек, сагаеп тыңланды.

Бер кычкырды да тынды кәккүк. Бәлки ул күк катларыннан иңгән тәкъдир тавышы булгандыр...

Шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып, урман аланнарында бер-береңне тиң итеп, ачылып сөйләшеп йөрүнең соңы җитте. Көн кичкә авышкан талгын бер мәлдә без күл аша салынган асылмалы күпер төбендә хушлаштык. Ул аргы ярда басып калды. Соңгы... дигән хәтәр хакыйкатьне белмәү бәхете бирелгән шул адәм баласына...

Сары көз Хәсән Сарьянны безнең арадан мәңге тынлык иленә алып китте. Аңа нибары кырык тугыз яшь иде. Сарьян, диюгә миңа әлеге ике урман чиге күз алдына килә. Шул чикнең кайсы ягына чыгып кунарга белми җилфердәп очкан сары күбәләк күрсәгез, тимәгез аңа. Бәлки ул аның сары җаныдыр. Былбыллы дала күкрәгендә янган борынгы учагын эзләп очадыр...

## «Искән җил. Үткән гомер. Калган хәтер...»

*Күңелеңне тоз тот — иткәндә дә аh,*
*Алла сине кимлеккә салмас — үзе ул шаh.*

Утыз Имәни.

Хан булырга омтылган шагыйрьгә караганда шагыйрь булырга омтылган ханнар дөньяда күбрәк. Әмма ни хәл итәсең — газаплы вә бөек ләззәт кеше йөрәгендә икегә бүленә алмый; тәхет биеклеген сайлыйсың икән, илаhи Күк бәгыре белән араны өзәсең. Менә ни өчен үз күңеленең ханы булып кына калу — чын шагыйрьләрнең тәхетсез бәхете. Әмма тарих хәтеренә күчкәч, хан (яисә патша, король, шаh) биләгән тәхет дәвере, шул чор зирәклеге Шагыйрь иҗаты аша бәяләнә, аның каурый каләменнән төшкән hәр кәлимә сүз хаким әмереннән үтемлерәк яңгырый башлый. Дәүләт иярендә утырган фәhемле хаким бу хакыйкатьне белә, менә шуңа күрә дә Шагыйрь белән кылычка-кылыч килми: үткер күзле Арыслан hәм күк катламнарын ярып очкан Кошның яссылыклары кисешми, әмма алар бер-берсенең барлыгын сизеп, тоепкүзләп торалар. Икесе дә Вакытның күз карасында...

Булган бит заманалар...

Шәрекъның мәшhүр шагыйре Хафиз болай дип язган: «Әгәр Ширазның төрек гүзәле йөрәгемне учына алса, мин аның бер миңе өчен Сәмәркәнд вә Бохараны бүләк итәм».

Ширазны басып алгач, Аксак Тимер шагыйрьне табып китерергә боера. Дөньяны тетрәткән җиhангир шагыйрьгә болай ди:

— И бәхетсез! Мин үземнең яраткан шәhәрләрем Сәмәркәнд вә Бохараны данлау өчен гомеремне кызганмадым. Ә син аларны нинди дер себеркенең миңе өчен бирергә телисең!

Җиhангирның бу ачуы баш бәhасенә торганын яхшы аңлаган Хафиз каушап калмый:

— И изгеләр хакиме! Артык юмартлыгым аркасында шушылай ярлы ич мин! — ди.

Тимербәк шагыйрьнең тапкырлыгыннан шаркылдап көлә hәм иңенә затлы чапан салып, аны ирекке җибәрә. Бер ым кагуга күпме калаилләрне көл итә алган җиhангир шушы мизгелнең, шагыйрь аркасында, тарихка якты сәхифә булып керәсең, бәлки, аңлап эш иткәндер.

Аксак Тимер золымы хакында лаф орган Аурупа егерменче гасырда шактый шагыйрьләрне эшафотка меңгереп, вәхшиләрчә юк итте.

Канлы язмышка Андалузиянең гаҗәеп шагыйре Гарсиа Лорка да эләгә. Аны кырга атарга алып чыгалар. Айнадамар чишмәсе янында цикадалар җырлый. Кайчандыр «оҗмах иле» дип аталган Испанияне калдырып, «галибанә яктырып ал таң аткан»да ничек инде бу җирдән китмәк кирәк. Шагыйрь җылый. Аның үләсе килми. Конкистадорлар Лорканың кулын машина борысыннан көчкә каерып алалар. Бу тормышны бибәhа яраткан шагыйрьнең соңгы, тетрәнгеч халәтен мин аңлыйм. «Атыгыз!» — дип күкрәк киереп баскан, әллә нинди ялган батырлык үрнәкләреннән өстен табигыйлеккә ия бу халәт.

Әйе, фәрештәләрнең канатын сындырган егерменче гасырда күп шагыйрьләр тарих тәгәрмәче астында калып тапталды. Әмма без алар

арасыннан Җәлил, Фучик кебек рәсми дан бирелгәннәрен генә еш ишетеп беләбез. Яшь белеп яшәүгә караганда үлемне бәхет итеп күрсәтә алган тоталитар җәмгыятебездә очраклы дан бусагасында тизрәк үлеп, һәйкәлгә әвереләсе килү теләге аң-акылны томалап, бөтен тән күзәнәкләренә сеңгән бер чорда кинәт... Сәер аваз... Сискәндереп яңгыраган бу фикернең асыл мәгънәсенә төшенүне хәтта үз-үзеңнән, бер-береңнән яшерәсе килә иде. Һәм ул шулай булды да...

Үлеп үлемсезлек яулау
бердәнбер юл түгел тормышта!

* * *

Ак шигырь... Ирекле шигырь...

Тыюлы капкалар ачыла башлаган алтмышынчы еллар. Кеше дигән затның Җир тарту көчен җиңеп галәмгә чыгуы зиһен офыкларын ачып җибәрде. Рухи күтәренкелек. Күңел ирегенә тантана итү мөмкинлеге бирелгән дәртле чор. Хәтта шигырь көйле үлчәмнәрдән чайпалып түгелә, араннарны күкрәк белән бәреп ачкан аргамаклар кебек, иркен хәяткә омтыла, мәңгелеккә исәп тоткан кануннарны җимерә.

Үз җаны тибрәнешен түгел, ә җәмгыяти фикерне гел бер чама ритмга салып, тыныч кына агым уңаена аккан «иске шагыйрьләрне» сискәндереп, «фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт» кысаларына сыеша алмыйча, сүз кодрәтен ирекле шигырь бураналарына чәчеп яшьләр килә. Равил Фәйзуллиннар буыны...

Бу ташкынның күкрәп килүен күреп, поэзия арысланнары, бурзайлары, төлке-куяннары, хәтта, мәңге гамьсез ишәкләренә кадәр күңел колакларын торгызып, йокымсыраган аңнарны уятып, дәртлерәк алдырып китәләр. Ә инде әдәбият ишеге төбенә килеп өелешкән күпләр, өннәре алынып, тормышның каядыр төшемле ярыкларына посалар. Андыйлар, менә хәзер генә, егерме-утыз ел үткәч, көя кискән шул чор шигырьләрен тотып, атасыз калган әдәбият мәйданына кызгандырып керә башладылар...

Алтмышынчы еллар... Мәгънәле, кызыклы, иҗаттан шашынган, бәхәсле, бәхетле чор... Университетның ак рояль кебек затлы бинасында укып йөрүләр горурлык, әлбәттә. Әмма чын белем алырдай кешелек акылыннан тупланган җәүһәрләр тирән мәгарәләрдә, җиде йозак белән бикләнгән. Аларның барлыгын шәйлисең генә... Әмма Казан борынгы шәһәр, тыелган акыл монда астан сатыла. Бер йодрык булып барганда күп нәрсәгә ирешергә була. Әнә бит Парижның Монпарнас урамында гасыр башыннан бирле дөнья шагыйрьләре, рәссамнары җыела торган атаклы «Ротонда» кафесы булган. Ул хәзер дә бар. Париж исән торганда киләчәктә дә шулай булачак. Әгәр инде бездә дә шулай әдәби мәсләкле кешеләр җыела торган урын булса, аны җимерерләр, юк итәрләр яисә исемен алыштырырлар иде. Чөнки без хәтерне кисеп барудан ләззәт ала торган милләт кул астында яшибез.

Ә яшьлеккә Пегас тоягын дагалау урыны барыбер кирәк. Казанның үзәгеннән ерак түгел генә Әмәт тавы бар. Куе бакчалар рәтеннән килеп шул тау итәгенә сыенып кына бер йорт тора. Аның тар гына тимер баскычыннан күтәреләсең дә, алкалы каен төбендәге сыңар тәрәзәне шакыйсың. Эчтән пәрдә селкенеп куя, аннары ишек ачыла. Студент-шагыйрь Равил Фәйзуллинның мәгарәсенә шаулашып шагыйрьләр кереп тула. Мондагы хөрлек, мондагы иркенлек, бүлмә үзе бәп-бәләкәй югыйсә...

Поэзияне актарып ташлап, моңарчы күрелмәгән биеклеккә ирешәсе яшьләр (хыял булса, шундый булсын!) вакыт белән дә, дәрәҗәләр белән дә хисаплашып тормыйлар. Потларга сукырларча табыну — шәхеснең рухын кимсетә. Алар өчен табыну кыясы бер генә — поэзия...

Кемнәр алар? Кулдагы биш бармак кебек бердәмлеккә кемнәр керә соң?

«Көлемсерәп көн башланды», дип Дәрдемәнд рухын кабаттан шигърияткә алып кайтырга хыялланып та, Рәмиевләрнеке кебек алтын көшеле булмау сәбәпле, иркен, үтемле поэмаларга күчеп, асылташ кебек мең яңгырашлы нечкә лирикасын гел алдагыга калдыра килгән РЕНАТ ХАРИС...

«Йөрәкләр турында язасы бар әле!» дип гомере буена җитәрлек ымсындыру тудырган, кискен бәхәскә кергәннәрне, ике арага төшеп, беркатлы вәгазе белән килештерә белгән, онытылган керәшен җырларын күтәреп чыгып, искиткеч җырлый белгән ГӘРӘЙ РӘХИМ...

Үзенең туган авылы «Марс»ны кайчакларда Марс планетасы белән бутаучы, башын Байроннарча югары чөеп «Ирләр булыйк!»ны укыгач, мәхәббәт шигырьләренә күчеп, залдагы хатын-кызларның йөрәк тибешен алкышлар давылына әйләндерүче РӘДИФ ГАТАШ...

Гадәти кешегә насыйп булмаган «дүртенче яссылык»тан торып, көтелмәгән яктан аркылы килеп бәхәс уятучы, шигырендә Җир шарын дәвалау өчен палатага алып керүче РӨСТӘМ МИНГАЛИМ...

Һәм... бишлекнең лидеры — РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН...

Бу плеяда үз арасына читләрне кабул итми. Үз артларыннан килгән талантларны (Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Разил Вәлиевләрне) кайчакларда сынап, «уйнатып» карыйлар да... тагын калканны ябалар.

«Ротонда» кафесы бер якта торсын. Кайчакта бәхәсләр кызып, үпкәләшеп аерылышыр чак җиткәндә Равилнең әнисе — Әминә ханымның нәкъ кирәкле мәлдә керткән тәм-томнары, кайнар чәе дусларны түгәрәкли дә куя. Арган чакларында, Габдрахман абзый өлгерткән мунча — яшьләргә икеләтә егәр өсти.

Алтмышынчы еллар... Гасырның шигърият белән сулаган бәхетле дәвере... Мәскәүдә зур-зур стадионнар шагыйрьләр трибунасына әйләнә. Кайнар сүзгә сусаган халык диңгезен атлы милиция чак тыеп тора. Сүз егәре, хисси куәт бөтен илгә тарала, яңадан яңа исемнәр калка. Мәскәүнең иң танылган, китаплары мең бәла белән табыла торган шагыйрьләре: бөтен җир кайгысын иңенә салган кыяфәт алып, икенче Христос булырга теләп, китап тышларында рәсемен чыгарып, шигъриятендә «каенлы» Есенин белән «кувалдалы» Маяковскийны кушарга хыялланып менә дигән талантын шактый исраф итүче Евгений Евтушенко...

Тумыштан хиссез булу сәбәпле, ташны сүзгә, сүзне ташка әверелдерергә теләп гомер буе кирәксез экспериментлар ясаган, соңыннан инде югары катлау даирәсенең салон шагыйре булып җитешкән АНДРЕЙ ВОЗНЕСЕНСКИЙ.

Йөгерек ритмлы шигърияттән көтелмәгән метафоралар белән баеткан, вакыт-вакыт сагаеп, Кремль ягына карап алгалап, «тәртипле» яшәүне мәслихәт күргән, шуның аркасында поэзиясен дә үтмәсләндереп, «дөрес» юлны сайлаучы — РОБЕРТ РОЖДЕСТВЕНСКИЙ.

Алла колыннан югары шигърият ачкычын үрелеп алып, Шәрыкның еламсыраулы көенә гаҗәеп шигырьләр язган, үзенә табынган күпме ир-атларның йөрәгендә «тояк эзе» калдырган БЕЛЛА АХМАДУЛЛИНА (арадан иң көчле булып шул калыр, ахрысы, чөнки аның шигырьләрен аңламыйм, дип берәү дә әйтергә кыймаячак...).

Бу плеяданың рухи яңгыравыгы — Арарат тауларын Арбатка сыйдыра алган, виолончель тавышлы БУЛАТ ОКУДЖАВА...

Без боларга сокланып яшәдек. Әчтән бәреп торган сәяси каршылыклар фонында алар батыр күренә иде. Хәзер инде артка борылып карыйсың да... җирлекле, нигезле, чын даһи шигъриятле Есенинга кайтасың да... аның Константиноводагы өенә кереп, әнисе акшарлаган мич янынан үтеп, тәрәзәдән карасаң... чип-чиста ак кыр күренә, рус поэзиясе кыры...

Алтмышынчы еллар. Казан үзенчә кайный. Татар яңалыкка авыр бирешә, зур дәүләтле кебек әкерен борыла. Фәйзуллиннарның ирекле шигырьләрен баштарак аңлап бетермиләр, аларны Рөстәм Кутуй рус матбугатында чыгарырга мәҗбүр була. Нинди кызык чор. Көн аралаш мәкаләләр. «Шигырьме, әллә башваткычмы?» — Нурихан Фәттах. Аңа каршы кайнарланып Әнвәр Давыдов күтәрелә: «Төнкыйтьме, әллә күсәк күтәрүме?» Сез, яшьләр, Европага йөз тотасыз, әмма меңәр еллык тарихы безнең каннарда типкән Шәрекъ барын да онытмагыз, шул чакта гына сезнең шигъриятегез ике канатлы булыр, дип берәү дә үз вакытында кисәтми. Алласызлык байрагы астында, җан саклау мәсләген отышлырак күргән өлкәннәр бибаһә рухи мирасны Шәрекъка игътибар юнәлтүдән сакланалар.

Югыйсә бит «Такташ үлде» шигыреннән соң татар шигъриятендә озын гомерле вакуум хөкем сөрде. Хәсән Туфанның әрнүе — башка... Болай да сәясәткә хирыс рус һәм Европа поэзиясе, Маяковскийның көчле йогынтысыннан соң, бөтенләй ялангачланып, шартлау, кизәнү, янау, йодрык культын чатаклы ритмга алып, Латин Америкасы, Африка һәм башка кыйтгаларны бөтенләй исертте, саташтырды. Татарның тыйнак сүз хасияте, табигать һәм хис нечкәлекләренә хирыс поэзиясе дә шинельләргә әйләнде. Өндәү билгеләренә мохтаҗлык артты. Кеше күңеленнән бик еракта калган шигърият нииндидер мифик дошман, давыл, дулкыннар белән көрәшеп гомерен уздыра иде. Илленче елларда әдәбиятка күгәрчен темасы килеп керде. Американың Антон Рефрежье дигән бер саташкан рәссамы чарлак тәрәзәсеннән карап гарип күгәрченнәр ясый торгач, аңа сәяси төсмер биреп, тынычлык күгәрченнәре дип атадылар. Моны Пикассо да күтәреп алды. Бу безнең илгә җитә калды. Кызыл мәйданны меңләгән күгәрченнәр белән тутырдылар. Татар поэзиясе ун ел буена кинәнде шул тема белән. Җитмәсә, Кызыл мәйданда күгәрчен көтүенә җим биргән күренешләрне вакыт-вакыт газета-журналларда чыгарып, беркатлы шагыйрьләрне кыздырып торалар иде. Күгәрчен халкы шактый дорфа, аларга сандугач кебек асыл кош тәрбиясе бирелмәгән... Артык азып китеп, архитектура җәүһәрләрен танымаслык итеп хәкарә итә башлагач, Мәскәүнең кремль күгәрченнәрен көчле насослар белән суыртып алып юк итәләр һәм поэзиядә бу темага вето салына.

Әнә шулай идеология пульсы белән сугарылып торган әдәбият мәйданына алтмышынчы елларда көчле дулкын булып Фәйзуллиннар плеядасы килүе табигый иде. Алар ясалма шигърият дөньясына тере, мәгънәле СҮЗ алып килделәр. Бу шагыйрьләрнең җанга якын, тормышның үзеннән сирпелеп чыккан канатлы гыйбарәләре халык теленә күчеп, күңелләрдә тәңгәл яңгыраш тапты. Баксаң, чын шигърият йөрәк биеклегендә икән! Шушы бик гади хакыйкатьне, шактый каршылыклар аша үтеп аңлатып биргәч, үз каланчасына кунаклаган күпме шагыйрьләр шыбыр-шыбыр җиргә коела башладылар һәм күңел кылларын яңача көйләп, бердәм агымга кушылып киттеләр.

Алтмышынчы еллар... Фәйзуллиннар буынының үз иҗатына бәрәкәтле йогынтысы хакында, эчкерсез шәхес буларак, Сибгат ага Хәким һәм Нури ага Арслан ачыктан-ачык әйткән иде. Хәер... нигә югары сүзләр, бу чорны әле өйрәнерләр, күп нәрсәне гадел сабырлык белән ачыкларлар. Ә мин, шул чорга кайтып, гади генә бер күренешне тасвирламакчы булам. Әнә ул, яшь шагыйрьләр, төн уртасында Әмәт тавы итәгенә чыгып басканнар да хушлаша алмыйча торалар. Кара яндырып, бердәм тәмәке тарталар. Шигъриятләре кебек, монда да һәрберсе үзенчә... Равил Фәйзуллин, әти килеп чыкса тиз генә яшерергә кирәк, дигән шикелле, кыбырсыбрак, ләззәтсез тарта. Ренат Харисның төтене каршында басып торучының күзенә туп-туры төбәлеп бара. Гәрәй Рәхимнең төтене нәселле борын тишекләреннән иркен булып, бөҗраланып чыга. Рәдиф Гаташ исә, эчтәге уйларым да төтен белән бергә чыкмагае дигән кебек, эчкә алмыйча тиз генә бөрки дә, йөзенә уралган төтенне черки куган шикелле тарата

башлый. Гомере буе арзанлы, әче тәмәкегә хыянәт итмәячәк Рөстәм Мингалим тартуның тәмен белеп, тәтенне фәлсәфи микъдарда гына теш арасыннан саркыта. Бу аның Күк белән элемтәдә тору мизгеле...

Ә капка төбендәге каен алкаларында язгы тамчылар. Күктә пәйгамбәр тырнагы кебек Ай, чалкан ятып, тын гына Сөембикә манарасы тарафына йөзеп бара...

— Бу дуслыкны мәңге саклый алмаячакбыз. Күп тә үтмәс, кемнәрдер властька омтыла башлаячак. Күреп торырсыз, юлларыбыз аерылачак!— ди Гәрәй Рәхим. Аның бу фаразын дәррәү юкка чыгаралар. Ничек инде, нинди аерылу булырга мөмкин. Без мәңге бергә!

Ә күктән сыңар күзле тәкъдир, кинаяле елмаеп, яшьләргә карый, тормыш кануннары катгый: шулай булачак, һәркемнең үз тармагы... Бу гаҗәеп бергәлекнең таркалуын акларга теләп, соңыннан Равил Фәйзуллин «Арысланнар йөрми көтү белән!»—дип язды. Әмма шунысы да бар бит әле: ялгыз арыслан филне ега алмый...

* * *

Эрмитаж залларында үле зиннәтләрне тәүге тапкыр тамаша кылып йөргәндә яшь шагыйрь көзгеле, алтын нәкышьле диварларда хакыйкать шәүләсен күргәндәй була:

Эрмитажда йөрим җиңүчедәй!—
сынатмыйлар
элек камыл ерган табаннар.
Алар белән
монда гына түгел, бар дөньяны
урап чыгарга да чамам бар!
...Ышаныч һәм өмет күзе белән
гасырлардан
карап тора кебек бабамнар.

Әйе, тормышның асылына төшенү өчен күпне белергә, күпне күрергә, ашыгырга кирәк. Ә дөньялыкта сине һәркайда тышау, авызлык көтә. Ераккарак китеп каратмас өчен, төпкәрәк төшеп уйлатмас өчен һәрдаим синең алдыңа җәмгыять кирәксез эшләр китереп куячак. Ә гомер бер генә бирелгән.

«Җиңүче... Көрәшче...» дигән төшенчәләрнең зураюы, мәгънәсе үзгәрүе өчен берничә дистә ел үтүе, җәмгыятьнең тетрәп, мәңгелек диварлар чатнавы кирәк әле. Хәзергә... Равил Фәйзуллин, бишенче курс студенты буларак, ак шигырь, ирекле шигырь хакында диплом эше язарга керешә. Ул елларда диплом эшенең күләме йөз-йөз илле бит, гел дә фикерсезләрнең ике йөзгә кадәр тарта иде.

Профессор Хатип ага Госман шагыйрьнең эшен карап чыга да:

— Кереш өлешең әйбәт кенә чыккан, шушылай дәвам ит,— ди.

— Мин бөтен фикерне шушында сыйдырдым,—ди Равил Фәйзуллин.

Унбиш-егерме битлек диплом эше язганны үз гомерендә күрмәгән Хатип ага ачуыннан нишләргә белмичә өнсез кала. Ул аңга килгәләгәнче, берничә көннән Равил Фәйзуллин, сәяхәткә Югославиягә китеп бара. Күләгәсен дә хәтта «дөрес» яшәү кануннарына тугры тотучы буын вәкиле буларак, Хатип Госман «чыгымчы тай»ның бу адымын, әлбәттә, кичерми. Равил Фәйзуллин дипломны икенче елда гына алуга ирешә. Үз чорында бу вакыйга аның данына нур гына өсти. «Бөекләрнең язмышы шундый була, дип юаталар аны. Толстойны да әнә Казан университетыннан чыгарганнар, Евтушенконы да әдәбият институтыннан куганнар...»

Хатип агага ул беркайчан да кинә сакламый, киресенчә, яшьлек «юләрлеге» булып калган ул чорны көлеп, эчке бер горурлык белән искә ала.

Ә бервакыт...

Әлмәттә, Язучылар союзының секретаре булып эшләгән чакта ул Казанга кайта. Өч яшьлек улы Алмазны житәкләп Язучылар йортына килә. Анда, Тукай бюсты янында, гадәттәгечә, язучылар җыелышып, уртак тәмәке төтененә күмелеп, гәп саталар. Равил Фәйзуллинның бер урында озаклап тукталып торырга түземлеге житмәгән чоры. «Мунчага барыш... улым белән...» ди ул. Сумкасыннан каен себеркесенең очы күренеп тора. Йөзендә, бөтен гәүдә торышында самими горурлык. «Улым белән... Мунчага...»

Шулчак бу төркемгә профессор Хатип ага Госман килеп кушыла. Танылган шагыйрь булып өлгергән укучысы — Равил Фәйзуллин белән ул аерата җылы итеп, иңеннән сөеп исәнләшә. Итагатьлек саклап, улына да иелеп эндәшә:

— Исемең ничек, улым? Әтиеңә охшагансың икән, исемең ничек соң? Йә, әйт инде исемеңне! — дип, кат-кат сорап та малай эндәшмәгәч, үпкәләгән атлы булып: И-ии, телең юк икән синең! — ди. Алмаз профессорга зәңгәр күзләрен төбәп карый да, кинәт телгә килеп:

— Ә синең башың юк! — дип чатнатып куя.

Мәзәктән туя белмәгән язучыларга житә кала бу, рәхәтләнеп шаркылдашалар, рәсми елмаю рәвешен дә боздырып, Хатип аганы да көләргә мәҗбүр итәләр, хәтта.

Равил Фәйзуллинның «Горурлык» дигән шигыре, бәлки, нәкъ менә шул көнне дөньяга килгәндер әле...

Таз эчендә орчык малай.
Пар эчендә — ата елмаюы:
«Арка ышкырга кеше бар!»

* * *

«Вакытында үлә бел!..» — беренче карашка сәер тоелган бу фикерне Заратустра кешелек акылына безнең эрага кадәр үк салган. Яшәү дигән бөек газапка карата әйтелгән тирән мәгънәле, хикмәтле сүз. Һәм аның хикмәте гавам эчендә гадәти җан асраучыларга, әлбәттә, кагылмый. Ул — сәмави рухлыларга арналган... Әйтик, Гайсә-пәйгамбәр яшенә житкәнче үк (33) чын шагыйрьләрне Күк иелеп аламы? Бәлки шәхес җаны күккә ашмый торып, аның иҗаты илаһи кабул ителмидер?.. Ә шагыйрь яшен узып китеп тә гомер сөргәннәрнең язмышы ялгышлыкмы? Бәлки аларга тагын бүтән миссияләр дә йөкләнәдер...

...Адәм күкләргә ашканчы
күпме мәкер юл үтә.

Бу юлларны язганга кадәр, «шагыйрь яшендә» Равил Фәйзуллинга да Күк иясе бер кизәнеп алган иде бит... Казанның үзәк урамында ачык китапка охшаган мәһабәт бина бар. Шуның икенче катында элек Җәлил, Туфаннардан мираска калган Язучылар берлеге — алтмыш-житмешенче елларның иҗатчылары өчен үзе бер Мәккә иде. Шуның олы тәрәзәле бер кабинетын ачып керсәң, киң өстәл артында, җаваплы сәркәтип булып, Равил Фәйзуллин эшләп утырыр иде. Кайчан кермә, тәмәкесе иреннәре арасына кереп бетеп сүнгән булыр, ул аның барлыгын онытып, кәгазьләр арасында чумган булыр. Аның баш очында «һәммә тереләрдән тererәк» Ильич сурәте эленеп торыр. Калын, ялтыр агачтан эшләнгән, галәмәт авыр, саллы барельеф.

Бүгенге көн нинди матур!
«Кемнәр бар да кемнәр юк!»
Моны бүген мин пышылдыйм,
иртәгә кем?
...Кемнәр бар да, кемнәр юк...

Шагыйрь көрәзәче түгел. Кинәнүле яшәгән тормышта ул зарын да, шатлыгын да, данын да, сагышын да йөрәге аша үткәрә. Тукай яшен (27) узган вакытта һәр шагыйрь күңел упкыны аша кичеп чыга. Аргы якта каласы килү теләге артыгын көчле икән, Хак Тәгалә, бәлки, кеше гомере белән бер «уйнап» аладыр.

Кеше гомеренә караганда —
Суга ятып тибрәнүче
күләгәләр күпкә ныграк!

Бу очракта... Күкнең җиденче катыннан әмер бирелгәндер. Һәм ул, үз йолдызың аша җиргә иңеп, котелмәгән очраклылыкка әвереләчәк. Шулай итеп карар кыланган. Мизгелләр санала. Дөньяви гөнаһ туплаган Ильич-Иблис сурәте дивардан убылып, нәкъ менә Шагыйрьнең баш түбәсенә төшәргә тиеш. Тәкъдирнең соңгы кылы өзеләм дигәндә генә... телефон чылтырый. Шагыйрь, гадәтенчә, урындыгын күчереп, кырыйдагы кече өстәлдә торган телефонга иелә. Нәкъ шул мәлдә гөрселдәгән тавышка ул, сискәнеп, борылып карый, күпмедер вакытка өнсез кала. Ильич сурәте, бөтен авырлыгы белән кубарылып төшеп, үткен почмагы белән идәнне кисеп кергән. Кайбыч имәненнән эшләнгән паркетның баш сөяге кебек чытырдап ватылуы колак төбендә яңгырап тора. Әнә шулай итеп Шагыйрь чак кына Ильичның чираттагы корбаны булмый кала.

Мин зур түгел. Мин —
үзем кадәр генә.
Тезләнмә!

Бәләкәй түгел мин. Мин —
үзем кадәр әле.
Кизәнмә!

Әгәр шуннан соң Равил Фәйзуллин әлеге Иблис урынына изге сүзләр язылган Шәмаил элеп куйган булса... бу — бөтен Казанны шаулатырлык олы бер вакыйгага әйләнгән булыр иде. Чү! Адарынма, хыял! Тираннарның сакалын тартып уйнар кыюлык шактый дәвер узгач кына килә шул һәммәбезгә.

Ә тәвәккәллеккә мөмкинлекне һәрчак табарга була. Равил Фәйзуллин башка юлны сайлый. Башына береккән тирене маңкорт ничек сакласа, эш урынында биләгән урындыгын да шулай саклау заманында, күпләрне гаҗәпкә калдырып, Фәйзуллин шундый адым ясады: иҗат өчен бирелгәсе асыл вакытның заяга үткәнлеген сизенеп, бөтенесенә кул селтәп, эштән китте дә барды. Хушыгыз Иблисле кабинетлар, сездә утырып вакытлы ләззәт алган күпләр онытылырга дучар ителгән! Ә болай... Үз-үзеңне яшәтә алсаң, син — җил кебек иркле! Иҗат әһеле өчен шуннан да зур бәхет бармы дөньяда?!

Әйе, тәхет биләмичә генә ул чорда танылып кара... Вакыт белән бергә-бер дуэльгә чыгып, иҗат белән генә көн үткәрүнең — бәйсез рухыңны саклап, коры ипи белән суга калган чакларында да сыкранмыйча, тормышны күкрәк белән ерып баруның ялгыз башка никадәр кыен икәнен бер үзе генә белгәндер...

Курыкма, биек оч, Кошым!
Күк чикне беләмени!
Көл, күңел! Дөнья моңы
бер безгә генәмени!

Оч, оч, Кошкай, кис җилләрне!
Шаш, Рухым — дуласын җан!
...Егылсак — күргән-белгәннәр
яхшыга юрасыннар.

* * *

Хәтердә калырлык шәхси бәйрәмеңне дә үткәрә бел икән бу тормышта. Соңыннан искә төшереп, еллар аша кадере арткан мизгелләрне бер-береңне бүлдерә-бүлдерә сөйләрлек булсын. Туган көнендә Равил Фәйзуллинның Казансуда шаулатып йөзү марафоны оештыруы күпләргә мәгълүм. Яңа күпердән (Компрессор заводы янындагы) ул Явыз Иванның яугирләре хөрмәтенә куелган һәйкәлгә кадәр йөзеп килә, тарихи нәфрәтен ел саен бер яңартып ала иде.

Шагыйрьне һәрчак табигатьнең өч могҗизасы, тереклек күзәнәген кабындырып җибәргән өч берлеге — Җил-Су һәм Ут гаҗәпкә калдыра, шигъриятенә җавап таләп ителмәгән серле сорау-гамь булып килеп керә. Бер-берсе белән кайчакта кул бирешә торган Җил һәм Су кебек кодрәт иләренә чыныккан ир генә күкрәгән куя ала. Спартаннарча, үз-үзен аямыйча тәнне чыныктыру, саулык-сәламәтлекне культ итеп куя белү, хәтта эссе мунчада җилкәгә түшәмнән тамган салкын тамчыга рәхмәтле булып, мәдхия-шигырь язу да — Фәйзуллинның яшәү рәвеше. Ул каен яисә имән себеркесенең яфраклары теткәләнеп беткәнче ләүкәнең иң биек катында чабына, алай мәмнүн булмаса, себеркенең сап яты белән тәнен кыйнап, изрәтеп, мунчадан яңадан туып чыгарга ярата.

Су — шагыйрь өчен фәлсәфи төшенчәгә бәрабәр. Моның асыл мәгънәсен, бәлки, суның шомын да, ләззәтен дә сәгатьләр буе япа-ялгыз калып, чиксез күк һәм чиксез су дәрьясы арасында йөрәк тибешеңне тыңлап йөзгәндә генә аңлыйсыңдыр. Дулкын арасында, Мартин Иден кебек, гомер йомгагыңны учка кысып, ихтыяр көчеңне сынарга да була.

Су «өянәге» аңарда, бәлки, легендар йөзүче, табип, галим, зур марафоннарда Тубыл, Идел, Дунай, Амур елгаларында рекорд куйган атаклы милләттәшебез Искәндәр Фәйзуллинга соклянудан тугандыр?..

Ә бәлки... малай чагында мөмкинлек-шартлар булмау сәбәпле, спорт мәйданына бәреп чыгасы дәрт-дәрманы аңа һаман тынгылып бирмидер. Әнә бит ул, камыл ерып үскән кәкрерәк-ныклы аякларына чит илдә эшләнгән бутсылар киеп, аксөякләр генә уйный торган теннис уенын да түзем-үҗәтлек белән үзенә буйсындырды. Теннис мәйданчыгында кенәз, барон, король малайлары кебек, гәүдәсен бәләкәйдән күнектерелгән ыспайлык белән йөртмәсә дә, ракетканы нәзакатьле тотмаса да, тупка «а-ля Ельцин» бәрә белә, кайчакларда, кагыйдәгә туры килеп бетми торган көтелмәгән алымнар кулланып, аксөяк партнерларны җиңәргә дә маһирлыгы бар.

Су — аның гомерлек стихиясе. Су тәвәккәлләрне ярата. Кырык яшьлегендә Равил Фәйзуллин «үзенең ярымутравына» катер китертте. Августның аяз, матур көне. Катер бөтен тәнен йомшак калтыратып, Казансуда тыйнак буразна сызып кузгалды. Бердәнбер каютага төшеп, өйдәгечә, чәчәкле клеенка җәелгән озын өстәл тирәли утырыштык. Каютаның түбәсе ачык. Янәшәдән генә яшеллеккә чумып утырган ярлар шуыша. Кремльнең ак диварлары калка. Сөембикә каерылып озатып кала. Каютада итәгатьле тынлык. Ул чакта яшьләр өлкәннәр каршында тыйнаклык чиген саклый белә иде әле...

Үзәктә — өлкән шагыйребез Сибгат ага Хәким. Аксакалның романтикланып табигатькә чыгып китүе безгә ошый. Сибгат аганың күзләре укучы дәфтәрендәге самими өтер сыман рәхәт кысылган. Күңелендәге тәхет биеклеген белеп, сугыш михнәтләреннән исән калуына шөкерана кылып, бу тормышның ләззәтен тоеп, талгын гына уйлар дулкынында тирбәлә. Йөзендә — татар елдамлыгы һәм мари сабырлыгы кушылган мәҗүси елмаю. Кыланып калыгыз, яшьләр, дигән шикелле, сүзсез генә фатиха биреп утыра.

Аның янәшәсендә — Гариф ага Ахунов. Башына җиңел кепка элгән, күлмәкчән генә. Аны болай галстуксыз, костюмсыз беренче тапкыр күрәбез. Язучылар съезды үткәнгә ике айлар чамасы, аның председатель

түгеллегенә әле ышанып та булмый. Дөньяны тибрәтебрәк күрсәтә торган хакими рәшә үзе өчен дә әле таралып бетмәгәндер: башлап сүзне ул әйтә, ул нокта куя...

Равил Фәйзуллин үзен уратып алган энекәшләре эргәсендә булса да бәйрәмчә-ваемсыз кыяфәткә керә алмый. Ни дисәң дә, ул бүген шушы язучы, рәссам, җырчылардан торган «пиратлар командасының» җаваплы капитаны. Әлегә бик тыныч та, соңыннан ни булмас...

Менә ул өстәлгә зур төргәк чыгарып куйды, бисмилласын күз карашы белән йөгертеп, көттерү газабын һәммәбезгә тигез таратып, төргәкне шактый озак сүтте. Ниһаять, катлы-катлы төргәк ачылуга, катерга ияреп очкан акчарлакларны сискәндереп, «О-оо!» дигән халыкара ымлык бердәм куәт белән яңгырады. Табын уртасында ни дисез? Шәрекъ кояшы астыннан кыйтгаларны, гасырларны кичеп килгән чын татар ризыгы — гәрәбә тәненә май өреләре шытып чыккан, тетрәп торган каклаган каз!.. Ул арада Хәрәзем корычыннан коелган чын үзбәк хәнҗәре каз өстендә уйнаклый башлады. Туганчы ук юмартлыгы маңгаена язылган Гариф ага, беренчеләрдән булып, затлы шәрабын чыгарды. Ул арада табын, әкияттәге җәймә сыман, һәртөрле нигъмәтләр белән тыгызланып, бу бәйрәмгә тел ачкычлары бирерлек халәткә килде.

Мадерада ак йөземнән эшләнгән «Серцеаль» шәрабын ачып җибәргәннән соң, Рәсул Гамзатовтан кала иң оста телле тамада Гариф ага сүз алды: «Шаһидә апагыз да Равилгә иң кайнар теләкләрен әйтеп калды... Яратмасак, аны Әлмәт язучылар оешмасының җитәкчесе итеп, үземнең урынга калдырыр идекмени... Аңа ул чакта егерме дүрт яшь иде! Сынатмады. Әйбәт эшләде. Ул төбәктән күпме яшь язучыларны күтәрде... Мин аның иҗаты турында язып та чыктым, Сибгат ага аны яхшы хәтерли... Кыскасы шул: мин Равил Фәйзуллинның шигърият дәрьясында киң колач салып йөзүен телим. Әйдәгез, шушы алтын теләкне көмеш билбау белән буып куйыйк!»

Сибгат аганың тостын ишетер өчен катерның мотор тавышын әкренәйтергә туры килде.

— Равильләр шигърияткә... традицияне җимереп килделәр... Хәзер... аларга... төзеп күрсәтергә... вакыт җитте...

Шул рәвешле Сибгат ага сүзен әйтеп бетергәндә без инде Маркиз утравына килеп җитә язган идек. Маркиз... Казанның зыялылары илленче елларда пикникка чыга торган мәшһүр утрау. Монда Сәйдәшләр, Җәлилләр эзе калган. Сибгат ага өчен ул көнне әллә нинди хатирәләр яңаргандыр. Аның бит монда яшьлеге күмелгән. Беренче тапкыр Идел суы күтәрелгән чорда Маркиз утравындагы җәнлекләр коры җиргә туплана барганнар. Утрауда тәүлек буе иңрәү, сыкрау, ялвару тавышлары ишетелеп торган. Җәнлекләр, кешеләргә рәнҗеп, аягүрә үлгәннәр.

Кайчандыр олы киңлеккә җәелгән Маркиз утравы инде күптән су астында, Идел дулкыннары кочагында. Ә без төшәсе яшел тирәкле утрау — шуның кайтавазы, быел су азаю аркасында калыккан нәни генә бер өлеше иде.

Катер сайга җитеп борынын төртте дә якорь ташлады. Утрауга тездән су ерып шактый чыгасы бар иде. Яшь шагыйрьләр Сибгат аганы күтәреп иңгә утырттылар. Гариф ага бу рәхәттән баш тартты, җәһәт кенә аякларын чишенеп, балагын сызганып, һәммәбез шикелле малайлыгына кайтты.

Утрауның көньяк полюсыннан алып төньяк полюсына кадәрге араны өйрәнеп чыктык — шылт иткән җан иясе юк, монда без хуҗа бүген! Фәйзуллин бу кырмыска көтүенең дилбегәсен үз кулына алды: кемгә учак урыны әзерләргә, кемгә — табын, кемгә — утын, кыргый хискә зарыккан җаннарга иркенлек иде монда. Нindидер пароходтан төшеп калган төпсез кәнәфи (капитанныкы булырга тиеш) табып алдык. Аның төбенә кирпечләр тезеп, яшел үлән салдык та Сибгат аганы утырттык. Ул, гәҗиттән ясалган таҗ киеп, бәләкәй генә дәүләтнең ханы шикелле тәхет-

тә утыра. Ян ягына тән сакчысы булып, тал чыбыктан кылыч аскан, билдән ялангач яшь шагыйрьләр басты. Ханның баш вәзире — Гариф ага Ахунов. Без аңа утраудан бик сәнгатьле итеп тимердән коелган, шактый зур һәм авыр «А» хәрефе табып бирдек (ул аны иңенә күтәреп Казанга алып кайтты). Шулай итеп, бу утрауда без бер көнгә дәүләтле булып алдык. Ә төп гаепле — Равил Фәйзуллин, аны эшафотка бастырган шикелле уртага куеп, ду килеп мактап тост әйтәбез дә (җилкә калын, кабул итә), тагын мәҗлес үз көенә кайтып төшә. Алмаз Хәмзин баянын сузып җибәрә. Шәп тавыш белән Газинур Морат җыр сузуга, аңа кушылырга кыймыйча, утрау бер мәлгә, тын кала. «Мена безнекеләр нишли!»— дигән шикелле Ркаил Зәйдулла иңгә төртеп куя. «Шагыйрь булып интеккәнче... җырчы гына буласы калган Газинурга...» ди, кызыгуын яшермичә. Кызыгуының сәбәбе дә бар: Аллаһы Тәгалә аңа да, минем кебек үк, моңны кызганып биргән. Колагына «аю басканнар» тагын бар әле — Зөлфәт, Равил Фәйзуллин бер тирәгәрәк оешып, бер-беребезне ишетмәскә тырышып, сыек кына мөгерәп җырга кушылабыз. Безгә Ниагара шарлавыгы янында гына кычкырып җырларга язгандыр шул...

Ә көн шундый матур. Күңелләрнең таралып, кыйбласыз калган чагы. Бер читтә, учак янында, тотеннең үзеннән яралган шикелле Рөстәм Мингалим кайнаша, шашлыкларга тылсым өрә. Кемдер килеп, киңәш бирә башласа, «Әйбәт кешеләр сез!» дип куя. Тутык тавыш белән шушы өч сүзне ничек әйтүенә карап аның сүгенәме, рәнҗиме, мактыймы, кисәтәме икәнен үзең чамалыйсың. Ә бер якта, учак өстендә күпне күргән казан, аңа шаулатып чиләге белән кысла салалар. Аһ, нинди шөкәтсез, чирканыч кыяфәтле җанварлар, бераздан сезнең сөякләрне дә калдырмыйча суырып-ялап бетерәчәкләр бит!

Арабыздан бердәнбер чын башкорт та бар. Рәссам — Рәшит Имаш. Борынгы җиргә аяк баскан тәүге кеше — неандерталецка охшаган кыяфәте белән ул хатын-кызны башта куркуга төшерә, аннары гаҗәеп иплe холкы белән аптырашта калдыра, аннары шәп ир нәкъ менә шундый кыяфәтле булырга тиешлеген исбат итмичә генә гомерлеккә гашыйк итә. Ярый әле бүген — гөнаһсызлык көне, Фәйзуллин әмере буенча, утрауга бер генә хатын-кыз да кертелмәде. Имаш барыбер елмая, зур папкасын чыгарып, һәммәбезгә шаржлар ясый. Аның мул булып ерылган калын ирен читләре ике колак очына җитеп терәлә. Имаш рәсемендәге бөтен кешенең дә авызы бер ярымга зуррак чыга.

Ә көн шундый матур. Ак битләрен җил ачкан көндәлек сыман акчарлаклар очына. Моңлы җыр... Якты Идел... Янда дуслар...

Хушлашырга безгә
иртәрәк бит әле,
иртәрәк бит әле, аккошлар.

Яшьләрнең кан кайный. Берзаман алар кул көрәштерә башлыйлар. Пржевальский кыяфәтле, озын буйлы Ләбиб Лерон монда инде беренчелекне бирмәс дип уйлыйсың, юк, базыграк гәүдәле Ләис Зөлкарнәй нык тора. Ык буенда чыныгып үскән егетнең кан тамыры гүләп тора, күрәсең. Менә, сөзгәк үгез сыман куркыныч кыяфәт чыгарып, Ркаил Зәйдулла барып тотына, юк. Зөлкарнәй бер талпынуда тегенең дә кулын «сындырып» төшерә. Фәйзуллинның да йөрәк түзми, тәки барып кушыла бит, аны җиңәләрме, ул җиңеләме — бусы хәтердә калмаган...

Бераздан Гариф ага өлгереп җитә. Аның нинди генә мәшһүр табыннарда җырланмаган «коронный» җыры бар:

Туп-туп кына басып килә
көмеш тояк тулпар атым...

Аның үзенчәлекле итеп «һә-әәй!» дип куйган нотасын бөтен утрау күтәреп ала.

Кай арада кояш баеп та өлгергән. Төнме бу төн? Безме бу без? Баш очында Киек каз юлы белән типчелгән күк гөмбәзе, йолдызлар мириадасы. Менә без, кулга-кул тотынышып, халык гимны — «Туган тел»не җырлыйбыз. Сибгат агага карагач, Фәйзуллинның шигырь юллары искә төште:

Байтак мәҗлестәшләр онытылыр,
гел хәтердә тормас бу табын.
Тик онытмам Сибгат Хәкимнең мин
«Туган тел»не җырлаган чагын.

Учаклар пышылдап сүнә. Миллионлы шәһәрнең таш йортларына сибелеп яшәгән безләрне шушылай бер учка җыеп, табигать хозурына алып чыккан өчен Фәйзуллинга мең рәхмәт әйтеп кузгалабыз.

Безне көтеп, үзалдына мыр-мыр гына эшләп утырган катерга су ерып керәбез. Сибгат ага яшьләр иңендә, биектән елмаеп бара, башы йолдызларга тиеп-тиеп китә. Моннан соң нибары өч ел үтәр дә, олуг шагыйребез Сибгат ага Хәким белән бәхилләшербез дип берәүнең дә әле уена килми. Шушы ук яшь шагыйрьләр аның табутын иңгә салып, изге рухын йолдыз аланына озатып җибәрерләр...

Ә төне — мәңгелек вәгъдә иткән төн иде югыйсә...

* * *

Үзең яшәгән төбәкнең чишмә-суларын, кыргый ташларын, тавының маңгай сырларын, агачларның еллар бөҗрасын гомерең буена өйрәнеп, җир-су белән тәңгәл сулышта «утрак олпатлык» белән яшәүнең дә үз мәгънәсе бардыр. Ә инде офык арты офыклар күреп, юллар соңы юлларга чыгуның тәмен бер татыгансың икән, акыл-гамьнең хәрәкәттәге халәтен билгеле бер кимәлдә тотар өчен, илләрне гизәргә дә гизәргә кирәктер. Равил Фәйзуллин нәкъ менә шул икенче кыйбланы сайлады. «Тамыр җибәрә башлавын» тоюга ул, форсат табып кузгала, тарыккан җанны самолет шавы яисә поезд тәгәрмәчләренең тыкылдавы еракларга алып китә.

Менә ул кыпчак кайнарлыгы күзләрендә кара күмер булып чәчрәп янган хохол кызының чиләгеннән чатнап торган салкын су эчә, кайчандыр Европаны тез чүктерергә барышлый, алмачуар атларыннан төшеп, Бату хан белән Сүбүдәй баһадир хәл алган ташка утырып, көз палитрасына манылган Карпат тауларына карап хозурлык кыла.

Менә ул тымызык Балтиканың дымлы җиленә күкрәген куйган Сигулда усакларына, Роза-Турайда замогына сокланып йөри. Моннан инде литва шагыйре Эдуардас Межелайтисның туган җиренә дә ерак калмый. Заманында күпме яшь шагыйрьләрне иманыннан яздырган шәхес иде ул. Аның хөкүмәт иң югары бүләк белән данлаган «Кеше» поэмасында Җир шарына басып кояшны (имеш!) тотып торган йөрәксез, җансыз, тоталитар җәмгыятьнең үзе шикелле гигант бәндә сурәте күз алдына килсә, әле дә тәннәр чымырдап китә. Ә заманында ничекләр соклanмадык... Күпме шагыйрьләр шушы робот-поэмага ияреп, «зурлык авыруы» йоктырдылар, үз халкының гамен санламыйча, планетар шигырьләр яза башладылар. Айнып, кире үз асылына кайтып төшкәннәргә инде соң иде... Садә хисләрнең сыктап сүнгән шәүләләре өстендә тантана иткән салкын акыл ритмы башка шул... Күңел саңгыраулanган. Тургай моңына тотынып арышларның буйга сикерүен дә искәрмисең, бал кортының чәчәк таҗында калган аяк эзен дә күрмисең, сандугач сайравыннан чык тамчысының кытыкланып җиргә сикерүен дә тоймыйсың. Нәзберек күбәләк канатындагы алтын тузан коелган, ул — очышын җуйган инде...

Шул чор шигъриятендәге гариплек агымын акылы белән генә түгел, ә бөтен тән-күзәнәге белән тойган Равил Фәйзуллин табигатькә отыры

ныграк тотына бара. Дога укылган бер җирдә чишмәләр бәреп туган авылы Балтачка (Юлсубино) кайтып, күңел юшкыннарыннан арынып, илһамга баеп килә.

...Туган ягын онытканга
кош җанын бирсен Ходай!

Менә ул Карадагның чалкан тәшкән салкынча күләгәсен күкрәгенә алып, Тәркия ярына ашкынган ирекле дулкыннарда тирбәлә. Ә дулкыннар зарлы, кайгылы ярдан сыктап кузгалалар. Ватансыз калган кан-кардәш Кырым татарларының фаҗигасе таулар күкрәгенә мәңге кичерелмәс яра булып уелган. Бу әрнүне кычкырып, дөньяга яңгыратып буламыни ул заманда, тавышың инрәп, метафораларга йодрыклана...

Таулар кузгатыр идегез
халыклар күчергәнче!
Икмәк үстерер идегез
каберләрне сөргәнче!

Җырлар чыгарыр идегез
указлар чыгарганчы!
Котырына шулай вәхши
үз канын чыгарганчы...

Шагыйрь рухын сәяхәтләр баета. Рәтле илдә туып үссә Равил Фәйзуллин да егетлек ягыннан, Хэмингуэйдан ким куймас иде. Йодрык сугышлары оештырыр, үз баркасы белән океанга акула ауларга чыгар, Килиманджарода үзе аткан леопард тиресен стенага эләр, Мадридның биш йолдызлы бай һотелендә яшәп, испан конкистадорларына каршы сугышта катнашыр, тагын, тагын әллә ниләр... Ярый әле, Хак Тәгалә аңа кечерәк җирлек биргән, югыйсә барысын күреп, кыланып бетергәч, бөтен Җир шары бик бәләкәй, кызыксыз калып, ул олы моңсулыкка бирелер һәм Хемингуэй кебек, ау мылтыгын үзенә каратыр иде...

Казансу буенда Равилнең чит кеше аяк басмый торган гаҗәеп тын ярымутравы бар иде. Без ул «Яфрак асты» кафесына еш җыелабыз. Монда барысы да була: су коену, ярыш, яңа шигырьләр, көч сынашу, бәхәс-әңгәмәләр, салкын сыра, төнге учак. Фәйзуллинның спорт сумкасында ни генә юк. Аның өчен бу сумка — фатир, ашханә, язу өстәле, хыянәтсез иптәш... Шундый чаклар була: без гөр киләбез, ә «Кенәз»нең (бу кушамат аңа шул чорда тагылды) юка ирене кысылган, уй-исәпле күзләрен еракка төбәп, үзалдына йомылып утыра. Борчуы бардыр, тагын Мәскәүдә китап чыгарырга йөридер, дисең. Ә аның күңеленә ераклыклар җиле кагылган икән...

Бер-ике көннән Мәскәү радиосыннан ишетәбез: СССР язучыларының әдәбият көннәре. Равил Фәйзуллин Ерак Көнчыгышта. Бер атнадан ул кайтып төшәр, Уссури тайгасында казып алган алтын тамырларын безгә күчтәнәч итеп өләшер. Үзе әйтмешли, «самореклама» белән шөгыльләнеп алыр: барган-күргәннәрен эфирдан сөйләр, газета битләрендә күренер. Ул килеп кергән кабинетта телефоннар «кызыша» башлый, ил киңлегенә сибелгән шәһәрләрне ул телефоннан «кадап» кына ала. Бер-ике гасыр элек яшәсә, Фәйзуллин атчабарлар тотар, Уралдан, Себердән, Кавказдан, Кырымнан аның атлары, хәбәр алып, ак күбеккә батып кайтып керерләр иде, дип шаярталар аны.

Менә ул ерак Монголиядә. Бөек җиһангир — Чыңгыз хан һәм аның баһадирлары күмелгән Борхан-Халдан тавына менеп, изге ташлар, илаһи тынлык догасын тыңлагач кына ул гаярь холыклы монгол йөрәген аңлар. Бөек дип үз-үзен исертеп йөргән кайбер халыклар әлифне таяк дип белмәгән гасырларда ук инде монголларның алтын белән язылган китаплары булган, кеше тәнен үтәли күрү — табиплык фәне үскән. Монгол

атларының тояк эзендә күлләр хасил булган, ук сызгыруыннан таулар ишелгән, бу аяусыз халык турында күпме дастаннар язылган. Шигырь кысаларына гына сыйдырып буламыни мәшһүр тарихны...

Менә ул Италиянең башкаласын биектән торып күзәтә. Бакый заманда, дәһшәтле гаскәре белән чолгап алгач, Атилла «мәңгелек шәһәр» — Римне җимертми, унбиш гасырдан соң татар шагыйре килеп сокланып, Эллада осталары төзегән сарайларга карап, үзенең ата-бабалары корган шәһәр-калаларның явыз кавемнәр тарафыннан юк ителүе хакында сыктап уйлансын дип калдыра.

Безнең якта — борынгыдан
хәрабәләр генә.
Чын тарихны азлар белә,
хәбәрдарлар генә...

Тарихыбызның нәни бер йөзек кашы — Болгар чоры белән генә мавыгып, Алтын Урда зурлыгын аңга сыйдырырга курыккан бер чорда шагыйрь Әстерхан якларына барып, мәшһүр башкала — Сарай-Бату урынын карап, аннан җыеп алган әрем учмасын безгә дә күрсәтеп, әрнүле хозурланып йөргән иде.

Әдәбият көннәре... Яңа җирләр, яңа гореф-гадәтләр күреп гыйбрәт алу да, бер-берең белән аралашу-танышу өчен җирлек тә бар иде ул бәйрәмнәрдә. Күз уңында, иң биектә һәрчак бер исемнәр булыр. Һәр халыктан бер корифей... Артык та, ким дә булмасын. Сугыш чорын кичергән бер төркем (Р. Гамзатов, М. Кәрим, К. Кулиев, Д. Көгелтинов һ.б.) бер-берсенә таяна белә һәм алардан узып алга чыгарга кем дә кыймый иде. (Татар хатыны тудырып үстергән атаклы кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматов дөньяви шөһрәткә ия, аның язмышы башкачарак иде). Алар каршына дан һәм бүләк бирү баскычлары эзлекле чиратка куелган, шул ноктага килеп җиткәндә «дөрес» әсәр, «дөрес» мәдхия уку мәҗбүриятеннән азат була алмыйсың. Кремль җылы куенында юкка гына асрамый, партия чираттагы бүләкне сузган саен, манежда бер шакмак шикәр өчен саллы гәүдәсен селкетеп биегән аю кебек, реверанс ясарга тиешсең. Ни хәл итәсең, җәмгыяте шундый, нәфсе җепләре хакими көч кулында, шуны тартып кеше белән уйныйлар. Толстой кебек «икенче патша» дәрәҗәсендә йөрү өчен граф титулы гына җитми, бәйсезлек биргән биләмәң-байлыгың да булырга тиеш. Бер акыллысы: «Әгәр Толстой коммуналь фатирда яшәсә, Салтыков-Щедрин булыр иде...» — дигән иде.

Әлеге корифейларның данына, тантаналы яшәү рәвешенә Фәйзуллин кызыгып та карагандыр. Шулар дәрәҗәсенә менәргә омтылыш ясап, баскычларны да әзерләп куйган иде шикелле. Әмма татар хәятендә үз көчең белән генә калкынып лидер булу — гайре табигый эш. Безнең олтан белән солтанны рифмалаштырган милләткә үзәккә тартылу түгел, ә үзәктән куылу, чәчелү миссиясе язмыш тарафыннан бирелгән күрәсең. Татар, үз-үзен бетерүдән ләззәт тапканга күрә, бүтән милләтләрнең канын, аңын яңарту өчен чимал итеп файдаланыла...

Әмма бу әче хакыйкатькә каршы җан карыша. Килешәсе килми!

Япан дала киңлегендә Шагыйрь, утырып баеган кояшка карап, вакыт һәм чиксез яссылык арасында бәргәләнгән кеше җанының гасырларга сирпелер кодрәте барлыгына ышана. Моның тере мисалы — калын, каты чәч мәгарәсеннән Европага утлы карашын төбәгән, шигырь сөйләгәндә корыч тавышы белән залны чүктерә торган әдип — казакъның дала бөркете — Олжас Сөләйманов. Аның белән таныш булу, замандаш шагыйрь буларак аралашу — үзе бер бәхет түгелмени. Заманында бу гаярь егет үзенең «Аз и Я» китабын чыгарып, гомер буе ялган тарих язып мүкләнгән рус академикларының касыгына типте (кайберләре шуннан соң мантый алмадылар). Аның баш очында Мәскәүнең кылычы күтәрелгән иде,

татар булса үз арабызда ук сытарлар иде, ә монда башка... казакъның зур урын биләп тә үз халкын сатмаган Динмөхәммәт Кунаев кебек якларлык, могътәбәр шәхесе бар иде шул.

«Нишләп безнең татарда алтмышынчы еллар диссидентлары юк, тыелган әсәрләр дә күренми?»— дип сорау биргәндә Равил Фәйзуллин кайнарланып та чыга. «Руста да бик юк бит. Яһүдләр кебек дөнья байлары үз шәхесен күтәреп алырга торсалар, әз генә кагылуга бөтен информация чаралары белән чаң суксалар — бездә дә булыр иде. Ярый әле булмаган, халык дошманы, дип исемеңне дә чыгармыйча таптап бетерәчәкләр иде. Без дә ләббәйкә дип тормадык. Язганнарны укый белү өчен дә талант кирәк!»

Әнкәләрен санламаучы
сантыйлар да житәрлек.
Бездә шигырь — аңлаганга —
башың Себер китәрлек!

Иманга тугры калу — җиңел бирелми. Күпме сәләт ияләре егерменче гасырның явыз шаукымына ияреп харап булдылар. Бу турыда сүз күпса, Равил Фәйзуллин яшьлегендә читтән генә күреп калган Назыйм Хикмәтне мисалга ала. Истанбул төрмәләреннән шагыйрь булып чыккан бу горур маңгайлы, чибәр төрек мең мәчетле, азанлы гүзәл илен «кызыл саташуга» алыштырып, Мәскәүдә яшәде. Шул ук Маяковский күләгәсеннән котылып алган мизгелләрендә дөньяга гаҗәеп шигырь тәлгәшләре ыргыта һәм шуның белән үзен яраттыра белә иде. Бу кабатланмас шәхеснең иҗади фаҗигасе — күз алдында, ярый да бит заман аның идея сөреме кагылмаган әсәрләрен сайлап таба алса...

Ах тау юклыклар!
Кыя юклыклар!
Күз текәмә кая —
үзәң, калкулыклар!

Фәйзуллинның бу — мәңге кар түбәле Тянь-Шань, Памир, Алатау, Эльбрусларны күргәч туган юлларымы? Шагыйрь әллә үзебезнең төбәктәге Урсал, Кыз тавы, Керкәле, Чатыр тауларның карсак булуы өчен туган җир-хәяткә үпкә белдерәме? Юк, әлбәттә, монда мәгънә тирәнрәк. Кайчандыр кыйтгаларны биләгән төрки-татар дөньясының сулышы кысылганлыгы, офыгы тарайганлыгы шигырьдә сыктау-киная-үкенеч булып килеп керә түгелме?!

Үз халкыңны ничек бар шулай ярата алу зурлыгы илләр гизеп, чагыштырып караганда тагын да көчәя. Алдан шигырьләрең барып җитеп, чит телдә яңгыраш таба, аннары — үзең. Ә күрәсе җирләр тагын күпме әле...

Элегрәк аның сәяхәтләр соңы Идел буенда, Займищедагы дачасында төгәлләнә иде. Төнге учак... Җил, су, уттан торган өч берлекнең иң серлесе — ут. Керсез ялкыннарның дөрләп биешүенә карап утырасың да дөнья гамнәрен иңеннән кагып төшерәсең. Якыннан гына, урман буеннан җиргә тибеп-тибеп поездлар уза. Яшәүнең кадерен искәртеп Вакыт йөрәге шулай тибә... Йолдызлы күк астында, мәңгелекнең гадел бу мәлендә үзеңне җиңүче-Цезарь итеп тә тоярга була. Ә каршыңда — төн пәрәнҗәсен иңенә салган гүзәл Клеопатра. Йолдыз атылып сүнгән арадагы матур алдануның шигырьдә адашып каласы мизгеле...

* * *

Шагыйрьнең уйлы-гамьле юлларын өзеп карап, аерым бер тәэсир белән укыганда хатирәләр яңара, артта калган еллардан өзек-өзек вакыйгалар күз алдыннан сызылып үтә.

«...Салават күперенең бер очында Габдулла Тукай, икенче очында — Равил Фәйзуллин.» Аяз Гыйлаҗевнең моннан унбиш еллар элек язарга уйлаган, әлегәчә нигәдер тәгәлләнмәгән бер мәкаләсе шулай башланган...

Сындырып сыный дөнья,
дусларны чәчеп җыям.

...Татарның милли тарлыгында күрелмәгән хәл! Равил Фәйзуллинның утыз өч яшендә калын томлыгы чыккан! Гайсә пәйгамбәр яшендә шундый китап бастырып кара... Энесе Рөстәм (Акъегет) китапны баш бармагы белән җырлатып кына актара да: «Монда чын җиде шигырь бар...» — ди. Кара диңгез буенда ял итеп яткан шагыйрьгә китап һәм шушы фикер кайнар хәлдә килеп җитә. Ярсудан ул тугыз баллы дулкыннарга гәүдәсен ыргыта. Соңыннан, исән-аман ярга чыгып, пальма төбендә хәл алгач, шаркылдап көлә башлый. Тукайның ничә бөек шигыре бар? Җидедән артамы? Пушкинныкын санап кара, Есенинны!..

Беркатлысы булу кызык
дошманы бар бу дөньяның.

...Хәсән Туфанны соңгы юлга озату (Июнь, 1981). Гасыр йөрәге кысылып куйды. Әдәби хәятебезнең иясез калуы шул көннән башланды бугай...

Җанга якын җаннар китә тора.
«Яшәгез, яшьләр! Афәрин!» — диючеләр,
җилкәдән кагып, безгә юл бирүчеләр
китә тора.

...Чернобыль фаҗигасе. Равил Фәйзуллин (Ренат Харис, Вакыйф Нуруллин белән бергә) шул хәтәр урынга барып, радиациянең үзәгендә коенып чыга. Фаҗигаләр күбәйгән заманда аларның бу адымы искәрелми һәм бүтән каләмдәшләр тарафыннан кабатланмый да...

Бүтәннәр юри уйныйлар,
мин-юләр чынлап уйныйм.

...Илле яше тулган көннәрдә ул галәми сагышка бирелеп ала. Гүя тормыш бизмәненең бер ягыннан икенче ягына күчә.

Бу чакта ничек үлим соң —
кыр казы исе килә!

...Туган ягына кайтып сәҗдә кылып, Каманың балык исе сирпелгән дымлы җиленә күкрәген куеп, үсмерчак пристаненнән хәтер дәрьясына ак пароходлар озатып килгән чакларында ул гади-якын, тойгыларга юмарт, күңел капкалары ачылган була. «Әти-әнине күреп килдем әле», дигәндә шагыйрьнең бәхетле елмаю саркып киткән йөзендә дөнья кагыйдәләренә сыймаган табигый бер канәгатьлек нуры яктырып ала.

Нәшрият бинасына кереп, лифтта уңынчы катка күтәрелгәндә, ул күзгә күренеп җитдиләнә башлый, кабинет ишеген ачып кергәндә инде ул «Казан утлары» журналының баш мөхәррире роленә кереп бетә. Рәсми тавышка күчәр алдыннан, саллы итеп, ютәлләүгә тартым тамак кырып ала, ирен читләрен авыртулы кыса, бик үк яратып тагылмаган галстугын, муенын азат итәргә теләгәндәй, төененнән йолыккалап куя, биниһая зур кульяулык алып, тир бөртекләре күренергә тиешле бронза маңгаен сөртә дә, җилкәсен утыртыбрак куеп, эшкә керешә. Шулай итеп, көндәлек мәшәкатьләре белән казна эше башлана.

Ә бу мәлдә Шагыйрьнең туган ягыннан чабуына тотынып килгән малайлыгы, үзенә игътибар беткәнгә үпкәләп, мыштым гына ишектән чыга да, паркет идәндә сары яфрак эзләр калдырып, үз иленә — өянкеләр шаулаган, күкеләр моңланган су буйларына кайтып китә.

Санама, күке, санама
гомерем елларын!
Күңелем тулар да
йә үксеп елармын...

* * *

Гадәттә, шагыйрьләргә куелган һәйкәлләрне аудармыйлар. Мәйдан учындагы һәйкәлгә халык соңлап килгән үкенечен дә, садә чагына кайтып алу кебек хәтер яңарту мизгелен дә сала. Безнең Тукай — гасырның яшьлек маягы.

Бөекләр булган. Җуйганбыз.
Гасырлар — ерак ара.
Кайта-кайта: «Тукай!» — дибез, —
ул шул яңарак яра... —

дип яза Равил Фәйзуллин. Әйе, Тукай җәмгыятьнең билгеле бер үсеш аралыгында, комета булып, тарих гөмбәзен ярып үткән шагыйрь. Аның иҗади язмышы килер буыннар өчен сабак та... Сәясәт белән шигърият кайсы ноктада кисешә ала? Чорның байрагы белән сәясәт шәме сүнүгә, утка ташланып өтелгән күбәләкләр күмере шикелле, төбендә үкенечле шигырь эзләре генә калмыймы?

«Тукай яшен узып барам», — дип кыенсыну белдергән фикерләр (күбесе эффект өчен) ни өчен шагыйрьләрнең уртак табышына әйләнде? Сәясәт шаукымында вакытлы хисләрнең тиз саегуын сизеп акланумы бу? Бәлки безгә табынуның чик-чамасын белеп, киңрәк Шәрекъ дөньясына борылып карарга кирәктер! Андагы дөньяви бөек шагыйрьләрнең гомер бизмәне күпмегә тарткан, бармакларны бөгеп карыйк әле: Хафизның яше — 64, Низами — 68, Бируни — 77, Физули — 62, Фирдәүси — 70—80, Рудаки — 81.

Алар өчен «шагыйрь яше» дигән төшенчә булмаган. Яшьлегендә олпатлыкка, картлыгында яшь калу зирәклегенә ирешкән бу шагыйрьләр зур Ислам дөньясын, борынгыдан килгән асыл мирасны яхшы белгәннәр. Шәрыкъ — кояш бишеге, акыл һәм шигърият учагы, тарих дәрьясы. Төрки-мөселман хәятен бербөтен итеп карап, шул бәһасез мираска таянганда гына шигъриятнең биләгән колачы киңәячәк.

Кайчандыр яшь Европаның учына фәлсәфә ташын салып, иңеннән кагып җибәргән Шәрекъ бүген, ак сакаллы карт булып, юллар чатында күзәтеп басып тора. Акылдан исергән Европа, үзенең олуг остазын күрмәмешкә салышып, җир хәтерен таптап, каядыр ашыга, омтыла, алгысына. Ул Шәрекънең кабат яшәрә алу тылсымына ия икәнлеген башына да китерми. Һәр милләтнең яшьлеге — шигъриятендә!

Европаның таш өстендә туып, бәгырьсезлектән, хиссезлектән интеккән поэзиясенә биһуш китмичә, без үзебезнең көчле аһәңне куярга тиеш. Аның өчен, сәнгати югарылыкка җиткән шигъриятебезгә бер тамчы бәлзәм генә өстәргә кирәк. Ул — Шәрекъ мутлыгы...



# МАТУРЛЫК ИЛЕНӘ ЮЛ

**Укучыларыбыз игътибарына тәкъдим ителә торган бу сәхифә — төрле төбәкләрдән килгән шигырьле «сәламхат»лардан сайланып төзелде. Аларның авторлары — әдәби сүзгә гашыйклар, димәк ки, Матурлык иленә юл тотучылар, аны фәкать туган телебез — «изге сөт» ватаныннан эзләүчеләр һәм табуларына ышанучылар — төрле һөнәр һәм язмыш ияләре, милләттәшләребез... Әйе, аларның барсы да Шигърият әнкәбез балалары. Өлкән галимебез — ономастика белгече профессор Гомәр ага Саттар-Мулилле исеме, мәсәлән, укучыларыбызга мәгълүм; шулай ук Ринат Мәннан (Казанда яши, табиб.) исеме дә көндәлек матбугатта күренгәли; трамвайлар йөртү идарәсендә эшләүче, чит җирләрне күп күргән, катлаулы тормыш юлы узган, әмма шигырь өчен хатын-кыз назын саклап калган Фәридә ханым Хаҗиева да инде укучыга беркадәр таныш дип беләм. Ә инде Оренбурдан — зур белем иясе, милли җанлы мәгърифәтче мөгаллимә апабыз Мәдинә Рәхимкулова эшчәнлеге турында журналыбызда мәкалә дә чыккан иде. Чаллы педагогия институты доценты, әдәбият белгече Әнвәр Шәрипов (юкка гына Утыз Имәни иҗатын утыз ел буе өйрәнмәгән — үзенә дә шигырь җене кагылган лабаса!), Азнакайдан — элекке укытучы, батыр рухлы Фәүзия Төхбәтуллиналар...**

**Ә Гөлнур туташ (Хәсәншина) — арада иң яше. Ул — чын-чыннан юл башында. Актаныштан — Пучы авылыннан, быел гына мәктәп тәмамлап, университетка, журналистика бүлегенә килгән. Язучылар берлегенең «Шигърият остаханәсе» аның иҗатын уңай бәяләп, укырга керү өчен рекомендация һәм журналга тәкъдим итү өчен шигырьләренә дә фатиха бирде. Хәерле юлга!**

**Кыскасы, төрле исемнәр, төрле кимәлдәге шигъри эзләнүләр, табышлар, фикерләр, милли бизәкләр... Кабул итеп ал, укучы!**

**Рәдиф ГАТАШ**

⁂

# Гомәр Саттар-Мулилле

## Кемнәр варисы без?..

Асыл зат бабаларыбыз
Колгалиләр, Колшәрифләр,
Колсәетләр, Мәүлакол —
Олуг шагыйрьләр
Булмаган һичбер вакытта
Җәмгыятьтә гидай кол.
Йә укучым, искә алып,

Ошбу изге бөек җаннар
Шәрәфенә дога кыл.

Исемнәренең «кол» өлеше —
Димәк, «Бер раббе колы»...
Шагыйрь булып, чын ир булып,
Рухани изге зат булып,
Хезмәт иткәннәр халыкка —
Мәдхия укыганнар яхшылыкка,
Чик куярга тырышып явызлыкка...

Гасыр-чорлар дәвамында
Халкын агарткан, яраткан,
«Тел» дип, «әдәп» дип кайгырткан,
«Халкым» дип җан аткан
Әдипләребез барында
Татар халкы югалмас:
Юк булмас беркайчан
Тынычсыз дөньялы
Борынгы Җир шарында.

* * *

Чурабатырга тиң Тинчурин бар,
Галимҗаны, җаны татарның —
Гаяз, Аяз, Әмирханнар белән
Яңа гасырларга атларның...

Тамырлары тарих төпкеленнән —
Бик ерактан килә татарның —
Рухи байлыгы мул, зур мирасы —
Көнләшерлеге бар ятларның...

Габдерәхим Утыз-Имәни бар,
Утыз Имән — утыз алып ир;
Рухияте мулдан булсын диеп,
Идел белән Чулман елгаларын
Бүләк иткән безгә Туган җир.

Камаллар бар, мәрҗән Мәрҗани бар,
Риза Фәхретдин бар, Насыйри,
Бөек Тукай, Колгалиләр белән
Халкым өзелмәс җыр — асыл мирас —
Милли рухи җанын асрый.
Заман бездән — миллилекне саклау,
Татарлыкны яклауны сорый.
Йәгез!

## Мәдинә Рәхимкулова

* * *

Тәнең көчле — көрәшләрдә җиңдермәсәң,
Җаның көчле — әрнүләрен сиздермәсәң.
Бәхетле син — йөрмичә зур байлык эзләп,
Итсәң илгә, кадәри хәл, тугры хезмәт!

* * *

Ат бир, тун бир, ни бирсәң бир:
Төче бал, ачы миләш...
«Дошманым булмасын»,— дисәң,
Бирмә... наданга киңәш!

* * *

Тормыш бавын үрер булсаң, ике җептән,
Сүтмәсен, дип аны сиңа дошман кеше;
Булу тиеш бер җеп — картның тәҗрибәсе,
Икенче җеп булу кирәк — яшьнең көче.

* * *

Чын күңелдән туры сүз сөйләсәң,
«Тыңлаучы аз»,— диеп кайгырма.
Изге ният белән сәфәр чыксаң,
«Юлдаш булмас»,— диеп кайгырма.

* * *

Валчык кадерен белү өчен,
Ачлык күрү кирәкме?
Хөрлек кадерен белү өчен,
Коллык күрү кирәкме?

Солых кадерен белү өчен,
Сугыш күрү кирәкме?
Тормыш кадерен белү өчен,
«Үлеп карау» — мотлакмы?

Уйлап карау — кирәкме?!

## Нәрсә кирәк?

Чабата ясарга шөшле кирәк,
Утын кисәргә — балта,
Кар көрәргә — кирәк агач көрәк.
Афәт булса — кирәк батырлык.
Ир кешегә — миһербанлы йөрәк,
Хатын-кызга — күркәм сабырлык.

* * *

Океаннарда була цунамилар,
Диңгезләрдә — төрле дулкыннар...
Сазда булмый андый давыл-туфан,
Сазда була — фәкать упкыннар.

Баһадирлар цунамидан котыла,
Дулкыннарда йөзеп, юл сала.
Ә сазда — алар хәрәкәтсез кала,
Упкыннарга төшеп югала.

*Оренбур шәһәре*

# Әнвәр Шәрипов

## Әйләнәм дә кайтам Тукайга

Тигез генә бармый безнең тормыш,
Эш гел барып тормый уңайга...
Эш-гамәлләр авыр барган чакта,
Күңелемә азык кирәк чакта
Әйләнәм дә кайтам Тукайга.

Кулга алсам Тукай китапларын,
Күңелләрем китә яктырып.
Эзләп табам аның фикерләрен
Китап битләреннән актарып.

Көтмәгәндә авыр хәсрәт басса,
Күңел төшсә көнгә йә айга,—
Кайгыларны тизрәк басар өчен
Әйләнәм дә кайтам Тукайга.

Кайчагында уңыш та елмая,
Эшләр бара минем уңайга.
Шатлыкларны уртаклашыр өчен
Әйләнәм дә кайтам Тукайга.

Тукай — йолдыз, Тукай — идеал ул,
Минем өчен — Кояш һәм Аем!
...Тормышыңны дөрес кичәр өчен
Булсын икән шагыйрь Тукаең!

*1995 ел, 11 апрель.*
*Чаллы шәһәре.*

## Истанбул

Ташкын булып чаба машиналар,
Ташкын булып халык агыла.
Мәхшәр көне җиткәнме соң әллә,
Халык болай кая ашыга?

Истанбулның үзәк урамында
Басып торам, карап берүзем...
Мин бер бөртек монда, бер тузан кук,
Халык агыла, агыла күнозын.

Күпме кеше, күпме язмыш монда,
Күпме хисләр, күпме аһ-зарлар!..
Күпме шагыйрь язган бу шәһәрне,
Әле тагын күпме язарлар!..

Бертуктамый сату-алу монда.
Ниләр сатмый адәм баласы?!..
Кием сата, икмәк, йөзем сата,
Чишмә суы, китап, шигырь сата,—
Күз камаша, хәйран каласың...

Һәр урамы бөек базар моның,
Беренче кат — фәкать кибетләр...
Һәрберсе тик үз товарын мактый,—
Кирәкме ул сиңа, кирәкмәсме,—
Кил генә син монда, килеп ал!

Кычкыралар: «Кил, әфәндем, бакың!
Биш мең! Ун мең! Төрек лирасы!
Алыш-биреш яса! Кил, әйбер ал!
Нишләп басып, карап торасың!..»

Ирексездән мин дә кузгаламын,
Урам буйлап алга юл алам.
Мин — бер юлчы, халык арасына,
Ташкын эченә кереп югалам...

*Истанбул. 1993 ел, 16 сентябрь.*

## Фәридә Хаҗиева

* * *

Үземне эзләп йөрдем мин!—
Көтмәгәндә... сине таптым:
Пышылдап сихри сүзләрең,
Яшьлегемә алып кайттың.

Сине таптым... Ә үземне?—
Үземне... тагын югалттым:
Күзгә күктә атылган бер
Йолдыз халәтендә калдым.
...Сине — югалтмаска таптым!

* * *

Кая ашкынасың, сәгатем?
Яшәүдән, соң, туеп буламы?
Тау-тау эшне ташлап калдырып,
Әле нокта куеп буламы?

Эшләнмәгән эшләр күп әле —
Ашыктырма, сәгать, ашкынма.
Мәгънәсезгә вакыт уздыра
Койма астындагы таш кына...

Кеше гомерен саный мизгелләр,
Ашыктырма, кыска ул гомер.
Минем дә тынгысыз җаныма
Тынычлык бер килер ул, килер...

Әй, ашыкма әле, сәгатем,
Чират бер җитәсен мин аңлыйм.
Мыскал бәхет тапсам дөньяда,
Мин — Кояшы җирнең, ал таңның...

* * *

Минсез кичләреңне син санамадың,—
Ә мин көйдем, утсыз күмергә калдым...
Үз гаебеңне һичкайчан танымадың,—
Мин давылда синсез — җилкәнсез, ярым...

Диңгез тынар бер, җил-давыл шашса да;
Канаты сынган кош сыман калсам да,
Ялгыз итмәс мине — сагынуым уты,
Рухым сүнмәс — бүген кыен булса да...

* * *

Күпкатлы таш бу йортта да —
Биек... башым.

Тик уемда әллә нигә
Мин адаштым.

Гомер уза... Әле җирдә
(Көйсез — өзгәләнә үксез)
Ялгыз башым...
— Булмасмы, ди, чыннан да бер
Күккә ашып?!

Әле яшим:
Рухым — горур,
Биек — башым...

* * *

Үпкәләүләрдән туңа җан,
Бозга әйләнде яшьләрем.
Бер, эреп, түгелермен... йә
Яшеннәр булып яшьнәрмен!

Бер җылы караш табалсам,
Рәнҗешнең эзе дә калмас.
Буран уйнатырлык хистә
Әллә, димсез, көч табылмас?

Әле бер күрерсез: ярсып,
Ургылырмын, ташкын булып...
Әле боз да, яшь тә — җанда,
Сабыр савытым да — тулы!

* * *

«Елап яшәү — егет эше түгел»,—
Ә без туган — хатын-кыз булып.
Тик нишләтә алам сине, Дөнья?!—
Күңел катты синдә, боз булып...

«Елап яшәү — егет эше түгел»,—
Мин, хатын-кыз, яшим үземчә:
Кыйблам эзлим — юлдан кайтмый күңел,
Һәм ни кылыйм — һаман түзмичә.

«Елап яшәү — егет эше түгел»,—
Яшь — яшәртми хатын-кызны да...
Чын ир-егет сүзе эретә ала
Наздан мәхрүм күңел-бозны да!

*Казан.*

## Ринат Мәннан

* * *

Ачы җилләр исә урман ягыннан:
Калкып чыккан айның бите өшегән,
Кар көртләренә карый да моңая:
Ай да гүя көтә җылы — кешедән.

Ә кешенең синдә бер уе да юк,
Булса да ул сине җылыта алмый:
«Кулланучы» булып килгән дөньяга,
Тормышка ул ай-кояштай карамый.

...Тимер капкын куйды карга яшереп,
Шуңа «шатлык белән тулган» күңеле...
Ай югалды... күктән йолдыз атылды...
Ә, бәлки, ул — күз яше иде бүренең?!

### Бер уй

Сүзләр — әрем,
Тормыш — әрәм.
Кояш — күктә,
Хисләр — тирән.

* * *

Кеше кала Җирдә
Эше белән,
Ә Җир җафалана...
Кеше белән.

* * *

Күктә тургай сарый
Яздан шашып.
Бәлки, иске хисләр
Киткән — ташып?..

### Сагыну

Елатып яңгырларны,
Син киттең көзен...
Тау башында бер агач,
Моңсу — нәкъ үзем.

Юк, ул агач түгелдер —
Кан тамырларым...

Өзелмәде, тик артты —
Сагынуларым!

### Югалту

Егет чаклар, сиздермичә,
Атларын куган икән,
Бер дә үтмәс кебек иде —
Яшь гомер узган икән.

Бернәрсә дә кабатланмый,
Инде язлар да үзгә,
Хәтта шушы язгы җил дә —
Ике җил — икебезгә.

Син еракта, еллар кебек,
Белмим кайда калганың...
Кояш белән аерылыштым,
Ә Айны — табалмадым...

*Казан.*

## Фәүзия Төхбәтуллина

### Алмагач

Сындырганнар, алмалары өчен.
Явызлыктан гарипләнеп калган.
Җиргә чәчелеп калган алмаларга
Әйтерсең лә кәүсә каны тамган.

* * *

Битарафлык суын эчеп
Мәрткә китү — буламы?
Була ахры, андыйларны
Әрнетми Җир елавы.

* * *

Яшьлеккә хас дәртле, сихерле ут
Күзләреңнән тора бөркелеп.

Минем инде күптән көлгәнем юк,
Сиңа кушылып куйдым бер көлеп.

### Кар бөртеге

Әллә уйнап, әллә елап буранда,
Кар бөртеге бөтерелә урамда.
Кар бөртеге түгел ахры, мин бугай,
Урын табалмыйм җаныма гел шулай.

### Дус бул...

Син хөкемдар булма, булсаң дус бул,
Чын дуслыкның беләм бәһасен:
Йөрәгеңнең иң түреннән чыккан
Хис иң кыйммәт булыр — бәхәссез.

*Азнакай.*

## Гөлнур

### Таңда

Серле тынлык. Җилләр генә
Талгын исеп нидер сөйли.
Гүя алар табигатькә
Моңлы бишек көен көйли.

Күзен ачкан чәчәкләр дә.
Шатлык балкый һәрбер җанда.
Эх, вакытны туктаталсам,
Калыр идем мәңге — таңда!

### Яңгыр ява

Яңгыр ява. Һәр көз ява тора,
Юып үтә күңел керләрен;
Үзенчә ул, шаулап, сөйлидер күк
Җир йөзенең сихри серләрен.

Яңгыр ява, коеп яңгыр ява,
Ә мин торам һаман уйланып.

Җирнең яшерен матурлыгын тойдым,
Яңгыр асларында чыланып...

## Нигә икән?

Нигә икән бу дөньяда
Назлы сүзгә сусый күңел?
Янып сөю нигә газап,
Нигә икән бәхет түгел?

Ник төзәлми бу дөньяда
Йөрәктәге тирән яра?
Ник әрни ул, ник сызлана?
Бармы икән аңа дәва?

Ни өчен соң кайвакытта
Мәрхәмәтсез була язмыш?
Нигә икән бер мизгелгә
Онытылмый ачы сагыш?

Борчу катыш әрнү белән
Яшь гомерләр нигә ага?—
Шуңадырмы, күзләремнән
Әче, кайнар яшьләр тама...

Өзелеп сөю нигә газап?..
Нигә икән бәхет түгел?
Мең сорауга җавап эзли,
Тик табалмый гына күңел.

## Күзләр

Күзләр — күңел көзгеседер,
Күпме сер бар аларда:
Аңлау өчен кешеләрне
Кирәк күзгә карарга.

Балкыса бәхет кояшы
Күңел күгендә әгәр,
Шатлык-сөенеч нурлары
Күзләрдән сирпеләләр.

Йөрәкләрдә борчу булса,
Сагыш иңә күзләргә.
Таратырга шул сагышны
Җитә назлы сүзләр дә.

Күзләр сере бик тирәндә —
Йөрәкләргә тоташа.
Эчке дөньяга юллар да —
Бары тик күзләр аша...

Күзләр сүзләр кебек түгел:
Алар алдый белмиләр.

Күзләр — йөзнең йолдызлары,
Гел балкыйлар, сүнмиләр.

Аңлар өчен күңелләрне,
Укыр өчен җан серен,
Кирәк бары тик бер нәрсә:
Белергә күзләр телен.

* * *

Юл буенда — каен кызы,
Ап-ак күлмәк өсләрендә.
Язгы җилләр сарылалар
Аның сары чәчләренә.
Шул каенның ак тәненә
Кемдер салган тирән яра.
Ярасыннан, күз яшедәй,
Каен суы һаман тама.
Кулларына балта тотып,
Сусауларын явыз адәм
Каен суы белән түгел,
Баскан — каен каны белән.
Ак күлмәге каенкайның
Ак кәфенгә әйләнер дә,
Каен авар. Калыр бары
Кара каргыш ул бәндәгә.
Елый каен. Тели гүя,
Гомерен калган каеннарның:
Әллә юып алмакчымы
Яше белән кайгыларын?
Юл буенда — каен кызы.
Гомеркәе аның тагы
Бик аз калган. Шунсы авыр:
Ак каенда — кара кайгы.

*Актаныш районы, Пучы авылы.*

# ХАТЫН-КЫЗНЫҢ СЕРЛЕ ДӨНЬЯСЫ



**Иң әүвәле әңгәмәдәшебезнең кем икәнлеген әйтик: Бөтендөнья татар Конгрессының башкарма комитеты рәисе урынбасары, «Ак калфак» Бөтентатар хатын-кызлар берләшмәсе рәисәсе, «Татарстан хатын-кызлары» дигән иҗтимагый оешманың рәис урынбасары, Татарстан Президенты каршындагы «Ярлыкау» комиссиясе әгъзасы Роза ТУФИТУЛЛОВА. Роза ханым шушы оешмаларның һәркайсында иң нык ихтыярлы ирләрне дә шаккаттырырлык дәрәҗәдә, бабайларыбыз әйтмешли, җир җимертеп эшләп йөри. Барлык хезмәт вазифаларының иң өстене итеп Роза ханым үзенең «Сөембикә» журналына мөхәррирлек кылуын саный. Һәм хәзер, бөтен дөньяда хатын-кызлар өчен чыга торган бердәнбер татар журналының «Азат хатын» — «Сөембикә»нең туган көне — җитмеш еллыгы алдыннан Роза Туфитуллова белән шагыйрь ЗӨЛФӘТ сөйләшә.**

**Зөлфәт.** *Роза ханым, 1913 елда мохәррир Ягъкуб Хәлили әфәнде һәм аның җәмәгате Әсма Хәлилия ханым тырышлыгы белән дөньяга килгән бу матбаганың иң беренче исемен — «Сөембикә»не яңадан кайтару өчен Сез җан тартышып көрәштегез. Нәрсә, «Азат хатын» килеш калса, ярамас иде мени?*

**Роза Туфитуллова.** Ярамас иде! Заман башка, уй башка дигәндәй, беренчедән, мондый сорау куйыйк: хатыннар нидән азат булырга тиеш? Икенчедән, татар хатынының кайчан азат булганы бар? Өченчедән, хатыннар өчен генә чыга мыни бу журнал? Ә туташ-кызларыбызның мәнфәгатьләре кайсы матбагада чагылырга тиеш? Шуңа күрә без җәмгыятьтә сизелерлек үзгәрешләр башлангач, «Сөембикә» исемен кире кайтару турында җитди уйлана башладык. Гаять авыр эш булды бу... «Милләт! Милләт!» — дип йөрүче кайбер эшлекләләребез кискен таләп куйды: «Сөембикә» икән, журнал бары тик милли мәнфәгатькә генә хезмәт итсен! Ханбикә исеме — дәүләтчелек символы! Икенче яктан да таләп кырыс булды: хатын-кыз үзе генә белергә тиешле серләрне гавамга чыгарып җилпеп, итәк күтәреп сөйләшмәгез! Тагын бер таләп: хатын-кызлар өчен генә кирәкле киңәшләрне укыйсыбыз килә! Ярар, боларны хатын-кызларга ничек тә аңлатып булыр иде булуын. Әмма хакимиятебез бу исемгә каты кыя булып каршы басты! Ходайның рәхмәтедер инде, хәзер һәммәсе дә шушы исемгә ияләште шикелле.

**З.** *Безнең халыкның яктылыкка омтылышы һаман көрәшкә барып бәйләнә шул инде. Әнә, 1913 елда чыга башлаган «Сөембикә»не 1918 елда ябып та куйганнар. 22 битле журналның 115 саны гына чыгып калган...*

**Р. Т.** Аяныч хәл, әлбәттә. Әмма, аның каравы, татар халкы яшь торган бүтән төбәкләрдә хатын-кыз басмаларын ача башлаганнар. Әйтик, Хаҗитархан (Әстерхан) төбәгендә «Азат хатын» дигән журнал тарала башлый.

Уку-язу ягыннан халкыбыз Рәсәйдә алдынгы урынны тоткан. Инкыйлабка чаклы дистәләп ел эчендә 120 тирәсе татарча гәзит-журнал илгә таралган. Һәр гаилә гәзит-журнал алдырып укыган.

**З.** *Роза ханым! Тәгаен генә бер теманы ачыклап китик әле. Мондый журналның бүген кемгә кирәге бар? Халыкка Сез ни әйтмәкче буласыз?*

**Р. Т.** Тәгаен сорауларга тәгаен җавап бирәм. Без хатын-кызны асыл халәтенә кайтарырга омтылабыз. Һаман саен ирләр урынына чабарга да, ир-ат күтәрә алмастай йөкне күтәрергә тиеш түгел ләбаса татар хатын-кызы!

Һәм, ниһаять, гомерем буена йөрәгемдә кайнаган бер хис, теләк, фикер алгысытып яшәтә мине: татар хатыны милләтебезнең таза-сау генофондын булдырырга тиеш! Әйе, Милли генофонд — менә кайда хатын-кызларыбызның төп миссиясе. Балаларыбыз мәгърифәтле аналардан тусын. Шул чагында гына милләтебезнең, әгәр шулай әйтергә яраса, сыйфаты яхшырыр, халкыбыз күңеленә нур иңәр.

Ә без хәзер хатын-кызларыбызга бүтән фикер сеңдерергә тырышабыз: ул үз язмышын үзе сайласын, аңлап сайласын.

**З.** *Акыл ирешмәстәй идеаль хатын-кыз хакында сөйлисез түгелме соң Сез, Роза ханым?*

**Р. Т.** Ә нишләп акыл ирешмәслек идеал булсын ул? Без шуңа омтылырга тиеш. «Сөембикә» тарафыннан 1993 елда уздырылган «Гыйффәт туташ» исемле зур бәйге-тамаша хакында «Российская газета» болай дип язды: «Бөтен дөньяда беренче тапкыр буларак, татарларның хатын-кыз журналы хатын-кызның күңел ямен ачыкларга омтылды. Бу омтылышны дөнья халыклары өчен үрнәк итәргә иде. Гыйффәтлелек — җан сафлыгы дигән сүз ул. Күкрәкнең, арт санның «матурлыгын» күрсәтеп мактанышка торган конкурслар мондый гүзәл бәйрәм янәшәсендә чүп кенә булып кала.

**З.** *Сез оештырган тамашалар гел аклыкка, сафлыкка бәйле. Белгәнемчә, әлегә эшкә ашмый калган тагын ике бәйге-тамашагыз бар бугай: «Ханымсолтаным», «Акъәби»... Сез укыткан мондый «дәресләр»дән кызлар азмы-күпме сабак алamы соң?*

**Р. Т.** Редакция архивында без уздырган бәйге-тамашаларны хуплап, кызыксынып, белергә-өйрәнергә теләп язылган 24 меңгә якын хат саклана. Безнең өчен бик кадерле хатлар алар.

Безнең халыкның югалып бара торган рухи хәзинәләре байтак. Хатын-кызларыбыз аларны һичшиксез белергә, өйрәнергә, сакларга тиеш. Һәм, барыннан да бигрәк, үзләренең гаилә учагын, тормыш учагын саклаучы зат булуын һәрдаим тоеп яшәргә тиеш.

**З.** *Татарлар, бигрәк тә мишәрләр, яраткан кешесенә «канатем» диеп сөеп эндәшә...*

**Р. Т.** Менә шул сөеп эндәшә белүне югалта барган саен халыкның дәрәҗәсе төшә бара да шул инде. Ир белән хатын арасында наз, хөрмәт югала. Әнә шул ихлас хисләрне яңартасы иде. Ирне ир иткән дә — хатын, чир иткән дә хатын, диләр түгелме соң?

**З.** *Журналда шушы хакта хатын-кызлар ачыктан-ачык, сер яшермәстән сөйләшә башласа...*

**Р. Т.** Уйладык без бу хакта, Зөлфәт. «Татар кызы, сылуым-иркәм!» — дип аталган рубрика булыр ул. Сорауларны турыдан-туры куябыз. Син парыңның нинди булуын телисең? Сиңа нинди ир кирәк? Ничә бала табасың килә? Яратышу серләрен сиңа кем өйрәтте? Ир хатыны булырга син тулаем әзерме? Без бу рубрикада әнә шундый сорауларга җавап табарга тырышачакбыз.

**З.** *Безнең халык андый сүзләрне уртага салып сөйләшергә күнекмәгән бит. Кайберәүләр рәнҗемәсме? Ялгыш аңламаслармы?*

**Р. Т.** Рәнҗүчеләр табылыр, билгеле. Ә киресен сукалаучылар болай да җитәрлек. Югыйсә, уйлап карыйк, безнең яшь кызларның күпчелеге нишләп бала таба алмыйча җәфалана? Чөнки мәхәббәт, яратышу тәрбиясе юк. Мәхәббәтле ата-анадан гына сөйкемле, сәләтле бала туарга мөмкин. Көнбатышка ияреп «сикерүдән» милләт сафланмас. Журналыбызның шул хакта сөйләвен телим. Һәм бер нәрсәгә сөенәм — безнең идеялар торган саен ераккарак тарала тора. Чәчкән орлыкларыбыз җимеш бирә башлады. Яшь хатын-кызларыбыз бу хәлләргә кагылышлы җавапларны «Сөембикә»дән табарга тиеш бит. Хәер, татар дөньясында бу хакта сөйләрдәй матбагалар ишәя башлады. «Сөембикә»нең «кыз балалары» туды. Түməндә «Ак калфак» дигән басма чыга башлады, Омск шәһәрендә — «Зәңгәр шәл», Симәйдә — Семипалатта — «Галиябану»... Исемнәре генә ни тора!

**З.** *Сезнең борынгы гореф-гадәтләребезне яңартырга омтылуыгызны «архаика» дип тиргәмиләрме?*

**Р. Т.** Кем ничек бәһали бит... Әйткәнемчә, акъәбиләр аз калды инде. Аларның бәйрәмен махсус уздырасы иде. Соң булуы бар. «Әбием сандыгы» — безнең гореф-гадәт сандыгы. Без аны «Гыйффәт туташ» кичәсендә юкка гына сәхнәгә чыгардыкмы әллә? Андагы сандыкны ачкан кызлар күптәннән бирле инде уңган килен булып дөнья көтеп ятадыр. Кызык бит... Әйтик, гап-гади аяк чолгавы... Яшь киленнәр ирләренә — чиккән чолгау бүләк итә торган булган. Кульяулыгы хакында түгел, чолгау хакында сүз бара!




**З.** *Димәк, ачыктан-ачык әйтик, хатын ирен ни белән үзенә җәлеп итәргә тиеш?*

**Р. Т.** Иң әүвәле, ризыгың тәмле булсын! Икенчесе — иреңнең аягы мамыкта булсын! Бусы — ирне көйләү сере! Нәкъ менә шуларны күздә тотып, без халыкның йөрәгенә ятып калырдай тамашалар уздырырга булдык. Кызлар өчен — «Аулагөй», киленнәр өчен — «Утырма»! Бусында киленнәрне кайнанага ничегрәк ярарга өйрәттек.

**З.** *Сез матбугаттагы бер әңгәмәгездә чорыбызның акыл иясе хатын-кызларының берсе булган Елена Рерихка зур бәһа биргән идегез.*

**Р. Т.** Әйе, соңгы зур сугышны булдырмый калу өчен аның кадәр зур көч түккән кеше булдымы икән? 1936 елда ук ул иң җаваплы дәүләт башлыкларына дәшә: «Адәм заты — очар кош шикелле... Без сыңар канатта гына оча алмабыз...» Аның шушы рәнҗеп әйткән сүзләренә иң асыл җавапны Франклин Рузвельт кына бирә. Ул болай дигән: «Дөнья халкы кайчан да булса Сезнең фикерләрне хуплар, мөгаен. Әмма илләр-халыклар әле Сез әйткәнне аңларлык дәрәҗәдә үк түгел». Монда әлбәттә, кошелекнең икенче канаты — хатын-кыз хакында сүз бара.

Уйлап карасаң, безнең татар да һаман шул ук сыңар канатта очып маташа. Хатын-кыз канаты һаман җилпенми бит!

**З.** *Роза ханым, мин Сезне аңладым шикелле. Сез әйтергә теләгән фикергә мин һич тә каршы түгел. Җиһаныбызны хатын-кыз идарә итсә, доньялар күркәмрәк булыр иде, бәлки. Әйтик, оборона министры хатын-кыз булган ил күршеләренә сугыш белән керер идеме?*

**Р. Т.** Бу хакта теләсәң, теләмәсәң дә уйланырга туры килә. Әнә, Ирландия белән Норвегия идарә йөгәнен хатын-кыз кулына бирде. Очраклы хәлме бу? Затлы гаиләләр, затлы илләр хатын-кызга таяна. Һәм алар, минемчә, моның белән һич кенә дә оттырмый.

**З.** *Сезнең мондый бер фикерегез халыкка мәгълүм: «...акрынлап кына булса да патриархатка алмашка биархат чоры, ягъни җәмгыятьне пар канатлы итәргә, камилләштерергә омтылу чоры якынлаша... Җәмгыятебез... бүген фәрештәсез калган ташландык йортны хәтерләтә». Роза ханым, бу фикерегездән бүген баш тартмадыгызмы?*

**Р. Т.** Дөньялар юньлегә үзгәрсә, шунда ук баш тартыр идем. Әмма, хатын-кыздан башка гына ил-йортыбызны юньгә китереп булмас шикелле. Мин бу хакта бер генә тапкыр әйтмәдем. Чөнки әйтми калу мөмкин түгел!

**З.** *Димәк, Сөембикә исемен яңадан матбугат доньясына кайтаруыгыз да юкка түгел?*

**Р. Т.** Моны тарих үзе бәяләр.

**З.** *Бәйрәмегез мобарәк булсын, Роза ханым! Гел шулай зур, дәрәҗәле булып калырга язсын «Сөембикә»гә!*

**Р. Т.** Безнең максат бер генә: милләтебезгә, тарихыбызга мәхәббәт яңарсын, «Без — татар!» — дип горурланып яшәргә язсын. Һәммәгез дә аңлап торсын: янәшәгездә хатын-кыз яши һәм аның серле дөньясы бар!..

Нәҗибә Сафина

# Ә СҮЗ БИРМИЛӘР...

Хәзер дә шулай микән, ә безгә ул чакта, Казан Дәүләт университетына укырга керергә килгән абитуриентларга, бәхет ак мәрмәр баганалы тылсымлы бина булып гәүдәләнде. Безнең өметләр, күңелләр кебек ак иде ул колонналар, безнең кебек ямь-яшел иде ак бина янына тезелгән юкәләр. Елы нинди ел иде бит аның! 1967 ел — безнең татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга кергәннәр язмышында иң олы тарихи дата. 467 төркем исеме белән безне ак бәхет кочагына алган ел иде.

Монысы — беренче хисләр, беренче тәэсирләр. Аннан соң инде шул аклык кочагында чын бәхетле булу өчен кирәк булган гыйлем эстәү, дөньяны тану, үзеңне дөнья белән таныштыру башланды.

Ул елларда гыйльми дөньяга керү бәрәңге басуы аша башкарыла иде. Әмма мин беренче курсның танышу семестрында — бәрәңге алуда катнаша алмый калдым. Чакыру соңлап кына килеп җитте. Шуңа күрә укуның беренче көннәрендә үземне сабакташларымнан читтәрәк хис иттем. Беренче лекция дип, төркемнең җитәкчесе белән танышуга җыелгач та, ишек янындагы бер буш калган урынга соңгы кеше булып кына килеп утырдым.

Каршы өстәл артында утырган укытучы кискен хәрәкәт белән башын күтәрде һәм күз карашы белән аудиториядәге гөжләүне кисте дә төшерде. Менә ул торып басты да, йә, ни әйтерсез инде дигәндәй, кырыс күз карашы белән һәммәбезне сыйпап, юк, көйдереп үтте. Миңа аның күзлек астындагы күзләре дә, нәкъ мыеклары төсле, коңгырт һәм чәнечкеле кебек тоелды. Ул — интектерә-интектерә миннән керү имтиханы алган профессор Ибраһим ага Нуруллин иде. Ничек танымыйсың! Әллә сәгатьтән артык аның каршысында Һади Такташның «Тапшырылмаган хатлар»ының ни өчен тапшырылмаганын, ни өчен алай аталганын аңлата-аңлата арып беткәч (аңламый гына бит профессор), кызып киткәнне дә сизмәстән:

— Ни-нәрсәсе бар инде аның, просто литературный прием гына инде ул. Кирәк икән, пажалысты, мин аны сезгә уптым илаһи яттан сөйләп бирәм, әле үзегез дә белеп бетермисездер,— дип тезеп киткән идем. Шушы урында ул мине бертуган абыем шикелле үк гап-гади итеп:— Укы әйдә, вакыт бар ич,— дип куймасынмы!

Укыдым. Аның күзлек астындагы кырыс карашы моңсулана, мыеклары йомшара барганын тоя-тоя укыдым. Укып бетерүгә ул:

— Шул әдәби алым дигән җавапны бирер өчен ярты сәгать вакытыңны үткәрдең, анда да татарчасын әйтмәдең. Ә яттан белгәнеңне болай да аңлаган идем инде,— дип елмаеп ук җибәрде.

Без бу имтиханны тапшырып чыкканда Казан урамнарында инде кара төн иде.

Ул чакта мин: «Әстәгъфирулла, шундый кеше дә елмая белә микәнни»,— дип уйлап куйган идем. Менә хәзер тагы аның кысык иреннәре арасыннан елмаюга охшаган галәмәт таралды. Юк, иреннәре белән түгел, ул күзләре белән елмая икән бит. Имтихан вакытында, куркудандыр инде, күзләренә күтәрелеп карамаганмын, күрәсең.

Ибраһим аганың кулында безнең төркемнең исемлеге булгандыр. Ул бер кәгазьгә, бер безгә күтәрелеп карый-карый:

— Мин сезнең төркемнең акдем җитәкчесе булам инде, әйдәгез, таныш ыйк,— дип, янә кәгазьгә текәлде. Нәкъ мәктәптәгечә берәм-берәм исем-фамилияләребезне атый, танып калырга тырышып йөзләребезгә текәлә. Исем аталуга, ялт итеп мин дә сикереп торып бастым. Ул миннән дә, ничә яшь, дип сорауга, «унсигез» дигән идем, аның йөзе тулы савытны чайпалткандайрак түгелеп китте.

— Бар, паспортыңны алып кил, монда егетләрне шаяртып тормыйсың,— дип, кулы белән, чыгып китегез, дигән үк хәрәкәт ясамасынмы! Дәрес дигәннәре беткәндерме, юкмыдыр, мин чыгып йөгердем. Трамвайга утырып тормыйча гына, әлегәчә бер тапкыр да йөрмәгән туры юллардан гына Тельман урамына чаптым. Тулай торак тәтемәгәч, шунда фатирга урнашкан идем. Сулуыма кабып паспортымны тотып килеп кергәндә, аудиториядән студентлар чыгып бетеп килә. Ә профессор исә, студентларның чыгып беткәннәрен көтептер инде, кулына папкасын тоткан килеш торып баскан иде. Никләр генә шулкадәр дулкынланганмындыр, калтырый-калтырый аңа паспортымны сузам. Ибраһим ага аны ачып карады да карашын миңа төбәп тынып торгач:

— Сезнең белән әллә бер-бер фаҗига булдымы?— дип сорап куйды. Шуннан соң гына мин беренче тапкыр телгә килеп:

— Ник?— дип сорый алдым. Ул миңа инде бер егерме биш яшьләр бардыр дип уйлаган икән.



Башкача ул бу хакта сүз кузгатмады. Мин дә бөтенләй диярлек оныттым. Ә миңа исә Ибраһим ага, киресенчә, үз яшеннән яшьрәк тоела иде. Профессорга тиздән кушамат та беркеттек. Аны Аксак Тимер, ә инде яһүд профессорларының «Волга»лары янында тәтәй кашыктай гына күренгән аның «Запорожец»ын «ташбака» дип йөртә башладык.

Лекцияләргә килеп кергәндә миңа аның бар торышында: «Йәгез, тагын бер укталып карыйк әле, бер-бер эш чыгарып булмасмы?» — дигән фикер укый идем. Һәм ул миңа университет укытучылары арасында иң аңлаешлы шәхесләрнең берсенә әверелде.

XIX йөз ахыры — XX йөз башы әдәбияты. Хәзер шул сүзләрне кабатлыйм да янә бер ачыш ясыйм: заман сынылышы әдәбиятын укыткан икән ул безгә. Әллә хәзер сынмый торганы бармы соң ул заманнарның! Ә Ибраһим ага нәкъ шул сынылыш эчендә безнең — студентларның рухын сындырмый, сау заманга алып барырга тырышучы гаҗәеп бер шәхес булган икән.

Башка студентларга төрлечә булырга мөмкин, ә мин университетта укыганда Хатыйп ага Госман аша бәйдәге хисләремә очыш алсам, Ибраһим ага Нуруллин аша бикләнгән, тыелган фикерләремә бәйсезлек яуладым. Чөнки, әдәбият дәресләре башлануга, Ибраһим ага белән минем арада рухи һәм фикри күпер салынды. Лекция барышында мин аның фикер агышын дәвам итсәм, еш кына ул минем фикерләремне ачыктан-ачык сөйләп таң калдыра иде. Ул, кайбер укытучылар шикелле, бервакытта да язганын укып яки шушы дәрестә сөйләргә тиешлесен генә сөйләп чыгып китми. Аның өчен иң зур казаныш — студентларның уй агышын тоту, аларга ияреп үз фикерен бирү булгандыр. Еш кына шуңа ирешү өчен лекцияләрне күңелсез генә сукмакларга да борып кертә иде ул. «Нуруллин лекцияләрне күңелсез үткәрә икән»,— кебек сүзләрне без, студентлар, чыбыксыз телефон аша ишеткәли идек. Бу сүзләрнең асылын аңларга миңа Мөхәммәт ага Мәһдиев дәресләре булышты. Алары чын спектакль-дәресләр булса, Ибраһим аганың дәресләре тормышның шәп-шәрә үзе булып үтәләр иде.

Ибраһим ага бер лекция барышында 20—30 сорау куя һәм шуларга студентлардан җавап та ала белә иде. Әйе, әле бөтенләй яңа тема, яңа әсәрләр, ә без сөйлибез, җавапларны табабыз.

Шулай бер дәрестә матур әдәбиятның функцияләре турында сөйли профессор. Әй әйттерергә тырыша бу әдәбиятның функцияләрен. Без әйтмибез генә бит инде. Шулчак ул урындыгын ук борып минем якка карап утырды да сорауның башламын җентекләп биргәч:

— Шуннан соң мондый сорау туа, туарга мөмкин, Сафина? — дип күз карашы белән мине өтеп алды. Мин шуннан соң инде лекция буе туарга мөмкин булган сорауларны кычкырып әйтеп бардым. Бергәләп шул сорауларга җавап та бирә бардык, әлбәттә. Сүз әдәбиятның танып-белү һәм тәрбияви функциясенә җиткәч, Ибраһим ага авыз эчендә әллә нәрсәләрне чәйнәп йоттымы, йомшарттымы, аннары бер тын иреннәрен кысып торды һәм:

— Әйе, танып-белү һәм тәрбияви функцияләр дә үти иде ул,— дип шаклар катырды. Мин теге вакытта керү имтиханындагы ачу белән диярлек:

— Әле дә шундый ук функцияләрне үтәмимени? — дип кычкырып ук җибәргәнемне сизми дә калдым. Ибраһим аганың иреннәре язылып китте. Ул теләгенә ирешкән иде.

Менә шушы лекциядән соң инде безнең арада чын тормышчан сөйләшү башланды. Әдәбиятның, тарихның ни дәрәҗәдә хакыйкатькә тәңгәл килергә мөмкин яисә мөмкин түгеллеген, ни рәвешле кешеләрне генә түгел, тарихны да төрмәләргә, зинданнарга ябарга мөмкин икәнлеген мин беренче булып аннан ишеттем. Ә иң авыры — ул миңа 18 яшьлек кызга, ачы хакыйкатьне шушы үзебез яшәгән мохиттән алып күрсәтә, мине тамчы да кызганмый иде шикелле. Чөнки ул минем шушы хакыйкатьне кабул итә алмыйча, кабул итәсе килмичә төннәр буе газаплануымны, елый-елый шигырьләр язуымны белми иде. Үзем дә аны бик нык яшерә идем шул. Әле дә яшерер идем, җанга битлек кидереп буламыни?

Минем Ибраһим ага дигән күңел сердәшем шулай бар булды. Ул миңа көн саен, очрашкан саен диярлек бер яңалык, бер дөнья ача иде. Бер көнне ул миннән:

— Әллә син бар күрсәтелгән әдәбиятны укып барасыңмы? — дип сорады.

— Почти,— дидем мин уңайсызланып кына.

— Алайса, син Альберт Фәтхиев янына бар, ул сиңа тагы китаплар бирер,— диде.

Сирәк китаплар бүлегенә йөрүем шулай башланды. Биредә укылган һәр әсәр, һәр мәкалә шулай ук безнең бәхәс җисеменә әйләнә иде. Өстәвенә, мин монда тагы бер кызыклы да, кыен да бер шәхесне — Альберт Фәтхи дигән дөньяны ачтым. Шунда хакыйкатьнең никадәр тирәнгә яшерелгәнлеген тагы да ныграк аңлый башладым. Аңлаган саен ныграк аптырыйм, аңлаган саен тына, сүзсезрәк була бардым. Әкренләп-әкренләп тормышның — минем мантыйкка, ә минем — тормыш мантыйгына туры килмәвем, буйсынмавым ачыкланды. Мин, дөньяның мантыйгы нинди, димәк, законнары да шундый, дигән авыр ачыш ясадым. Тора-бара мин дә иреннәремне чәйни башладым. Чәйнәдем дә йоттым, чәйнәдем дә йоттым һәм... үз дөньяма кереп киттем.

Мин бу хисләремне дә Ибраһим агага күпмедер сиздергән идем, ул мәкаль сыманрак тезмә белән җавап бирде:

— Тормыш бик җиңел узса, баштагы акыл тиз туза.

Мин бу сүзләрне башка бер китаптан да тапмадым, үз сүзләре булган, күрәсең. Ул тагы да озак кына авыз эчендә әллә тормышның каты почмакларын чәйнәп йомшартып торды, аннары гына әйтеп куйды:

— Сиңа яшәү җиңел булмас. Тик син кыз бала, бәхетле булырга да тиеш әле. Бәхетнең ни икәнен белмәгән кешеләрнең башкаларга бәхет өләшергә маташуыннан болганган бу дөнья. Син шул болганчык суда тотылырга тиешле балык булма инде.

Мин бу сүзләрне соры тышлы дәфтәремә сүзмә-сүз язып куйганмын. Һәм менә аның җан халәтенең кабатланышына хәйран калып утырам. Әле шул ук дәфтәрдә: «Үз-үзеңне генә алдама, калганнарныкын аңлап, кичереп була»,— дигәннәре дә бар. Тагы уйлар, тагы фикерләр... Ягъни бу минем аның лекциясен язуым булган инде. Ә күпме уй-фикерләр безгә, яшьләр колагына, эленмичә яшендәй яшьнәп кенә узып киткән.

Мин Ибраһим ага җитәкчелегендә курс эше дә, диплом эше дә яздым. Диплом эшенең темасы әдәбият теориясен мәктәптә укытуга багышланган иде. Мөхәммәт ага Гайнуллин төзегән дәреслектәге методикага каршы килгән булып чыкты ул диплом эше. Мөхәммәт ага исә үзе үк диплом яклау комиссиясенең рәисе булган икән. Диплом эшенә билге куяр алдыннан Мөхәммәт ага Гайнуллин белән Ибраһим ага Нуруллин коридор почмагына чыгып та бик авыр сөйләшү алып бардылар. Мин инде «шулкадәр начар яздым микәнни?» дип котым купкан хәлдә, ни гөнаһ булса да, аларның тарткалашуын тыңлап торырга мәҗбүр идем. Ибраһим аганың таягын селтәп, тавышын күтәрә төшеп әйткән сүзе шул булды:

— Куй «икеле»... Минем фикергә туры килми диген!

Шушы сүзләрне ишетүгә, диплом яклагач, җитәкчемә бүләк итәрмен, дип алып килгән гөлчәчәкләремне ныграк кысып тоттым бугай, энәсе кулыма кадалды. Юк, кычкырып җибәрмәдем. Лобачевский бакчасына чыгып утырып, розаларның энәләрен кечкенә кайчы белән соңгысынача кыркып бетердем. Тик тормыш энәләрен алай гына кискәләп булмаганлыгын аңлап калдым ул чакта.

Ибраһим ага миңа фән өлкәсендә өмет баглаган, күрәсең. Казанда калырга өндәп, «Чаян» журналына эшкә тәкъдим итүче дә, аспирантурага имтиханнар тапшырырга чакыручы да ул булды. Тик тормыш мантыйгы мине үзенә буйсындырырга тырыша, ә мин — вөҗдан колы. Үз авырлыкларымны кемгәдер салу турында уйлап та карый алмыйм. Ибраһим ага әйтмешли, мин — кыз бала, мин — хатын-кыз, мин — ана, бәхетле булырга тиеш ич әле. СССР кануннары нигезендә, хатын-кызның ир-ат белән тигезлеге «мантыйгы»на буйсынып, баласын да үзем бактым, торагын да, азыгын да үзем таптым. Үзем ир, үзем хатын булдым дигәндәй, үзем уйладым, үзем еладым. Күз яшьләре авыр бит ул. Аның тамчылары кеше гомеренә тора. Шул яшьләр башны түбәнгә тартып торганда аны кешечә горур күтәреп йөртү кыен икән шул.

Ибраһим ага үлде диделәр — ышанмадым. Кеше ятып тормыймыни? Арыгандыр. Бу кадәр каршылыклар аша бару — кешегә түгел, машинага да авыр. Әнә ул минем күз алдымда Татар Иҗтимагый үзәгенең съездында Камал театры сәхнәсенең баскычында, дога өмет иткән әрвахтай, кулына нотыгын тотып, сүз сорап утыра. Гаяз Исхакыйны кайтару иде аның максаты. Ә сүз бирмиләр. Чөнки күп нәрсәләр, хакыйкатькә туры килсә дә, түрәләрнең фикерләренә туры килми. Дөнья бүген дә менә шушы мантыйктан тиберчена. Бу — миңа остазымнан күчкән мантыйгым. Мин Ибраһим аганы әтиемдәй якын сердәш, киңәшче, акыл иясе, киңәшче итеп тә яратканмын икән. Аны мин генә түгел, бөтен сабакташларым да аңлый, ярата иде ләбаса. Аңлашылмаган кешене яратып буламыни? Без — аннан, ул — бездән рәхәтләнеп кенә дә ала идек бит әле. Ә моның өчен җаннар арасында күпме якынлык булырга тиеш.

Әйе, Ибраһим атлы бер җайсыз шәхеснең йөрәге тибүдән туктады. Һәм ул 1995 ел минем өчен иң зур югалтулар китергән авыр ел булды. Ул китте, тик дөньясы гына барыбер җайланмады. Ахрысы, ул дөнья дигәннәре җайсызлар мантыйгыннан ерагая барган саен җайсызлана, тагы да ныграк җайсызлана бара.

Минем бүген шул хакта остазым Ибраһим агага бик тә әйтәсем килә. Тик хатларым барып җитмәстер шул инде.

# ӘДИПНЕҢ ФАҖИГАСЕ



Мәхмүт Галәү. Утызынчы еллар.

Гасыр башында ук кулына каләм алып, халыкка мәгърифәт тарату юлында армый-талмый хезмәт иткән һәм, ниһаять, әдәби әсәрләре, бигрәк тә «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» исемле тарихи романнары белән татар әдәбияты хәзинәсенә зур өлеш керткән бу талант иясенең абруйлы исеме һәм иҗат мирасы совет чорында озак еллар буе халыктан яшереп яткырылды. Алай гына да түгел, ул мирасның шактый өлеше тоталитар режим шартларында бөтенләй юкка ук чыкты. Бу яктан Мәхмүт Галәүнең катлаулы тормыш юлы һәм фаҗигале язмышы утызынчы еллардагы репрессияләр шаукымында нахактан һәлак ителгән татар мәдәнияте эшлеклеләренең күпчелегенең язмышына охшаш.

Тумышы белән ул татарның бөек мәгърифәтчесе, тарихчы-галим Шиһабетдин Мәрҗанигә шактый якын кардәш туры килә. Әдипнең бабасы — Ш. Мәрҗанинең бертуган энесе. Октябрь инкыйлабына кадәр Мәхмүт Галәү үзе дә, әдип һәм журналист буларак, язган әсәрләрен «Мәрҗани» имзасы белән бастырган.

М. Галәүнең туган җире — Татарстанның хәзерге Арча районындагы Ташкичү авылы. Шунда әтисе Галәветдин хәлфәдән укып — башлангыч мәктәпне, аннары Казанда гали мәдрәсә тәмамлаганнан соң, унҗиде яшьлек егет 1903 елны үз көнен үзе күрергә дип, Әстерхан шәһәренә юл тота һәм шундагы татар мәктәпләренең берсендә мөгаллим булып эшли башлый. Әстерханда М. Галәү 1907 елның ахырларына кадәр яши. Шушы өч-дүрт ел дәвамында шәһәрнең хөр фикерле зыялы шәхесләре белән даими аралашып яшәү, төбәктәге демократик рухлы мөселман яшьләре оештырган төрле милли-мәдәни һәм әдәбият-сәнгать кичәләрендә, театр тамашаларында катнашу, яшерен җәмгыять җыелышларына йөрү, әлбәттә, яшь егетнең дөньяга карашы, иҗтимагый-сәяси омтылышларының билгеле бер юнәлештә формалашуына ярдәм итә. Моның өстенә, Бакуда чыга торган «Шәркый рус» һәм 1906 елдан Әстерханның үзендә нәшер ителә башлаган «Борһанел тәрәкъкый» газеталәренә мәкаләләр язып, 1907 елда исә «Туп» исемле көлке журналын оештыруда һәм чыгарышуда якыннан катнашып, М. Галәү журналистика өлкәсендә дә яхшы ук тәҗрибә туплый.

Милли-мәдәни җәмгыятьләр һәм сул юнәлештәге яшерен оешмалар белән элемтәдә торганы, бигрәк тә беренче саныннан ук шик астына алынган һәм өченче саныннан бөтенләй туктатылган «Туп» журналын чыгарышуда катнашканы өчен М. Галәү Әстерхан охранкасы тарафыннан эзәрлекләнә башлый һәм даими күзәтү астына алына; тора-бара охранка аны мәктәптә балалар укыту хокукыннан да мәхрүм итүгә ирешә. Тормышны алып бару өчен зарури соңгы матди чыганак урыныннан — мөгаллимлек эшеннән дә куылган М. Галәү, ниһаять, 1907 елның ахырларында Әстерханны ташлап, Оренбур шәһәренә күчеп китә.

Оренбур чоры (1907—1918) М. Галәү гомеренең тышкы яктан иң тыныч, хәвефсез, эш һәм иҗат өчен шактый киң мәйдан, мөмкинлекләр ачылган еллары булгандыр дияргә тулы нигез бар. Бердән, Оренбур шәһәре ул чор татар мәдәниятенең иң эре үзәкләреннән берсе санала. Монда күпсанлы татар укымышлыларының, әдәбият, мәдәният эшлеклеләренең бишеге булган атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсе, 1900 елда ук Гыйльман Кәрими нигез салган һәм үз эшчәнлеген елдан-ел җәелдерә барган татар матбагасы урнашкан. Тормышның һәр өлкәсе, дөньядагы һәр яңалык, үзгәреш турында объектив мәгълүматлары белән укучыларын даими таныштыра барып, татар халкының үзаңы үсүенә, милли, иҗтимагый-сәяси карашлары чарлануына гаять уңай йогынты ясаган мәшһүр «Вакыт» газетасе һәм «Шура» журналы да шушы шәһәрдә чыгып килә. Шулай ук монда XX йөз башы татар әдәбиятының күренекле вәкилләре — Дәрдемәнд, Ф. Кәрими, Ш. Мөхәммәдев, Ш. Камал, Җ. Вәлиди, Г. Сәгъди, С. Сүнчәләй, Я. Вәли, Б. Шәрәф, К. Бәкер, Р. Фәхретдин һ. б. яши. Даими яшәү урыны итеп Оренбурны сайлаганда М. Галәүнең бу фактларны күздә тотуы, әлбәттә, бик табигый.

Оренбурга күчеп килгәч тә, ул атаклы «Кәримев-Хөсәеневләр» китап басу һәм сәүдә ширкәтенең матбагасына хәреф җыючы һәм корректор булып эшкә урнаша. Соңрак, 1909—1913 еллар арасында, шул ук ширкәтнең китап кибетендә сатучы булып эшли, ә 1914 елда «Белек» исемендә хосусый нәшрият ачып, 1918 елга кадәр аның эшенә җитәкчелек итә. Оренбурда М. Галәүнең журналистлык һәм публицистик эшчәнлеге тагы да киңрәк колач ала. Үзенең икърар итүенчә, ул «инкыйлабка кадәр чыккан барлык татарча газитә һәм әдәби журналларга языша». 1915—1918 елларда үз наширлегендә һәм мөхәррирлегендә нәшер ителгән «Кармак» журналы саннарындагы материалларның — мәкалә, әдәби парча, фельетоннарның да байтагы аның үзе тарафыннан языла. «Кәримев-Хөсәеневләр» китап ширкәте бастырган һәм «Белек» нәшрияты заказы белән чыккан китапларны пропагандалау максаты белән, ул көндәлек матбугат битләрендә әледән-әле шәрехләп язылган игълан-мәкаләләрен бирен бара. Әдәби тәнкыйть һәм публицистика жанрындагы мәкаләләре белән ул үзен тирән белемле, нечкә зәвыклы әдәбиятчы итеп таныта.

Үз кул астындагы хосусый нәшрият мөмкинлекләреннән файдаланып, М. Галәү популяр характердагы фәнни рисаләләр, уку-укыту кулланмалары, дәреслекләр бастырып чыгаруга зур игътибар итә. Бу төр басмалар арасында аның үзе төзеп яки тәрҗемә итеп чыгарганнары да бар. «Төрки сарыфы» (1910) исемле татар теленең морфология дәреслеге, табигать, хезмәт, бала тәрбиясе һәм төрле һөнәрләр турындагы хикәяләрдән ике кисәк итеп төзелгән «Төрки уку» китабы (1911) әнә шундыйлардан.

М. Галәү иҗат эшчәнлегенең бу чордагы тагы бер тармагы — тәрҗемәләр. Ул рус классик язучыларыннан А. Пушкинның «Буран» хикәясен, Л. Толстойның атаклы «Хаҗи Морат» повесте белән «Крейцер сонатасы» хикәясен, поэзиядән А. Пушкин, К. Батюшков, М. Лермонтовларның аерым шигырьләрен, шул җөмләдән Лермонтовның «Пушкинның вафатына» исемле мәшһүр шигырен татар теленә тәрҗемә итә. Соңыннан шигъри тәрҗемәләре, М. Галәүнең үз шигырьләре белән бергә тупланып, 1912 елны Оренбурда «Ник язылганнар?» исеме астында аерым җыентык булып басылып чыга. Җыентыкка язган кереш сүзендә үзенең шигъри тәҗрибәләре турында автор болай ди: «Кулына каләм тота белгән һәрбер татар яшьләрендә әллә нинди бер авыру хөкемен алган «шагыйрь» булу арзусы (теләге) бу тарихтан бик аз элек миндә дә бик куәтле булган. Шул авыруның тәэсире илә мин дә кулымнан килеп-килмәве илә исәпләшмәстән, «шигырь» исеме бирен байтак кына нәрсәләр язып ташлаганмын икән. Билгеле, минем шушы кулыңызда торган язуларым илә чын «шигырьләр» арасында һичбер төрле мөнәсәбәт булмаучылыгын язарга лазем дә күрмим, аны һәркем аңлар, күрер. Дәрт арзу (дәрт омтылышы) илә язылган нәрсәләр әллә кайда югалып калмасын өчен һәм әдәбиятымызның тарихы мәсьәләләре илә шөгыльләнүче затлар өчен, юк дигәндә, сәлби (кире) җәһәттән мисал булырга ярарлар дип, төрле вакытта төрле мөнәсәбәт илә язылган мәзкүр (әлеге) язуларны җыеп, «Ник язылганнар?» исеме илә бер мәҗмуга рәвешендә бастырдым».

Җыеп әйткәндә, Мәхмүт Галәүнең 1917 елга кадәрге иҗтимагый һәм иҗат эшчәнлеге күп тармаклар буенча бара. Бу чорда ул татар әдәби-тәнкыйди фикер дөньясының алгы сызыгыннан атлаган талантлы журналист һәм публицист, тәҗрибәле нашир һәм матбага белгече, оста оештыручы һәм халыкка аң-белем таратучы мәгърифәт эшлеклесе булып таныла. Татар журналистикасы, әдәбияты һәм мәгарифе тарихында ул шушы хезмәтләре белән генә дә үзенә лаек хөрмәтле

урынны алган булыр иде. Ләкин, әдәбиятыбызның бәхетенә диик, болар әдип-мәгърифәтченең алда, инде совет чорында туачак төп әдәби әсәрләрен язуга хәзерлек, тәҗрибә туплау гына булган икән.

Ниһаять, зилзиләле, табигый агышындагы тормыш тәртипләрен пыран-заран китергән 1917 елның Октябрь вакыйгалары башлана.

Элегрәк бездә 1917 елга кадәр әдәбият дөньясында исеме танылган теге яки бу язучының Октябрь вакыйгаларына мөнәсәбәте хакында сүз кузгалганда, «ул Октябрьне шатланып каршы алды», яисә «кабул итмәде, чит илгә качты» кебек катгый төшенчәләр куллану гадәткә кергән иде. Әйе, тормышта андыйлары да, мондыйлары да булган. Әйтик, инкыйлабкача милли-азатлык хәрәкәтендә чыныгу алган өлкән буын әдипләре һәм җәмәгать эшлеклеләренең бер өлеше (Г. Исхакый, С. Максуди, Г. Баттал, Ф. Туктар һ. б.), Октябрьне ачыктан-ачык кабул итмичә, чит илгә чыгып китәргә мәҗбүр булганнар. Ләкин илдә торып калганнар арасында, Октябрь вәгъдә иткән «якты киләчәк» һәм милли ирекләр хакына аны чын күңелдән кабул итүчеләре булганы кебек, икеләнеп калучылары да, иманнары какшап, бөтенләй өметсезлеккә төшүчеләре дә, рухи фаҗига кичерүчеләре дә булган, билгеле. М. Галәү иҗтимагый-сәяси тормыштагы бу кискен үзгәрешне, кыйблалар алмашынуны ничек кабул иткән соң? Моны ачык кына, кистереп әйтүе кыен, әмма чамаларга була. Җайланган тормыш тәртипләренең кисәк кенә бозылып куюы, 1914 елдан бирле уңышлы эшләп килгән «Белек» нәшриятының яңа хакимият тарафыннан конфискацияләнеп, дәүләт кулына күчүе, ниһаять, үз наширлегендә, үз мөхәррирлегендә чыгып килгән, ул вакытта татарча бердәнбер көлке журналы булган «Кармак»ның яшәүдән туктавы — болар, әлбәттә, әдипнең рухи халәтенә тискәре тәэсир итмичә калмаган. Әмма, намусы чиста кеше буларак, аннан да бигрәк, яңа хакимият вәгъдә иткән әлеге дә баягы «якты киләчәк»кә өмет итеп һәм егерменче еллар башында милли сәясәттә, милли дәүләтчелек юлында ирешелгән кайбер уңай үзгәрешләрне күреп, М. Галәү дә ихластан «яңа, якты тормыш төзүчеләр» сафына басарга омтыла. Хәер, аны моңа тормыш үзе үк мәҗбүр итә: «Эшләмәгән — ашамый!» лозунгысының иң популяр чагы — җан асрау өчен нинди юл белән булса да барыбер акчалы эш табарга кирәк.

Ләкин даими эш табу мәсьәләсендә М. Галәүгә шактый гына кыенлыклар кичерергә туры килә. Егерменче еллардан ук тормышның барлык өлкәләрендә хөкем сөрә башлаган идеологик чикләүләр, һәр нәрсәне фәкать сыйнфый көрәш күзлегеннән генә карап бәяләү практикасы, иң беренче нәүбәттә, «иске заман», «буржуаз дәвер» зыялыларына — фикер иясе кешеләренә, язучыларга, мәдәният эшлеклеләренә, белгечләргә каршы юнәлтелә. Гадәттә, алар «сыйнфый яктан ышанычсыз кешеләр» исемлегендә йөртеләләр. Аларны җаваплы эш урыннарына алмыйлар, алсалар да, озак тотмыйлар, берәр сәбәп табып, китәргә мәҗбүр итәләр. Моны Мәхмүт Галәүнең эш эзләп бер төбәктән икенче төбәккә күчеп йөрүләре мисалында да күрергә мөмкин. 1919 елда ул Башкортстан Мәгариф комиссариатының кантон бүлегендә хезмәт итсә, 1920 елны Оренбур губернасында һәм Мәскәүдә мәгариф, нәшриятлар системасында эшләп кала. «1921 елның көзендә, ...эшсез калып, янадан Оренбургка кайттым һәм ачлык сәбәбеннән башкалар белән берлектә хосусый бер җитештерү артеле оештырып, эшмәкәрлек белән шөгыльләнергә мәҗбүр булдым,— дип яза ул 1930 елда, үзенең хезмәт биографиясеннән мәгълүмат биреп.— 1923 елда артель таратылгач, янә икенче бер хосусый ширкәт кибетенә эшкә кердем. 1924 елны бөтенләй эш табалмый уздырдым. 1925 елда Мәскәүгә күчеп, Центриздатта эшли башладым, анда Үзәк наборщиклар мәктәбе оештырып, асылда, аның мөдире вазифаларын башкардым. 1926 елдан алып бүгенге көнгәчә мин тагын эшсез. Ничек кирәк алай, ярым ач хәлдә көн кичерәмен...»

Иң гаҗәбе шунда, «ярым ач хәлдә көн кичерүенә» карамастан, нәкъ менә шушы елларда М. Галәүнең матур әдәбият өлкәсендәге нәтиҗәле иҗат эшчәнлеге башлана. 1924—1930 еллар арасында гына да ул дистәдән артык хикәя, «Саламторханнар», «Пугач явы» исемле ике сәхнә әсәре һәм «Канлы тамгалар» исемле тарихи эпопеясен язып тәмамлый. Шул вакыт эчендә биш китабы дөнья күрә — икесе пьеса, өчесе хикәя җыентыклары. «Төеннәр» (Казан, 1928) һәм «Каяу» (Казан, 1927) җыентыкларыннан башкалары барысы да Мәскәүдә Центриздат нәшриятында басылалар.

«Канлы тамгалар» эпопеясенең язмышы исә гыйбрәтле дә, аянычлы да. Ул дүрт китаптан торырга тиеш була. Автор алдан ук һәр китапның киңәйтелгән планын төзи, исемнәрен билгели. Бүгенге көндә дүрт китапның алдагы икесе генә безгә мәгълүм — алары да русча тәрҗемәләре аша гына. Русча басмаларында

«Муть» һәм «Мухаджиры» дип исемләнгән бу ике роман алтмышынчы елларда яңадан татарчага тәрҗемә ителеп, «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» дигән исемнәр белән татар телендә ике тапкыр басылып чыкты.



Мәхмүт Галәү үзенең хатыны Зәйнәп белән. 1920 ел.

Мәгълүм булганча, совет чоры әдәбият фәнендәге вульгар социологизм тарафдарлары егерменче елларның ахырларында М. Галәү иҗатына бер-бер артлы һөҗүмнәр оештыралар, аңа «контр-революцион фикерләр тарата торган буржуа болганчыгы» дип мөһер салалар. Бу һөҗүмнәрнең нәтиҗәсе билгеле: әдипнең күп кенә әсәрләре, шул җөмләдән әлеге «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары, үз вакытында төп, асыл оригиналында матбугатка чыкмый калалар. М. Галәүнең бу нахак гаепләүләрдән нинди кыенлыклар, нинди рухи газаплар кичерүен аның СССР Үзәк Башкарма Комитеты каршындагы Милләтләр советына һәм РСФСР Халык Комиссарлары Советына адреслап 1930 елның 10 маенда язган ачынулы хатыннан күрергә мөмкин[1]. Машинка күчермәсендә 6 бит тәшкил иткән һәм 7 пункттан торган бу хатның алдагы өлешләрендә үзенең Октябрьгә кадәрге һәм Октябрьдән соңгы тормыш һәм хезмәт юлын, әдәби эшчәнлеген, сәяси карашларын сөйләп чыкканнан соң, 5 нче пунктында ул менә нинди сүзләрне терки:

**«...Менә берничә ел инде, мин үземне ниндидер аңлашылмаган, сихерле-серле бер түгәрәк эчендә калган итеп тоям. Җаваплы урыннарда утыручы татар агайлары һәммәсе диярлек мине күрмәмешкә салыша; язучы итеп мине рәсми танымыйлар, үткәндәге хезмәтләремнән баш чөерәләр, әсәрләремнең социаль әһәмиятен, мәкаләләремнең актуальлеген томаларга — кыскасы, мине һәрничек читкә, арткы планга чигерергә тырышалар. Шул сәбәпле мин даими психологик басым астында яшим. Ә бит мин гади ихтыяҗымнан артык бернәрсәгә дә дәгъва итмим. Минем бердәнбер ихтыяҗым — бер телем икмәк, яшәү хокукы һәм башкалар кебек үк пролетар җәмгыяте файдасына хезмәт итү. Менә бу хокукларга мин тулысынча ия түгелмен. Үз белгечлегем буенча аппаратта эшләргә телим, хезмәтемне тәкъдим итәм — төрле сәбәп табып, кире кагалар, эшкә алырга теләмиләр. Шул ук вакытта бөтен җирдә квалификацияле хезмәткәрләр җитешми дип чаң сугалар. Мәкалә язам, телдән һәммәсе хуплый, мактый, фикере көчле, эзлекле, актуаль дип әйтә,**

---

[1] Хат русча язылган, монда тәрҗемәсе бирелә. Оригиналы КПССның Татарстан ӨК архивында (ф. 15, тасв. 325, сакл. б. 57, бб. 65—67; 1930). Аның копиясен 60 нчы елларда мин, фиркасез кеше, Нил Юзиев аша алдырткан идем. Р. Д.

ләкин басмага кабул итми, кабул итсә дә, бастырып чыгармый һәм сәбәбен ачыктан-ачык сиздереп куя: янәсе, минем исемемне популярлаштырырга ярамый; яки бастырган очракта да, мәкалә темасы белән актуальлеген югалткач кына дөнья күрә. Әдәби әсәр язып тапшырам — аны да әүвәл хуплаган, мактаган булалар, рецензияләләр, нәшер итәр өчен чиратка куябыз дип ышандыралар, хәтта вак-төяк әҗерен дә түлиләр, әмма үз вакытында барыбер бастырып чыгармыйлар, шул юл белән мине яңа хезмәтләремне тәкъдим итү мөмкинлегеннән мәхрүм итәләр. Бер яки ике ел үткәннән соң нәшер ителсә дә, ул арада мин күтәргән тема каләм тоткан теләсә кем тарафыннан матбугатта инде чәйнәлеп беткән була. Нәшриятларның миңа булган мөнәсәбәтләрен күрсәтү өчен шундый фактны мисалга китерү дә җитәдер: соңгы ике ел эчендә минем бер генә әсәремне дә матбугатка чыгара алганым юк. Ә шул ук вакыт эчендә бүтән язучыларның һәркайсы диярлек берничә җыентык һәм элек гарәп хәрефендә басылган иске әсәрләрен яңалиф язуында чыгарып өлгерде.

VI. Һәр урам чатында чаң сугып кычкыралар, революциядән соңгы татар әдәбияты киң укучылар массасы таләбен канәгатьләндерерлек тулы канлы, уңай эчтәлекле әсәрләр белән баемый, диләр. Ләкин миңа карата әлеге иптәшләрнең бу мәсьәләдәге эш-гамәлләре әйткән сүзләренә каршы килә. Менә җиденче ел инде мин социаль эчтәлекле зур бер роман өстендә эшлим. Каралама рәвешендә әсәр тәмамланган дияргә була, ә аның «Канлы тамгалар» исеме белән йөргән 25 басма табак күләмендәге беренче томы күптән басмага әзер. Абруйлы татар тәнкыйтьчеләре һәм әдәбият галимнәре һәммәсе диярлек романны укып чыгып, аны социаль мәгънәсе белән дә, сәнгатьчә дәрәҗәсе белән дә зур кыйммәткә ия әсәр дип бәяләделәр һәм тизрәк нәшер ителүен яклап чыктылар (язма рецензияләре кулымда бар). Мәсьәләнең гамәли чишелеше исә инде менә ике елдан артык сузыла килә. Политиздат редколлегиясе романны нәшер итәргә карар чыгарды (5 март, 29 ел), ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты каршындагы махсус әдәби киңәшмә дә 12 март 29 ел карары белән аны раслады. Ләкин Татиздатның баш редакторы ипт. Әхмәтов Фәтхи, ышандырырлык һичнинди дәлилләр китермичә, романны басмага кабул итүдән катгый төстә баш тартты. Центриздат, әсәрнең күләме канәгатьләндерми, артык зур дип, нәшер итүдән шулай ук баш тарта. Мин исә ачлы-туклы хәлдә язуымны дәвам иттерәм.

VII. Бу санап үтелгәннәр, минем уемча, миңа билгесез һәм миңа белгертелми торган ниндидер субъектив фикер-аңламау яки Татарстандагы җаваплы урында утыручыларның бер өлешендә туган кирәгеннән артык шикләнү, чиктән ашкан саклык күрсәтү нәтиҗәседер. Болаймы, теләйме, моны ачыклау һәм төенне чишү кирәк. Бу хәлдә яшәргә, эшләргә һәм гаиләмне туйдырып торырга минем бүтән көчем калмады.

Шуңа күрә үтенәм сездән, иптәшләр, минем бу хәлемне тикшереп ачыклау өчен тиешле боерык бирсәгез иде. Әгәр минем өстә үземә бөтенләй билгесез нинди дә булса «гөнаһлар» барлыгы ачылса, бу хакта миңа әйтүегезне һәм бар эшкә тиешле юнәлеш бирүегезне сорыйм. Шулай иткәндә Сез миңа үз-үземне яхшырак таныл белергә булышачаксыз.

Ә инде алда санап үтелгәннәрдән тыш минем өстә бүтән бернинди «гөнаһ» эшләр юк икән, ул чакны, уйлыймын, мин Сездән түбәндәгеләрне сорарга хаклымын:

1) минем намуслы һәм бернинди хилаф эшләр белән йөзен каралтмаган совет гражданнары җөмләсеннән булуым турында махсус карар чыгарып, ул карарны «Эшче» (Мәскәү) һәм «Кызыл Татарстан» (Казан) газиталәрендә бастыруыгызны;

2) милли өлкәдә яки гомумҗәмәгатьчелек линиясе буенча миңа даими хезмәт урынына урнашу мөмкинлегенә ярдәм итүегезне;

3) «Канлы тамгалар» исемле романымны бастырып чыгаруда миңа чынлап торып ярдәм итүегезне; бер уңайдан, ВКП(б) өлкә комитеты каршындагы махсус киңәшмә карары булуга карамастан, Әхмәтовның бу романны бастырып чыгарудан катгый баш тартуының асыл сәбәбен ачыклавыгызны.

Әлеге таләпләрне үтәвегез белән Сез миңа тормыш бүләк итәсез.

Кирәк булса, мин бу мәсьәләләр буенча аңлашу өчен шәхси әңгәмәгә дә әзермен; чакыруыгызны зур канәгатьлек һәм шатлык хисе белән кабул итәчәкмен.

10/V-30. *М. Галәү».*

Бу ачынулы хатның беркадәр уңай нәтиҗәләре дә була, әлбәттә. Аерым алганда, «Канлы тамгалар»ның беренче ике томы, алда әйтелгәнчә, «Муть» һәм «Мухаджиры» дип исемләнеп, 1931 һәм 1934 елда Мәскәү нәшриятларында

аерым китаплар булып басылып чыгалар. Аларның беренчесенең тәрҗемәсен төрки телле әдәбиятларны русчага тәрҗемә итү өлкәсендәге хезмәтләре белән ул заманда ук исеме танылa башлаган язучы Гайшә Шәрипова (1901—1969) эшли, ә икенчесен автор үзе тәрҗемә итеп, соңыннан аны рус әдәбиятчысы С. Быстрицкая эшкәртеп чыга. «Эшкәрткәндә» һәм, гомумән, нәшрият хезмәткәрләре тарафыннан редакцияләнгәндә романнарның төп текстлары урыны-урыны белән кыскартылган һәм оригиналларындагы кайбер милли үзенчәлекләре кыркыла төшкән булса кирәк. Моны «Мөһаҗирләр» романының татарча басмада сакланып калган өч өзеген («Чүлмәк тулгач» җыентыгы, Мәскәү, 1929) русча тәрҗемәләре белән чагыштырып караганда шактый ачык күрергә мөмкин.

Шул ук 1934 елны Мәскәү язучылар ширкәте нәшриятында әдипнең, шулай ук үз тәрҗемәсендә, өченче, күләмле әсәре — заман темасына багышланган һәм татар авылына 1917 ел алып килгән кискен үзгәрешләр фонында төрле катлау кешеләр арасындагы киеренке мөнәсәбәтләрне психологик планда тасвирлаган «Кабылсай» романы да дөнья күрә. Көндәлек матбугат битләрендә урнаштырылган берничә өземтәсен исәпләмәгәндә, бу әсәрнең дә татарча асыл оригиналы сакланмаган.

Ә менә Казан белән, Татиздат җитәкчелеге белән хезмәттәшлек барыбер җайга салынмый, әдипнең хатта язган үтенеч һәм таләпләренең күбесе җавапсыз кала. Романнарының, башка әдәби әсәрләренең кульъязмалары бастыру өчен нәшриятка кат-кат тәкъдим ителсә дә, субъектив тәнкыйтькә яки, әдипнең үз тәгъбирençә, «чиктән ашкан саклык күрсәтү»гә очрап, һәр юлы «төзәтү өчен» авторына кире кайтарыла. Шундый «кире кайтарулар»ның соңгыларыннан берсе 1936 елның ахырларында булган булса кирәк, бу хакта нәшрият җитәкчелегенең язма рәвештә теркәлгән рәсми боерыгы бар. Нәшриятның 1936 елгы боерыклар кенәгәсендәге бу боерыкны эчтәлегенә хилафлык булмасын өчен монда русча язылганынча китерәм:

**Приказ № 145**
**по Государственному Издательству**
**при СНК ТР «Таттосиздат»**
**от 17/XII-36 г.**

**Рукопись романа М. Галяу «Мохаджиры», представленная автором по договору № 31, требует коренной переработки (основание — рецензии т. Г. Галеева).**

**Исходя из сего, рукопись «Мохаджиры» вернуть автору М. Галяу для переработки и считать рукопись принятой лишь после исправления автором на основе рецензии с последующим просмотром главредакцией.**

**Управляющий Таттосиздатом** **(Мухсинов)**

М. Галәүнең алда телгә алынган хаты ахырында, кушымта сыйфатында, роман хакында язылган рецензияләрдән берничә өзек китерелгән. Рецензентлардан Мәхмүд Максуд, Шамил Госманов әсәрне тулаем яхшы дип табалар һәм басарга тәкъдим итәләр. Гомәр Гали исә, әсәр нәшер ителергә хаклы дию белән бергә, аны яңадан бер кат карап-төзәтеп чыгу зарурлыгын искәртә һәм: кеше типларына, аерым вакыйгаларга автор үзенең социаль мөнәсәбәтен, карашын-симпатиясен ачыграк белдерсә, әсәр отар, аның сәнгатьчәлек кыйммәте кимемәс иде, дигән мәгънәдә нәтиҗә ясый; икенче төрле итеп әйткәндә, автор алдына пролеткультчылар, вульгар социологизм тарафдарлары алга сөргән бер үк таләпләрне куя. Гомәр Галинең ул еллардагы иҗтимагый һәм әдәби абруеның зур булуын, аның фикере белән исәпләшүләрен исәпкә алсак, М. Галәү романнарының үз вакытында татарча чыкмый калуларына күпмедер дәрәҗәдә ул да гаепле түгелме икән дигән гөнаһлы фикер килә башка, рухы рәнҗемәсен.

Әдип үзенең рецензентлары, нәшрият җитәкчелеге һәм башка «хәсрәт тәнкыйтьчеләр» (М. Мәһдиев гыйбарәсе) кушканча әсәрен «төзәтергә» керешкән булгандырмы-юктырмы, анысы безгә билгесез. Хәер, «төзәтергә» керешсә дә, өлгерә алмагандыр, чөнки ул арада дәһшәтле 1937 ел өскә килеп ябырыла, тоталитар режимның хөкем тегермәне — «өчлек»ләр эшли башлый. Ул инде милли интеллигенциянең кайсы тәнкыйтьче, кайсы автор дип талымлап тормый: исеме күзгә ташланырдай һәр шәхесен бәрәмләп тә, уптым да таш капчыкка җыярга тотына...

Истәлекләргә караганда, М. Галәүне Мәскәүдәге фатирында кулга алып, хөкем итәр өчен Казанга китерәләр. Махсус киңәшмә (ОСО) 1937 елның 4 ноябрендә була. НКВД биргән белешмә буенча, вафаты (атып үтерелүе?) 1938 елның 12 ноябрендә дип фараз кылына.

Мәхмүт Галәүнең әдәби иҗаты, бигрәк тә «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» романнары, вакыт сынавын үтеп, XX йөз татар әдәбиятының мөһим бер казанышы буларак бүгенге көндә мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнелә. Шулай да әдип калдырган мирас бөтенләе белән тупланып беткән дип әйтеп булмый. Кульъязмалар хәлендә яки төрле гәзитә-журнал битләрендә чәчелеп яткан, моңа кадәрге җыентыкларына керми калган публицистика, тәнкыйди әсәрләр, фельетоннар күздән кичерелеп, аларның библиографик исемлеге төзелмәгән. Кызганычка каршы, әдипнең шәхси архивы да үзе белән бергә китеп югала. Ә анда матбугатка чыгуны көтеп яткан яңа әсәрләр дә шактый була. Кыскасы, яшь галим-голәмәгә Мәхмүт Галәүнең иҗат мирасы буенча да эзләнүләр мәйданы бик киң.

**Рәис ДАУТОВ**
*Июнь, 1996*

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

# Идрис Туктар

(1896—1982)

Танылган татар әдибе Идрис Ильяс улы Туктарның тууына быел 2 октябрьдә йөз ел тула.

Ул хәзер Башкортстанга кергән Булышлы авылында дөньяга килә, Уралдагы Кучкар алтын приискаларында үсә һәм бик яшьли шунда эшли дә башлый. Беренче дөнья сугышында катнаша һәм Февраль революциясеннән соң гына Кучкарга кайтып, китапханәдә хезмәт итәргә керешә.

Колчакка каршы үгет бирүдә гаепләнеп, Идрис 1919 елда аклар тарафыннан кулга алына һәм Ерак Көнчыгышка озатыла. Владивосток төрмәсеннән котылгач, ул шул якларда акларга каршы көрәшә, 1923—1924 елларда Чиләбе шәһәрендә китапханә һәм клуб мөдире, 1924—1932 елларда Екатеринбург шәһәрендә татарча чыгарылган «Коммунист» гәзите һәм «Шәпи агай» көлке журналы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр вазифаларын үти. 1932—1936 елларда Казан пединститутын тәмамлагач, Зеленодольск шәһәрендә укыта, аннары Казанда «Кызыл Татарстан» гәзитен чыгарыша. Икенче дөнья сугышында артиллериядә хезмәт итә. Сугыштан соң ике ел Киевтә, 1953 елдан алып даими рәвештә Зеленодольскида яши, укытучы, китапханәче, тәрҗемәче эшләре белән шөгыльләнә.

И. Туктар 1924 елда иҗат дөньясына аяк баса. Матбугатта эшчеләр тормышын, патша гаскәрендәге солдат хезмәтен һәм илдәшләр сугышын гәүдәләндергән кыска хикәяләрен бастыра. Бай тормыш тәҗрибәсенә ия язучы ул әсәрләрдә каһарманнарын ышандырырлык итеп чагылдыра.

Идрис Туктар балалар өчен күп яза һәм дистәләп хикәя, нәсер, әкият китапларын нәшер иттерә. А. Куприн, А. Волошин, И. Ликстанов, В. Бредель әсәрләрен тәрҗемә итә. Шуның белән бергә ул туган әдәбиятыбыз тарихына шахтерлар тормышын һәм эшчәнлеген сурәтләгән «Сиксән беренче штольня» (1930) повесте һәм «Ике егет» (1964) романы белән дә кереп кала. Бу зур күләмле ике әсәргә заманында матбугатта югары бәя бирелә.

И. Туктар 1934 елда СССР Язучылар Берлегенә кабул ителә һәм өлкән яшьтә дә иҗаттан аерылмый, аның китаплары әле дә укучылар тарафыннан яратып укыла.

Китап күзәтү

# ЯЗМЫШЛАР ЯЗЫЛГАНДА




Татар җырларының эчтәлеге турында бераз гына булса да уйланган кеше игътибар итми калмый: халкыбыз еш кына үзенең язмышыннан зарлана. Бу, әлбәттә, юкка түгел. Чөнки татар милләте кебек каһәрләнгән, кагылган-сугылган, рәнҗетелгән бүтән кавемне табуы кыен. Сорау туа: ә нигә шулай? Ныклап уйлангач, мин мондый җавап таптым — бу аның акыллылыгыннан һәм затлылыгыннан килгән бәла. Үзең тарихи мәгълүматлы була барган саен, моңа ныклабрак ышанасың. Бик ерак барасы юк, 922 елда Идел буе Болгарына килеп киткән Әхмәт ибне Фадланның язмаларында да борынгы элгәрләребезнең затлы дәүләтле, белемле булганлыклары ачык күренә. Бу сыйфатлар аларны башкалардан өстен иткән. Ә үзеннән булдыклыларны кем соң яратсын?! Киресенчә, көнләшеп аларны үзләре дәрәҗәсенә тартып төшерергә тырышалар...

Безнең ерак әби-бабаларыбызның күргән михнәтләре дә күп очракта «акыллылык бәласе» булган. 1552 елдан соңгы вакыйгалар моның шулай икәнлеген аеруча ачык күрсәтте. Шуннан бирле татарның акылын алу өчен ниләр генә эшләнмәде! Аның милли аңын, телен бетерергә омтылдылар. Аны чукындырырга тырыштылар, туган телдәге мәктәбен тартып алдылар, матбугатына аяк чалдылар, театр сәнгатенең аваз бирүен тоткарладылар... Алай да булмагач, аны, ата-бабасы туфрагыннан кубарып, дөньяның төрле кыйтгаларына сибү сәясәте уздырдылар. XX гасырның утызынчы елларында бу эш тагын да рәхимсезрәк алымнар белән эшләнде. Мәсәлән, бары тик бер аты, бер сыеры булган өчен генә кулак итеп Арпаяз авылыннан (Кукмара районы) Магнитогорск якларына сөрелгән Мәрүрә Хәйрулла кызы 1931 елда Чиләбе төрмәсеннән җибәргән хатының ахырына мондый җыр өстәгән:

Чиләбенең төрмәсенең
Иләнендә ятабыз,
Телеграмм баганасы
Чәчәк аткач кайтабыз.

Билгеле булганча, телеграмм баганасының чәчәк ату ихтималы юк. Шуның кебек, туган җиреннән куылган кешеләрнең дә өметләре тәмам киселгән. Һәр җыр, шул рәвешле, язмышның кайтавазы буларак иҗат ителә килгән.

Белмәдем яшьлеккәемнең
Чәчәк кебек суласын.
Язмышымның алгы көндә
Болай авыр буласын,—

кебек җырлар да буш җирдә генә барлыкка килмәгән. Аларда кешенең язмышы, шәхси сәбәпләрдән бигрәк, иҗтимагый-сәяси мохитнең рәхимсезлеге белән бәйләнгән.

Әбрар ага Кәримуллинның «Язмыш, язмыш...» дигән яңа китабын укыгач, бу турыда тагын бер тапкыр уйланмый кала алмыйсың. Күренекле галимебез әлеге

хезмәтендә милләтебезнең тулаем язмышының катлаулылыгын шулкадәр киң планда карый, авторның мәгълүматлылыгына, хәбәрдарлыгына һәм гомумиләштереп фикер йөртү сәләтенә зур хөрмәт уяна. Бирелгән мәкаләләрнең һәм язмаларның берсе дә болай гына, коры фикер эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә язылмаган. Аларның кыйммәтле яклары шунда — галим бу китапка кергән хезмәтләрне татар бәхете, азатлыгы өчен көрәш барышында язган. Равил Рахмани китапка язган кереш сүзен «Халкыбызның көрәшче галиме» дип атаган икән, бу нәкъ менә шулай. Әлеге исем җисеменә тап туры килүе белән күңелне кинәндерә, китапта язылганнарга ышанычны арттыра. Әйе, Әбрар Гыйбадулла улы, галим буларак та, үз милләтенең вәкиле буларак та — чын мәгънәсендә көрәшче. Китапның «Татарика» дип исемләнгән бүлегендә аның галимлеге ачылса, «Язмыш, язмыш...» дип аталганында гражданлыгы өскә калкып чыга. Хәер, болай бүлү шартлы рәвештә генә. Беренчесендә дә, икенчесендә дә без киң эрудицияле, үзенең язмышын татар халкының хәл-әхвәленнән аерып карый алмаучы галимкөрәшчене күрәбез. Нигездә публицистикага өстенлек бирелгән соңгы бүлектәге кайнар мәкаләләрне Ә. Кәримуллин дәрәҗәсендәге галим генә яза ала. Фәндә төрле биеклекләр бар. Ә. Г. Кәримуллин исә академиклык дәрәҗәсендәге караш тирәнлегенә һәм киңлегенә ия шәхес. Шуңа күрә халкыбыз ул язганнарны яратып укый, күңеленә сеңдерә һәм үз гамәлләренә нигез итеп ала. Аны икенче бер академигыбыз И. Р. Таһиров белән янәшә карыйсы килә. Дөрес, алар икесе ике төрле галим, ләкин бу хөрмәтлеләребезне тоткан мәсләкләре берләштерә.

«Язмыш, язмыш...» китабын укыганда, яхшы танышың белән очрашкандай буласың. Әйе, чыннан да, фикердәшең, аңгәмәдәшең, мәсләктәшең белән. Ни өчен дигәндә, бирелгән мәкаләләр соңгы ун елдагы көндәлек матбугат белән танышып барган кеше өчен үз булып әверелгән инде. Ә без 1985 елдан соң барыбыз да матбугатка ташландык, аны «су кебек эчеп» барабыз. Бу вакыт эчендә матбугат безгә икенче «югары белем» бирде. Ә мөгаллимнәребез арасында академик Ә. Г. Кәримуллин үзәк урында тора. Г. Тукай әйтмешли, «чү, аз гына бер нәрсә «шылт!» иттеме, инде аның тугрысында иртәгә урамга бәетләр чыга». Бу ун ел эчендә вакыйгалар шундый тизлек белән барды, кайвакыт өермәләр дә купты. Әгәр Г. Тукай әйткән «шылт!» итү бәет жанрын сораса, хәзерге хәл-әхвәлләр исә бик тирәннән каерып алып әйтелгән төпле сүз белән бәя бирүгә мохтаҗлар. Моны теләсә кем эшли алмый. Ә. Кәримуллин кебек мөхтәрәмнәребезне вакыт нәкъ менә сиксәненче-туксанынчы еллар өчен махсус өлгерткән булып чыкты. Халыкның милли үзаңын үстерүгә алар әйтеп бетергесез зур өлеш керттеләр. Ә. Кәримуллин, мәсәлән, вакытлы матбугатта дистәләрчә мәртәбә чыгыш ясады, теге яки бу мәсьәләләргә бик күпләрнең күзен ачты. «Язмыш, язмыш...» китабына аның шушы еллардагы кайбер әһәмиятле чыгышлары тупланган. Аларның иң «карты» 1985 елның июлендә язылган булса («Татар китаплары кайда саклана?»), иң «яше» дип әйтерлеге — «Төрки дөнья Төркиядә очрашты» дигәне — 1994 елның сентябрендә каләмнән төшкән. Димәк, барысы да шушы тугыз ел эчендә дөньяга чыккан. Бирелгән егерме бер мәкаләнең бары тик икесе генә — «Гаяз Исхакый Ерак Көнчыгышта» һәм «Үзәк Азияне өйрәнү җәмгыяте» һәм татарлар» дип аталганнары гына — шушы китап өчен махсус язылган. Шуңа күрә бу мәкаләләрне укыганда бик якын танышың белән очрашу хисе кичерү табигый. Аларның, бер калын китап рәвешенә кереп, синең алдыңа килеп ятуы бик тансык. Ә. Кәримуллинның аларда үткәрелгән карашлары үзләренең бурычын тагын да югарырак дәрәҗәдә үти дигән сүз бу. Милләтебезнең үткәне, бүгенгесе һәм бигрәк тә киләчәге турында гамьләнгән беркем дә аңа битараф калмас дип уйларга кирәк. «Кая китә бу татар?», «Казан урамнары ни сөйли?», «Тел ачкычы — язмыш ачкычы», «Иҗтиһат итәр вакыт» кебек байтак чыгышларда үткәрелгән карашлар инде бик күпләрнең хәтерендә урын алды. Алар, кәгазьдән кешенең күңеленә күчеп, иҗтимагый аң булып яши башладылар.

Шулай да, галим буларак, Ә. Кәримуллинның мәсьәләне җитди, нигезле һәм киң итеп куясы килә. Дөрес итә. Чөнки бары тик ныклы нигездә басып торганда гына иҗтимагый аңның гамәли хәрәкәтләрне максатка ярашлы оештыруы нәтиҗәле була. Ә. Кәримуллин бик тә өлгереп җиткән бер мәсьәләне күтәрә — безгә хәзер татар халкын өйрәнүне кирә кагылгысыз фәнни нигезгә кую таләп ителә. Бирелә сүз аның тарихын, формалашу эволюциясен, рухи хәзинәсен, телен дөньякүләм киңлектә өйрәнү турында сүз бара. Моңа кадәрге «Татарстан АССР тарихы» кебек хезмәтләр бу таләпкә һич кенә дә җавап бирә алмый. Әгәр дә татар халкын берәр җан иясе, әйтик барс рәвешендәге матур, камил җәнлек рәвешендә күз алдына китерәбез, ди. Без бу җанварның бер аягын гына өйрәнеп,

аның турында тулы күзаллау булдыра алабызмы? Юк, әлбәттә. Татар халкы дөньяга шулкадәр киң сибелгән, Татарстанда яшәүчеләр аның шактый бер кечкенә өлешен генә тәшкил итә, ягъни, барсның бер тәпие кебек, аерым өлеш турында гына сүз бара. Димәк, барс турында тулы төшенчә булдыру өчен, бердән, аны тулаем тикшерергә, икенчедән әлеге җәнлекнең бүгенге көнгә кадәр булган үткәнен дә яхшы белү мөһим. Шуның кебек, татар халкын дөнья күләм өйрәнү бүген иң өлгергән бурычларның берсе булып кала.

Хәлбуки, гасырыбызның егерменче елларында «Гыйльми үзәк» оешкач, Г. Ибраһимов, Г. Рәхим, Г. Гобәйдуллин һәм башка галимнәребез эшне шул юнәлештә оештырырга омтылып караганнар иде. Алар моның беренче адымнарын да ясадылар, халкыбызның гомуми тарихы, әдәбияты тарихы буенча кайбер хезмәтләр чыгарырга да өлгерделәр.

Ләкин империячел хакимият хөкем сөргәндә, азчылык милләтләрнең телен, рухын, тарихын кыерсыту, инкар итү кануни күренеш булса кирәк. Моның кәсафәте бездә — татар халкы язмышында да ачык күренде. Кытайдан уйгар Т. Каһһари да шулайрак яза: «Маочылар хөкем сөргән хәзерге шәркый Төркестанда кытай булмаган халыкларның культурасы нык эзәрлекләнә. «Культура революциясе»нең шаукымы чын мәгънәсендәге афәткә әверелде». («Казан утлары», 1977, № 11, 165 б.) Мондый афәт Рәсәйдә күпкә элегрәк башланган иде. XX йөз башында татарларда иҗтимагый, фикри, мәдәни уяну хәрәкәте көчәя башлагач, бу хәл шовинизм тарафдарларын куркуга салды. Алар, моңа тоткарлык ясау өчен, төрле чаралар күрергә керештеләр. Ләкин бер кагыйдә бар — теләсә кайсы иҗтимагый эшне оештыру өчен башта аның идеологик нигезен булдырырга кирәк. Шовинистлар анысын да уйлап таптылар, ул — пантюркизм, ягъни Россиядәге мөселманнарның төрек бердәмлеге шигаре астында тупланырга омтылулары. Ләкин бу ясалма, хәтта, әйтергә кирәк, провокацион уйдырма иде. Татар «милләтчелеге»нә каршы көрәш өч баскыч үтте: пантюркизм — җидегәнчелек — солтангалиевчелек. Сүз дә юк, иң хәтәре солтангалиевчелек дип аталганы иде. Ул инде идеологик басым гына түгел, ә бәлки асыл затларыбызны җисмән юк итүгә нигез булды. Менә ни өчен дистәләгән еллар буена татарны милләт буларак өйрәнү турында уйларга да мөмкин булмады. Иң күп дигәндә, безгә Татарстан АССР тарихын сыйнфый караштан чыгып өйрәнү генә мөмкин булды.

Әбрар ага Кәримуллин әйтә: безгә хәзер «Татарика» (Татароведение — татарны өйрәнү) фәнен алга алып китәргә, моның өчен махсус фәнни-тикшерену институты ачарга, аның максатка ярашлы төрле бүлекләрен булдырырга, өйрәнүне әһәмиятле тармаклар буенча алып китәргә кирәк. Чөнки бу гаять киң колачлы эшне аерым энтузиастлар, бигрәк тә һәвәскәрләр генә колачлый алмый. Моңа дәүләткүләм әһәмиятле бурыч итеп карау кирәк. (Олы галимебезнең бу тәкъдиме хәзер тормышка ашты: тарихыбызны өйрәнү буенча махсус институт оешып килә.)

Хәзер шундый карашны көчләп тагарга тырышу да сизелә: имеш, Татарстаннан тыш яшәүче татарлар барысы да «диаспора» икән. Болай дип раслауның ялгыш булуын бары тик татар турындагы фәнне үстерү юлы белән генә ачып була. Дөрес, эзләнүләрнең бүгенге торыгыннан чыгып без Башкортстанда, Оренбурда, Әстерхан, Төмән, Пермь, Пенза, Сембер һәм башка тарафларда яшәүче татарларның үз ватаннарында икәнлекләрен раслый алабыз.

Сүз дә юк, татарларның диаспора булып яшәгән урыннары да байтак. Әйтик, Ә. Кәримуллин сүз алып барган Кытайда, Кореяда, Ерак Көнчыгыш илләрендә, Польша, Англия, Финляндия, Канада һәм башка илләрдә яшәүче татарларны җирле халык дип әйтеп булмас. Аларның бу илләргә күчеп килүләре һәм төпләнеп калуларының тарихы китапта галим тарафыннан ачык итеп, нигезле аңлатыла, күп кенә чыганаклар да күрсәтелә.

Ә. Кәримуллин беренче карашка тар белгечлеккә ия галим булып тоелырга мөмкин. Ул — китап белгече. Бу шулай. Ләкин татар китабын өйрәнү аны бик зур киңлеккә, халкыбызның күптармаклы тарихына китереп чыгара. Ә бит китабы буенча үз тарихын, дөньяга таралган халкын өйрәнү барлык милләтләрнең дә мөмкинлегеннән килмидер. Моның өчен халкыңның элек-электән үк язулы, китаплы булуы, алай гына да түгел, китапка зур мәхәббәт белән яшәве кирәк. Татарлар бу яктан караганда да зыялы милләтләрнең берсе. Бу юл Ә. Кәримуллинны татар милләтенең тарихына, язмышына алып чыга, аның шулай булмавы мөмкин дә түгел. Академик галим өчен, ихтимал, шушы эшчәнлеге дә җитеп ашкандыр. Әмма Әбрар абый бу фәнни нәтиҗәләрнең

һичкичекми эшли башлавы турында да кайгырта һәм шуның өчен көрәшкә кушылып китә. Бу хәл исә аның шәхесенең тагын да киңрәк һәм хөрмәтлерәк бәяләнүенә китерә.

Әбрар Кәримуллин — энтузиаст, әмма академик энтузиаст. Аның эшчәнлеге турында уйланганда шундый нәтиҗәгә килми булмый: талантлы, эшлекле, арутalu белмәс аерым бер кеше генә дә милләте өчен күпме эш башкара ала икән бит! Иң мөһиме шунда: Ә. Кәримуллин үзенең тикшерү объекты өчен кирәкле булган шәхесләрне эзли, таба, аларны бер максатка — халкыбызның рухи хәзинәләре тарихын ачыклауга хезмәт иттерә белә. Аның танышлары арасында Япониянең Токио университеты профессорлары Тадаши Сузуки, Хисао Комацу, Төркиядән Осман Серткая, Садри Максудиның кызы Гадилә Аида, Мәхмүт Таһир, Мостафа Өнәр, Англиядән Мэри Броуксоп (бик мәгълүм ориенталист галим Александр Беннигсенның кызы) һәм башка бик күпләр бар. Аларның кайберләрен ул Казанга шәхси кунак итеп чакыра, бездәге чыганаклар һәм, тагын да мөһиме, халкыбыз белән таныштыра. Мондый танышуларның файдасы күз алдында. Әйтик М. Броуксоп, Татарстанда булганнан соң, Англиядә чыга торган «Үзәк Азияне күзәтү» журналының бер санын үзе биредән алып кайткан материалларга багышлаган. Анда Я. Абдуллин, Р. Әмирханов, Р. Мөхәмәтдинов, Б. Солтанбеков һ. б.ларның төрле мәүзугларга язган мәкаләләре урнаштырылган. Үз чиратында Ә. Кәримуллин да чит илләрдәге галим коллегаларының хезмәтләрен бездә бастыруга зур игътибар бирә. Аның киң күңеллелеге сүз бара торган китабында да күренә. Әйтик берәү (исемен әйтеп торасы килми) 1934 елда Шанхайда Г. Исхакыйның «Идел-Урал» дигән бүгенге көндә безгә яхшы мәгълүм булган гаять кыйммәтле хезмәтенә яла ягып, газетада чыгыш ясый. Мәдинә Сәлихмәт дигән милләттәшебез исә моңа рус телендә «Наш ответ» дигән листовка белән җавап бирә. «Шанхай төрек-татарларының Идел-Урал комитеты» дип имзаланган бу документны Ә. Кәримуллин үзенең китабында урнаштырган. Без аннан мондый юлларны укыйбыз: «Гаяз Исхакый артыннан ниндидер бер төркем яки адәм актыклары түгел, бәлки үзенең милләте кадерле булган һәм тамырларыннан куркусыз элгәрләренең каны агучы аңлы кешеләр бара. Әгәр алар читләр мәнфәгатьләре өчен батырларча сугышып кан түкәннәр икән, милли идеяләрне тормышка ашыру бәрабәренә алар тормышларын да шатлык белән бирәчәкләр». 1934 елда мондый сүзләрнең басылып чыгуы зур батырлык иде. Шуңа күрә Мәдинә Сәлихмәт турындагы язмасын автор «Халкыбызның батыр кызы» дип атый да. Кытайда революция җиңгәч, милли азатлык өчен көрәш алып барыр мөмкинлекләре бетерелә. Мәдинә Сәлихмәт тә Төркиягә китә (1964 елда вафат була). Улы Равил АКШның Бирменгем шәһәрендә яши.

Мондый затлы кешеләргә Ә. Кәримуллин ничек юлыга, алар турындагы мәгълүматларны каян эзләп таба? Барысы да аның аралашырга, йөрергә, эзләнергә ярату галәмәте. Кечкенә генә фактларның җебенә тотынып, максатка юнәлешле эзләнү сәләтенә ия булу нәтиҗәсе. Мәдинә Сәлихмәтнең «Россия төрекләре» дигән зур гына күләмле хезмәтенең инглиз теленнән тәрҗемә ителеп шушы китапка кертелүе җыентыкның танып-белү әһәмиятен тагын да арттыра. Р. Сәлихмәтнең «Шанхайда татар җәмгыяте», Ләбиб Каранның «Татар хатыннарына киңәш һәм үгетләр» кебек мәкаләләре турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Бездә иң артта калган өлкә — кыскача гына булса да милли энциклопедиянең булмавы. Ә. Кәримуллинның «Язмыш, язмыш...» китабы билгеле күләмдә шушы хезмәтне дә үти ала. Анда халкыбызның тарихы, таралу урыннары, яшәү шартлары һ. б. турында бай мәгълүмат тупланган.

Шулай да иң мөһиме — күренекле шәхесләребезнең тормыш юллары һәм эшчәнлекләре белән таныштыру. Алар арасында Гаяз Исхакый, Габдулла Баттал Таймас, Садри Максуди Арсал, Йосыф Акчура, Һади Атласи, Габдулла Гыйсмәти һәм башка бик күпләр хакында бирелгән мәгълүматлар укучылар өчен бик кыйммәтле.

Китапта аерым фактлар, вакыйгалар турында кабат-кабат сөйләүләр, искә төшерүләр дә очрый. Мәсәлән, Р. Ибраһимов турында. Бу — китапка тупланган мәкаләләрнең төрле вакытта язылулары белән аңлатыла. Китап итеп туплаганда аларны бер карап чыгу кирәк булгандыр.

Әмма хикмәт китапның информация байлыгында һәм яңалыгында, укучыга гаҗәеп күп мәгълүмат бирүендә, тагын да әһәмиятлесе — бу язмалар артында милләтнең бәхете өчен көрәшүченең торуы даими сизелүендә. Әйе, мәкаләнең башында үткәрелгән фикергә яңадан әйләнеп кайтып, шуны әйтәсе килә: гасыр

башында милләтебезгә С. Максуди, Й. Акчура, Г. Исхакый, Г. Тукай һәм башкалар бинһая өлеш керткән булсалар, XXI йөз якынлашканда бу байракны Ә. Кәримуллиндай фидакарьләр күтәреп алды. Алар меңнәрчә-меңнәрчә тарафдарларын тәрбияләделәр. «Язмыш, язмыш...» китабын укып чыккач, моның шулай икәнлегенә тагын бер тапкыр ышанасың.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН**

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

### Габдрахман Минский

(1906—1983)

Габдрахман Мөхәммәт улы Минский — кызыклы язмышлы язучыларның берсе. Ул 1906 елның 29 сентябрендә Әстерхан шәһәрендә дөньяга килә. Төрле мәктәпләрдә белем алганнан соң, 1924 елда аның хезмәт эшчәнлеге башлана: уку йорты, клуб мөдирләре булып эшли, әдәбият-сәнгать түгәрәкләрендә катнаша, беренче пьесаларын яза башлый.

Егерме яшьлек Г. Минский 1926 елда Казанга аяк баса, театр техникумында укый. Ә инде 1928 елда аның беръюлы беренче өч китабы басылып чыга, Татар дәүләт академия театрында исә «Мансуровлар гаиләсе» дигән драмасы уйнала. Яшь язучы Һ. Такташ, Г. Кутуй кебек талантлы яшьләр белән аралаша, дуслаша.

1928—1930 елларда Г. Минский — кызылармеец. Хәрби хезмәт тормышын сурәтләп «Шлем» дигән драма яза, ул да сәхнәләрдә куела.

1932—1935 еллар. Г. Минский — Чиләбедә. «Төзү ударнигы» газитендә — җаваплы сәркатип.

1936—1938 еллар. Г. Минский — Мәскәүдә Бөтенсоюз дәүләт кинематография институты студенты. Сценарист дипломы алып, ул, Бөек Ватан сугышы башланганчыга кадәр, Баку киностудиясендә эшли, сценарийлар яза. Аның сценарийлары буенча ике документаль фильм һәм «Ватан улы» дигән нәфис фильм төшерелә.

1941—1946 еллар. Г. Минский — фронтта, сугыш хәрәкәтләрендә катнаша, чик буе гаскәрләрендә хезмәт итә. Аннары 1947—1951 елларда ул Советлар Союзы телеграф агентлыгының (ТАССның) Әзәрбайҗан бүлеге хезмәткәре була.

1952 елда Г. Минский яңадан Казанга килә. 1957 елга кадәр «Чаян» журналында бүлек мөдире, 1957—1959 елларда Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир урынбасары вазифаларын башкара. 1960 елдан ул тулысы белән язучылык хезмәтенә күчә.

Г. Минский — төрле жанрларда иҗат иткән язучы: дистәләгән сәхнә әсәрләре, киносценарийлар, күпсанлы хикәяләр һәм берничә повесть — аның иҗади хезмәт җимешләре. Ике дистәдән артык китаплар авторы ул. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Минский «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» (1957) һәм «Почет билгесе» (1976) ордены белән бүләкләнә.

Г. Минский 1983 елның 26 мартында Казанда вафат була.

Ул 1995 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы иде.

# ТӨЗӘТӘСЕ ИДЕ ДӨНЬЯНЫ...

Һи, беренче генә алдануыбызмы соң!

Дөрес анысы, «Казан утлары» кебек олпат-әдәби журналда (1996 елгы 1—2 саннар) «Тәүбә» исше роман күрергә аз гына да теләгем юк иде. Минем — укучының — ихтыярына-зәвыгына каршы килеп, шундый әсәрне дөньяга чыгарганнар икән, димәк, мине алдаганнар. Әмма мин шактый тыныч, гамьсез. Без, ара-тирә романнар укырлык дәрәҗәдә зыялы саналучылар, яшәп яткан социализмны кеше кыяфәтенә китерәбез, тоталитар хакимияттән демократик идарәгә, халык хөкемдарлыгына күчәбез, милли дәүләтчелегебезне яңартабыз дип ду-чат килгәндә, тормыш дилбегәсен Сәет Сакмановлар үз кулларына алыр, мөстәкыйльлек, ирек җимеше дә шуларга гына тияр һәм нәкъ шулар роман герое булып әверелер, дип уйламаган идек. Чынлыкта әнә нәрсә килеп чыкты.

Әдәбият галиме, университетның милли факультет җитәкчесе Тәлгат Галиуллин да шушындый әсәр язарга хыялланмаган, хәтта әзерләнмәгән булгандыр, бәлки. Күренеп тора бит, аның күңелендә һәм каләмендә бөтенләй бүтән образлар, башка бизәкләр. Автор шулар белән «мафия башлыгы» Сәетне тасвирлый, Сәет белән Зөлфия мәхәббәтенә дастаннар матурлыгын салып иза чигә, әдәбият профессорының мәгълүматлылыгын элекке милиционер башына шыплап тутыра. Сәет дигән кеше Андрей Платановның мәшһүр «Чевенгур» романын да укыган, Жюль Вернның «Су асты дөньясы» белән дә таныш. Чичиковка «Үле җаннар»ның ни өчен кирәк булганын яхшы аңлап, кирәксә, бу тәҗрибәне кулланып эш итәргә чамалый, якыннарын исә, кешесенә карап, Катюша Маслова, Клим Самгин, Надежда Крупская белән чагыштыра. Баш каһарманның мондый «бизәкләре» вакыт-вакыт кирәгеннән артып та киткәндәй була. Автор, әйтерсең, күңелендә йөргән образларны, сурәтләрне, әдәбият дөньясы мәгълүматларын шушы романга сыйдырып бетерергә омтыла.

«Сәет Сакмановны нигә шушы кадәр уңайлаштыра соң әле бу?»— дип уйлап та куясың. Туфан Миңнуллинның «Ир-егетләр» драмасында исерек архитектор авызыннан әйтелгән (безнең әдәбият-сәнгатьтә күптәннән инде иң зирәк сүзне йә эчкече, йә юләр генә әйтә) шундый сүзләр бар: «Укыган туң йөрәкләрнең салкыны зәһәр була». Сәетне югары мәгълүматлы итү дә аның фаҗигасен тирәнәйтеп күрсәтү өчен түгел микән? Хәер, уңай сыйфатлар салу өчен бүтән рәтле герое да юк ич роман авторының. Бөтенләй язмас кына иде — тормышыбызны, чынбарлыгыбызны күмеп, үз пычрагына суырып бара торган бу хәлләргә күз йомып ничек, күпме яшәргә соң? Җитмәсә, романнар, повестьлар язып байтак каләм шомарткан бүтәннәр кинәт кенә зиһенсез калгандай булдылар, бер ишесе базарга кайсы ишектән керергә белмәгәндәй, газета-журнал битләрендә вак-төяк белән сату итә. Гаҗәп түгел: чөнки без хәзер кайда, нәрсәдә алданачагыбызны да белмибез, аларның хисабын, күз текәп барган маякларыбызны югалттык. «Үземчә гаделлек белән вәхшилек, олылык белән явызлык арасындагы көрәшне, тартышны күрсәтергә, төркемнәр арасындагы аяусыз сугыш, көрәш, кеше каны су бәясенә дә тормаган әшәкелек-явызлык каләмдәшләремне уйландырыр, җитди сөйләшү юлына алып чыгар дип көткән идем»,— дип язды Тәлгат Галиуллин «Ватаным Татарстан» газетасында (21 май 1996 ел) һәм теләгенең «әлегә» акланмавын әйтеп узды.

Менә монысы да — реаль чынбарлыгыбыз чагылышы, алданулар чылбырының чираттагы бер буыны. Әле алай гынамы: язмыш явыз шаярып, (тфү-тфү!) романның чынбарлыктагы каһарманнары, җәмгыятебезнең Сәет Сакмановлары, Северцевлары әсәрдә үзләрен танып, автор белән хәтәр алыш башласалар, гади халык дигәнебез аны яклап өн дә чыгармаячак — киресенчә, «тегеләрне берәмберәм депутатка сайлаячак. Шулай буласын Тәлгат Галиуллин да белеп тора. «Без үз җиребездә кирәк чакта гел азчылык»,— ди Сәет әсәр башында, «гастролер» алып сатарлар белән уңышсыз көрәш көннәрендә. Минемчә, нәкъ шул

чорда Сәет теленнән авторның дөньяга, чынбарлыгыбызга мөнәсәбәте чагыла торган сүзләр күп ишетелә. Роман азагында Сакмановлар азчылык түгел, «мәҗлес»не үз кулларында тотарлык зур өер инде, хәтта үзләрен тудырган язучы ихтыярына да буйсынмыйлар бугай, нәкъ тормыштагыча әшәкелек кылуны дәвам итәләр. Романны укучы һәр кеше анда сурәтләнгән «Игелек» ширкәте урынына үз төбәгеннән, үзе белгән башка ширкәтьне яки исеме дә билгесез төркемнәрне куеп карый ала һәм аларда да Сәет Сакмановларны, Шөрепләрне, мәкерле Наилә-Нонсаларны таный. Әмма бу инде, романның уңышы булудан бигрәк, чорыбызның бәласе.

Әсәрнең баш каһарманы Сәет «мафия башы»на тормышта бөтенебез күреп торган юллар-бусагалар аша килә. Милициядә мавыгып эшләүче участок инспекторы була ул. Законча эшлим диган булып йөргәндә, хокук сагындагы юньлерәкләрнең һәркайсы кебек үк, кагылырга ярамаган затка юлыга. Хаклыгын раслап, бераз чәбәләнгәндәй итсә дә, коллегалары, бигрәк тә прокурор аны аңламыйлар, төгәлрәге, аның ташына сөртенергә теләмиләр. Романның шушы юлларын укыганда, җәмгыятебезнең бозыклыкка никадәр тирән кереп батуын тагын бер кат күргәндәй буласың. Чөнки, автор тырышып сурәтләсә дә, Сакмановның законлылыкны яклап сөйләнүләре укучыны ышандырмый. Кайдадыр кемнеңдер мондый сүзләрне ихлас күңелдән әйтү ихтималын күз алдына китерү шактый кыен.

Сәетне ресторанда эшләтеп, ишек төбе саклату һәм яшерен аракы сәүдәсенә тартып кертү дә әсәр өчен күпне бирми — болар баш каһарманның үсешен азмы-күпме эзлекле итеп күрсәтү өчен генә кирәктер. Монда роман безгә булырлык оригинальлек юк: кемдер нәкъ шушы юл белән, кемдер дефицит товарны партия райкомының беренче секретаре кулыннан алып-сатып, җинаятьчел байлыгына мая башы туплады. Тик болар икейөзлелек түгел, аз дигәндә, булдыклылык, яши белү дип санала икән ич! Бу мохит — җәмгыятьнең каймагы икән! Шуңа күрә «Гулаг» җәһәннәмен кичкән, инде рухи яктан саф, иманлы булырга тиеш Әхмәдиша карт та шушы төркем эчендә. Ширкәтнең нәрсә белән шөгыльләнгәнен күреп-белеп тора, әмма үзе мафиягә кулыннан килгәнчә булыша, шул ук вакытта «Игелек» егетләре каршында әдәп хакында фәлсәфә сата. Чөнки автор «Тәүбә» романына үтә авыр тема сайлаган һәм аны заманча чишкән: әсәр каһарманнары, без укып күнеккән әдәби геройлардан аермалы буларак, чиста акка һәм карага гына бүленмиләр. Хәзер мәшһүр Такташның кискен борылыш чорындагы кебек, «бер кешедә бүген ике «мин». Аннары, романнан күренгәнчә, Тәлгат Галиуллин бу чорга, тормыш агышына, сәясәткә үз карашларын да, сезнең-безнең мөнәсәбәтләрне дә белдерергә тели һәм бүтән мөмкинлеге булмагач, үз карашларын Сәет аңына, Әхмәдиша фәлсәфәсенә сала кебек. Килешле, ышандырырлык чыгамы бу, дип шикләнер урыныбыз бар-барын, әмма реаль тормышыбызда бөтенесе дә килешле, без теләгәнчәме соң? «Көнбатыштан кайткан нәрсәләр исәбенә күпме яшәп була? Бу бит коллыкка төшүнең, кабаланың төп юлы», ди Сәет, ә үзе наркотиклар алып-сату белән дә шөгыльләнә. «Элекке партия түрәләренең берәрсенең ким-хур булганын, фатирсыз калганын күргәнең бармы? Эшлисе килмәсә, досрочно пенсиягә озаталар», — ди Әхмәдиша. Бүгенге газеталарыбыз тукыган публицистика «дәрәҗәсендәге» бу зарлы сүзләр романның тукымасын төртеп-килешсезләп торсалар да, аларны урынсыз дияргә тел бармый. «Татарның үз милли мафиясе булырга тиеш. Мафияле булу — балигълык күрсәткече» дип уйлау бер Сәетләр миендә генә тумыйдыр. Беренчедән, юньле эшләрнең генә түгел, мәкер һәм алдашуның да миллилек япмасы астында, милләт исеменнән башкарыла торган чоры. Халыкның азмы-күпме генә булса да милли хисләре уянудан, мөстәкыйль дәүләт төзергә омтылышыннан һәр акыллы баш үз мәнфәгатен кайгыртып, үз урынын ныгытып калырга ашыга ич!

«Безгә аларны үзебезгә якынайтып, малларын республикага, син һәм мин яраткан халкыбызга хезмәт иттерергә кирәк. Байлыкны бөтен Рәсәйдән, дөньядан бирегә ташысыннар», — ди эчке эшләр министры урынбасары Әскәр Әлмиев. «Алар» дигәндә «мафия башы» Сакманов, Башориннарны, «әзер машиналар сатып, Оргсинтез заводын кычкыртып талап» киткән Вәһаповларны күздә тотып. Аларга «кычкыртып талаучы» исемен министр урынбасары түгел, эчке эшләр органының тагын бер бәхетсезе Җәүдәт Габдуллович тага. Әмма бәхетсезлеге үз башлыгы алдында шушы сүзләрне әйтә алуында гына түгел аның. Чөнки кызы Регина Сакманов башкисәре Шөреп белән йоклап йөри. Озын һәм дулкынландыргыч телесериалга лаек бу сюжет төенен без гамьсез генә укып узабыз, ни өчен дигәндә тормышта аннан хәтәррәк бәйләнешләрне дә күреп-ишетеп торабыз.

Икенчедән, мафиягә шундый соклану, симпатия булмаса, аның кинәт кенә шулкадәр үсеп китүенә шартлар да тудырылмас иде. Әле бер дистә фамилия язылган бюллетеньнән ил белән акыллы идарә итәрлек бер президент сайлап ала алмый изаландык. Чөнки белеп торабыз: властька кайсы килсә дә, беренче чиратта үз төркеменә хезмәт итәчәк. Ә гади сайлаучы — властьны бер төркемнән алып, икенчесенә бирүче генә. Президент булып кем генә сайланса да, сайлауга кадәр дә, аннан соң да ул кайсыдыр төркемнең акчасына һәм җәмгыятьтәге йогынтысына, соңгы исәптә (Алла сакласын берүк!), коралына таянырга тиеш булыр. Ә без кабат чит һәм тагын бер тапкыр алданучылар хәлендә калырбыз. Илдә дистә еллар буена урнашкан тәртип-канун шундый: гади халык үз сүзен әйтә, хакимнәр эшенә йогынты ясый алмый, идарә җебен Сәет Сакмановлар үз кулларына эләктергәндә дә ул каршылык күрсәтми, әле бер яктан, әле икенче яктан куркып гомер кичерә.

Чынбарлыгыбызның кеше куркытырлык якларын ачык күрсәтү өчен роман авторы Тәлгат Галиуллин да буяуларны җәлләми. Иң яманы — бирердәге образлар, җәмгыятебездәге кебек, бар да нигәдер ачулы, кемнәндер җәберләнгән, аларның җаннарын нәрсәдер борчый, бимазалый. Андыйлар янында бүтәннәргә дә гел хәтәрлек янап тора. Кара инде милиция полковнигы Җәүдәт Насыйровны! Җитәкчесе Әскәр Әлмиев аны түгел, Сакмановларны, Ваһаповларны яхшырак аңлый, шуларга соклана. Хатыны да аның сүзен тыңламый, бердәнбер кызы да пакь юлдан язган. Зөлфия фаҗигасе Сәетне дә тәмам үчкә батыра. Шушындый хәлдәге полковник һәм майорларның, хаким һәм хөкемдарларның җәмгыятьне савыктыруларын, мафия башыннан депутат булганнарның гадел законнар чыгаруын көтеп яшәүче безләр турында тагын бер роман язучы гына юк — «Тәүбә»дән дә караңгы чырайлырак роман килеп чыгар иде! Дөрес, авторы Тәлгат Галиуллин булса, бу «чырай»ны яктырту өчен тел бизәкләре дә кулланып карар, әмма алар уңышсыз салынган ямаулык кебек аерылып торырлар.

Авторда тәвәккәллек бар икән: детектив әсәрләрнең укучы каршында популярлыгы нык кимегән (тормышыбыз бертуган Вайнерлар романнарыннан күпкә хәтәррәк, тагын аны милли журналлардан да укып саташыргамы?) чорда «Тәүбә»не язып чыгарсын, җитмәсә, дәвамын да вәгъдә итсен әле! Хәер, дәвамы барлыгы, булырга тиешлеге әсәрдән ук күренеп тора: Сәет җинаять юлында тирәнгәрәк кереп кенә бара әле. Ә тәүбә итәргә кичегеп килә инде — ышандыра алмаячак. «Атакага барганда, гел беренчеләрне кыралар, ахырдан килгәннәрнең түшенә тәре тагалар»,— ди Сәетнең урынбасары, элекке «мент» Хәлил Нигъмәтуллин. Автор Сакмановка, бәлки, алда менә шушындый «беренче» булу язмышы әзерлидер. Ә тәүбәгә алар түгел, тормыш агышын Сәетләр кулына бирүчеләр — без килергә тиешбез. Нәрсә карап тордык? Зыялыларның, матбугатның, әдәбиятның әдәпкә, тыйнаклыкка, күндәмлеккә, гади хезмәткә чакыруын кабул иткән чордашларыбызны явыз көчләрдән ни өчен якларлык дәрәҗәдә түгел, якларга тиешлеләр каршысында ник шулкадәр мескен хәлдә без? Менә хәзер халыкның шушындый романнарны, милли матбугатыбызны аз укуына, зыялыларны депутат сайлау бюллетеньнәреннән «тәгәрәтүләренә» үпкә белдерәбез. Әмма урынлымы бу? Сез чакырганда артыгыздан бардык, ирек, дәүләт мөстәкыйльлеге даулап мәйданнарга чыктык, заманында байтагыгызны депутат та итеп карадык, шушы көрәшнең җимешләрен сез кемнәргә бирдегез, тормыш дилбегәсен ник кулыгыздан җибәрдегез дип, халык үзе үпкәле сүз әйтергә тиеш түгелме? Руслар әйтмешли, яхшырак булуын теләдек, гадәттәгечә килеп чыкты. Элекке иминлекләрне риваятьләр итеп сагынып сөйләргә генә калды, түбәннән әйтелгән сүзләргә колак салучы да юк. Әдәбиятның, зыялыларның һәм милләт уңганнарының халыкка йогынтысын киметү өчен властьияләре күпне эшләде һәм эшли, теләгенә дә ирешеп килә. Каләм ияләре хәтта бер-берсен дә укымыйлар һәм ишетмиләр. Бисмарк әйткән, революцияне даһилар уйлап чыгара, фанатиклар галәмгә ашыра, ә җимешеннән юньсезләр файдалана, дигән. Әнә мафия киты Нургали Ваһапов «братогы» Сәеткә «Югары Советка депутат буласы киләме? Теләсәң, әйт» дип тора, «сәгать унбергә Камбинга сугылырга вәгъдә иткән идем» дип чыгып китә. Буш сүз сөйләве түгел, теләгән кешесен депутат та итәчәк, тирескә дә әйләндерәчәк ул, ә без һаман Ваһаповлар сайлаткан «халык хезмәтчесе»ннән игелекле законнар, гадиләргә гадел гамәлләр көтеп яшәрбез.

Юньсезләр галәмендә әдәп-әхлак юк та юк инде. «Әйдәгез, татарлар, бер-берегезне күбрәк утыртыгыз, безгә яшәргә җиңелрәк булыр» дип «шаярта» романның бер персонажы Родион Зильберштейн. Ул тагын: бер-берегезне ныграк талагыз, каһәрләшегез, өстәгеләр түбәндәгеләрне тыннары да чыкмаслык итеп

басып торыгыз, исерткеч белән миңгерәүләтегез, үтерешегез, дип тә әйтә алыр иде. Гаҗәп булмаячак, мондый уйлары белән ялгыз түгел ул, әнә эчке эшләр министрлыгындагы кайбер түрәләр дә шундыйрак фикердә...

Романда мафия пәрәвезе шулкадәр катлаулы, шундый ышандырырлык үрелгән, аларның «коммерция серс» шундый ачык фашланган — авторның шулай булдыра алуына соклансаң да, бик авыр уйлар белән укыйсың. Күп сәясәтчеләр мондый тормышны алга бару диеп бәялиләр, унга-сулга, бигрәк тә имин үткәннәргә борылып карамыйча, аны дәвам иттерергә чакыралар. Ә «Тәүбә» авторы гүя кисәтә: күрегез, без менә кая килеп кердек. Шулай кисәтүе белән хаклы, тик укучыны авыр уйлары белән калдырмыйм, тупиктан чыгу юлын ачам дип, соцреализм стилендә Сакмановлардан, Ваһаповлардан тәүбә иттерүгә генә бармасын берүк! Әсәр үзенең тормышчанлыгын бердәй югалтачак аннары.

Җыйнаятьчел элемтә төеннәре, катлаулы вакыйгалар белән тыгызланган бу романның теле дә бик үзенчәлекле. Тик мондый үзенчәлек, минемчә, отышлардан гына тормый. Автор образлы әйләнмәләрне, сурәт ясарга тиешле сүзләрне, әһәмияте ягыннан төрле дәрәҗәдәге мәгълүматларны җөмләләргә дөмбәсләп тутыра: вакыйгалар артыннан бара торган укучы андый урыннардан күз йөгертеп кенә узарга тиеш була. «Көйле, моңлы җаны, иркәләү, сөю өчен яратылган тәне белән Зәмзәмия ханым малае белән ундүрт метрлы бүлмәдә гомерен уздыра», — дип яза ул, шушы кеше турында бар белгәнен әлеге җөмләгә сыйдырып бетерергә теләгәндәй. «Нәкъ менә шул гадилеге, арпа мыегы кебек өскә бөгелеп торган керфекләре, киң, җыерчыксыз маңгае, кысан күлмәген төртеп торган, өлгергән алма кебек тыгыз күкрәге, еландай биле, озын аяклары хөрмәт уятмый калырлык түгел иде», — дип сурәтли бер чибәрне. «Ир, нык муенга утыртылган башын борып, ханымның яшь әрекмән яфрагыдай үтә күренмәле колак очларыннан үбеп алды, ак муенга хәтле төште», — дип тасвирлый баш каһарманның мәхәббәтле мизгелен. «Фил сөяге төсендәге тиресенә кыйгач кашлары, зур соры күзләре җылылык бөркеп тора» — дип бизәкли мавыгып китеп бер гүзәлне. Тәлгат Галиуллинның персонажы сүз башламый, ә «башлам кәлимәсен тышка чыгара». Үтә модалы мондый метафоралар аерым бер каһарман сөйләмендә, аның холкын яхшырак ачу өчен түгел, автор тасвирламаларында күп кулланыла. Сурәтләнгән вакыйгалары белән дә шактый авыр булган бу әсәрне мондый тел әйләнмәләре тагын да авырайталар.

Әсәренә игътибарсызлыкка хәтере калган автор әлеге газета мәкаләсендә урынлы әйтеп уза: «Тәүбә» темасы, халыкның, җәмгыятьнең әдәбе хакында бик җитди сөйләшү-бәхәсләшү бик тә кирәк. Бу инде газета-журнал эше генә түгел, бөтен җәмәгатьчелек, яхшы мәгънәдәге барлык милләтчеләр вазифасы. Чөнки әхлагы булмаган милләт үсә, яши алмый, андыйның дәүләте ныгымый. Күзләрне ачыбрак карасак, моны һәр тарафта күрәбез. Әхмәт әфәнде Сәхапов күптән түгел «Мирас» журналының «Баш мөхәррир сүзе»ндә гуманитар фәннәргә яшь галимнәрнең аз килүенә борчылып язды, ләкин «әйе шул» дип аны хуплаучы, сәбәпләрен ачарга тырышучы булмады. Ә әдәбиятка күпме кеше һәм кемнәр килә, сәнгатебездә ниләр эшләнә? Инде татар халкына «милли мафия»дәге Сәет Сакмановлар белән генә горурланырга калырмы? «Кыйблам — йөгәнсез җил. Җилнең төсе юк», — ди ул милиция полковнигы Җәүдәт Габдуллович белән бер бәхәс вакытында. Без шул җил артыннан йөгерикме? Аларның сүз көрәштерүеннән шул ачык: кайсы як җинсә дә, милләт вә халык файдасы күздә тотылмаячак. Россия сайлавында Ельцинмы, Зюгановмы җиңәр, янсә кайсына тавыш бирергә кушарлар, шунысын сайларбыз дип, сәясәттә бер хәрәкәтсез күп айлар көтеп торуыбыз да, хакимнәрнең иң мөһим шөгыльләрен читкә куеп, хәтта бик үк теләмәсәләр дә, шул сайлау нәтиҗәләре өчен җан атып йөрүләре дә көчләрне һәм гомерләрне юкка сарыф итү генә иде, чөнки милләтнең беркемгә бәйсез үз сүзе, үз кыйбласы булырга тиеш. Тәлгат Галиуллин үзенең «Тәүбә» романы белән җәмгыятебезнең һәм милләтнең иң яралы, авырткан урыннарын ачып күрсәтте. Аңа күз салабызмы, гыйбрәт һәм сабак алабызмы, уйланабызмы — болары бездән тора. Югыйсә, тәүбә бик авыр булмагае.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,**
*Балтач.*

# БИТАРАФ КАЛДЫРМЫЙ...

...Романның исемендә үк урын алган «тәүбә» сүзе — дөресрәге әле тәүбәгә килмәү берничә урында кабатланыла. Авторның бу сүзгә бәясе түбәндәгечә бирелә:

«Зөлфия өчен ул бары үзен битәрләде. Көндәм генә, баш иеп, берни булмагандай, тук тормыш белән, табигать ямenә, ризык тәменә сокланып кына яшисе иде дә бит, Сәет булдыра алмады. Нәфесе җинде...

Бу фани дөньяда һәр тайчыну өчен түлисе буласын белә иде ич ул... Соңарган тәүбәсен Ходаның кабул итмәсен чамаласа да, тыелган чикне үтте».

Автор Сәет сүзләре аша безгә, зәңгәр күк астында яшәүче кешеләргә аваз сала, өч көнлек дөньяда иманыңа хилафлык китермичә яшәргә өнди.

Әсәрдә «Идегәй» дастаннарыннан килгән үч алу, яманлыкка яманлык эшләү теләге эчтәлегенә салынган.

Кеше каны җирдә ятмаска тиеш!

Үтерелгән балага бәйле сөйләшү дә берничә урында кабатлана: Сәет участковый булып эшләгәндә үтерелгән бала өчен гаепле читтә калган булса, бу юлы инде «бер гаепсезгә корбан баланың» үче алына. Гаеплеләрне бәйрәм ясап яткан кичләрендә, өйләрен бикләп алып, төркемнәре белән яндыралар.

Әсәрнең башланып киткән өлешендәге, «Балам, кайсы миһербансызы рәнҗетә? Әйт үземә, мин аны... Хәзер кызган табага утыртам», — дигән сүзләр әсәргә метафора булып килгәнлегенә дә шик калмый. Зөлфияне рәнҗетүчеләр Сәетләр төрткән утта янып үләләр.

Ирләрне көчле иткән, үзләренең ирлеген тоярга, зур эшләр майтарырлык энергия өстәүче хатын-кыз матурлыгы турында да әсәрдә күп тапкырлар кабатлана. Ир — дөнья ыгы-зыгысыннан арынып ял итә, самими бала хәленә кала, алдагы эшләргә көч җыя. «Анасы сөтенең муллыгы рәхәтеннән тончыккан бала кебек» иде Сәет Зөлфия куенында. «Төннәрен аз йоклаганда да иртән ял итеп, үзендә Салсал батырларны җиңәрлек көч сизеп уяна иде».

Автор ир белән хатын арасындагы яратышу хисен, натуралистик кытыклануларга артык бирелмичә, бик табигый итеп, мәхәббәтне кешегә илаһи көч өстәүче, яшәртүче сыйфат итеп сурәтли.

— Хатын-кызның тәне табигать тарафыннан ирләргә ләззәт бирү өчен яратылган, — ди Сәет сөйгәненә.

Әсәрдәге чагыштырулар тормыштан бик тә табигый алынган, кайберләренә генә булса да игътибар итик әле.

«Кызыл балчыктай яргаланып беткән иреннәр» Әхмәдиша картка туры килә.

«Сөт суытырга салган бака тоткандай» була иде Вилсурга Северцев белән кул бирешү.

Сәеткә телефоннан, Зөлфия турында тавышын үзгәртеп хәбәр итүче Наилә-Нонса сүзләре: «Кешелеген кызыл балчыкка ташлап кысыр кәҗә тоягы белән изә».

Машинадагы йөнтәс кул «пычак белән сарымай кискәндәй» Зөлфияне карашы белән үтәли тишеп шөреп Регинага «нарат тактасыннан бәреп чыккан сары чәер төсле» ябышты һ. б.

Бу чагыштырулар образларны тагын да тирәнрәк ачарга ярдәм итәләр.

...Романда бүгенге җәмгыятебез тормышы сурәтләнгән. Мафия тормышы, андагы язылмаган законнар, тәртип ачып бирелә, яшьләр-студентлар проблемасы да үзәктә тора.

Илдә тәртип урнаштырырга тиешле милиция хезмәткәрләренең дә югарыдагы басым астында көчсез булуы күрсәтелә.

«Безнең илдә дөресен сөйләгән, хакыйкатьне ярып салган кешегә яшәү юклыгын, сәясәтнең пычрак нәрсә, көчленең кулында курчак фахеш икәнлеген аңладым», — дип, автор Сәеттән әйттерә ул фикерне.

«Тәүбә» — җиңел укыла, уйландыра, геройлар язмышына бәрәүне дә битараф калдырмый торган әсәр.

**Бану КАДЫЙРОВА,**
*Апас урта мәктәбе укытучысы.*

# ИХ СИН, ЯШЬЛЕК!

Бер... Ике... Өч... Унсигез... Егерме... Агач яфраклары узыша-узыша җиргә якынаялар. Җир-Ананың җылы куенына сыенырга ашыгалар. Ләкин нигә шулай ашыгырга? Сез юньләп агач ботакларының баллы ширбәтен, кояшның иркәләвен, кошларның моңлы тавышын да ишетмәдегез бит! Бер аерылгач, кире юл юк инде. Яфраклар коела, ә алар белән бергә еллар уза, кеше гомере уза. Балачак — яшьлек белән, яшьлек исә картлык белән чиратлаша.

«Казан утлары»н кулыма алгач, иң беренче җәлеп иткәне тышлык булды. Нигәдер, әсәрләнеп, байтак кына карап тордым. Үсеп, өлгереп җиткәч кенә сындырып алынган нарат ботаклары, саф су, ямь-яшел алма, әйтерсең, ниндидер булачак хәл турында кисәтергә телиләр. Мин моны Т. Галиуллинның «Тәүбә» романын укып чыккач кына аңладым. Сусыл алма — Зөлфия, ә сындырылган нарат — Сәет. Берсе — олы ир, икенчесе — яшь кыз...

Әсәрне укыганда да җанга иң үтеп кергәне яшьләр тормышы булды. Нинди аяныч хәл! Безнең Регина, Наташа, Сәнгать кебекләребез көннә-көн күбәя бит. Ирексездән шундый сорау бирәсе килә: «Безнең буыннан олыгайгач нинди тәрбиячеләр чыгар соң?» Ләкин йөрәкнең бер өлеше аваз сала: барыбер Әлфияләр күбрәктер...

Тагын Зөлфиянең үлемен искә алыйк. Менә ул коточкыч юллар:

«Өченче тәүлек тәмамланып килгәндә... Зөлфия дөнья кайгы-хәсрәтеннән, үзен мәсхәрә итүләреннән котылды». Кабат-кабат шул юлларны укыйм. Йөрәк елый! Нигә? Ни өчен җәзалап үтерделәр аны? Бер гаебе дә юк иде бит Зөлфиянең! Ул бары яратты гына, чын яшьлек сөюе белән Сәеткә гашыйк булды. Хәтта табигать елый. Әгәр дә аның тавышы булса: «Кешеләр! Бу дөньяда мин сездән дә әшәкерәк затларны күрмәдем», — дияр иде кебек.

Әсәрнең алдагы битләрен кабат ачканда, яшьлек дәрте дөрләп торган Зөлфиянең кырау суккан чәчәктәй «шиңүен» күз алдына китереп булмый...

Тагын бер аяныч мисалга тукталып китмичә булмый. Җирдә иң гүзәл зат — ана. Ә Фәридә шушы сүзне пычракка, җиргә салып таптый, изә. Үз газиз балаңнан баш тарту, аны вәхшиләрчә үтерүне иң зур җинаятькә тиңләргә мөмкин. Бер яктан аны аңлап та була, яшь кыз, кияүдә түгел, алданган. Шул кайгыдан ул баласын кире кагарга мөмкин. Ләкин ул бит Сәет янында гаебен танығач та, соңыннан кемнеңдер көче белән кире кага. Тыштан караганда саф татар кызларына охшаган Фәридә чынлыкта упкынга төшеп баткан инде. Ярар, ул яшьлеге белән ялгышкан да булсын ди. Тик нигә туган баланы канализация коесына илтеп салырга?! Үз кулларың белән үз балаңны! Аны бит беркем дә бу юлга этәрмәгән. Күңелендә аз гына миһербаны калган кеше, бу бит минем җанымның бер кисәге, дияр иде. Әйе, ана исемен аклый алмаганнар күбәя шул.

Егерме биш... Утыз... Әнә күпме яфрак коелды инде. Әнә күпме гомер үтте. Яшьлекнең саф җилләре күптән башкаларны иркәли.

**Наилә ЗӘЙНУЛЛИНА,**
*Апас урта мәктәбенең 11а сыйныфы укучысы.*

Рашат Низамиев

# МИН ДӘ КЕШЕ ЛӘБАСА!

ЮМОРЕСКА

Доктор, дим, иң элек мин сезгә кичәге хәлләрне сөйләп бирим булмаса...

Шулай иртәнге җиделәрдә баш авыртуга уянып киттем. Уяндым да ах-вах киләм: мин бит бу вакытта инде әллә кайчан станогым артында басып торырга тиеш ләбаса! Юрганны селтәп кенә ташладым да хатынга кычкырдым:

— Нигә уятмадың, боламык?

— **Йомран** кебек йоклыйсың-йоклыйсың да, аннары **эт** шикелле таларга тотынасың,— дип гайрәт чәчте хатын.

Соңлап булса да эшкә киттем. Акча маясын кичкә сакларга кирәк, шуңа күрә трамвайда билетсыз гына барырга иде исәп. Тик кая ул, вагон эче буйлап ишекле-түрле йөрүче контролер хатын:

— Әй, **куян**, нишләп билет алмадың? — дип бәйләнде генә бит, шайтан алгыры!

Ни пычагыма кирәк диген инде, әнә шул ыгы-зыгы арасында кырык бишенче размерлы күнитегем белән ялгыш берәүнең аягына басканмын икән. Берәү дигәнем — чәчен-башын буяткан, кашын-күзен уйнаткан чибәр генә «тутый кош» булып чыкты.

— Ах, зверь, **фил** икәнсең! — диде ул кызыл иреннәрен мул гына чалшайтып һәм тизрәк миннән ераклашу җаен карады.

Шәһәрдә адәмнән күп нәрсә юк, ходаем. Трамвайдан төшкән арада башымдагы кәпәчем авышкан, плащ төймәләрем шатырдап коелган икән.

— И-и балакай, тәмам **йолкыш тавык** булгансың бит, әй,— дип җәлләде үземне тукталышта басып торган тешсез бер әби.

Ярар, инде бу мәрәкәләрдән котылдым, ахрысы, дидем дә станогым артына килеп бастым.

— **Ташбака** сыман кыймылдыйсың син бүген,— диде мастерыбыз, житди генә кисәтү ясап.— Болай селкенсәң, бригаданы төп башына утыртуың бар.

Ниһаять, әбәт җитте, завод ашханәсенә кердек.

— Эшләгәндә шүре күк, ашаганда **бүре** күк безнең Хәйрүш,— диде бер иптәшем, гомер булмаганны мыскыл итеп.

Кич белән өйгә кайтырга чыктым. Күнегелгән гадәт буенча, юл уңаенда гастрономга сугылдым, билгеле. Кайсыдыр чатта биш-алты яшьлек кызның:

— Әнием, кара әле, бу абый цирктагы **аю** шикелле алпан-тилпән атлап бара,— дигән сүзләре колагыма кереп калган.

Өйгә үз аягым белән кайтып җиттем аңысы. Әмма аяк астындагы арзанлы келәмгә абынып шап итеп егылуым кая, каршыма ялт итеп хатын килеп чыкты.

— Кайда йөрдең болай? Тәмам **чучка** булгансың бит...— дия-дия уклау белән сыйларга керешә үземне.

Доктор, дим, кеше булуым турында, зинһар, ыспыравка язып бирегез, әй! Юкса мине һәммәсе хайванга чутлый башладылар... Мин дә кеше ләбаса! Әгәр менә баш төзәтсәмме, шундук чып-чын кеше итеп сизә башлыйм мин үземне...

## ҖӨМҺҮРИЯТ КӨНЕ

30 августта — инде менә алтынчы тапкыр — Татарстан күләмендә Җөмһүрият көне зурлап билгеләп үтелде. Бу көнне Казан шәһәрендә дә күпсанлы чаралар тормышка ашырылды. Ат чабышларын карарга яратучылар ипподромда, су спорты белән мавыгучылар Кабан күле һәм Казансу елгасында, шигърият сөючеләр Г. Тукай бакчасында, сәнгатькә гашыйклар Камал театры, цирк янында, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә, үзәк стадионда булып, үзләренә җан азыгы таптылар.

М. Солтангалиев исемен йөртүче мәйданда исә, Хөррият символы — очыштагы кошны сурәтләгән, биеклеге — 7 метр, киңлеге 5 метр булган бронза скульптураны ачу тантанасы булды. Аны күренекле скульптор — Мәскәүдә яшәүче якташыбыз Кадим Җәмитов иҗат иткән.

## ТАТАРСТАННЫҢ АК КИТАБЫ

Җөмһүрият көне уңаеннан, «Белая книга Татарстана. Путь к суверенитету, 1990—1995» дигән яңа китап — рәсми документлар тупланмасы дөнья күрде. Ул рус һәм инглиз телләрендә нәшер ителгән. Китапның авторы — күренекле сәясәтче, Татарстан Президентының Дәүләт киңәшчесе Рафаэль Хәким.

Әлеге үзенчәлекле китап Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларация белән ачыла. Анда Россия-Татарстан сөйләшүләренә кагылышлы язма-документлар белән дә танышырга мөмкин. Алар матбугатта беренче тапкыр басыла. Җыентыкта шулай ук 1992 елгы референдум һәм башка сәяси вакыйгалар хакындагы кызыклы язмалар, документлар да урын алган.

## ОЧУЧЫЛАРГА — БҮЛӘКЛӘР

20 августта Казан Кремлендә Татарстан Президенты М. Шәймиев «Аэростан» авиакомпаниясенең «ИЛ-76» самолеты экипажы әгъзаларын — бер елдан артык әфган талибләры кулында тоткынлыкта булган һәм аннан үз очкычлары ярдәмендә күмәкләшеп качуны оештырган батыр очучыларыбызны кабул итте. Җөмһүриятебез Илбашы аларга ныклыклары, шулай ук азатлыкка чыккандагы тәвәккәллекләре һәм кыюлыклары өчен рәхмәтен белдерде. Экипаж командиры Владимир Шарпатов, икенче очучы Газинур Хәйруллин, бортинженер Әсхәт Аббязов һәм башкалар Татарстан Республикасының Мактау Грамоталары һәм Президент сәгатьләре белән бүләкләнделәр.

* * *

Россия Президенты Б. Ельцин Указы белән, Ил-76 экипажы командиры В. Шарпатовка, икенче очучы Г. Хәйруллинга «Россия Герое» дигән югары исем бирелде. Экипажның башка әгъзалары исә «Батырлык» («Мужество») орденына лаек булдылар. Әлеге бүләкләрне кыю очучыларга 23 августта Мәскәүдә Россия Премьер-министры В. Черномырдин тапшырды.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК НЫГЫЙ

20—22 август көннәрендә Җөмһүриятебез Илбашы Санкт-Петербургта булды. Визит барышында икътисад, промышленность, фән-техника һәм мәдәният өлкәсендә үзара хезмәттәшлек мәсьәләләре турында эшлекле сөйләшүләр үткәрелде. Нәтиҗәдә, Татарстан Президенты М. Шәймиев һәм Санкт-Петербург губернаторы В. Яковлев ике арада дуслыкны һәм хезмәттәшлекне тагын да ныгытучы Шартнамәгә кул куйдылар.

Татарстан делегациясе әгъзалары әлеге сәяхәт дәвамында Санкт-Петербургның Җәмигъ мәчетендә, Петродворецның сарай-паркында булдылар, Нева буендагы шәһәрдә яшәүче милләттәшләребез белән очраштылар.

ТР Президенты М. Шәймиев Смольныйда үткән матбугат конференциясендә һәм «Европа-Гранд» отелендә оештырылган халыкара конференциядә АКШ конгрессменнары алдында чыгыш ясарга да өлгерде.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Елдагыча, быел да 25 августта көндез мәркәзебезнең Беренче Май мәйданындагы Муса Җәлил һәйкәле янында каһарман шагыйрьгә һәм аның көрәштәш дусларына багышланган «Хәтер җыены» булып үтте. Моннан 52 ел элек Алманиянең Плетцензее төрмәсендә башлары киселгән ватандашларыбызны искә алырга М. Җәлилнең кызы Люция ханым, оныгы Лилиан, Абдулла Алиш һәм Абдулла Батталның туганнары Габдрахман Алишев, Мөбәрәк Батталов, Рушад Хисаметдиновның сеңелләре Кафия Хәбибуллина (Алматы шәһәре), әдибә Азалия Бадюгина, Әмир Үтәшевның тормыш иптәше Рәйсә ханым, кызы Әлфия килгән иде. Матәм митингысында язучылардан Рафаэль Мостафин, Шаһинур Мостафин, Башкортстанның Миякә районыннан сугыш һәм хезмәт ветераны Хөснулла Хәбибов һ. б. чыгыш ясады.

Каһарманнарны искә алу аннары М. Җәлилнең музей-квартирасында дәвам итте һәм С. Сәйдәшев музей-йортында «Җырларым» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә белән тәмамланды.

## «КИНОСӘЯХӘТЛӘР КЛУБЫ»НДА — ТАТАРСТАН

Июль аенда республикабызда мәшһүр сәяхәтче, Россия җәмәгатьчелек телевидениесенең «Киносәяхәтчеләр клубы» мөдире, медицина фәннәре докторы, профессор Юрий Сенкевич булып китте. Ул биредә мөстәкыйльлек юлына баскан бүгенге Татарстан турында телефильм төшерергә килгән иде. Аның җитәкчелегендәге киногруппа борынгы Болгарда, Бөгелмә, Алабуга, Казан шәһәрләрендә һәм башка төбәкләрдә булды, Сарман районында үткәрелгән татар туенда катнашты.

## ҖӨМҺҮРИЯТЕБЕЗНЕҢ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

Башкалабызның Ирек мәйданында Татарстан Республикасының Зур концерт залы сафка басты. Казан дәүләт консерваториясенең концерт залы нигезендә барлыкка килгән мәһабәт бу бинада әлеге югары уку йорты студентларына күнегүләр алып бару һәм чыгышлар ясау өчен дә тиешле шартлар тудырылган.

Зур концерт залы үзенең мөстәкыйль эшчәнлеген ТР Дәүләт симфоник оркестры, халык уен кораллары оркестры (җитәкчеләре — Ф. Мансуров, А. Шутиков) чыгышлары белән башлап җибәрде. Киләчәктә бу залның үз хоры, үз оркестры да булачак.

Зур концерт залының директоры итеп Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Мансур Әхмәт улы Шиһапов билгеләнде.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ПОЛИГРАФИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ

ТР Министрлар Кабинетының чираттагы утырышында Татарстанда полиграфияне һәм китап бастыруны үстерү программасы проекты тикшерелде. Мәгълүмат һәм матбугат министры И. Әхмәтҗанов, «Мәгариф» нәшрияты директоры, язучы М. Вәлиев, Татарстан газета-журналлар нәшрияты директоры Д. Хәйруллина һ. б. әлеге мөһим мәсьәлә буенча үз фикерләре белән урталаштылар.

Министрлар Кабинеты полиграфия тармагын үстерүгә юнәлтелгән тәкъдимнәрне яклады.

Утырышны ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Р. Моратов алып барды.

## КҮРШЕЛӘР КУЛ КЫСЫША

8 августта Татарстан Язучылар берлегендә «Көмеш бөҗра» буйлап сәфәр чыккан бер төркем чуваш язучылары һәм сәнгать әһелләре белән очрашу булды. Сәфәрчеләр арасында Чувашстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Михаил Юхма, аның урынбасары Роза Шевлепи, аксакал әдип Аркадий Петров, шагыйрьләрдән Николай Ларионов, Сарра Баранова, Анатолий Иванов-Хум, Маргарита Гурьева, прозаиклардан Анатолий Ыхра, Геннадий Федотов, җырчы-композитор Марина Ильичева һәм күп кенә газета-журнал мөхәррирләре, китапханәчеләр бар иде.

Очрашу барышында Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе, Татарстан халык депутаты Р. Мөхәммәдиев чуваш әдибе М. Юхмага «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» таныклыгын һәм бүләген тапшырды. Әлеге бүләк аңа татар халкының каһарман улы Мулланур Вахитов турындагы романы һәм ике республика арасындагы мәдәни багланышларны ныгытуга керткән шәхси хезмәтләре өчен бирелде.

Чувашстанда туып-үскән күренекле татар язучысы К. Латыйп кунакларга үз телләрендә җылы сүзләр белән мөрәҗәгать итте, яңа шигырьләрен укыды.

## «КОЛЫМА ХИКӘЯЛӘРЕ» — СӘХНӘДӘ

8—11 август көннәрендә Казагыстанның Кукчәтау өлкәсендә күренекле татар язучысы — Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Ибраһим ага Салаховның 85 яшьлек юбилеена багышланган тантаналар булып үтте. Юбилярны Алматы, Павлодар, Петропавловск шәһәрләреннән һәм Казагыстанның башка төбәкләреннән килгән күпсанлы кунаклар котлады. Татарстаннан исә бирегә Фәрит Хәбибуллин җитәкчелегендә Казандагы Татар яшьләр театрыннан 25 кешелек делегация килгән иде. Алар әдипнең «Колыма хикәяләре» роман-хроникасын сәхнәләштереп, Кукчәтау шәһәрендә һәм Имантау станицасында яшәүче тамашачыларга күрсәттеләр. Спектакльдә язучы үзе дә катнашты һәм чыгыш ясады.

Татарстан Аксакаллар Шурасы исеменнән мөхтәрәм юбилярны күренекле мәгърифәтче-галим Габделгаллям Рәшиди оныгы — әдипнең якын дусты Арнольд әфәнде Кәбиров тәбрикләде.

## ТАТАР РОМАНЫ — БАШКОРТСТАНДА

Тугандаш Башкортстанның «Китап» нәшриятында Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновның «Габбас хәзрәт» романы дөнья күрде. Әлеге китап ике республика арасында мәдәни элемтәләр ныгый баруга тагын бер матур мисал булып тора. Өлкән каләмдәшебезнең бу әсәрен башкорт теленә Әмир Әминов тәрҗемә иткән.

## ИКЕ ИЛ КИТАПЛАР АЛМАША

Татарстан Милли китапханәсенә АКШ Конгрессы китапханәсеннән 40 ка якын матур әдәбият, фәнни-публицистик һәм укуукыту китаплары килде. Алар арасында сирәк очрый торган бик әһәмиятле һәм кыйммәтле әсәрләр, фәнни хезмәтләр дә бар.

## ШӘФКАТЬЛЕЛЕК БАЛКЫШЫ

Татарстан радиосының «Балкыш» тапшырулары программасының эфирга чыга

башлавының 5 еллыгына һәм «Әл-зәкят» хәйрия җәмгыятен тәгъдир итүгә багышлап, К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында кичә булып үтте. Аны авыру балаларга ярдәм итү белән шөгыльләнүче дин-мәгърифәт үзәге — «Әл-зәкят» хәйрия җәмгыяте оештырды. Концертта «Әл-зәкят» ансамбле җырчылары, танылган артистлардан Зөфәр Билалов, Айдар Фәйзрахманов, Искәндәр Биктаһиров, яшь җырчы Рәсим Низамов һәм театр училищесы студентлары катнашты. Һиндстанда белем алучы — Һинд җырларын һәм биюләрен оста башкаручы Светлана туташ һәм иң нәни җырчы Рамил Кадыйровка алкышларның иң көчлесе яңгырады. Кичәне Татарстанның халык артисты Мингол Галиев һәм Татарстан радиосының «Балкыш» тапшырулары мөхәррире Гадилә Нургали алып барды.

## «ДИЛӘФРҮЗ» ТЕАТРЫ

Мәскәүдә эшләп килүче «Диләфрүз» татар театры (житәкчесе — Диләфрүз ханым Хәйруллина-Дежурова) үзенең 10 еллык юбилеен 22 август көнне Казанда, Тәзүчеләр мәдәният сараенда зурлап билгеләп үтте. Күпсанлы тамашачыларга Г. Камалның «Бүләк өчен», Т. Миңнуллинның «Бәйләнчек», Г. Насрыйның «Яшел эшләпә» спектакльләреннән кызыклы өзекләр күрсәтелде, скетчлар уйналды.

23—24 август көннәрендә әлеге театр артистлары Биектау районының Ямаширмә авылында һәм Арчаның үзендә чыгыш ясадылар.

## ИСЕМЕ МӘҢГЕЛӘШТЕРЕЛДЕ

Татарстан Республикасының Министрлар Кабинеты карары белән, Минзәлә татар дәүләт драма театрына Җөмһүрияте-безнең Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Сабир Гаделҗан улы Өметбаев исеме бирелде. Әлеге театрга нигез салган, аның беренче директоры һәм тәүге баш режиссеры булган әлеге мөхтәрәм шәхеснең исеме, әнә шулай, мәңгеләштерелде.

## ГАЗИЗ КАШАФ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Быел 30 августта күренекле язучы Газиз Кашаф-Үзиленең вафатына 5 ел тулды. Фани дөньяда нибары 49 ел яшәп калган талантлы әдипнең һәм шагыйрьнең якты истәлеген якыннары, каләмдәшләре, дуслары кадерләп саклый. Күптән түгел генә аның кабер ташы да яңартылды. Бу эшне башкарып чыгуда Газиз Салихҗан улының якын дусты, сабакташы — Саба район газетасының баш мөхәррире, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Тәлгать Нәҗмиев зур тырышлык күрсәтте. Мәрхүмнең кабер ташына ул язучының үзе исән чакта ук әйтеп калдырган:

**«Бар нәрсәдән кадерлерәк миңа**
**Туып-үскән җирем — Үзием!»**

— дигән шигъри сүзләрен дә яздырды.

## КОЛ ГАЛИ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Күпгасырлык тарихи-мәдәни мирасыбызны тергезү өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен, Кол Гали исемендәге халыкара премия быел, «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» дигән тарихи романы өчен, язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинга һәм «Казан татарларының орнаментлары», «Урта Идел буеның борынгы һәм урта гасыр сәнгате», «Татарстанның борынгы сәнгате» дигән фәнни монографияләре өчен сәнгать фәннәре докторы Фуат Вәлиевка (үлгәннән соң) бирелде.

## МӘДӘНИЯТ ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕНӘ — Ф. КӘРИМ БҮЛӘГЕ

Башкортстан Республикасының Язучылар берлеге һәм Бишбүләк районы хакимияте мәдәният эшлеклеләре өчен күренекле татар шагыйре, фронтовик Фатих Кәрим исемендәге премия булдырылды.

Әлеге бүләкнең беренче лауреаты октябрь ае башында язучының туган җире — Бишбүләк районында үткәреләсе тугандаш мәдәниятләр кичәсендә билгеле булачак.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә, дәүләт алдындагы хезмәте, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен, Казан кинохроника студиясе кинорежиссеры **Фәтхетдинов Харис Фәсхи улы** «Халыклар дуслыгы» ордены белән бүләкләнде.

* * *

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты **Николай Иванович Дунаев** һәм В. Качалов исемендәге Зур рус драма театры артисты **Феликс Михайлович Пантюшин,** сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен, РФ Президенты Указы нигезендә, «Россия Федерациясенең атказанган артисты» дигән мактаулы исемгә лаек булдылар.

* * *

Мәдәният өлкәсендәге казанышлары һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен, Татарстан Республикасының «Татар-информ» Мәгълүмат агентлыгы генераль директоры **Богданов Умәр Хәмзә улына** «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, рәсем сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен, Чаллы шәһәрендә яшәүче рәссам **Сафиуллин Ким Мөхәммәт улы** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә лаек булды.

# ИҖАТ УЛ — ТӘКЪДИР ЭШЕДЕР!..

Белгечләр еш кына кешенең киләчәктә нинди юл белән китәчәген чамалау өчен аның сабый чактагы мавыгуларын күзәтү дә җитә, диләр. Белмим, мондый катгыян раслау чынбарлыкка ни дәрәҗәдә туры килә торгандыр (чөнки тормыш юллары бик катлаулы, анда очраклылык дигән нәрсә дә бар бит әле), әмма рәссам Рәшит Имашев язмышына килгәндә, мондый караш белән тулысынча килешергә мөмкин. Кечкенә Рәшитнең үзен-үзе хәтерләгәннән бирле иң яраткан шөгыле сурәт төшерү була. Бу хакта ул үзе болай дип искә ала.

— Миңа ничә яшь булгандыр инде, ансын бер Алла белә, Сәвия апам мәктәптән кайтып керде исә аннан калган «дәфтәр» битләренә төрле сурәтләр төшерергә керешә идем. Дәфтәр дигәнең — гәҗит кисәге, пумалам — каен әрдәнәсеннән телеп ясалган чырагач, буявым — корым карасы. Шулай бервакыт апам минем шулай тырышып-тырмашып кадерле кәгазь кисәген пычратуымны карап торды да сорап куйды:

— Йә, үскәч кем буласың инде?

Ә мин күземне дә йоммыйча:

— Рәссам булам, — дидем. — Күрәсең, Тәкъдир эше булгандыр инде, менә алтмышымны тутырып килгәндә дә сурәтләр төшерәм. Уйнап кына башланган мавыгу шулай гомерлек шөгылемә әйләнер дип кем уйлаган...

Тәкъдир эше булгандыр инде!.. Рәшит Имашев бу сүзләрне ихлас күңелдән һәм тирәнтен ышанып әйтә, чөнки ул моның асыл мәгънәсенә озак еллар буена сузылган рухи эзләнүләр нәтиҗәсендә төшенгән шәхес. Ә бу эзләнүләр рәссамга җиңел генә бирелми, аның артында йокысыз төннәр, мольберт каршында үткәргән бихисап көннәр, табышлар һәм югалтулар ята.

— Ярый, Казан рәсем сәнгате училищесына укырга кердем. Көчкә-көчкә генә, имтиханнарны «3»легә биреп. Ник дисәң, мин бит авылдан гына килгән малай, майлы буяуларны күргәнем дә юк. Ә тирә-якта — махсус мәктәп бетергән малайлар, кызлар. Шәһәрнекеләр. Өч ел буе училищедан чыкмый эшләп яттым һәм, мактану булып яңгырамасын, күпләрне куып җитеп узып киттем.

Әйе, бу сүзләрдә арттыру юк. Ул училищены «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый һәм Мәскәүнең Суриков исемендәге сәнгать институтына укырга керә. Менә шушыннан башлап Рәшит Имашевка зур дөнья ачыла. Беренче курста укыганда ук ул «Балалар әдәбияты» нәшриятында эшли башлый һәм шул чорда Кайсын Кулиев, Рәсул Гамзатов, Давыт Көгелтинов, Мостай Кәрим кебек олы шәхесләр белән аралаша, соңрак шушы очрашулар аның төп иҗат юнәлешен дә билгели. Ул әдәбият-сәнгать әһелләренең якын дустына, кәтеп алган кунагына әверелә. Шушы дуслыкның ачык билгесе булып аның иҗат хәзинәсен 50 гә якын портретлар галереясы бизәп тора. Әйтергә кирәк аның картиналарында шәхесләр — көчле рухлы, фәлсәфи, уйчан шәхесләр.

Рәшит Имашев чыннан да — портретлар остасы. Бу хакта озаклап тукталып торуның, мөгаен, кирәге юктыр, чөнки вакытлы матбугатта алар киң яктыртылды. Ләкин, форсаттан файдаланып, бернәрсәне искәртеп үтик: Рәшит Имашев киң колачлы рәссам. Портретлардан тыш ул, пейзажлар һәм натюрмортлар, мозаика, гипстан сыннар, монументаль әсәрләр дә иҗат итә. Китаплар да бизи. Чөнки Рәшит Имашев олы иҗатчыга гына хас булганча, чын мәгънәсендә тынгысыз, тырыш кеше. Ил буйлап йөргән сәяхәтләреннән дә, чит ил маршрутларыннан да ул этюдлар, зарисовкалар, портрет сурәте өчен эскизлар алып кайта. Бүген «Казан утлары» укучыларына тәкъдим ителә торган картина да әнә шундый иҗади эзләнүләрнең — Тәкъдир эшенең бер үрнәге булып тора.

**Наис ГАМБӘР.**

**Тышлыкның беренче битендә:** «Җәй ахыры» — рәссам Рәшит Имашев картинасыннан фотокүчермә.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Салисә Гәрәева.

**Д. БУНТУКОВ** фотосурәте.

# ЯҢА КИТАПЛАР

**Изгелек сукмагында.** *Хикәяләр*. Төзүчесе — Д. Морзакова. Уфа: Башкортстан «Китап» нәшрияты. 1996 ел. 528 бит. Тиражы — 6500 данә.




Ниһаять, соңгы елларда Башкортстанда да татарча китаплар чыга башлады. «Изгелек сукмагында» дигән бу китап моңарчы чыккан басмалар арасында иң саллысыдыр, мөгаен. Үзенә күрә хикәяләр антологиясе рәвешен алган бу зур күләмле китапка башкорт (арада башкорт һәм татар телендә иҗат итүче татар әдипләре дә бар) прозаикларының асылда 70—90 елларда иҗат ителгән иң яхшы хикәяләре тупланган.

Китап авторлары — Мостай Кәрим, Динис Бүләков, Ибраһим Абдуллин, Булат Рафиков, Ногман Мусин, Шакир Янбаев, Рәшит Солтангәрәев, Сабир Шәрипов, Җиһат Солтанов, Роберт Баимов, Талха Гыйниятуллин, Тайфур Сәгыйтов, Суфиян Сафуановлар кебек күренекле прозаиклар һәм яңа танылу ала башлаган яшьрәк әдипләр — Таңчулпан Гарипова, Әмир Әминов, Динә Булгакова, Факил Морзакаев, Ринат Камалов һ. б.

Халыклар дуслыгына хезмәт итә торган бу яхшы китапны чыгарып Уфаның «Китап» нәшрияты зур игелекле эш башкарган.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЫ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)